# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН
БАШЛАП ЧЫГА*


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Гөлүсә БАТТАЛ. Мин үзем дә уллар үстерәм... *Шигырьләр*. ....3
Рабит БАТУЛЛА. *Хикәяләр*. ....9
Эльвира САФИНА. Җыр-биюләр безне көчле итә... *Шигырьләр*. ....25
Фирдүс ГЫЙМАЛТДИНОВ. Урда ханы Үзбәк. *Роман*. ....29
Роберт СӘЛАХИЕВ. Башымда хыяллар кәрваны... *Шигырьләр*. ....91
Ринат МӨХӘММӘДИЕВ. Галимә туташ. *Хикәя*. ....95

ЕРАКТАГЫ УТЛАР

Муса ЧАХОРОВСКИЙ. Минем гомер – ерак бер ил... *Шигырьләр*.
*(Ленар ШӘЕХ тәрҗемәләре.)* ....111

«СЕЗ ИҢ ГҮЗӘЛ КЕШЕ ИКӘНСЕЗ!» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Кани калды Нишапур... *Хикәя*. ....114

«КАЗАН УТЛАРЫ»НДА – «АГЫЙДЕЛ»

Мөнир КУНАФИН. Әдипләр иңендә халык сүзе һәм какшамас намус ята.
*(«Агыйдел» журналына – 100 ел)*. ....122
Хәсән НАЗАР, Гүзәл СИТДЫЙКОВА, Кадим АРАЛБАЙ, Гөлфия ЮНЫСОВА,
Әхмәр ҮТӘБАЙ, Гөлнур ЯКУПОВА, Салават ӘБҮЗӘР, Йомабикә ИЛЬЯСОВА,
Таңсылу КАРАМЫШЕВА, Лилия САКМАР, Хисмәтулла ЮЛДАШЕВ,
Тамара ИСКӘНДӘРИЯ, Айсылу ГАРИФУЛЛИНА, Зөлфия ХАННАНОВА,
Галия КӘЛИМУЛЛИНА, Гөлназ КОТЫЕВА, Лариса АБДУЛЛИНА *шигырьләре*. ....125
Рәшит СОЛТАНГӘРӘЕВ. Татар белән башкорт. *Хикәя*. ....132

2023 ЕЛ – ДАСТАННАР ЕЛЫ

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА. Дастаннар – үткәннәрнең сабыр сурәте. ....160

ФӘН

Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Рәшит Сүнәевнең гыйлем галәме. ....170

ИДЕЛ БУЕ БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕНДӘ ИСЛАМ ДИНЕН КАБУЛ ИТҮНЕҢ 1100 ЕЛЛЫГЫ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Татар сәүдәгәрләре ислам динен тарату системасында
*(XVIII гасырның икенче яртысы – XIX гасырның беренче яртысы)*. ....177

КИТАП КҮЗӘТҮ

Әзһәр ШАКИРОВ. Әхсән хатларында моң ята. ....187

«Казан утлары» архивыннан. ....168
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 3 (1205) 2023*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 27.02.2023, график буенча 27.02.2023, басылып чыгу вакыты 03.03.2023
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-0409. Тираж 6209.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
12+

© «Казан утлары», 2023 ел



Гөлүсә
Баттал

# МИН ҮЗЕМ ДӘ УЛЛАР ҮСТЕРӘМ...

## Мин – татар!

«Мин – татар!» – дигәнгә көлделәр:
«Соңардың – санаулы көннәрең!»
Горурлык – ул кимлек икән бит –
Нигә соң элегрәк белмәдем?!
«Ул – татар!» – дип башны чөйгәндә,
«Коллыкка ишарә!» – диделәр.
«Оныт син үзеңне – бабаңнар
Борынгы далада үлделәр!»
«Без – татар!» – дип мәйдан урадык,
Мыскыллы елмаю озатты.
Җиде-ят тимәде, үз кешең
Йөрәккә турылап төз атты.
Көлсеннәр! Изсеннәр! Барыбер –
Без тере! Без исән! Әле дә!
Мин – татар! – бу синең паролең –
Төшермәс үлеләр хәленә!
Кем тыяр? «Ул – татар!» – дигәндә
Күңелең ашкынса биеккә?
Кемгәдер төрмә дә килешер,
Тик безнең хөррият – иректә!
Без – татар! Кемгәдер – илбасар,
Кемгәдер – кыямәт өрәге.
Бигайбә! Йөрәкләр типкәндә
Какшамас милләтнең үзәге!
Мин – татар! Син – татар! Без – татар!
Ашыкма сызарга исәптән.
Нәкъ вакыт – ияргә менәргә
Кодрәтне уятып йөрәктән!

---

Гөлүсә БАТТАЛ (1982) *– шагыйрә; «Бер йотым бәхет», «Кесә тулы – давыл!» исемле китаплар авторы. Әтнәдә яши.*

## Ватаным

Мин сине сайланып алмадым,
Син минем – бердәнбер Ватаным!
Тик бергә үтәргә ни өчен –
Язмышның явызлар язганын?
Мин синең далаңнан яралган,
Иделең үстергән бер балаң.
Йөземдә – хәсрәтем шәүләсе –
Хак белән нахакны бутамам!
Бабамнар бик күпне күргәннәр –
Тик... миннән бәхетле бабамнар!
Алар бит Ватанын коткарып
Кырларда башларын салганнар!
Син минем бердәнбер Ватаным!
Үзәгем өзелә уйласам...
Акылдан язмаска төн ката
Ялгызым бүредәй уласам...
Җиңелрәк булыр күк... Кендегем
Җебеннән өзелер-өзелмәс...
Бәгырьгә укмашкан кутырлар
Инде юк, мәңгегә төзәлмәс...
Мин сине сайланып алмадым,
Син минем бердәнбер... җан ярам...
Сөюем-нәфрәтем – янәшә –
Көлеңдә гөл булып яралам...

## Бер бөртек

Җан бит ул – бер бөртек, бер генә.
Алмашка юк бүтән сыңары.
Тарталар, йолкалар – мин түзәм –
Кулларым сузыла югары.

Ышанып, таяныр нокталар
Шулкадәр нәзберек – уала.
Янәшә булганнар берәмләп
Бүгеннең төбендә югала.

Бу җирдә кешеләр эзлимен –
Тик очрый ачулы гәүдәләр.
Гөлләргә үрелә теш кайрап,
Җаннары сатылган шәүләләр...

Куркыныч. Туасы җаннарга
Ни дияр аждаһа ишеләр?
Җир шары – бер бөртек, бер генә –
Акылга килегез, кешеләр!

## Давыл

Давыл үтте бүген... Тигезләде
Туфрак белән яшәр йортымны.
Сизмәде дә дөнья – шунысы бигрәк
Алды бугай минем котымны.

Кая сизсен? Утлы гарасатлар
Уңлы-суллы кыйный яңактан.
Ә бүгенге давыл шыпырт кына
Туар таңны өзде сабактан.

Кисеп аударды ул тамырларны,
Кыяметкә юлны кыскартып.
Бары хыял калды, нәүмиз булып,
Ирек дигән тәмне искәртеп.

Давыл үтте. Әллә төш булдымы?
Алдандыкмы тагын йөз кабат?
Хупладылар. Кемдер телгә килер:
Үткән эшкә инде салават.

Башны ияр кавем идекме соң?
Кайда алыпларың әзмәвер?!
Дәшми генә торып калдык шулай
Давыл каршысында тезләнеп...

## Анага

Бәгыреңнән өзеп озаттың син –
Белми – кая, белми – ни өчен?
Җүләр хатын диеп кимсеттеләр –
Синнән алып яуның бар үчен.
Доган белән ялгыз калган чакта –
Күкләреңнән елап сорадың...
Яшәр өчен тапкан уллар ласа –
Үлем белән ара – бер адым.
Ни дип әйтим? Адәм җанын кыю
Гөнаһ диеп акыл сатыйммы?
Дөнья баткагына тиздән кереп,
Шул пычракны сиңа атыйммы?

Киткәннәрнең һәркайсына бердәй
Әрнегәндә сыңар йөрәгем,
Чоңгыл йоткан һәрбер корбан белән
Кабат-кабат мин дә үләмен.
...Кайгысыннан кинәт картайган да,
Хәсрәтеннән кипкән яшьләре...
Минем кыйблам – бары минеке ул,
Ул хакта мин бер сүз дәшмәдем...
– Улың исән-саумы?
– Шөкер, исән...
Тау төшкәндәй булды өстемнән...
Синең хәсрәт – минем хәсрәтем ул –
Мин үзем дә уллар үстерәм...

## 40 көн

Кырык көн тоташтан төш күрәм:
Кап-кара давылда калганмын.
Өстемә дәһшәтле яу килә –
Далада югалган калканым.
Кап-кара дегеткә буялган
Йөземнән югалган яктылык.
Куллардан кан тама... һәм кала
Чак тере җаныма ягылып.
Кырык көн тоташтан төш күрәм.
Китәргә иде лә уянып!
Тик булмый – тәкъдирне кичәсе
Тоташтан дегеткә буялып.

Бу төшем озатып барачак
Көннәргә алмашкан төннәрне.
Җил белән китереп бәрәчәк
Яртылаш өзелгән өннәрне...
Кырык көн саташу. Ахрысы,
Таң белән уяну язмаган.
Офыклар сискәнә – начар фал –
Күкләрне кискәли ажаган.
Кап-кара дегеттә – йөземне
Оялып, дөньядан яшерәм.
Кырык мең буынга җитәрлек
Кырык көн тоташтан төш күрәм...

## «Минем йортым читтә тора»

*«Моя хата с краю...»*
Рус халык мәкале

Кайдадыр упкыннар убыла,
Гөрселдәп егыла кыялар...
Кемнеңдер – түгәрәк дөньясы,
Шат чырай, кәефле хыяллар!
Кемнәрдер бүгеннән дөм ятим...
Газизен югалткан кайсысы?..
Кемнеңдер – ваемсыз көненә
Килешми бүтәннәр кайгысы.
Кемнеңдер бер валчык сые юк,
Бер йотым суы юк үлгәндә...
Кайдадыр – бер гамьсез җан асрау –
Аларның эше юк бүтәндә.

Сукырлар, чукраклар, телсезләр...
Язылган тәкъдирдер, нишлисең...
Бу рәхәт дөньягыз – мескенлек,
Җылыгыз туңдыра – өшисең.
Телләрне киссәләр – сөйләшмә,
Күзеңне капласа – карама.
Кемнәрдер газизен җуйганда
Минем йорт читтәрәк торамы?!
Кемнәрдер бүген бар, иртәгә
Беләме дөньядан үтәсен?
Кыямәт көнендә туй иткән
Адәмнән тагын ни көтәсең...

## Әйт миңа

Әйт миңа, олы сер чишкәндәй,
Бар – диеп – бу җирдә ышаныч.
Офыкта – таң, диген – югыйсә,
Яшәвең (җан асрау?) кызганыч...

Әйт миңа – ышандыр – мәхәббәт
Әле дә исән дип дөньяда!
Югыйсә... беләсең – кемгәдер
Без күптән шыр чыккан дивана...

Әйт миңа – өмет, дип, барыбер
Иң соңгы нәүбәттә үләчәк...
Ышандыр, инандыр! Бар, диеп,
Хыялдан яралган киләчәк!
Әйт миңа, пышылда догадай:
Син ялгыз түгел лә, без – күбәү!
Мөмкинме бу җирдә җаннарны
Тигәнәк буенча тигезләү?

Әйт миңа – бер сүзең, бер ымың –
Никадәр кадерле бу көндә.
Иртәгә, кем белсен, кемнәрнең
Башлары куелыр бүкәнгә...
Әйт миңа, ышандыр – иманым
Дөньяны коткарыр әле бер!
Шулчакта... хәсрәтле йөзләргә
Ниһаять, елмаю җәелер.

## Елмаям

Соң чиккә тартылган кылларның
Өзеләм дип әрнер мәлләре.
Юатыр кеше юк – һәркемнең
Акылын җуярдай хәлләре.
Шул хәлдә бәгырьдән өзәм дә
Бер сыңар, дөм ятим өметне...
Җиремә сузамын – кулларым
(уйларым төсле үк) дегетле.
Мин инде беркемгә ышанмыйм!

Ышанмыйм! Беркайчан! диям дә...
Иң нәүмиз йөрәккә бер телем
Ышаныч саклыймын кесәмдә.
Ваз кичәм ничә кат... Ничә кат
Шайтанга сатылган дөньядан...
Һәм кабат көчемне җыям да,
Яратып(!!!) дөньяга елмаям.
Ел-ма-ям!

## Кочаклыйм

Кочаклыйм үзеңне – Кояшка сусаган
Дөньямда сиңа да, миңа да урын бар!
Салкын дип ваз кичмә – кар эрер, мин беләм –
Тирәндә – яз көтә – теп-тере уҗымнар!
Бөреләр тулышкан – бер тыны, бер ымы
Җитәчәк бу җиргә көтелгән язларның.
Кочаклыйм үзеңне – мизгелгә онытыйк –
Ярату җитмәүнең өшеткеч газабын...
Онытыйк, онытыйк – ызаннар, чикләрне,
Кем әйтә – нинди сүз бу җирдә үтемле?
Иртәгә туасы сабыйлар хакына –
Яратып... яратып кочаклыйм үзеңне!

## Көтелгән бураным

Юлымны кистең дә, йөз чөйдем үзеңнән,
Юкса, син – һаман да көтелгән бураным!
Беләсең, юк минем бүтәннәр каршында
Тырышып-тырмашып акыллы булганым.
Мин – юләр! Мин – тиле! Канатлы бу ләззәт
Йөрәкне кытыклап, табанга йөгерә.
Бүгенге буранның аклыгын салыйммы
Соң чиккә алҗыган сабырым төбенә?
Кирегә борылу – бураннан качумы?
Үзеңнән качумы? – Аңлаучы табылмас...
Кар өзгән юллардан эземне эзләмә –
Кисәүгә әйләнгән кабаттан кабынмас.
Юлымны кистең дә... ахрысы, коткардың...
Нишлим соң – гомергә чуалчык уйларым.
Адашкан дөньямнан куеныңа тартып ал –
Син минем һаман да көтелгән бураным!

## Салкын, димә!

Салкын, димә!
Яратусыз яшәп,
Ялгыз учак тергезәлми
Пыскып сүнгәннәр бар...
Олы мичкә сыңар чыра тапмый,
Поста йорты кебек үлгәннәр бар.
Салкын, димә!
Бозлы баскыч төбен
Яланаяк таптап
Үксез тәкъдир кичкәннәр бар...
Эчендәге утны басар өчен
Ачы әрем суы эчкәннәр бар.
Салкын, димә!
Чынлап туңганнарның
Кутырлаган җан ярасын
Кузгатырсың ялгыш...
Бүрәнәләр шартлап ярылырлык
Кышлар безгә, исеңдәме, таныш?
Салкын, димә!
Бүген кояш үзе
Йөрәкләрдә посып яткан
Җылыбызны көтә.
Онытылган сабыйлыкны уят –
Юешләнгән борын астың сөрт тә.
Салкын, димә!
Салкын, димә әле!
Исәрләник көртләр ерып,
Пар чыгарып «түбәләрдән».
Тәмен татыйк тел очында карның –
Без үзгәргән, ә ул үзгәрмәгән...
Үзгәрмәгән...

## Ул сурәт...

Яшәлгән, яшәлгән... дөньяны онытып.
Йөрәкне яшереп җиде ят күзеннән...
Таң аткан, кич булган елларга сузылып –
Тиеш дип, беленгән... ничектер түзелгән...
Өр-яңа офыклар ымсытып ачылган,
Үткәнгә борылып карамый атланган...
Бәгырьнең иң ерак, караңгы төшендә
Ул көннән кадерле истәлек сакланган!
Су өстен яктырткан тулган ай сукмагы,
Дымлы җил сулышы – тулышкан ирендә...
Җәйнең соң көннәре, санаулы төннәре –
Кемнәрнең бүген дә (һаман да!) исендә?
Кемнәргә хатирә – битараф күрсенү,
Кемне соң шул сурәт әле дә яшәтә?
Ул кичнең җылысы күңелдә йөрмәсә,
Өннәрнең бушлыгы җаннарны өшетә...
Яшисең, яшисең дөньяга табынып –
Тиешле җөмләдә уйланган өтерләр...
Бәгырьдә кадерләп сакларга язганнар –
Инде чит. Ул якка җимерек күперләр.
Күнеккән (кайчаннан?) – давыллы хисләрне
Бикләргә, тыярга беркатлы йөрәктә...
Яшәргә көч бетсә – кайтырга чыгам мин
Ай нуры яктырткан кадерле сурәткә...

## Кайтып егылдым

Биштәремдәниләр булды икән?
Хыяллардыр... ниләр булсын тагын...
Бара идем... Туктаттылар кинәт:
– Нәрсә, бер дә юкмы әллә кайгың?

Абау, абау... йөрәгеңне ачсаң,
Бәгыреңне учлап умырырлар.
Баштан сыйпап, әфсен-төфсен белән
Юл бутыйлар икән убырлылар.
Чәбәк-чәбәк алкышлардан җирдә
Башлар тубал, күңел каеш кына.
Чи җүләргә түнеп, әйдә бераз
«Былбылларның» каркылдавын тыңла.
Биштәремә хыялларны төяп
Киткән идем үз-үземнән качып.
Дөньясыннан югалырлык икән...
Аңладым да... Егылдым мин кайтып.


## Башка шул...

Мин инде башка шул... үзгәртте дөньясы.
Акылга җиңелде беркатлы исәрлек.
Чәчләргә җил кушып үргәннәр – үткәндә,
Ул җәйләр күптәннән... кадерле истәлек.
Елмаю – үлчәнгән, сүзләр дә иләктән
Үткәреп әйтелә икән лә күптәннән.
Бары тик күзләрдә – инде юк дигәндә
Сагышлы яктылык сирпелә үткәннән.
Мин инде башка шул... бүтәндер сөйгәннәр...
Акылны иш итеп дөньяны көтәдер.
 Япь-яшь кыз толымын юксынып җәйләрдә,
Берүзе яланда таң җиле исәдер...

## Ютәл

Битлекләр илендә ел кичеп,
Ютәлләп буылган дөньяга
Карыйм да, үртәләм – кайсыбыз
Акылга туймаган дивана?
Кулымда – палачның хөкеме,
Гасырның җөйләре – үпкәмдә.
Ни калыр ютәлдән юньлерәк
Вакытның сиратын үткәндә?
Ни калыр шагыйрьнең сүзеннән?
Җилләргә ияргән гайбәтме?
Гасырлар өрәген шүрләтеп,
Үткәннән эзләрбез сәбәпне.

Чүп басар күңелне, дөньясын,
Кем утар хасиятләп түтәлне?
Без диеп какканда күкрәгең
Кайларга яшерик ютәлне?
Диагноз бер безгә: кулларда
Кылычтан үткәннәр хөкеме!
Аңнарны томалап, туй итә
Илемдә гамьсезлек сөреме.
Ни калыр бездән соң? Сүзләрдән
Ялыгып югала барганда?
Шагыйрьнең догасын пышылдыйк,
Ютәлдән буылган заманга...



Рабит Батулла

# ӘҖЕМ ХАН

хикәя

Унбишенче гасырның 94 нче елы иде. Казан падишасы Әҗем диван мәҗлесе туплады. Сарайга йөргәндә үк, Мөхәммәдьяр сизенә иде: Әҗем хан аны утлы табага бастырырга чакыра. Әҗем ханның Мөхәммәдьярга ниндидер үче бар. Һәм тезләндереп яргулаганда[1] карачыларның берсе дә аны яклап, ханга сүз катмаячак. Дөресе дә шулай булып чыкты, диван җыелып беткән, бер Мөхәммәдьярны гына көтеп утыралар иде. Мөхәммәдьяр диванханәгә[2] килеп керүгә ханның чырае ук үзгәрде, ул кырыс кына дивани мәҗлесне ачык дип белдерде. Карачылар белән дивани мәҗлескә чакырулы башка бәкләр ни өчендер башларын иеп, чүбе булмаса да, идәнгә җәелгән келәмнән нидер тапкан булалар, нидер чүплиләр иде.

Мөхәммәдьярга туры карамыйча гына Әҗем хан сүз башлады:

– Тәхет янындагы дүрт карачымның берсе, ханның вәзире, илемнең тарханы була торып, син отышлы уеннарга бирелеп, кузнаханәләргә[3] йөрисең, диләр...

Мөхәммәдьяр калкынып, җиңелчә генә хан тарафына карап, баш иде. Сабыр-салмак тавыш белән әйтте:

– Тарханнарга кузнаханәләрдә йөрү Анаканунында тыелмаган, – диде.

Әҗем хан тәхетендә кымырҗып куйды.

– Тыелмаган! – диде хан, сабыр булырга тырышып. – Әмма тархан белән карачы бәккә анда ни калган?

– И хан! – диде Мөхәммәдьяр. – Минем шәхесемә кагылганы болардыр ки: кузнаханәләрдә ярымсәрхуш, ярымминңке[4] бәндәләрең ил хакында дөресен сөйли. Ханлык турында халыкның хаклык фикере бар. Мин халык белән аралашам. Ә синең башка карачыларың сарай капкасыннан сакчы-

[1] яргулау – хөкем итү, җәзага тарту.
[2] диванханә – диван вәзирләре җыела торган урын.
[3] кузнаханә – отышлы уен урыны, эченә алтын-көмеш, кургаш тутырылган кузналар белән уйнау.
[4] ярымминңке – ярым миңгерәү.

Рабит БАТУЛЛА (1938) – *Татарстанның халык язучысы; илледән артык китап авторы. Казанда яши.*

каравылсыз чыкмый. Алар халыктан курка, халык вәкилләре халыктан курка икән, димәк, яки халык тиле, яки аның вәкилләре, карачылары – карак. Синең бәкләр бәге вәзирең чынлыкта ул кече хан, «Бер шигырь укымасам да, мин ханга иң якын карачы булдым», – дип, шигъри китапларга нәфрәт уятмакчы була. Син шуны ишетмисеңме, күрмисеңме, и хан? Әүвәл-әүвәлендә Казан иле белемле, мәгърифәтле ил булган, укый-яза белмәгән вә дәхи китап укымаганнарны Казанда мокытка санаганнар. Синең уң кулыңда утыра торган бәкләр бәге вә карачылар үз наданлыклары белән мактана башлагач, Казанның хәлләре бик тә мөшкел булыр. Бистәләрдә, каладагы матур иске йортларны сүттереп, Мәскәү өслүбендәге йортлар сала башладылар. Хан күрмиме аларның башбаштаклыкларын? Аларның Казанга булган нәфрәтләрен сизмиме хан? Озакламый Казан кяфер каласына әверелер. Халыкның карак байларга булган нәфрәтләрен, аларның Мәскәүгә ярарга тырышуларын сизмиме хан? Атаң Ибраһим хан, Мәхмүт хан, бабаңның атасы Олуг Мөхәммәд хан калдырган биналарны юк итәрбезме, и Мөхәммәд Әмин хан? Син яңа йортлар кордырыр өчен Казан казнасындагы алтынны түләп, Мәскәүдән мәгъмурлар[5], мөһәндисләр[6] чакырттың. Үзебездәге оста мәгъмурлар эшсез каңгыра, алар чит илләргә китеп, мәһабәт манаралар, мәчетләр корырга мәҗбүр, үз илендә шушы осталар ике кулына бер эш табалмый. Ә син Мәскәүгә гашыйк, син Мәскәүнең хәмерен эчәсең, син Мәскәү кызларын кочасың. Сине Мәскәүдә яхшы тәрбия кылганнар, син анда мәдәниятле булгансың, аракы чөмереп, чучка ите җыеп, корсак үстерергә өйрәнгәнсең...

Әҗем хан тәбегә эләккән күсе кебек тәхетенең әле уң, әле сул ягына авыша, ул карышкысын[7] әле бер кулына ала, әле тәхетенә сөяп куя, аның бу дорфалыкка җен ачуы чыккан иде.

– Мөхәммәдьяр! – дип кычкырды ул. – Авызың ни әйткәнне колагың ишетсен! Син ни сөйлисең? Канымны кыздырма!

Мөхәммәдьярның туктарга исәбе юк иде, ул да кыза барды:

– Әҗем хан Мәскәүдә аракы чөмереп, чучка ите җыеп, корсак үстерергә өйрәнгән, дип сөйлиләр кузнаханәләрдә, бөек ханым! Мин гавам сүзен сөйлимен!

Әҗем хан аклану ягын карады:

– Нишлим? Мине биш яшемнән рәһен[8] сыйфатында Мәскәүгә биргәннәр. Мин анда үстем, мин аларның йолаларын кабул иттем. Нишлим? Сиңа рәхәт, син үз атаң-анаң химаясында[9] үскәнсең. Мине рәһен итеп Мәскәүгә аткарганнар. Өйрәт алайса миңа Казан йолаларын.

– Өйрәтеп тормыш итәм, – диде карачы Мөхәммәдьяр. – Ләкин син сүзләремә чукрак, кыйлганыма сукыр. Казан йорты үз туфрагыннан чыккан хан бирамалмады, диләр гавам арасында. Дөрес, Олуг Мөхәммәд Казанлы түгел, аның углы Мәхмүт тә Казан туфрагында яралмаган. Хәтта синең атаң – атаклы Газый хан хәзрәтләре дә Казанлы түгел, әмма син, Ибраһим углы Мөхәммәд Әмин хан – Казан туфрагында яралган бердәнбер хан. Килмешәк

[5] мәгъмур – архитектор.
[6] мөһәндис – инженер.
[7] карышкы – дәрәҗә таягы, скипетр.
[8] рәһен – залог.
[9] химая – ярдәм, тәрбия, терәк.

ханнар килгәннәр дә киткәннәр, син – ватаныбызда яралган хан – шушы ватанны Мәскәүгәме кычкыртып сатасың? Атаң – Ибраһим хан унбер ел дәвамында Мәскәүгә каршы торды, җиңү артыннан җиңүгә иреште һәм Ибраһим хан «Гази» исемен яулады. Газават каһарманы Ибраһим ханның углы Мөхәммәд Әмин хан атасына лаек варис түгелмени?

Әҗем хан әйтте:

– Ярар, анысы калып торсын... Син ханыңа каршы төрле бөһтаннар[10] таратасың дип әйтәләр, шагыйрь Мөхәммәдьяр... Имеш, Мөхәммәд Әмин хан ул ике яклы пәке, ике яклы хәнҗәр, дисең икән...

– Аны мин әйтмәдем, и олуг хан, – диде Мөхәммәдьяр.

– Алайса, кем әйтте? – дип кызыксынды хан.

– Сүз иясе белән йөрми, и олуг хан!

Әҗем хан сабырланды, ул Мөхәммәдьярга үгетләгән кебек мөрәҗәгать итте:

– Син гел мине кимсетергә, үчекләргә, чыгырымнан чыгарырга телисең. Синең «Олуг хан» дигәнең дә мыскыл булып ишетелә, янәсе, мин олуг түгел.

– «Олуг хан» дип Чыңгыз ханга да, Батыйга да, Олы Мөхәммәдкә дә, Ибраһим ханга да әйткәннәр бабаларыбыз.

– Ләкин син «Олуг хан» гыйбарәсен мыскыллы тавыш белән артык купайтып әйтәсең. Артык хуплау хурлауга бәрабәр... Димәк ки, мин ике яклы пәке? Ни-нәрсә була инде ул «ике яклы пәке»?

– Кылычларның күбесе бер генә яктан кисә, ике ягы да үткен хәнҗәрләргә «әҗем пәкесе» диләр, ягъни бу фарсылардан килгән корал. Әҗем – фарсы пычагы, дигән сүз. Чәнчегәндә, ике яклап кисә, бәндәнең исән калу мөмкинлеген киметә. Әҗем хәнҗәре, белгәнеңчә, иң сыйфатлы һәм мәшһүр корал. Сине шуның белән чагыштырганнар икән, сөен.

– Юк, бу мыскыл рәвешендә әйтелгән сүз, янәсе, мин бер кискәндә, дошманнарны турасам, икенчесендә дусларымны турыйм, булып чыга.

– Юк, хан, ике яклап турый торган Әҗем-хәнҗәр булу бер дә яман түгел.

– Син жумба балык[11] кебек шома, сине яланкул тотып булмый... Син минем сараемдагы иң гүзәл җарияләремнең берсенә күз атасың, кул саласың, диләр. Шул дөресме?

– Мин сукыр түгел бит, и хан, каршыма килгән, каршымда торганнарның барысына да күз атам, аның гөнаһысы бармы, и хан?

– Димәк, минем җариямә кул салуың хак?

– Юк, хан, мин синең җарияңә кул салмадым. Сүз иярә сүз чыкканнан гына әйтәм. Әмма синең илне, ватанны, йортны сатарга җыенганың миңа гына түгел, бөтен дөньяга фаштыр.

– Карачы Мөхәммәдьяр! Син артыгын кыланасың! Карачылар шаһитлегендә, яраннарым каршында, колларым алдында, ниһаять, ханбикә каршында син миңа дорфа сүзләр әйтәсең. Моның өчен нәрсә буласын, син беләсеңме, шагыйрь?

– Ярлы янудан курыкмый, хан. Минем югалтасым юк!

– Син минем урынга утырып бак, шагыйрь! – диде хан, аклангандай.

– Һәркемнең үз урыны, и хан. Син дә шагыйрь идең, ләкин син тәхетне

[10] бөһтан – ялган сүз, гайбәт.
[11] жумба балык – тәңкәсез балык, налим балыгы.

сайладың. Сине даның өчен, сине хан булганың өчен, сине хөкемдар булганың өчен, сине байлыгың өчен сөяләр. Ягъни син гүзәлләрнең мәхәббәтен дә сатып аласың. Ә мин синең бер җарияңә гашыйк булдым, минем бернәрсәм дә юк.

– Син дә бай, Мөхәммәдьяр, синең дә сарайга тиң йортларың бар, Ерак Кабан буенда синең малларың, болыннарың, елкыларың бар, Казан каласында синең сарайга тиң таш йортларың бар. Син ханнан да бай. Җариям сине шул байлыгың өчен ярата булыр.

– Ул байлыкларның бүгеннән минеке түгеллеген мин бик яхшы аңлап торам, хан. Чөнки синең шымчыларың, җасусларың, әләкчеләрең минем турыда булганын да, булмаганын да сиңа җиткезеп тора. Тыңланыр өчен, әләкләр өчен күпме акча сарыф итәсең син дәүләт казнасыннан. Юкса, минем үземнән генә сорарга кирәк иде, әйттемме мин ул сүзне, юкмы, кылдыммы мин шул гамәлне, юкмы? Син миңа караганда, үзеңнең ләббәйкәләреңә ныграк ышанасың. Мин сиңа турысын әйттем. Мин синең турыда гайбәт таратмадым. Мин синең турыда «ике яклы пәке» димәдем, ул сүзне синең яраннарың үзләре сөйләп йөри.

– Кемнәр сөйли, кайда сөйли? Мин аларны астырам, аттырам! Әйт!

– Мин әләкче түгел! Мин сине «тәһарәтсез урыс табанын ялаучы» димәдем, ләкин мин үзеңнең күзеңә туры карап әйтәм, син Мәскәү колы, син Бәчели ялчысы. Чыңгыз нәселле, тамырларында атаклы затлы, сыйфатлы кан ага торган Казан ханының Мәскәү колы булуы минем өчен түзә алмаслык шәйдер. Мине «халык дошманы» дип әйтүчеләр – синең дошманнарың, Ватан дошманнары. Син моны аңларсың, ләкин соң булыр.

– Аннан соң син, карачы бәк Мөхәммәдьяр, халыкны яныңа туплап: Әҗем хан ул минем белән ярышып, шигырь язып карады, чыкмады, аңа Аллаһ тарафыннан шагыйрьлек бирелмәгән. Мин – Мөхәммәдьяр, сарай шагыйре, халык шагыйре, Әҗем хан такмак чыгаручы шигырьче генә, дип сөйләгәнсең.

– Аны мин сөйләмәдем, хан, аны синең менә шушы ялчыларың астыртын гына сөйләп, халык арасына тарата, шулар үз фикерләрен, үз сүзләрен Мөхәммәдьярныкы дип, миңа сылтыйлар. Синең алдыңда мине каралтмак булалар. Ул сүзләрне таратучы мин түгел, ләкин синең ялчыларың синең шагыйрьлегең турында шактый туры фикер йөртә. Чыннан да син бит олы шагыйрь түгел, син олы шагыйрь була ала идең, ләкин син үз куәңә[12] хыянәт иттең. Син шагыйрь тәхетенә бәрабәр хөкемдар тәхетен сайладың. Шагыйрь тәхетендә сәясәтче була ала. Ләкин сәясәт тәхетендә шагыйрь була алмый. Сүзем бетте!

Бәкләр бәге Ширин ханның уң тарафында басып тора иде, ул шыпырт кына хан колагына әйтте:

– Карале, и хан, бәлки Мөхәммәдьярга үлем җәзасы чыгарыргадыр. Башын чаптырып яки асып үтерү кирәктер? – диде.

Әҗем хан да Ширин бәккә генә ишетелерлек итеп әйтте:

– Ярамый. Халык ни әйтер? Хан миһербанлы булып күренергә тиеш. Без аны башта болай гына, җиңелчә генә җәзалыйк, аннан соң кылычмы, агумы, бәхетсезлекме – эшне хәл итәр.

Ширин бәк канәгать елмайды:

[12] куә – талант

– Хе-хе-хе, ярый... хәл итәрбез! – диде.

Әҗем хан Борһан Сәедкә ым какты.

Баядан бирле яргулау сөрешен игътибар белән тыңлаучы Борһан Сәед хөкем карарын игълан итте:

– Карар-и Хөкем! – диде ул. – Мөхәммәд Әмин хан сараендагы карачыларның дүртенчесе, тархан Мәхмүт углы Мөхәммәдьяр хан тарафына җибәргән бөһтаннары, ягъни мәмләкәтебезгә зыян салганы өчен дүртенче карачы вазифаларыннан үз теләге белән азат ителә вә дәхи аның тарханлыгы[13] турындагы ярлык инкярь ителүе турында яңа ярлык языла, аның бөтен мал-мөлкәте байлыгы, казна файдасына күчерелә! Сүз тәмам!

Мөхәммәдьяр бу карарны тыныч кабул итте һәм сабыр гына Борһан Сәед тарафына карап әйтте:

– Синең ярлыгың язылганчы мин тархан әле, сүземне әйтеп калыйм. Тарханлык ул кире кайтарып алынмаслык вакытка тәгаенләнә, тарханлык ул хәтта җинаятьләрне дә гафу иттерә торган дәрәҗә. Тархан төрмәзиндан, тархан камчы суктыру, тархан асып үтерү кебек җәзалардан азат. Син, Мөхәммәд Әмин хан, ата-баба кануннарын бозып, атаң язган ярлыкны инкарь итеп, миннән тарханлыкны аласың, бу синең Мәскәү шымчылары тарафыннан миеңә сеңдерелгән бер хата, ялгыш, гөнаһтыр. Синең тәхеттән колак кагачагың йөздән туксан тугыз фаиздыр[14]. Ә мине шагыйрьлек тәхетеннән әллә нинди ярлыклар да мәхрүм итә алмый. Китәр алдыннан сүземне дә тыңлап бакчы, и хан. Син тәхетең тирәсенә җыен килмешәк бәкләрне тупладың, аларның ватаны Казан түгел, аларның хәтта үз ватаннары да юк. Алар үз ватаннарыннан үз халкы, үз ата-анасы тарафыннан читкә куылган, казак чыгып киткән бәндәләр, маҗарапәрәстләр[15], астыртын эш йөртүчеләр. Синең таянычың шул аламаннар[16] гаскәрендә – казакларда. Ләкин бу таяныч черек. Вакыт үзгәрүгә, сәясәт какшауга алар сине ташлап качачак, качсалар ярый әле, алар сиңа каршы барачак.

– Минекеләр хыянәт итсә... – диде хан.

– Синекеләр хыянәт итсә, – диде Мөхәммәдьяр. – Мәскәү гаскәре – синең таянычың! Ләкин ул да черек таяныч. Аңа таянсаң, и бөек хан, Сөләйман пәйгамбәрнең таягы кебек череп, син егылачаксың. Мәскәү бармак бирсәң, кулыңны, кулың бирсәң үзеңне кабып йотачак.

– Сине көнчелек сөйләтә, – диде Әҗем хан. – Карарым катгый, фәрманым алынмас, син бүгеннән тархан түгел.

– Мин Казан өчен күп көч сарыф иттем, тарханлыкны миңа син түгел, Ибраһим хан бирде. Атаң биргән ярлыкны ничек итеп син инкарь итәсең?

– Син бәклекне куеп, тарханлыктан мәхрүм булып, таш пулатларың казнага алынып, Болгар капкасы янындагы мазарстанга бакчы итеп куеласың, – диде хан.

– Ни кылаем, хан, синең сүзең канун! Син мине кимсетер өчен кабер өстен себерүче итеп куярга булдың. Юк, бөек хан, ул эш мине кимсетә

[13] тархан – хөкүмәткә яхшы хезмәт иткәне, сугышларда батырлык кылганына күрә каһарман иргә бирелә торган дәрәҗә; бүгенгечә әйтсәк: персональ пенсионер.
[14] фаиз – процент.
[15] маҗарапәрәст – авантюрист, маҗаралар эзләп йөрүче.
[16] аламан – ялланган гаскәр.

алмый. Син мине бәклектән, карачылыктан төшерә аласың, ләкин син мине шагыйрьлек тәхетемнән төшерә алмассың. Син генә түгел, мине ул тәхеттән бер генә бәндә дә төшерә алмас. Мин каберстанда да хезмәт итә алам, сарайдагы тере мәетләр белән мөзакәрә[17] кылганчы, мәетләрнең рухы илә зиратта сөйләшүе мең кәррә артыктыр. Ә менә сине, олуг хан хәзрәтләре, тәхетеңнән бер ябай гына юлбасар да төшерә ала, йолкыш кына Мәскәү кенәзе дә сине бу тәхетеңнән йолкып ала-ала.

– Мин дә – шагыйрь, мине дә ул тәхеттән беркем дә төшерергә җөрьәт итә алмас, – диде Әҗем хан.

– Бу тәхетең синең фани, Әҗем хан, – диде Мөхәммәдьяр. – Бүген бар ул, иртәгә – юк! Тәхеттә бәхет тапкан татар ханы юк тарихта, тәхеттән ләхеткә күчкән ханнар байтак. Ә шигырь тәхетенә килсәк, ханым-солтаным, эш болай торадыр ки: менмәгән тәхеттән кешене төшереп булмый. Мәскәүне мактаган Казанда шагыйрь булалмас!

Әҗем хан ярсып кычкырды:

– Тәмам! Алыгыз бу хәерчене!

– Диванханә түгел, диванаханә бу, и олуг хан Мөхәммәд Әмин! – диде Ярмөхәммәд.

Яраннар шагыйрьне урап алды. Мөхәммәдьяр җөббәсен, билхәнҗәрен, башлыгын, читекләрен, кошагын салып, яланаяклы дәрвиш кыяфәтендә сарайдан чыгып китте.

Әҗем хан карышкы таягын алып, идәнгә орды һәм әйтте:

– Ханга каршы барган һәр адәмне шушы язмыш көтә! – диде.

***

Әҗем хан Мәскәүгә аркалана, чөнки халыктан тупланган елкы, сыер, куй малының, тәпән-тәпән бал, кеш, җофар, кондыз кебек кыйммәтле тиреләрнең күп өлешен Казан Мәскәүгә озата иде. Шулар өстенә Идел дәрьясында гына булган тере чөгә балыгын, су тутырылган имән мичкәләргә салып, Мәскәүгә – Бәчели кенәзгә җибәреп тора.

Казан каласына карап сокланмаган, аңа кызыкмаган кеше юктыр. Мәскәү генә түгел, Кырымы, Әстерханы, Касыймныкылар да Казанга кызыгып, көнләшеп карый. Бигрәк тә Себер ханзадәләрнең «казанлы» буласы килә иде. Казан тәхетенең какшау булуыннан файдаланып, Себер ханзадәсе Мөхәммәтдин, халык аны «Мамык ханзадә» дип кенә йөртә, Казанга яу әзерли башлады, «урыс калдыгы» Әҗем ханны бәреп төшереп, үзе Казан тәхетенә утыру өмете илә яна иде. Мәскәү гаскәре Казаннан еракта чакны чамалап, Мамык Казанга яу чыкты. Яу алдыннан Мамык ханзадә Казанга шымчылар юллады. Икешәр-икешәр шымчыдан торган өч төркем корып, алар Казанның өч тарафыннан кереп, Себер ханзадәсе Мөхәммәтдин-Мамыкның коточкыч зур яу илә Казанга йөрүе, рус ялчысы Әҗем ханны тотып, аңа халык алдында җәза биреләчәге турында коткы таратырга, хан сараендагыларның да, кара халыкның да котын алырга тиешләр иде. Шулай булды да. Мамык ханзадәнең гаскәре Казан тарафына йөри торды, шымчылар Казанга кереп, төрлесе төрле яктан коткы таратып, халыкның күңеленә шом сала тордылар.

[17] мөзакәрә – әңгәмә.

Ике шымчы сәүдәгәр кыяфәтенә кереп, Казан сараена үтеп, хансарай хатыннарына кеш-җофар тиресе саткан булып, астыртын гына шомлы хәбәрне тарата тордылар. Мамыкның хәйләсе тормышка ашты, Казан халкы, бигрәк тә сарайдагылар куркуга төште. Шуңа күрә Мамыкның гаскәре һич каршылыксыз дип әйтерлек Казан капкасыннан узды. Әҗем хан качып өлгерде.

Мамык вә аның сугышчылары коралларын таккан килеш сарайга керде, итагать-әдәп дигән төшенчәләрне уйлап тормыйча, ул бушаган тәхеткә менеп утырды да беренче фәрманын игълан итте.

– Мин, Мөхәммәтдин – Мамык хан сүзем! Һич кичекмәстән Әҗем ханны табып, минем янга китерегез! Без аны яргулаячакбыз! – диде. – Минем яугирләремә юл күрсәтүче булып йөрер кешеләр әзерләгез! Кем дә кем качкан ханны тотып алып килә, шуңа бер кантар алтын!

Ыгы-зыгы килделәр, юл күрсәтүчеләрне билгеләделәр дә качкан ханны эзләүчеләр:

– Баш өсте! – дип, сарайдан чыкты.

Мөхәммәдьяр күптән мазарстан[18] сакчысы вазифаларын үти башлаган иде инде. Ул егылган ташларны бастырып, нигезләрен ныгытып, авышларын турайтып йөри иде. Зират сириннәре арасында бер баш күренде:

– Кем бар анда? – диде Мөхәммәдьяр.

Кеше куркып, артка чикте, кеше башы яфраклар арасында юк булды. Мөхәммәдьяр сирин агачларына якын ук килде, ул җиргә чүгәләгән, әлсерәгән, йончыган бер кешене күрде.

– Син нишләп утырасың каберләр арасында? – дип сорады шагыйрь.

Кеше калтырый башлады.

– Тор, әнә минем хөҗрәмә[19] кер! Җылы чәй эч, анда нан да бар!

Шулчак Мөхәммәдьяр хәерче киеменә төренгән Әҗем ханны танып алды.

– Бәрәкәт! – диде кабер караучы. – Мөхәммәд Әмин хан монда нишләп утыра?

Хәерче кыяфәтле хан аягына басты, өстен каккалап алды да әйтте:

– Мамык килеп басты Казанны! Ул мине таптыра.

– Беләм! – диде зират хуҗасы. – Синең башың бер кантар алтын тора!..

– Зинһар, сатма мине! Качыр мине кая булса да!

– Әйдә! – дип, кабер караучы ханны каядыр алып китте.

Алар каберстанның аргы башындагы бер келәткә килеп җитте, келәт эчендә баз казылган.

– Син шунда кереп ят!

– Кабергәме? – диде хан.

– Курыкма, кереп ят!

Ничарадан бичара, Әҗем хан базга төште. Мөхәммәдьяр баз өстен авыр таш плитә белән каплады. Аннан бер читтә торган таш кантарын плитә өстенә тәгәрәтеп менгерде.

– Менә шулай иткәч, сине беркем дә табалмас!

Астан Әҗем ханның нидер кычкырганы ишетелде:

---

[18] мазарстан – каберстан.

[19] хөҗрә – куыш.

– Зинһар, Алла хакы өчен, мине коткарсаң, мин сиңа үзем ике кантар алтын бирәм.

– Ярар, Әҗем хан, ләкин син вәгъдәңдә тормаячаксың! Син мине ялган шаһитлар сүзе белән сарайдан кудың.

Астан «валлаһи, билләһи» кебек сүзләр ишетелде.

– Мин сиңа ашарыңа-эчәреңә алып киләм! – дип, Мөхәммәдьяр китеп барды.

Качкын ханны эзләүчеләр зиратка якынлаша иде. Мөхәммәдьяр үз эше белән шөгыльләнә башлады. Ул арада юл күрсәтүчеләр белән Мамык ханның яугирләре дә килеп җитте. Алдан йөрүчесе Ялгай Мирза иде.

– Һәй, мөҗавир[20] Мөхәммәдьяр! – дип кычкырды алдан йөрүче Мирза. – Син монда Әҗем ханны күрмәдеңме, ул хәерче киеменә төренеп качып китте!

– Ялагай Мирза, мин бер хәерче дә күрмәдем, башың бармы синең, Ялагай Мирза? Хәерчеләр каберстанга хәер сорарга киләмени, тинтәк баш!

Гаскәрдәгеләр шаркылдап көлде. Ялгай Мирзаның ачуы чыкты. Ул гаскәр башына әйтте:

– Алдый ул кабер караучы, әйдәгез, зират эчен карыйк!

Эзләүчеләр атларын зират коймасына бәйләп, үзләре җәяү каберстанга кереп киттеләр. Мөхәммәдьяр да аларга иярде. Эзләүчеләр мөҗавир яши торган хөҗрәне дә җентекләп тентеделәр. Аннан зиратны тикшерделәр. Күпме генә эзләсәләр дә, качкын ханны таба алмадылар. Эзләүчеләрнең берсе кычкырды:

– Монда нindидер келәт бар!

Барысы да келәт янына җыелды.

– Бу нинди келәт? – дип сорады гаскәр башлыгы. – Ач ишеген!

Мөхәммәдьяр келәтнең ишеген ачты.

– Кабер казу әсбаплары өчен амбар бу! – диде мөҗавир.

Гаскәр башлыгы Ялгай Мирза китәргә ишарә итте. Киттеләр. Алар киткәч, Мөхәммәдьяр бер телем нан, бер чүмеч су алып, келәт янына килде, нанын, суын бер читкә куеп, өске ташны тәгәртеп төшерде дә плитәне ачты. Баз эчендә куркуыннан коты чыккан Әҗем хан ике тезен кочаклап калтырап утыра иде.

– Капкалап ал! – дип, кабер караучы ханга чүмеч, аннан соң нан сузды.

Хан башта йотлыгып су эчте, соңыннан нан ашый башлады.

Хан капкалап алгач, мөҗавир әйтте:

– Төнлә монда суык булыр, минем хөҗрәгә күчик... Алар кабат монда килмәс!

Әҗем хан Мөхәммәдьярга буйсынды.

***

Мамык хан гаиләсендә яхшы тәрбия алмаган бер сантый иде. Сәясәт, хәрби эшләрдә аның башы йөрми иде. Ул Казан тәхетенә кызыкса да, хан тәхетенә утырса да, аның мокытлыгы һәр эшендә чагыла иде. Тәхеткә утыруга ук Мамык хан халык өстенә авыр салым салды, аннан ул салымны гел үз мәнфәгатьләренә генә тота башлады. Халыкның

[20] мөҗавир – каберстан караучысы.

яңа ханга ризасызлыгы сәгать саен арта иде. Аннан соң дивана Мамык Арча даругасына[21] яуга чыкты. Арчаның бай як икәнен белеп, ул талау, куркыту сәясәтенә күчте. Арча малларын талап кайтып килгәндә, Казан халкы бөтен капкаларын да шартлатып бикләп куйды. Мамык хан адәм көлкесенә калды. Күтәрелде кара халык. Мамык Арчадан таланган байлыгын Казан диварлары янына ташлап качып китте. Себергә кайтып, энесе Агалак белән зур гаскәр туплап, алар тагын Казанга ябырылды, ләкин Казан каты каршы торды. Мамыкныкылар чигенергә мәҗбүр иде. Юлда кайтканда, ниндидер гауга чыгып, Мамык ханны үзенекеләр үтергән, дип сөйләделәр.

Мамыктан соң Әҗем хан тагын тәхетенә кайтты.

Йончылган хан ял итеп тормады, эшкә керешә. Иң беренче эше итеп, ул ялагай мирзалардан арынды. Аннан соң тагын дивани мәҗлесне чакырды. Диван бәкләре дә күбесе алмашынды. Диван мәҗлесе җыеласын ишеткәч, Мөхәммәдьяр үзе килде сарайга. Мәҗлескә ул кабер караучы киеменнән килгән иде.

Хан әйтте:

– Шагыйрь Мөхәммәдьярга үз киемнәрен кайтарыгыз!

Ләкин кул ишарәсе белән аны Мөхәммәдьяр туктатты:

– И хан, кирәкми! Мөҗавирлектә шушы киемем дә ярап торыр!

– Мөхәммәдьярга бөтен вазифаларын да кире кайтарырга! – дип боерды хан.

Мөхәммәдьяр вазифаларыннан янә баш тартты.

– Ни телисең соң син, Мөхәммәдьяр? – дип сорады хан. – Мин вәгъдә иткән бер кантар алтынныммы?

Дивандагылар аптырап калды, нинди алтын, нинди кантар, – диештеләр.

– Юк, хан! – диде Мөхәммәдьяр. – Шул алтыныңнан каберстандагы җимерелә барган төрбәләрне, башташларны төзәтер өчен бер микъдар бүлеп бирсәң ярый.

– Казначы! – диде хан.

– Мин, тәкъсир![22] – диде казначы.

– Мөхәммәдьяр сораганны бир! – диде хан.

– Тәшәккүр, и хан! – диеп баш иде Мөхәммәдьяр. – Тагын бер үтенечем бар, и хан. Мәскәүгә аткарылган салымнарны кыскарт яки бөтенләй туктат! Халыкның карыны тук, өсте бөтен булсын!

– Уйлашырбыз! – диде хан.

– Тәшәккүрләремне сонамын! Миңа китәргә рөхсәтең бир, и хан!

– Син ирекле, Мөхәммәдьяр! – диде хан.

Чыннан да Мөхәммәд Әмин хан шуннан соң салымнарны кыскартты, Мәскәү белән арасын рәтләде. Казан иле чәчәк атты.

Ләкин дошманнар гына тынычлана алмады. Казанда эшләр болай барса, Мәскәүне узып китәчәк, Мәскәүгә сатылган җасуслар көннәрдән бер көнне (1516 елда) Казан ханы Мөхәммәд Әминнең ашына агу салдылар. Ике елга якын интекте бичара хан, һәм, ниһаять, ул 1518 елның кышында җан тәслим кылды. Урыны җәннәттә булсын!

[21] даруга – бәклек, бәклеккә бара торган юл.
[22] тәкъсир – олылау сүзе.

# НАЗИК ҮТЕРЕШ

ХИКӘЯ

Миндияр ул – авыл гыйбады үзе. Ни Аллага, ни муллага, ни попка, ни партиягә яраша белә торган бәндә булалмады. Кая керергә белмичә генә журналистлыкка укырга барып керде. Аның бөтен хыялы башкалада фатиры булган тол хатын яки берәр байның сазаган кызына өйләнү һәм шул хатынга йортка кереп, калада төпләнеп калу иде.

Икенче курс узып бара, ләкин әле фатирлы хатын табылмаган.

Шулай каңгырып, укыр-укымас йөргәндә, журналистика кафедрасы башлыгы профессор Салих әфәнде Битугин авырып китте дә Миндиярны курс эше буенча үз фатирына чакыртып алды. Бер аны гына түгел, башкаларны да берәм-берәм чакыргалады. Ул дәресләрне үз өендә уздыра башлады.

Профессорның фатиры шаккаткыч иде, олы-олы дүрт бүлмә. Алгы мәйданы киң, корридор яп-якты, аш бүлмәсе – студентлар өчен тулай торак ясасаң, алты карават куярга булыр иде.

Аш бүлмәсеннән урта яшьләрдәге бер хатын чыкты да:

– Узыгыз, шәкерт! – дип, түр ишеккә күрсәтте. – Салих! Шәкертең килгән!

– Керсен! – диде профессор.

– Син кайсы яктан соң, егет? – диде хуҗабикә.

– Мин Байлар Сабасыннан, ярлы Миндияр булам! – дигәч, хуҗабикә рәхәтләнеп көлә башлады.

– Остроумно! Мин дә Саба ягыннан бит, Олбаттан!

– Шулаймыни! – диде егет.

– Исемем – Әлизә! Якташлар икәнбез!

Ханым тагын елмайды. Бу елмаю Миндиярның күңеленә май булып ятты. Әлизә ханым ишекне ачып, Миндиярны профессор бүлмәсенә алып керде.

– Салих! Бу минем якташым булып чыкты. Байлар Сабасыннан, ярлы егет Миндияр!

– Бик яхшы, ярлы егет Миндияр! Курс эшең әзерме? – диде профессор, кәгазьләреннән аерылып.

Миндияр каушый-каушый дәфтәрен профессорга сузды.

– Профессор әфәнде! – диде Әлизә ханым кыланчык тавыш белән. – Минем якташка бик каты бәрелмәсәгез иде!

– Бар, бар, Әлизә ханым, өчпочмагың көймәсен! Без үзебез белербез! – дип, профессор Миндиярның дәфтәрен актара башлады.

Салих әфәнде сызгалап-бызгалап язылган дәфтәрне байтак кына укып утырды, ул арада Миндияр профессорның эш бүлмәсен күздән кичерде. Китаплар, кульъязмалар. Диварларда әллә нинди битлекләр, шаман барабаннары, курайдыр, сыбызгыдыр кебек нәрсәләр тезелешеп китkән.

Ул арада аш бүлмәсе ягыннан Әлизә ханымның тавышы ишетелде:

– Һәй, фән кортлары! Өйлә ашына чыгыгыз!

– Әйдә, егет, Әлизә җиңгәң ике әйттергәнне өнәп бетерми! – диде дә профессор, таягын алып, урыныннан торды.

Өйгә хуш ис таралган. Табын янына утырыштылар.

– Җитешегез! – диде хуҗабикә.

Салих өчпочмакка беренче булып үрелде, аннан соң – Әлизә ханым.

– Тартынма, Миндияр! – диде хатын. – Ризыктан җитеш!

Миндияр да кыюсыз гына бер өчпочмак алды. Ул искиткеч тәмле иде.

Бер өчпочмакны ашап бетергәч, профессор сүз башлады:

– Егетем, син материалны күп туплагансың. Ләкин синең конкрет каһарманың җансыз. Аның холкы күренми. Очерк яки мәкалә әдәби әсәр кебек укылырга тиеш. Бу синең киңәйтелгән хәбәр генә булып чыккан. Хәбәрне аны теләсә нинди мәктәп укучысы да яза ала. Төбәк гәзитләрендә бастырырга ярый да торгандыр, әмма җитди матбугатка бу бармый.

– Салих, – диде Әлизә ханым. – Алай каты бәрелмә инде минем якташка...

– Әлизә ханым, сез өчпочмакны бик тәмле пешерәсез, әмма журналистикада сез ашчы түгел! – диде профессор. – Мин анда карандаш белән язып бардым, шуларны карап, яңадан китерерсең!

Эшләп китерде Миндияр һәм профессор курс эшен кабул итте. Миндиярдан битәр Әлизә ханым шат иде аның кабул ителүенә.

Зачёт алып киткәндә, ишек төбендә Әлизә ханым Миндиярга әйтте:

– Син безгә ешрак килеп йөр! Профессордан белмәгәнеңне сораштыр, берәр китап сораган бул, ул студентларның кызыксынуларын ярата. Син аңа җәй көне мәтрүшкә җыеп алып кил! Ул мәтрүшкәле чәй ярата.

Миндиярның эшләре хутка китте. Ул төрле хәйлә табып, профессор янына еш килә башлады. Ләкин өченче курс бетте дигәндә генә профессор Салих абыйның авыруы көчәеп, аны хастаханәгә салдылар. Ул шунда уңышсыз операциядән соң вафат булды. Аны бөтен студентлар каберстанга озата барды.

Миндияр Әлизә ханымны ялгыз калдырмаска тырышты. Салих абыйның өчесен, җидесен, кырыгын уздырырга ярдәм итте. Хатын тегене алып кайт, моны алып кайт дип, аны гел кибетләргә җибәргәләде.

Миндияр профессорның кырыгы узганнан соң, Әлизә ханым янына профессордан алып торган китапны китерә килде. Кичкә чаклы сөйләшеп утырдылар. Миндияр китәргә дип урыныннан торды.

– Соң бит инде, куна кал, институтка моннан гына китәрсең! – диде Әлизә ханым.

Егет риза булды һәм шуннан бөтенләйгә калды. Кырык яшьлек хатын егерме ике яшьлек егетне каптырды, Миндияр теләгенә иреште. Ашарга әзер, киенергә акча бар. Шулай итеп, ул институтны тәмамлап чыкты. Алар никахлы, загслы ир белән хатын булды. Миндияр студентларның, укытучыларның алар артында ни сөйләгәннәрен бик яхшы белә, ләкин ул сүзләргә игътибар итмәде, дөресе шул бит, ул үзеннән егерме яшькә олы хатынга йортка керде. Калада теркәлеп калды. Яхшы эш тапты. Шәһәр гәзитләренең берсенә хәбәрче булып урнашты. Ул атаклы кешеләр янында чуала, кемдер муниципаль төбәкне алга җибәргән, ул төбәк җитәкчесен мактый, күккә чөя, үзе дә буш калмый. Завод директорларын, авыл җитәкчеләрен, гомумән, өстәгеләрне мактаган кешенең авызы ризыктан өзелмәс, табыны мул булыр. Иномаркада гына җилдерә башлады.

Ресторраннарга, кунакларга барганда, хатыны белән Сабан туйларына кайткалаганда, күп кеше аларга, әлбәттә, гаҗәпсенеп карый. Чөнки аларның яшь аермалары шактый. Әлизә ханым инде иллегә җитеп килә, ул әле утызда гына.

Миндияр матди яктан да, рухи яктан да шактый ныгыды, аның күңел күзе картаеп бара торган Әлизәдә түгел, яшь, матур, тыгыз күкрәкле кызларда иде. Миндияр ир-егет булып өлгергән иде инде. Әлизә ханым аның сул якка йөргәнен сизенде, килеп тә әйткәләделәр. Ләкин Әлизә беркайчан да иренә: «Нигә соңга калдың, кайда йөрдең?» – дип бәйләнмәде. Сабыр гына яшәде. Әлизә үз урынын белә иде. Ул, Миндияр мине ташлап китәр, дип курыкты.

Ташламады Миндияр Әлизәне. Шулай яши бирде. Әмма ул бер кызга чынлап гашыйк булды. Башкалары белән арасын өзеп, бары тик шул кыз белән генә йөри, еш очраша, алар инде бер-берсен ярата иде кебек. Ләкин мәңге шулай дәвам итә алмый иде. Миндияр ике ут арасында калды. Аерылышса, ул урамда калачак. Кызның үз фатиры юк, ата-анасы белән ике бүлмәле хрущёвкада тора иде.

Бу хәл озакка сузылды. Кыз Миндиярның карт хатыныннан аерылуын тели иде. Ләкин бу хакта аңа телдән әйтмәде.

Миндияр еш эчә башлады. Ул редакциядән кайтышлый гел бер сыраханәгә керә. Редакциядә егетләр белән эчкәне өстенә, шул сыраханәгә кереп, күгәргәнче сыра эчә дә өенә кайтып ава. Әлизә сабыр гына ирен чишендереп, урынга яткыза. Гел шулай кабатлана башлады.

Сыраханәдә кеше күп, төтен, әче сыра исе, тозлы балык, кеше тире исе. Миндияр ике кружка сыра алып, буш урын карый башлады. Бер ир янында буш урын бар иде:

– Монда ярыймы? – диде ул.

– Валяй! – диде ир кеше.

Миндияр бер кружка сыраны тын да алмыйча эчеп бетерде.

– Шәпме? – диде күршесе.

– Шәп! – диде Миндияр.

– Менә моның белән тагын да шәп була ул! – диде өстәлдәше.

Ир кеше куен кесәсеннән башланган бер шешә аракы чыгарды да сыра өстенә агызды:

– Сиңа да салыйммы? – дип сорады.

– Сал! – диде Миндияр, күршесе Миндиярның сырасы өстенә бераз аракы агызды.

– Мин – Саныч! Танышлык өчен! – дип, Саныч кружкасын бушатып куйды.

– Мин – Миндияр! – дип, ул да эчеп җибәрде.

Миндияр күршесенең кулына карады, ир кешенең ике кулы да татуировка белән чуарланган иде.

«Зэк» дип уйлады Миндияр.

Зэк сумкасыннан каклаган корбан балыгы чыгарды, балыкны өстәлгә куйды да кесәсеннән пычак чыгарып, балыкны тураклый башлады.

Миндияр: кунак ашы – кара-каршы, дигәндәй, икесенә дүрт кружка сыра алып килде. Гәпләшә-гәпләшә бер шешә аракы да, дүрт кружка сыра да эчелеп бетте.

– Буранлый, – диде Саныч.

– Буранласын, мин әнә тегендәге йортта гына торам! – диде Миндияр.

– Ого! – диде Саныч. – Элитный дом!

– Элементарный дом! – диде Миндияр. – Дом есть, жена есть, детей нету.

Анысын сөйләштеләр, монысын сөйләштеләр, исерә төштеләр.

– Мин хатынны алтынга мандым, Саныч, – диде Миндияр. – Бриллиант алкалар, алмазлардан гына торган муенса – колье, антиквар беләзек, гранатовый браслет, ә үзе кысыр булып чыкты.

– Минеке дә бриллиант! – диде Саныч.

– Ничек – бриллиант?! – дип сорады Миндияр.

– Шулай, – диде Саныч. – Мин хуҗада чакта башкага чыкты... бриллиант булмаса, алмаслар иде. Хәзер әни янында. Мин дә якын гына торам, әнә теге агач йортта.

– Ну, мин киттем, – диде Миндияр. – Танышуыбызга мин шат, Саныч.

– Кайтып җитә аласыңмы?

– Җитә-әм! Әнә генә минем йорт.

Саубуллаштылар. Икенче көнне алар тагын сырахanә ишеге төбендә очраштылар.

– Хо-о, Миндияр дус! Әйдә! – дип, кочагын җәйде Саныч. – Каклаган чуртаным бар.

– Юк, Саныч, – диде Миндияр. – Хатын белән кичен «Смерч» ресторанына барасым бар. Шефның туган көне, ашыгам, әзерләнәсем бар, кичер! – дип, Миндияр ашыгып китеп барды.

Ул эштән кайтып керүгә, аны хатыны Әлизә асыл күлмәген кигән килеш каршы алды. Күпме тага алган кадәр алмазларын такты, балдакларын, йөзекләрен киде. Чыннан да алар «Смерч» ресторанында бик мулдан гүләйт иттеләр. Миндияр һәр салганны эчеп барды. Мәҗлес азагында ул инде аягында көчкә басып тора иде.

– Такси белән озатабыз, илтеп куябыз! – диделәр кичәдә кизү торучы шома егетләр. Ләкин Әлизә ханым кырт кисте:

– Җәяү кайтабыз, рәхмәт, егетләр! – диде. – Без монда гына торабыз, йөри торгач, ул айныр!

Алар төнге урам буйлап кайтып китте.

Икенче көнне иртән: «Ире журналист Миндияр белән төнге рестораннан кайтып килгәндә, Әлизә Битугинаны үтереп ташлаганнар. Полиция канга буялган пычак тотып ятучы исерек Миндиярны кулга алган», дигән хәбәр таралды.

Полиция бүлегендә иртән ике генә кеше иде: атаклы тикшерүче, эзтабар Гафар белән канлы җинаятьләр бүлегенә әле күптән түгел генә Башкортстаннан Казанга эшкә килгән тикшерүче Сәмигулла Җаббаров. Кизү торучы полиция өлкән лейтенанты Сидоров төнге сводканы шымчылар алдына кертеп салды.

Иң хәтәре Миндиярның үз хатынын үтерү турындагысы иде.

– Җә, атаклы эзтабар Гафар, – диде Җаббаров. – Бүген төнлә җинаять кылынган! Сез шушы җинаятьне шушы бүлмәдән чыкмыйча, кичкә чаклы ача аласызмы?

Мәгълүматта Әлизә белән Миндиярның кайсы ресторannнан кайтып килүләре, ханымның кайда үтерелүе турыда хәбәрләр бар иде.

– Карап карарбыз! – диде Гафар.

Яшь тикшерүче үҗәт рәвештә Гафарны котырта башлады:

– Карап карарбыз, түгел! Ача аласызмы? – дип сорыйм мин сездән.

– Карап карарбыз! – дип кабатлады Гафар, ул инде җинаятьне ачу турында уйлый иде. – Ачсам?

– Ачсагыз, мин сезгә Лондонда алган Шерлок Холмс төребкәсенә тач охшаш челемемне бүләк итәм!

– Ача алмасам?

– Ача алмасагыз, сез миңа көмеш саплы кәгазь кискечегезне бирәсез!

– Ярый! – диде Гафар.

Гафар бу эшкә чумган иде инде. Шеф аны үз янына чакыртып, бу эшкә алынырга кушты.

Кунактан кайтып килгәндә, каты ачуланышып, Миндияр хатынын суйган, дигән фаразны алга сөреп карады Гафар. Фаразлар күп иде: хатыны хыянәт иткән, артыгын эчеп, үзен белештерми торган хәлдә хатынын үтергән, затлы фатиры өчен үтергән.

Гафар үз алдына шушы сорауларны китереп куйды.

Ни өчен Миндияр хатынын кунактан кайтканда, урам уртасында суйган? Хатын үтерү өчен урамнан башка да кулай урыннар җитәрлек. Мотивлар бар, әлбәттә. Фатир! Миндияр инде ресторанда чакта ук шактый исерек булган. Шуңа күрә аны хатыны бераз айнымасмы дип, җәяү алып кайтып киткән. Ни өчен Миндияр ресторанга пычак алып барган? Юлда кайтканда, хатынын суяр өченме? Хатын бит җәяү кайтуны үзе оештырган. Юлда кайтканда, хатынын суярга уйласа, Миндияр аек булырга тиеш һәм җәяү кайтуны хатыны түгел, ул үзе оештырырга тиеш иде. Пычагы да сәер, төймәсенә баскач, чалтлап ачылып китә торган җайланмалы, слюда саплы, сабының як-ягы бизәкле. Бу аш пычагы түгел, бу кулдан ясалган, төрмәдә яки төрмәдә утырып чыккан кеше ясаган пычакка охшаган.

Миндияр хатынын үтереп, затлы алкаларны кая куйган? Узгынчылар үлгән хатынны талап качканмы? Үтереш аулак урындагы, төзелеш оешмасы янында булган. Бәлки берәрсе бу вакыйганы күргәндер, бәлки төзелеш комбинаты капкасына видеокамера куелгандыр?

Гафар ике полицейскийны шаһитларны табып сораштырырга җибәрде.

Үтерешне берәү дә күрмәгән, төзелеш комбинатына да видеокамера куелмаган булып чыкты.

Гафар җинаять коралы – кнопкалы пычакны һәм экспертиза нәтиҗәләрен соратып алды.

Һәм ике полицейскийны Зэк Саныч яткан Пләтән төрмәсенә юллады.

– Видеокамера алыгыз! Төрмәнең иң оста токарен эзләп табыгыз, ул ясаган берәр пычакны сатып алып кайтыгыз! – диде ул хезмәттәшләренә.

– Кулга алынган Миндиярны алып килегез! – дип боерды Гафар.

Гаепләнүче Миндиярны алып керделәр. Ул йончылган, каушаган, аптыраган. Әллә махмырдан, әллә борчылудан, аның күз төпләрендә кәҗә

тоягы эзләре ярылып ята. Ул Гафарга өмет белән багадыр кебек тоелды. Гафарга аның гаебе юк сыман күренде.

Миндияр ниләр булганын сөйли башлады. Гафар Миндиярны бүлдермичә тыңлап утырды да букчасыннан пычак чыгарып, төймәсенә басып, бер ачып, бер ябып күрсәтте.

– Зэкның кулында шушы пычак идеме? – дип сорады Гафар.

Миндиярның ике күзе дә маңгаена менде:

– Шушы пычак, ул аның белән балык турады.

– Ул синең кулыңа шушы пычакны тоттырып качкан. Хәзер син аңлатма язып бир, – диде Гафар һәм бер бит кәгазь белән ручканы Миндияр алдына куйды. Миндияр сул кулы белән аңлатма яза башлады.

Гафар шунда аңлады, зэк Саныч Миңдиярның сулагай икәнен белмәгән, пычакны аның уң кулына тоттырып качкан.

– Дивана! Мин бит сулагай! – дип кычкырды Миндияр. – Ни өчен пычак минем уң кулда?

Гафар кесә телефоныннан наряд чакырды.

– Тиз генә Заря каршындагы агач йортта яшәүче Александр Александрович Александровны кулга алыгыз! Өендә тентү ясагыз! Талаган әйберләрен яшереп яки сатып өлгермәсен.

– Алып чыгыгыз! – диде Гафар.

Сакчы Миндиярны алып чыгып китте.

Бераздан бүлмәгә зэк Санычны алып керделәр. Санычны Гафар каршына утырттылар да, бер янчык алтын-көмеш, алмаз әйберләрне өстәлгә куеп чыгып киттеләр.

– Бу хәзинә сиңа каян килде? – диде Гафар.

– Миңа аны Миндияр үзе бирде.

– Ни өчен?

– Саклар өчен!

– Танышуыгызга бер тәүлек узмаган, каян килә Миндияр тарафыннан сиңа шулкадәр ышаныч?

– Без гел бергә эчә идек.

– Бергә эчүегез бер генә булды!

– Димәк, ул миңа ышанган инде.

– Хатынны кем үтерде?

– Белмим, Миндиярдыр!

– Ялганлыйсың, Саныч, күпме бергә аракы эчеп тә син Миндиярның сулагай икәнен белмәгәнсең. Бәлки сез аның белән килешеп хатынны үтергәнсез?

– Юк!

– Ул сине үз хатынын үтерергә куштымы?

– Юк! Ул үз хатынының асылташлар тагып йөрергә яратканын сөйләде.

– Һәм син аларны сагалап торып, исерек ире егылгач, хатынны үтереп, талап качтың? Бу пычак кемнеке? Синекеме?

– Юк.

Сөйләшү озакка сузылды. Тел яздыру өчен Гафар алдагы сорауларын яңадан кабатлады. Ләкин зэк үз сүзендә торды. Икесе дә әлсерәп бетте. Плэтэннэн кайтып төштеләр. Гафар Санычның берүзен генә калдырып,

чыгып китте. Бераздан ул әйләнеп керде, аның кулында видеокамера белән ниндидер төргәк иде.

Гафар камераны арка ягына куеп, төргәкне сүтте, төргәк эченнән кнопкалы пычак килеп чыкты. Ул ике пычакны рәттән куйды. Пычаклар тач охшаш иде.

– Син алдаштың Саныч, Әлизә ханымны үтергән пычак синеке, менә аның ише. Син аны төрмәдә чакта алтын куллы Захардан ясатып алдың. Захар үзе сөйләде. Видеосы да бар кирәк булса...

– Кирәкми! – диде Саныч. – Хатынны мин үтердем!

Саныч барысын да ничек булган шулай сөйләп бирде.

Санычны алып киттеләр. Миндиярны алып килделәр.

– Сез мине чыгарасызмы? – диде Миндияр.

– Юк! Сине чыгармыйбыз! Син җинаятьне оештыручы буларак, монда каласың!

– Каян килеп? – дип кычкырды Миндияр. – Аны мин үтермәдем!

– Син үтермәдең, әмма син Санычны алгысыттың, аны котырттың һәм нәтиҗәгә ирештең. Әлизә куркаклардан түгел, каты каршы торган, ахырда рәтче пычагы белән аның бавырына чәнчегән, аннан соң пычакны ләх исерек килеш аунап ятучы ире Миндияр кулына тоттырып, хатынның зиннәтләрен алып, качып киткән. Алыгыз бу җинаятьчене!

Миндиярны тагын алып киттеләр.

Эзтабар Гафар иркен сулап куйды.

Бүлмәгә Сәмигула Җаббаров керде:

– Котлыйм, Гафар әфәнде! – диде ул. – Сезнең кәгазь кисә торган затлы пычагыгыз үзегездә кала.

Һәм ул үзенең төребкәсен Гафарга сузды:

– Алыгыз, эзтабар дус Гафар! Сез Шерлок Холмс төребкәсенә лаек эзтабар! – диде Сәмигулла.

**Редакциядән:**

*Бу айда татар җәмәгатьчелеге каләмдәшебезнең 85 яшьлек олуг юбилеен билгеләп үтә. Без аңа киләчәктә дә халкыбызны үзенең яңа иҗат җимешләре белән сөендереп торуын, бәрәкәтле озын-озак гомер кичерүен теләп калабыз.*



Эльвира
Сафина

# ҖЫР-БИЮЛӘР БЕЗНЕ КӨЧЛЕ ИТӘ...

## Толстой эзләре

Бу бинада Толстой яшәгән бит!
Бу юллардан Толстой йөр(е)гән!
Уку-язуыннан арып китсә,
Чыгып кергән «Черек күл»енә.

Толстой йөргән сукмакларны урыйм,
Толстой гамен тоеп җанымда.
Ниләр уйлап йөргән икән димен
Казанында, яшьлек таңында?

Толстой көндәлеген кулга алам,
Болыт кунса аяз күгемә.
Фикерләрне җайга салыр өчен,
Чыгып керәм «Черек күл»емә.

Толстой рухы анда, Толстой тыны,
Толстой сабырлыгы һаман да.
Шау-шу арасыннан тынлык эзлим
Толстой моңы сеңгән Казанда.

## Сәлам бирәдер...

Иртә. Метро. Таныш түгел берәү
Карап бара миңа нигәдер.
Бәлки берәр кайда күргәне бар?
Бәлки танышасы киләдер?!

Шулай була: бер үк кеше белән
Һәр көн саен юлың кисешә.

Эльвира САФИНА (1979) – *шагыйрә, җырлар авторы, филология фәннәре кандидаты; Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимәсе. «Күңелдәге хатлар» исемле шигырь җыентыгы авторы. Казанда яши.*

Гадәтләнгән вакыт, күнегелгән сукмак...
Меңнәр шулай юллар бүлешә.

Яңа йөзләр (җанга якын йөзләр!)
Җыеп кайтам һәрбер сәфәрдән.
Бер карасаң, күпме таныш хәзер,
Төрле авыл, төрле шәһәрдә.

Иртә. Метро. Таныш түгел берәү
Карап бара миңа нигәдер.
Бәлки берәр кайда күргәне бар:
Эчтән генә сәлам бирәдер?!

## Улым бии

Сәхнә уртасында улым бии!
Минем күзләр бары аңарда.
Йөрәккәем, аягына кушылып,
Бии гүя утлы табада!

Ялгышмасын, абынмасын диеп,
Дулкынланып карап торамын.
«Мәшаллаһ!» дип, «Сөбханаллаһ!» диеп,
Белгәнемне укып куямын.

Нинди шатлык, нинди горурлык бит!
Аңлатырга җитми сүзләр дә.
Әниләрнең өзелеп яратуы –
Баласына баккан күзләрдә!

Һәр биюең, һәрбер хәрәкәтең
Кабатланмас бүләк бит, балам!
Мәмнүн булып карап торып, шушы
Күренештән күпме көч алам!

Очып-очып биегәндә, улым,
Арыса да аяк-кулларың,
Бию көйләредәй җиңел булсын,
Матур булсын барыр юлларың.

Бии-бии күңелләрең үссен,
Бии-бии рухың ныгысын!
Шатлансаң да биеп җибәр, улым,
Сынауны да биеп узарсың!

Җыр-биюләр безне көчле итә,
Җыр-биюләр безне яшәртә!
Насыйп булсын, улым, гомер буе
Җырлап-биеп матур яшәргә!

## Җәй тәме ул – җиләк

Минем өчен җәй тәме ул – җиләк,
Туган якта үсә торганы!
«Балакаем кайтыр әле» диеп,
Кызарыплар пешеп куйганы.

Минем өчен җәй яме ул – җиләк,
Саф һавасы туган ягымның!
Җиләк вакытлары җиту белән,
Ничек түзим канат кагынмый?!

Минем өчен җәй төсе ул – җиләк,
Ел да килә шуны күрәсе.
Һәр җәемнең җиләкләрен җыеп,
Такыялар итеп үрәсе!

Минем өчен җәй җыры ул – җиләк,
Сайрар кошлар отып алганы,
Җиләк җыйган чакта җанны назлап,
Күңелемә кереп калганы.

Минем өчен җәй исе ул – җиләк,
Аңа җитәр исләр юктыр шул.
Тәмләп, сулап, җыеп кала торган
Ел буена җитәр көч бит ул!

## Саумы, диңгез?!

Саумы, диңгез, мин дә килдем сиңа,
Сөйлә әле, сөйлә хәлеңне.
Әллә синең бар дөньядан качар,
Үз-үзеңнән ташар мәлеңме?

Син дә безнең кебек ярсыйсыңмы,
Бәргәләнеп, эчең-тышыңда?
Һәр халәтең сизелә бит юкса,
Сизелә бит, әнә, тыныңда.

Бер шаулыйсың ярсып, ачуланып,
Үз-үзеңә сыя алмыйча.
Ярларымнан ташам, дия-дия,
Тирә-якка күз дә салмыйча.

Бар ачуың, үпкә, нәфрәтләрең
Дулкын булып ярга бәрелә.
Күз яшьләре синдә дә бар икән –
Күндек инде тозлы тәмеңә.

Үртәгәндәй, бәлки үртәлгәндәй,
Көч-гайрәтле булып аласың.
...Һәм тынасың, берни булмагандай,
Шундый сабыр булып каласың.

Могҗиза син, аңлап булмый торган,
Беркем белми – ниләр уеңда...
Күңел халәтеңне гөманлап мин
Йөрим менә ярың буенда.

## Халкым минем

Халкым минем – шанлы халык ла ул,
Еракларга киткән даны да.
Дөньякүләм шөһрәтләре аның
Тарихларда күпме языла.

Халкым минем – көчле халык ла ул,
Күпме яулар белән сыналган.
Әрсезлеге, үткенлеге өчен
Күпме түзгән, күпме кыйналган...

Халкым минем – затлы халык ла ул,
Затлылыгы аның каныннан.
Калфагыннан, читек, түбәтәйдән
Татарымны шундук таныйлар.

Халкым минем – зирәк халык ла ул,
Мәгърифәтле, аңлы, белемле.
Ата-бабаларың – онытмаган!
Онытма син туган телеңне!

Халкым минем – сабыр халык ла ул,
Сынаулардан сынмый узарлык.
Тагын да зур үрләр яулау өчен
Бер-беренә кулын сузарлык.

Халкым минем – тапкыр халык ла ул,
Үзен-үзе саклар җай табар.
Сынатмаслык көче-гайрәте бар!
Мәңге яшә, халкым, и татар!

***

*Җылыга, җылыга күнекмә,*
*Күнекмә ышыкка, бушлыкка.*
Луиза Янсуар

Ела да, ярсы да, елмай да,
Әрне дә, сызлан да, хурлан да...
Бары тик җылыга күнекмә,
Тыелма күңелең тулганда,
Курыкма ялгызың кунганда,
Килешмә, иләшмә, күнекмә!

Суксалар, син дә сук, оялма,
Яманга кул бирмә, буялма,
Ышыкка гына син өйрәнмә!
Елмай да, ярсы да, ела да,
Күнекмә бары тик бушлыкка!

***

*Бер җылы сүз көтә күңел*
*салкын бозны эретерлек,*
*җан үзәген чеметерлек.*
Л.Шәех

Бер җылы сүз көтә күңел,
көтә бары, белмим, кемнәндер...
Бәлки синең яктан хәбәр китерүче
җилдәндер,
Бәлки ерак яшьлегемдә калган,
күктә очып йөргән көннәндер...
Бәлки җан үзәген чеметтереп,
бүгенге көн миннән көлгәндер?!
Тик шулай да... өметләнеп,
ялынып һәм ялварырдай булып,
ике күзем яшьләремә тулып,
бер җылы сүз көтәм
кемнәндер...

## Укытучы куйган билге

«Тел ачкычлары бирә күр минем газиз балама,
Күңеленә гыйлем нурын, яктылыгын салгала.
Матур язсын, тиз укысын, барысын да аңласын,
Аңлаганын сөйли белсен, югалып та калмасын.
Укытучысын тыңласын, тәртипле була күрсен,
Барысына да өлгерсен, мөстәкыйль була белсен».
Көннәр буе сиңа шулай теләкләр теләп торам.
Начар билгеләрең күрсәм, йөрәгем әрни, балам.
Ә менә «дүртле», «бишле»ңә синнән артык куанам:
Тырышсаң булдырасың бит, булдырасың бит, балам!
Укытучы куйган билге гади сан түгел шул ул:
Әниләрнең йә шатлыгы, йә борчу билгесе ул...

## Буран шул ук

Казанымда буран бүген: дөнья акка күмелгән,
Әллә нинди серлелеккә, яктылыкка төренгән.
Кар бөртекләре, яратып битемне сыйпаштыра.
Керфекләргә кунып ала, чәчләрне буташтыра.
...Искә төшә яшьлегемнең иң матур бураннары,
Авылымның акка баткан гаҗәеп урамнары.
Их, хисләнеп йөрер идем ул буранда бүген дә!
Буран шул ук, күңел генә элеккеге түгел лә...

Фирдүс
Гыймалтдинов

# УРДА ХАНЫ ҮЗБӘК

РОМАН

### АЛТЫНЧЫ БҮЛЕК

1

Тормыш алга таба ага бирде. Сарай Әл-Җәдид шәһәре елдан-ел үсә барды, аның белән бергә хан гаиләсе дә ишәйде. Тайдула иренә тагын бер малай бүләк итте – анысына Җанибәк дип исем куштылар. Дәүләтнең хәлләренә килгәндә, аның үзәк өлешләрендә хәлләр бик шәп иде. Урда сәүдәне бермә-бер җанландырып җибәрде, тынычлык хөкем сөргән, ял итү, атлар алмаштыру өчен барлык шартлар да тудырылган юлны көнчыгыштан килгән кәрваннар ешрак сайлый башлады.

Дәүләт идарәсендә кабул ителгән карарлар да үзенең уңай нәтиҗәсен бирде. Үзара тарткалашу, сугышу, тәхет тирәсендәге низаглар кимеде. Халыкка тынычлап яшәргә, мал асрарга җай чыкты. Гаскәрнең даими булуы да файда китерде – бердән, югалтулар азрак, икенчедән, атлаган саен, эшне ташлап, яуга чыгып китәргә кирәкми.

Тик көнчыгыштагы хәлләр генә Үзбәккә тынгылык бирмәде. Мәҗүсилеккә табынган литвалылар Киев тарафларына яу йөри, поляклар Карпат тауларыннан ыргыла. Күпме генә тырышмасын, Үзбәк хан дәүләтнең мәйданын киңәйтә алмады.

Бер тапкыр, нукәрләрен җитәкләп, үзе Балкан тарафларына барып караган иде, аннан да рәт чыкмады – Византия гаскәрләре белән вак-төяк бәрелешләрдән соң, Константинополь белән дустанә мөнәсәбәттә яшәргә килештеләр.

Бу чорда Урдада Үзбәк ханның улы Тимербәк даны торган саен күбрәк таралды. Күпчелек яу сәфәрләрен җитәкләргә хан нәкъ менә аны билгеләде. Әледән-әле Хәрәземгә барып, кунак булырга да ярата иде Үзбәк. Үзбәккә Тимербәк, Котлы Тимер янәшәсендә рәхәт һәм күңелле иде.

Бу күренеш бер генә кеше – Тайдуланың гына күңеленә тиде. Тимербәк ханзадәнең болай кисәк кенә күтәрелүенә кара янып йөрде, тик тыштан моны күрсәтмәде. Хан әлегә көчле һәм нык, Тайдуладан туган балалары исә артык кечкенә...

Үзбәк хан рус олысындагы вакыйгаларга хафаланудан арына алмады.

---

*Ахыры. Башы 1,2 нче саннарда.*

Кенәзләр үзара тарткалашудан бер дә туктамыйлар, тынычлыкка ирешергә теләмиләр шикелле. Тверьгә билгеләнгән Дмитрий, Мәскәү кенәзе Юрий белән ничектер килешсә дә, ачуын онытмаган. Аңлый иде аны Үзбәк – нәрсә генә әйтмә, Юрий аркасында Дмитрийның әтисе Михаилны үтерделәр бит. Әллә шуңамы, Үзбәк тә Юрийга карата шактый суынды. Баштарак рус олысын берләштерерлек кенәз рәвешендә аны күрсә, хәзер моңа шиге бик зур иде.

Халык арасында Явыз Күзле[1] кушаматы белән танылган Тверь хакиме Дмитрий исә үч алу теләгеннән бер генә мизгелгә дә ваз кичмәде. Башта энекәше Константиннан барысын да белеште, аннан соң Урдага шымчыларын җибәрә торды. Бу эш еллар буенча сузылса да, Дмитрий өметен өзмәде, акрынлап, әтисенең үлеменә китергән вакыйгалар йомгагын сүтте. Һәм, ниһаять, Дмитрийга да бәхет елмайды. Тверь кенәзлегенең бер кара авылында Порфирий атлы бәндәне эзләп таптылар. Яшь чагында ул юлбасарлыкта йөргән, хәзер картаеп, хәлләре китә башлагач, туган ягына әйләнеп кайткан.

Порфирийның, картайган булса да, зиһене ачык иде. Ул Дмитрий кенәзгә барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Аны Урдада бер төмәнбашы яллавын да, хан җибәргән шымчыны үтерүен дә әйтте. Моннан бигрәк, Көнчәага тоткынлыкта утырган йортны саклаган дружиначыларның язмышы күп нәрсәгә ачыклык кертте. Төмәнбашы әмере белән Порфирий егетләре аларның барысын да берәм-берәм үтереп чыккан. Әмма берсе Көнчәага янына хан җибәргән төмәнбашының кичләрен килеп йөрүен, аны көчләвен күреп торган. Шуны Порфирийга җиткереп калдырган. Көнчәаганың соңгы көнен дә хәтерләгән мәрхүм дружиначы. Ул кичне алар янына ялгызы гына Урда нүкәре килгән, үзен Каугадый чаптары дип таныткан. Көнчәага янында озак тормаган, ул киткәч тә, хан сеңлесенең үле гәүдәсен табып алганнар.

Дмитрий кенәз, Порфирийны сак астында калдырып, баскак Ахмыл янына ашыкты.

– Миңа кичекмәстән бөек хан тарафына барырга кирәк, – диде ул кerә-керешкә үк.

– Ни йомышың бар аңа, кенәз?

– Ханның сеңлесе Көнчәаганың үлеменә бәйле яңа мәгълүматлар ачыкланды, мин аларны Үзбәк ханга үзем җиткерергә тиешмен.

– Буш сүз сөйләмисеңме? Көнчәага – ханның йөрәк ярасы, аны юкка кузгалткан кеше башыннан да колак кагарга мөмкин.

– Юк сүз түгел, Ахмыл бәк. Минем шаһитым да бар.

– Аңладым. Бераз көтәргә туры килер, Сарай Әл-Җәдидтән җавап килгәч тә, хан карарын үзеңә әйтермен.

Бу вакыт Явыз Күзле Дмитрий өчен мәңгелеккә сузылды төсле. Ул, түземсезләнеп, әледән-әле баскак янына боярларын җибәрә торды. Көннәр атналарга, атналар айларга кушылды. Инде ышанычы өзелде дигәндә, Ахмыл баскактан җавап килеп төште – бөек хан Үзбәк Дмитрий кенәзне үзенең башкаласында көтә. Моннан тыш, шундый ук чакыру Мәскәү кенәзе Юрийга да юлланган. Ике дошман яу кырында түгел, хан биләмәләрендә очрашырга тиеш иде.

[1] Явыз Күзле – Грозные Очи.

Дмитрий үзе белән шактый акча алды – ришвәтсез Урдада зур мәсьәләләрне хәл итү бик авыр. Сак астындагы Порфирийны да ияртте. Тегесе, алай да, болай да исән калмаячагын аңлап, үзе белгәннәрне ханга сөйләп бирергә ризалашты. Тверьдә исә хакимлекне вакытлыча энекәше Александрга тапшырды – Юрий кебек үк, Дмитрийның да ир балалары юк иде...

...1325 елда ике кенәз Сарай әл-Җәдидкә юл тотты. Юрийның күңеле тыныч түгел – соңгы вакытта Үзбәк хан аңа карата хәерхаһлыгын югалтты. Бөек кенәз ярлыгын да, аннан тартып алып, Тверь кенәзе Дмитрийга тапшырды. Хәер, моңа Юрий үзе гаепле. Ханга илтеп бирәм дип, Тверьгә салынган ясакны үзенә алды да Мәскәүдә калдырды. Нияте – шул рәвешле Дмитрийны нахакка гаепләү иде. Тик, ни гаҗәп, Дмитрий кенәз Үзбәкнең күңеленә хуш килгән. Шымчылары җиткергәнчә, хан аның белән бик озаклап сөйләшеп утырган. Әтисенең Көнчәага үлемендә гаепле түгеллеген исбатларга тырышып, Юрийга карата хаким күңеленә шик тә салып калдырган, күрәсең. Бер тапкыр, Үзбәк күзенә күренергә куркып, Мәскәү хакиме үзе урынына энекәше Иванны да җибәрде. Картая, ахрысы, Юрий, ханның колагына ятышлы сүзләрне таба алмыймы шунда. Иван да Урдада бик җылы кабул ителгән. Алай гына да түгел – Үзбәк аңа махсус акча янчыгы – кәлитә бүләк иткән. Бик матурлап бизәлгән шул янчыкны, кая барса да, Иван билбавына тагып йөри. Хәзер, әнә, шуңа бәйле кушамат та ябышкан үзенә. Иван Кәлитә дип атый икән аны халык...

Ачы язмышына борчылып, Юрий кенәз Сарай Әл-Җәдидкә килеп җитте. Дмитрий да бирелә икәнлеген әйттеләр. Икесе дә ханның, вакыт табып, үзенә чакыртуын көтәргә кереште.

Тик Дмитрийның түзәр әмәле калмаган иде инде. Чөнки хан айлар буе кабул итми йөдәтергә мөмкин. Шуңа күрә ул, уңлы-суллы ришвәт өләшеп, Тайдула хатын белән күрешү җаен тапты.

Тайдула аны якты чырай белән кабул итте. Бүләкләрен алгач та, табынга чакырды, рус олысындагы хәлләр турында сораштырды.

– Ни йомыш белән хан тарафына килдең, кенәз? – дип сорады ул. Үзенә Үзбәк белән очрашуны тизләтер өчен мөрәҗәгать итәсен чамалый, тик башта Тайдула Дмитрийның ниятен белергә теләде.

– Ханның яраткан сеңлесе Көнчәага-Агафья язмышы хакында бик тә җитди яңалык-хәбәрләрем бар, бөек ханбикә.

Тайдула кызыксынуын яшермәде, аның йөзе җитдиләнде:

– Нindирәк яңалыклар ул, кенәз?

– Анысын мин бары тик ханга гына сөйли алам. Гафу ит, сөекле ханбикә, аннан узып сиңа әйтергә хакым юк, башым бер генә.

– Әтиеңнең гаепсез икәнлеген расламакчы буласың, алайса?

– Әйе, сөекле ханбикә. Синең безнең нәселгә җылы мөнәсәбәтеңне без онытмадык. Михаил кенәзне дә якларга тырышуың билгеле, минем энекәшем Константин да ул чакта үз кешеләре белән синең тарафка сыенып кына исән калдылар. Без сиңа чиксез рәхмәтле. Мин әтиемнең якты истәлеген, җинаять кылуда тапланмаган исемен кайтарырга телим. Янә үзеңнең ярдәмеңнән ташлама, сиңа мәңге догада торырбыз, бөек ханбикә.

Үзе белгәнне зур сер итеп сакларга маташуы өчен Дмитрийга бераз үпкәләсә дә, Тайдула аның сүзләренә күнде.

– Хан белән сөйләшермен. Көт.

– Бөек ханыбыз каршына Юрийдан алданрак керәсе иде. Югыйсә ул, үзенең ялганын сөйләп, падишаһның фикерен икенче якка аударып куярга мөмкин.

– Борчылма. Әлегә исә юлыңда бул.

Озак та үтми, Дмитрийны хан тарафына чакырдылар. Тайдуладан сеңлесе Көнчәага язмышына бәйле хәбәрләр барлыгын белгәч, Үзбәкнең сигез ел дәвамында бәгырендә пыскыган кайгысы яңадан дөрләп кабынды. Шушы вакыт дәвамында ул, Михаилның гаебенә шикләнеп, беренче чиратта, үзен битәрләп яшәде бит. Бәлки, күңеленә тынычлык иңдерерлек вакыйгалар ачыкланыр?

Дмитрийны күргәч, йөрәге дуласа да, ашыкканлыгын күрсәтмәде. Кенәз, гадәттәгечә, бүләкләрен тапшырды, ханга чиксез мактау сүзләрен ирештерде. Үзбәк тә, үз чиратында, Тверьдәге хәлләр, аның тирәсендә кайнашучы дошманнар хакында сораштырган итенде. Тик уенда бөтенләй башка сораулар... Ниһаять, хан түзмәде, үзе сүз башлады:

– Миңа әйтүләренчә, – диде ул, янәшәсендәге Тайдулага күз ташлап, – син минем мәрхүм сеңлем Көнчәага хакынданиндидер мәгълүмат алып килгәнсең. Тыңлап карыйк, мин белгәннәргә өстәп, тагын ни әйтерсең икән.

– Бөек ханым, минем утардагы зинданда Порфирий атлы юлбасар бар. Без аны озак еллар буе эзләп, көч-хәл белән таба алдык. Ул барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде...

– Ни сөйләде?

Дмитрий Порфирийдан ишеткәннәрен түкми-чәчми ханга ирештерде. Һәр сүзе саен ханның да, аның янәшәсендәгеләрнең дә йөзләре карала барды. Көнчәаганы Каугадый көчләгән җиргә җиткәч, Үзбәк, йодрыкларын йомарлап, урыныннан ук сикереп торды.

– Каугадый?! Кайда ул мөртәт?!!

– Бөек ханым, ул Кырымда, төмәнбашы... – дип әйтергә ашыкты калтыранган Исабәк вәзир.

– Хәзер үк аны кулга алыр өчен нүкәрләр җибәрегез! Төмәне каршында коралларын тартып алып, кыякларын салдырсыннар! Сарайга, хөкем итәргә алып килергә! Мондый җинаять өчен бер генә җәза – үлем! Ишеттеңме, Бәдретдин казый?!

– Берсүзсез, бөек ханым, берсүзсез...

– Порфирийны минем хөкемгә тапшыр, Дмитрий кенәз. Аның да башын саклап кала алуы чамалыдыр дип уйлыйм. Тик әлегә ул шаһит рәвешендә кирәк.

– Яхшы, бөек ханым, – диде Дмитрий кенәз, тез чүккән җирдән өметле карашын Үзбәккә күтәреп. Тегесенең кыяфәте куркыныч, күзләре тонган, йөзе чытылган. – Порфирий барысын да белеп бетермидер, әмма бу вакыйгаларга Юрий кенәзнең катнашы бардыр шикелле.

– Анысын Каугадыйны алып кайткач ачыкларбыз. Кызганмыйча җәзаларга үзен, теле чишелсен, кабахәтнең! Исабәк вәзир, әгәр Каугадый качып котыла калса, аның урынына син җавап тотарсың. Аңладыңмы?!

– Төшендем, галиҗәнап ханым, төшендем...

– Ә хәзер барыгыз да күземнән югалыгыз!

Хан яныннан чыкканда, Дмитрийның кәефе кырылган иде. Ул төп максатына – Мәскәү кенәзе Юрийны хөкемгә тартуга ирешә алмады. Ни кызганыч, Порфирий Юрий хакында бөтенләй хәбәрдар түгел, алай боргаласа да, тегеләй итсә дә, аның исемен ишетмәгәнлеген әйтте. Юлбасарның бар белгәне Каугадыйга бәйле иде.

Тормышның гаделсезлегенә ачуы чыккан Дмитрий, хан нукәрләре озатуында, үзенең утарына юл тотты. Анда ул Порфирийны Урда хөкеменә тапшырды. Күрәсең, озакка сузылган тикшеренүләре, эзләнүләре бушка киткән. Хан Көнчәаганы Михаил кенәз үтермәгәнлеккә, ниһаять, инанды. Әмма этисен кире кайтарып булмый инде. Михаилны Урда хаиннары белән бергә типкәләп, теге дөньяга озаткан Юрий исә янәдән җәзасыз калды... Тик, шулай да, бер өмете бар иде Дмитрийның. Үзенең җанын саклап калырга омтылган Каугадый бөтен гаепне Юрийга сыларга мөмкин. Хан бу мәсьәләдә соңгы сүзен әйтмәде бит...

Икенче көнне Дмитрий кенәз, иртүк торып, чиркәүгә җыенды. Христианнар өчен бәйрәм – Изге Мәрьям-Ана туган көн иде. Иртәгә исә нәселләре өчен мәңгелеккә матәмгә әверелгәне – җиде ел элек Урдада Михаил кенәзне үтерделәр.

Дмитрий Урдада озак торгач, аңа өстәмә акча алып, энекәше Александр да бире килгән иде. Алар, берничә дружиначы һәм боярлары озатуында, рус олысы урамындагы чиркәүгә таба киттеләр.

Килеп җитәрәк Дмитрий кенәз үзләренә таба якынлашучы икенче бер төркемне шәйләде. Аның башында Мәскәү кенәзе Юрий килә иде. Картайган, бөкшәйгән, тик йөзендә барыбер мәкерле елмаю. Ул да Дмитрийны таныды, салмак кына атлап, Тверь кенәзенә ымлап, боярларына нидер сөйләргә кереште, кычкырып көлеп җибәрде.

Моны күргән Дмитрийның ачуы кабарды. Ул бишмәте астына яшерелгән хәнҗәрен капшады.

– Нәрсәдән шулай кинәт кәефең күтәрелде, Юрий кенәз?! – дип кычкырды Дмитрий, тынычлыгын саклап калырга тырышып.

– Чит җирдә кардәшеңне күрү кем өчен дә шатлыктыр, Дмитрий кенәз.

– Синең өчен мин бөек кенәз булам, әллә ярлыгыңны югалттыңмы?!

– Бөекләрне күп күрдек инде без... Исән килеш тә, үлгәннәрен дә.

– Әйтәм, бияләй кигәнсең, кулларыңа сыланган канны юып бетерә алмыйсыңдыр, кешегә күрсәтергә ояласың, димәк.

– Канга кагылырга туры килде, анысы хак. Ләкин гаепсезләргә тимәдем бит мин, намусым чиста.

– Алай ук чиста микән, Юрий? Хан синең әшнәң Каугадыйны кулга алырга боерды, ул хөкем каршына басачак. Бергә майтарган эшләрегез турында казыйга сөйләп бирер, аннан соң кемнең намуслы икәнлеген күрербез...

Юрийның йөзендәге елмаю шунда ук юкка чыкты.

– Ни сөйлисең син, көчек?! – дип җикеренде ул һәм Дмитрийга таба килә башлады.

– Мине көчек дип атадыңмы?! Тезләнеп, гафу үтен!

– Тезләнде, ди, тот капчыгыңны! Нәселең белән корытырмын!

– Синеке күптән корыды инде, мүкләк сыер!

Бу кадәр мыскыллауга түзми, Юрий, ике куллап, Дмитрийның муенынаябышты, аны буарга кереште. Тик Тверь кенәзе яшьрәк тә, көчлерәк тә иде. Ул, Юрийның кулларын каерып алып, төртеп җибәрде. Тегесе аркасы белән җиргә барып төште. Җәһәт кенә сикереп торып басарга мөмкинлек бирмичә, Дмитрий бер аягын Юрийның бугазына терәде.

– Хан кияве белән булышасың, маңка малай, – дип ысылдады тыны кысылган Юрий. – Әтиеңнең башына җиткәнне, сине генә хәл итәрлек кодрәтем бар әле!

Дмитрий хәнҗәрен чыгарды.

– Минем әтинең нахакка үтерелгәнен Үзбәк хан белә инде. Үзең аның янына барып, барысын да сөйлисеңме, әллә Каугадый кайтканны көтәсеңме?

Бар көчен җыеп, Юрий Дмитрий кенәзнең битенә төкерде. Аннан ни кылганын Тверь кенәзе үзе дә аңышмый калды. Җәһәт кенә хәнҗәрен югары күтәреп, Юрийның нәкъ йөрәгенә кадады. Аягын вакытында алып өлгерде – Мәскәү кенәзенең авызыннан шаулап кан китте. Берничә тапкыр тартышып алганнан соң, Юрий җан бирде. Дмитрий исә, ашыкмый гына хәнҗәрен сөртеп, бишмәте астына яшерде. Аларның үзара тарткалашу тамашасын карарга шактый кеше җыелган, барысы да сүзсез калган. Юрийга ияреп килгән боярлар баш киемнәрен салып, ни булганын әле аңышып бетмичә, кан эчендә яткан хакимнәренә текәлгәннәр. Урам башыннан исә атка атланган нүкәрләр ашыга – күрәсең, канкоеш турындагы хәбәр шәһәр сакчыларына ирештерелгән дә инде.

– Чиркәүгә керик, бәйрәмгә соңга калабыз, – диде, берни булмагандай, Дмитрий һәм ишеккә атлады.

Юрийның үлеме хакында хәбәр хансарайга яшен тизлеге белән барып житте. Шәһәр эчендә тәртип саклауга куелган нүкәр Исабәк вәзиргә барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде, тегесе исә Үзбәк янына ашыкты.

– Бәла, бөек ханым! – диде ул, хәвефле кыяфәт белән. Хан сискәнеп үк китте.

– Ни булды, Исабәк, ник йөзең качкан?!

– Башкалабызның урыслар яши торган почмагындагы чиркәү каршында канкоеш килеп чыккан. Тверь кенәзе Дмитрий Юрий кенәзне суеп үтергән...

Үзбәк урыныннан сикереп торды.

– Суеп?! Минем башкаламда адәм үтерүгә юл куелдымы?! Станым урнашкан җиргә кан агызылдымы?! Мөртәт Дмитрий кайда?!

– Ул чиркәүдә, бөек ханым...

– Хәзер үк нүкәрләр җибәреп, кулга алырга! Зинданга ташлагыз бәдбәхетне!

Бераз тынычлангач, Үзбәк хан үз тарафына баш казыйны, имамнарны чакыртты, үтереш шаһиты булган нүкәрне дәштереп, чиркәү каршындагы талаш хакында төпченеп сораштырды. Нүкәрне озаткач, хаким баш казый Бәдретдингә мөрәҗәгать итте:

– Ни әйтерсең, мөхтәрәм Бәдретдин хәзрәт? Бу вакыйгада сиңа барысы да аермачыкмы, әллә инде өстәмә тикшерү үткәрергә кирәкме?

– Галиҗәнап ханым! Әлеге вакыйга, һичшиксез, бик авыр җинаять буларак бәяләнә. Ул күпсанлы шаһитлар каршында кылынган. Дмитрий кенәз бөек хан биләмәләрендә, бигрәк тә аның станы яисә хансарае урнашкан җирдә кан коярга ярамаганлыгын белә. Шуңа да карамастан, ул әлеге авыр гамәлне кылган, синең кауннарыңны вәхшиләрчә бозган. Бу кыргыйлыкның тагын бер, аеруча да авыр ягы бар. Юрий кенәз – синең киявең, хан нәселенә мөнәсәбәтле бәндә иде. Аның җанын алу – синең чиксез хакимлегеңә кул сузу дигәнне аңлата. Боларның барчасын бергә кушсаң, Дмитрий кенәзнең гаебе минем өчен бик аермачык күренә. Минемчә, ул, әгәр син расласаң, үлем җәзасына лаек.

Үзбәк хан тирән уйга калды. Яман Күзле Дмитрийны үзенчә хөрмәт итә иде ул. Аның кызу канлылыгы белән бергә ихласлылыгы да бар. Әтисенең Көнчәага үлемендә гаебе булмавын раслаганда, кенәз елап ук җибәрде. Тверьны күтәреп, көчәйтеп, Үзбәк хан аны көнбатыштан янаган дошманнарга каршы ныклы саклану кирмәне итәргә теләгән иде. Чакматаштай Яман Күзле Дмитрий теләсә нинди яуга каршы чыгарлык сугышчы, гаскәрне оештыра белә. Һәм менә ул, үзенең уйланмаган гамәле белән, Үзбәкнең рус олысына багланган тагын бер өметен чәлпәрәмә китерде.

– Бәдретдин казый әйткәннәргә берәрегез нәрсә дә булса өсти аламы? – дип сорады Үзбәк хан.

– Син – Аллаһы Тәгаләнең җирдәге вәкиле, бөек ханым! – Сүзгә Борһанетдин имам да кушылырга булды. – Бары тик син генә җирдәге хөкем карарларын раслый аласың. Хөкемсез кеше үтерү болганышларга китерәчәк. Бәдретдин казый хаклы фикергә килгән дип уйлыйм...

Үзбәк хан уйланып торды, аннан соң Исабәк вәзиргә борылды.

– Ханның карарын тыңлагыз. Баш казый Бәдретдиннең әйткәнен тыңлаганнан соң, мин аның тәкъдиме белән килештем. Әмма җәза үтәүне әлегә кичектереп торыгыз. Дмитрий кенәзне зинданга ташлагыз. Юрий кенәзнең мәетен, христиан йолалары нигезендә җирләр өчен Мәскәүгә җибәрегез. Минем тарафка Тверьдән Дмитрийның энекәше Александрны, Мәскәүдән Юрийның бертуганы Иванны чакыртыгыз. Хан үз сүзен әйтте.

Зинданда иза чиккән Явыз Күзле Дмитрий ханның үзенә карата мәрхәмәтле булуына өметен өзмәде. Үзбәк аңа һәрвакыт җылы мөнәсәбәттә иде. Күрешкән вакытта кенәзнең моң-зарларын дикъкать белән тыңлады, хәленә керә белде. Үзе дә яшьли әтисен югалткан Урда хакиме аны аңлый, аталарча мөнәсәбәттә төсле тоелды. Юкка гына бөек кенәзлек ярлыгын Дмитрийга тапшырмагандыр бит. Тверь кенәзлеге ышанычлы кеше, курку белмәс гаскәр башы, рус олысын көнбатыштагы дошманнардан сакларлык баһадирдай ир кулында икәнлеген хан яхшы белә. Үзенә үлем җәзасы чыгарылуын ишеткәч тә, күңеле төште. Әмма хаиннар аның янына килергә ашыкмады. Бу да ышаныч өстәде кебек. Икенче яктан, Дмитрийның әтисе дә шулай озак интеккән, хан, бер карарга килеп тә, гомерен өзгән мизгелне шактый сузган. Биредә, бәлки, үзенә күрә бер сынау, кешене иза чиктерү теләге дә ятадыр. Үлемеңне көтеп яшәү үлемнең үзеннән дә авыррак дигән иде бит әтисе...

## 2

Ул арада хан нүкәрләре Кырымнан Каугадыйны китерделәр. Кыйналган, ябыккан, пычракка баткан төмәнбашы бик мескен кыяфәттә калган иде.

Урда башкаласының үзәк мәйданында күтәртмә корылды. Каугадыйны алып килеп, чак кына җирдән күтәреп, ике кулын ике якка каерып, учларын тимер казыклар белән агачка кадакладылар. Аякларын ныклы баулар белән төп баганага беркеттеләр. Кайчандыр көче ташып торган Каугадый кечерәеп калган иде, кулларын казыклар тишеп кергәндә, ул аңын җуйды.

Хөкем кылынасы мәйданга халык җыелды. Озакламый, ныклы сак астында, Үзбәк хан үзе дә күренде. Аның өчен күтәртмәгә нәкъ каршы якта кечкенә купшы чатыр корылган, ул шундагы тәхетендә урын алды. Хөкемне күзәтергә әвнухлар озатуында уллары Тәнибәк белән Җәнибәк тә китертелде. Хан тирәсендә хатын-кыз заты күренмәде.

Дөңгерләр кагарга керештеләр. Җәмәгать тынып калды. Барысы да тынычлангач, күтәртмәгә ханның сөрәнчесе менде.

– Урда халкы, хан әмерен тыңла! – Сөрәнченең тавышы, мәйданны уратып алган мәрмәр диварларга бәрелеп, берничә катлы кайтаваз булып кире әйләнеп кайта иде. – Солтан Гыйяс Әд-Дин Мөхәммәд Үзбәк хан, җир йөзендә Аллаһының әмерләрен үтәүче, гаделләрнең гаделе, зирәкләрнең зирәге, бөекләрнең бөеге, Урда дәүләтенең баш казые Бәдретдин хәзрәт тикшерүеннән соң чыгарылган хөкем карарын раслап, төмәнбашы Каугадыйны үлем җәзасына тартырга әмер бирә!

Сөрәнче усал тавышы белән Каугадый кылган җинаятьләрне санап чыгарга кереште. Һәрбер гаепләүдән соң моны дәлилләгән шаһитларның исемнәре аталды. Иң соңгы җөмлә алдыннан сөрәнче бер мизгелгә тынып калды, кысык күзләрен ханга төбәде. Тегесе, чак кына кулын күтәреп, дәвам итәргә боерды. Сөрәнче тамагын кырды.

– Төмәнбашы Каугадый кылган җинаятьләрнең иң куркынычы һәм авыры – бөек ханыбызның гаилә әгъзасы, турыдан-туры туганы Көнчәаганы берничә мәртәбә көчләү һәм агулап үтерү! Моны казыйларга рус олысыннан китерелгән Порфирий атлы юлбасар раслады!

Җәмәгать «аһ!» итте – күбесе Көнчәаганың мондый язмышка дучар ителгәнлеген белми иде, ә инде ханның сеңлесен аның нүкәре көчләү бөтенләй дә кыргыйлык буларак кабул ителде.

Күтәртмәгә җәллад менде. Кулында – кыска гына үткен хәнҗәр. Ул, Каугадый янәшәсенә килеп, ханга таба борылды һәм тез чүкте.

Әллә Каугадый әҗәле якынлашканын сизде, ул күзләрен ачты. Бер мәлгә, кая эләккәнен оныткан төсле, тирә-якны күзләде, аннан соң нәкъ каршысында утырган ханны абайлады.

– Бөек ханым, гафу ит мине, синең каршыңда тез чүгә алмыйм, – дип гырылдады ул, иреннәренә ябышып кипкән канны тел очы белән ялап алып. – Мин Көнчәаганы ихлас күңелдән яраттым. Мәхәббәт хакына кылынган гамәл җинаять түгел...

Тик хан аның сүзләрен ишетмәгән төсле иде. Ул торып басты, җәлладка кыска гына әмер бирде. Тегесе, җәһәт кенә килеп, Каугадыйның күкрәген хәнҗәре белән ярып җибәрде. Шаулап кан бәреп чыкты. Хәнҗәрен

билбавына кыстырып, җәллад уң кулы белән Каугадыйның күкрәгеннән йөрәген умырып алды һәм ханның аяк астына ташлады. Лачкылдап килеп төшкән ит кисәге, әйтерсең, җирдә килеш тә тибәргә маташты да тынып калды. Куркуыннан кычкырып елап җибәргән Җанибәкне әвнухлар тизрәк алып китү ягын карады. Тәнибәк исә, киресенчә, бу тамашаны бик кызыксынып күзәтте, әтисенә ияреп, атлар ягына барганда да, муенын каера-каера, Каугадыйның күкрәгендәге ямьсез яраны яхшылабрак өйрәнеп калырга маташты...

Улларының бу канлы вакыйгага мөнәсәбәтен күз уңыннан ычкындырмаган Үзбәк хан, кичке якта Тайдула белән очрашкач та, хатынына әйтергә булды.

– Ике улыбыз ике төрле кеше, Тайдула, – диде ул, назлы уеннан алҗып, йомшак юлбарыс тиресе астында хатынының шәрә тәнен үзенә кысып. – Тәнибәк канкоешка артык кызыксынып караса, Җәнибәкнең коты чыкты, кычкырып елап ук җибәрде.

– Икесе дә сабый гына бит әле, бөек ханым. Син аларга бераз йомшаграк мөнәсәбәттә була күр. Берсе зуррак – аның өчен ул тамаша кызык тоелгандыр, икенчесе артык кечкенә, ул әле берни дә аңламый...

– Алар сабый түгел, ханзадәләр. Хәзердән үк ир-атлар кырыслыгына күнегеп үсәргә тиеш. Ханлыгымны ышанычлы кулларда калдырып китәр өчен син аларга төпле тәрбия бирергә бурычлы.

– Ләкин, бөек ханым, аларга кадәр Тимербәк бар бит...

– Ханлыгымда өч улыма да урын табылыр, Тайдула, мин сиңа моны бер тапкыр әйткән идем инде. Улларым арасында канкоешка беркайчан да фатыйхамны бирмәячәкмен. Тәнибәкнең кансызлыгы борчуга салды. Җәнибәкнең җебеклеге дә шул ук дәрәҗәдә куркыныч. Игътибарлырак бул, Тайдула, аларның тәрбиясе, беренче чиратта, синең өстә...

Ике улының ике төрле дөнья иканлеген Тайдула бик яхшы белә иде. Олысы Тәнибәк артык киребеткән, үзсүзле булып үсә. Аның һәрбер адымында, һәрбер сүзендә Үзбәк чалымнары ярылып ята. Кырыслык ягыннан да кимен куймый – берничә мәртәбә этләрне кыерсыткан вакытта тәрбиячеләре эләктереп алгалады. Корал белән маташырга ярата, мөгаллимнәренә дә баш бирмәс. Җанибәк исә Тайдула ягына киткән төсле. Ул шаян, күндәм, әйткән сүзне тыңлый, хәзердән үк хәйләкәрлеге дә күренә. Әнисенә карата мәхәббәте дә көчлерәк. Тик бүген Тайдуланы алар артык борчымый. Балалары бик яшь, Үзбәкнең тәхеттәге урыны нык. Ә менә Тимербәк...

Тимербәк, Котлы Тимер янында Хәрәземдә дип саналса да, Урда гаскәре белән хәрби сәфәрләрдән кайтып керми. Хан аны әле Балкан ярымутравына, әле полякларга һәм литвалыларга каршы сугышларга җибәреп тора. Урданың үз эчендә чыккан вак-төяк тарткалашларны хәл итәргә дә Тимербәк җәлеп ителә. Аның, акрынлап, гаскәр һәм халык арасында дәрәҗәсе үсә бара. Даны озакламый ханны да узып китәчәк дип, әледән-әле Үзбәкнең йөрәгенә тоз сибеп торса да, Тайдуланың бу мәсьәләдә сүзе үтми. Урда хакиме балалары арасында канкоешка юл куймыйм дип ант эчкән, һәм шул вәгъдәсеннән бер генә дә адым чигенергә җыенмый. Ханны котыртып кына, Тимербәкне җиңәрлек түгел, моның өчен башка чаралар эзләргә кирәклеген Тайдула инде төшенгән иде...

### 3

Язмышы хәл ителүне көтеп, Дмитрий кенәз елга якын зинданда ятты. Ниһаять, Үзбәк хан хөкем карарын раслады – 1326 елның көзендә җәллад кылычы аның башын чабып өзде.

Урда хакиме исә бу вакытка кемнең рус олысында бөек кенәз буласын тәмам хәл итеп бетергән иде. Күңеленә тыныч холыклы, сүзендә тора белүче Мәскәүдәге Иван Кәлитә күбрәк якын торса да, ул янә Тверь ягын сайлады. Тверь – рус олысының көнбатыш чикләренә терәлеп үк тора. Ул тарафтан куркыныч янаучы көчләр бик күп. Шуңа күрә үзәк хакимиятне анда билгеләп, шундагы кенәзгә зур мөмкинлекләр ачу зарур. Дошман явы килә калса, Тверь кенәзе бер сызгыруда зур гаскәр туплый алырга тиеш. Шуңа да Үзбәк хан рус олысында бөек кенәзлек вазифасын мәрхүм Дмитрийның бертуган энесе Александрга тапшырырга булды.

– Рус олысында хакимлегең чиксез, Александр кенәз, – диде Үзбәк, әлеге яңалыкны ишеткән егетнең үз каршысына тезләнүен канәгатьлек белән күзәтеп. – Әмма бу мөмкинлекне кулыңнан ычкындырма. Әтиең, бертуган абыең ялгышларын кабатлый күрмә. Мәскәү кенәзе Иван белән ызгышлар оештырып, вакыт уздырма. Минем өчен рус олысында тынычлык урнашу бик мөһим. Ул җирләргәябырылырга торган козгыннар читтә дә җитәрлек.

Хан кабул итү бүлмәсенә җыелган имамнарны, аксөякләрне күздән кичерде. Карашы шәхси кәшәгәсе җитәкчесе, үз нәселенә караган төмәнбашы Чолханда[2] тукталды. Яшь, нык егет аңа үзенең тугрылыгы белән бигрәк тә ошый. Менә хәзер дә, әмер көтеп, ханына туп-туры карап тора. Карашы сабыр, теләсә нинди боерыкны үтәргә әзер ул. Шуңа аны үз янәшәсендә тота да инде Үзбәк хан. Тик егеткә үсәргә, тәҗрибә тупларга кирәк. Һаман да хансарай тирәсендә генә ятып, чын сугышның ни икәнлеген белми дә калыр.

– Дошманнар синең янәшәңдә зур көч барлыгын белеп торырга тиеш, Александр кенәз, – диде Үзбәк хан, күптән уйлап йөргән фикерен үз-үзенә раслап. – Шуңа күрә синең белән бергә минем гаскәремнән бер мең нүкәр җибәрәм. Аларны Тверьдә урнаштыр. Андый-мондый бәла килә калса, ул яугирләр күз ачып йомганчы беренче сафларга басар. Ул меңнең башлыгы итеп, Чолханны билгелим.

Чолхан шунда ук урыныннан сикереп торды, тәхет каршына йөгереп барып, аптыравыннан ни эшләргә белми торган Александр кенәз янәшәсендә тез чүкте.

– Олы ышаныч белдерүең өчен рәхмәтем чиксез сиңа, бөек ханым! Нүкәрең Чолхан, һичшиксез, синең өметеңне аклар!

– Шикләнмим, Чолхан. Бүгенгә тәмам, барыгыз да китә аласыз. Син, Чолхан, калып тор. – Бүлмәдә икәүдән-икәү калгач, Үзбәк хан нүкәрне аякка бастырды. – Башыңны җуйма, Чолхан. Рус олысында үзеңне тәртипле тот. Алар сине хәмер, җарияләр белән котыртыр. Синең биредә яман гадәтләр белән мавыгуыңны ишетмәдем, анда да тәртәдән чыга күрмә. Каугадый, биредән киткәнче, бик шәп яугир иде. Әмма, чит җирләргә баргач, бөтенләй бозылды. Моның ни белән тәмамлануы сиңа яхшы мәгълүм, аны җәзалап үтергәндә, син уң кулымда тордың.

[2] Чолхан – рус елъязмаларында Шевкал исеме белән дә атап йөртелә.

– Аңладым, бөек ханым!

– Сине рус олысына җибәрүем юкка түгел. Анда сугыш һөнәренә өйрәнерсең, чын бәрелешләрнең ни икәнлеген үз күзең белән күрерсең, орышларда катнашырсың. Мин синең тәҗрибә туплап, кире кайтуыңны көтәм. Хан янәшәсендә синдәй ихлас күңелле, тугрылыклы нүкәрләр бармак белән генә санарлык...

– Синең сүзләрең миңа олы бурыч йөкли, галиҗәнап ханым! Сиңа һәм нәселебезгә тел-теш тидермәмен!

– Ак юл үзеңә, сәргаскәрем Чолхан!

## 4

Бөек кенәзлек ярлыгы Тверьдәге Александрга тапшырылуны Мәскәү кенәзе Иван Кәлитә бик авыр кичерде. Үзбәк хан аңа илтифат күрсәтер дип өметләнсә дә, барып чыкмады. Урдадан кайткан төшенә Иванны тагын бер яман хәбәр көтә иде – митрополит Пётр якты дөньядан китеп барган. Аның кабере каршына басып, дин әһеле белән озын-озак сөйләшүләрен исенә төшерде.

Митрополит бик гыйлемле кеше иде, шул ук вакытта ул, башаяк дингә кереп китми, дөньяви хәлләрдән дә хәбәрдар, тирә-юньдә нинди вакыйгалар булып ятуын игътибар белән күзәтә, аларга үзенең зирәк бәясен дә бирә белә.

Пётрның күңеле соңгы елларда күбрәк Мәскәүгә тартылды. Биредә тынычрак, тәхет тирәсендәге гауга-тарткалашлар да азрак кебек. Мәскәүдә Пётр митрополитка рәхәт иде. Иванны да бер күрүдән үз итте, ул килгәч, вакытын кызганмый, гәпләшеп утырырга яратты. Ул сөйләшүләр Иванның әле дә хәтереннән чыкмый. Алар икесе дә туган җирләре өчен җан ачысы белән борчылучы кешеләр, сүзләре иртәме-соңмы Урда тарафыннан изелүгә барып тоташа.

– Дошман мәңге көчле була алмый, Иван кенәз, – диде бер тапкыр, ачылып китеп, Пётр митрополит. – Хәзерге хан, берсүзсез, бик кодрәтле. Дәүләтне ул учында ныклап тотып тора, безнең якларга да игътибары җитәрлек. Ләкин, йомарланган кулдан барыбер ком бөртекләре коелган төсле, аның тирәсендә дә учына сыймаган кешеләр бар. Мин аңа бик якын торган православ адәмнәрен беләм, үз күзләрем белән күреп кайттым. Алар безнең кавемне хәлләреннән килгәнчә якларга тырыша. Ә инде ханның тәхетенә кызыгучылар бигрәк тә күп.

– Хан көчле, дисең бит, изге атакай...

– Усал хакимне һәрвакыт юаш бәндә алмаштыра. Монысы табигать кануннары. Беркем дә, шул исәптән Үзбәк хан да бу җиргә мәңге яшәргә килмәгән. Сиңа көтә белергә, сабыр булырга кирәк. Вакыты җиткәч, туган җиреңне залимнәрдән азат итәргә әзер тор.

– Ул көн килмәс шикелле...

– Күңел төшенкелеге – бик зур гөнаһ, балам. Барысы да бер мизгел эчендә хәл ителеп куймас, әлбәттә. Ләкин син хан күңеленә хуш килгәнсең икән, моны кулдан ычкындырма. Ул кушканны үтәп, үзеңә кирәген эшләргә онытма.

– Нәрсәдән башлыйсы соң, изге атакай?!

– Урдага ясакны вакытында түләсәң, ул яу йөрми. Урда беркайчан да сәбәпсез һөҗүм итми. Шуңа күрә, беренче чиратта, үз җирләреңдә тынычлыкка ирешү мөһим. Халкыбыз ясагын түләсен, әмма көч җыйсын, ныгысын. Шыпырт кына хәрби һөнәрләргә өйрәтү дә зыян итмәс.

– Безнең җирләрдә, кая карама – баскаклар кукраеп тора шул...

– Беләм, балам, беләм. Алар бик оста халык, ул баскак шымчы да, хисапчы да, илче дә. Баскакны үтерергә ярамый – шунда ук яу белән килеп, шәһәр-авылларыңны тар-мар итәрләр, бер үтерелгән мөртәт урынына ике явыз килеп утырыр. Ришвәт белән дә сатып алып булмый аларны...

– Беләм, изге атакай. Күпме ришвәт бирсәң дә, беркайчан да синең якка аумый алар, акчасын ала, тик үзенекен эшли бирә.

– Шулай. Чөнки аларда ришвәт төшенчәсе юк. Алар өчен бу табигый хәл, бүләк мәгънәсендә. Бүләктән баш тартырга ярамый. Әмма бүләк алу аны биргән кешегә сатылуны да аңлатмый. Ханның үзенә дә олау-олау затлы әйберләр ташыйсыз, тик аңа карап кына, ул бер дә безнең кенәзлекләргә карата йомшамый...

– Нишләргә соң, изге атакай?! Бу сихерләнгән бoжра мәңге бетмәс төсле...

– Баскакларның файдасыз икәнлегенә ханны инандырырга кирәк, балам. Ул безнең җиребезне алардан үзе арындырсын. Аннан соң ашыкмый гына тормышны җайларга була. Әлегә явыз хан артык көчле – аның ачуын чыгармасаң, ясагыңны мулдан түләсәң, синдә кайгысы булмас.

– Явызлыкка каршы берләшеп кенә каршы торырга мөмкиндер, изге атакай...

– Анысы хак. Үзебезнең православ кешеләре арасында бердәмлек булмау да ханга көч өсти. Безнең кенәзләр үзара тик сугышып яталар шунда. Ханга моннан бернинди зыян юк. Ләкин авырлык-сынаулар мәңгелеккә килми, балам. Безнең җирләрне берләштерүче дә табылыр, анысына иманым камил, шуны сорап, көн саен Аллага ялварам...

Иван, митрополит Пётр кабере каршына баскан көе тәмам хатирәләренә чумып изрәгән иде, «Кенәз!» дип кычкырган тавышка сискәнеп китте.

Аңа таба атлы дружиначылары ашыга, иң алда – Мәскәү воеводасы Димитрий.

– Ни булды, Димитрий, янгын чыктымы әллә?! – дип, Иван як-ягына каранды. Тик чалт аяз күктә бернинди төтен әсәре дә күренмәде.

– Күпкә яманрак хәлләр булды, Иван кенәз! – Воевода, атыннан сикереп төшеп, уң кулын күкрәгенә куйган көе чак кына башын иде. – Әле генә Тверь тарафыннан бер төркем Урда нүкәрләре килде. Араларында яралылар да шактый. Тверь халкы Чолхан төмәненә каршы баш күтәргән, аларга Александр кенәз дә кушылган. Хан илчесенең шактый яугирләрен кырып-суеп ташлаганнар, бер өлеше генә качып котыла алган. Хәзер алар Ахмыл баскак утарына таба юл алды...

Көтелмәгән бу хәбәрдән Иван эсселе-суыклы булып китте, чукынып куйды.

– Чолхан да биредәме?

– Хан сәргаскәрен сакчылары белән бергә Александр кенәз утарына бикләп, ут төртеп яндырганнар дип сөйлиләр...

– Кичекмәстән кирмәнгә, боярларны җыйсыннар, киңәш тотыйк! Мондый гамәлләрнең арты хәерле булмас, Чолхан гади илче генә түгел, Үзбәк ханның якын туганы! Урда хакиме аның үлемен кичермәс!

Озакламый Иван кенәз тарафына боярлар җыелды, воевода белән чиркәү әһелләре дә биредә иде. Димитрий воевода үзе белгәннәрне бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Ул Тверь янәшәсендәге канкоешны тасвирлый барган саен бүлмәдәгеләр: «Кара инде син аны?! Кирәк бит, ә?!» дип, тирән уйга чумып, тел шартлатып утырдылар.

– Ни әйтерсез, боярлар? – Иван иңенә элengән кәлитәсен рәтләп куйды, хан бүләген ул, әйтерсең, йокларга ятканда да салмый иде.

Сүзне Афанасий атлы бояр алды:

– Әгәр Тверь халкы Урда нүкәрләренә каршы баш күтәргән икән, аларны бер дә гаепләрлек түгел. Явызлыклары һәммәбезгә дә мәгълүм. Үзебездәге баскакларны да тар-мар итсәк, ялгышмабыз кебек. – Афанасий сүзләрен уйлап, курка-курка әйтте. Фикерен җиткергәч тә, яклаучылар эзләп, бүлмәдәгеләрне күзләде, тик башкалар идәнгә караган килеш утыра бирделәр, беркем дә аны хупламады.

– Сүзеңдә хаклык бар шикелле, Афанасий бояр, әмма хәзер без дә аларга кул күтәрсәк, хан гаскәре, Тверь белән берочтан, Мәскәүне дә җир белән тигезләп китәчәк. Мин Үзбәк ханның холкын беләм, ул бик усал һәм үчле кеше.

Боярлар кенәз әйткәнгә каршы дәшмәде.

– Димитрий воевода, без синең белән Ахмыл баскак янына барыйк. Үзебезнең Тверь фетнәсенә катнашыбыз юклыгын исбатлап, ант эчик. Баскакның утарын ныклы сак астына алырга кирәк, безнең халык та, Тверь хәлләрен ишетеп, башын югалта күрмәсен. Ялгыш гамәлләр кылып, булганыннан да колак кагарга мөмкин. Тыныч кына хан сүзен көтик, Чолхан үлеме өчен бөтен рус олысын юкка чыгармас дип өметләник...

Ахмыл баскак утарына җитәрәк үк аларны Урда нүкәрләре каршылады. Карашлары усал, нәфрәт чәчрәп тора, берничә дружиначы озатуындагы кенәз белән воеводаны як-яктан әйләндереп алдылар.

– Ни йомыш белән?! – дип сорады бер нүкәр.

– Ахмыл бәк янына, киңәш тотар өчен килдек.

– Сугышчыларыгызны биредә калдырыгыз. Ахмыл бәк янына бары тик кенәз генә керә ала, – диде тегесе.

Воевода белән дружиначыларны калдырып, Иван кенәз ары китте. Капка төбендә аның барлык коралларын алдылар. Иңенә аскан кәлитәсенә дә сузылганнар иде дә, Мәскәү хакиме: «Бу – бөек хан бүләге», – дигәч, анысына тимәделәр, бары тик букчаны ачтырып, эчендә куркыныч корал юклыгына гына инандылар.

Ахмыл баскак утарында күптән күрелмәгән җанлану сизелде. Гадәттә, рус җирләре өстенә Урдадан яу килә калса, алар шушы халәткә керә иде. Эченнән генә Тверь кенәзенең ахмаклыгын тиргәп, Алладан үзләренә яклау сорап, Иван Кәлитә Ахмыл баскак йортының бусагасыннан атлады.

Ахмыл аны түрдә утырган килеш, бик салкын кыяфәт белән каршылады. Кенәз, уң кулын түшенә куеп исәнләшкәч тә, чак кына баш кагып сәламен кабул итте.

– Иван кенәз, нинди хәбәр алып килдең? – диде ул, чал төшә башлаган куе кашларын җыерып.

– Мәскәү кенәзлегенең Урдага тугрылыклы хезмәт итәчәгенә янә инандырырга дип, каршыңа басуым, мөхтәрәм Ахмыл бәк.

– Тверьдәге Александр да синең төсле сайраган иде дә, әнә, ни килеп чыккан бит...

– Мәскәүләр алардан нык аерылып тора, Ахмыл бәк. Моны без еллар буе раслап киләбез.

Ахмыл бәк чак кына йомшады төсле. Дөресен әйткәндә, Тверьдәге вакыйгалар хакында ишеткәч, үзенең дә астына су кергән иде. Котырынган халык биредә дә баскакка ябырылырга мөмкин бит. Җитмәсә, тегендә ханның туганын ботарлаганнар, ә Ахмыл исә аның белән чагыштырганда кем инде?

– Кирәк икән, мин сине сакларга үземнең дружинаны бирә алам, Ахмыл бәк, – диде Иван кенәз, баскакның уйларын укыган төсле.

– Кирәкмәс. Минем биредә нүкәрләрем җитәрлек. Дружиначыларыңны әзерлектә тот, ләкин минем утар тирәсендә эзләре дә булмасын. Бер генә сугышчыны күрсәм дә, моны фетнә дип кабул итәчәкмен.

– Аңладым, Ахмыл бәк. Бер генә үтенечем бар – Мәскәүнең Тверь вакыйгаларында гаебе юклыгын бөек ханга җиткерсәң иде. Әгәр рус олысына яу килсә, ул безне читләтеп үтүен сорыйм. Моның өчен сиңа әҗере мулдан булыр.

Ахмыл баскак авыр сулап куйды.

– Мин бөек ханыбыз әмереннән чыга торган кеше түгел. Ул ни әйтсә, шул булыр. Ләкин, җае чыкса, сине яклап, һичшиксез, сүз әйтермен аңа. Галиҗәнап хакимебезгә кайгылы хәбәрне җиткерергә тиешле чапкыннар бүген генә юлга чыкты. Мәгълүм ки, Чолхан сәргаскәр сөекле ханыбызның якын туганы һәм ышанычлы бәндәсе иде. Аның үлеме хакында ишеткәч, мәгърур хан нинди фикергә килүен күз алдына да китерүе кыен... Ә хәзер үзеңә кайт та әмерләремне көт. Язмаган булмас, Иван кенәз.

## 5

Хан чакыруын озак көтәргә туры килмәде. Ахмыл баскак, Урда чапкынынннан хәбәр алып, аны Мәскәү хакименә җиткерде. Иван кенәзгә кичекмәстән Үзбәк хан каршына тезләнәсе иде. «Акылы булса, Иван кенәз минем рәхим-шәфкатемә өмет итә ала», – дип тә өстәлгән иде Сарайдан килгән боерыкта. Иван Кәлитә, воеводасы Димитрий, берничә бояр һәм зур булмаган дружиначылар төркеме озатуында юлга кузгалды.

Иван Кәлитә моңарчы күрелмәгәнчә гөжләп торган Сарай Әл-Җәдидкә килеп керде. Һәр тарафта атлы хәрбиләр, һавада хәтәр исе. Шик юк – Урда ханы рус җирләре өстенә зур яу җибәрергә әзерләнә. Бу афәт Тверьгә генә яныймы, әллә инде башка кенәзлекләрнең дә язмышы хәл ителгәнме? Хан каршына басмый торып, моны аңлавы авыр иде. Тик ачуы яман икәнлеге әллә кайдан күренеп тора. Шәһәрнең руслар яши торган почмагында шуңа да тынычлык юк. Чолханның үлем хәбәрен ишеткәч, хан, ярсуыннан котырынып, ул чакта үзбашына Сарайга килгән Рязань кенәзе Василийның башын кистерткән. Сәүдә белән шөгыльләнүче рус кешеләренең күңеленә

нык курку иңгән. Бер гаепсез кенәзне ике дә уйламый кылычтан үткәргәнне, аларга гына үлемнән котылып калу насыйп булырмы икән?!

Иван кенәзне Үзбәк хан кара кайгыга баткан хәлдә кабул итте. Мәскәүдән китерелгән күчтәнәчләргә борылып та карамады. Әмма кенәзнең үзе бүләк иткән кәлитәне тагып килүен күргәч, күңеле йомшады төсле.

– Рус кенәзләре ни кылана, Иван? – диде ул, ниһаять, озакка сузылган тынлыкны бозып.

– Тверь ул әле бөтен рус олысы дигән сүз түгел, бөек ханым...

– Анысы шулай... Әмма Тверьдәге явызлык бүтән кабатланмас өчен һәммәсенә дә үтемле сабак бирергә кирәк.

Иван дерт итеп куйды.

– Бөек ханым, Мәскәүнең күндәм халкын исәнлектә калдыра күр! Без сиңа гомер-гомергә тугры хезмәт иттек. Алга таба да сиңа биргән антыбыздан кайтмаячакбыз.

– Әлегә сиңа ышандым дип уйлый аласың. Тик мине алдавың мәгълүм булса, синең кенәзлегеңә дә, үзеңә дә кичерү юк! – Үзбәк ханның күзләреннән ут чәчрәп чыккан төсле булды. – Әмеремне тыңла, Мәскәү кенәзе Иван! Озакламый Урдадан минем сәргаскәрем Бөдерчәк кул астында биш төмән Тверьгә кузгалачак. Син үзеңнең дружинаң белән аңа кушылырга тиеш. Бөтен әмерләрен үтә, сүзеннән чыгасы булма! Тверь җирендә каберлекләр белән утлы кисәүләрдән ары берни калмасын! Александр кенәзне әсирлеккә төшереп, хан хөкеменә тапшырыгыз! Барысы да аңлашылдымы, Иван кенәз?

– Аңладым, бөек ханым.

– Синең яу кырында хан әмерен ничек итеп үтәвеңне минем кешеләр дикъкать белән күзәтәчәк. Әгәр эленке-салынкы йөрсәң, Бөдерчәк Мәскәүгә дә кунакка кереп чыгар. Бусына төшендеңме?

– Төшендем, бөек ханым!

– Төшенсәң, бар, әмерләремне үтә.

Хан яныннан чыккач, Иван кенәз чиркәүгә юнәлде. Биредә ул бик озаклап дога укыды, үзенең туган җирен саклап калуны сорап, Ходайга ялварды. Рус җирләрендә үз куллары белән кан кардәшләренә каршы алып барылачак канкоеш өчен алдан ук ярлыкавын сорады. Догаларын тәмамлап чыгып барганда, ишек катында ул Суздаль кенәзе Александр Васильевичка тап булды.

– Саумы, Иван кенәз! – диде тегесе, Мәскәү хакимен данлыклы кәлитәсеннән танып. – Суздальдан мин, кенәз Александр.

– Саумы, Александр Васильевич, саумы! – Көтелмәгән очрашуга аптырап, Иван кыенсынып куйды.

– Бусы минем абыем, Василий Александрович, – дип таныштырды ул янәшәсендәге көрәк сакаллы ыспай киенгән ир-ат белән. – Урамга чыгып сөйләшик булмаса.

Алар чиркәү каршындагы мәйданга чыктылар.

– Хан тарафында булдыңмы әле, Иван кенәз?

– Булдым, Александр Васильевич.

– Мин дә... Ни уйлыйсың инде?

Иван кенәз, оялып, күзләрен җиргә төбәде.

– Ни уйларга мөмкин соң, Александр Васильевич?! Хан әмере, үзең беләсең. Дружинага әзерләнеп торырга боерып, Мәскәүгә чапкын җибәрдем.

– Шулай... Син борчылма, Иван кенәз! Үзебезнең җайны гына кайгыртмыйбыз бит, халкыбызны саклап калу теләге белән йөрибез. Без каршы килсәк, Урда гаскәре үзебезне дә изеп китәчәк.

– Әйе, хан бу хакта өздереп әйтте.

– Миңа да... Мин дә, синең кебек, дружинамны җыям. Биредә биш төмәннән торган гаскәр туплана икән. Илле мең нүкәр дигән сүз. Аларга безне дә кушсаң, шактый җыела.

– Тверь кенәзе Александр үзе хан каршына килеп, гаебен таныса, мондый яу юлга чыкмас иде дә бит...

– Александр бирешергә теләми, ярдәм сорап, берничә кенәзлеккә боярларын да җибәреп караган, тик беркем дә ризалашмаган, – дип кыстырды Василий Александрович. – Хәер, Александрның башын кисеп кенә тынычланмас Үзбәк хан. Аның барлык рус кенәзлекләренә дә сабак бирәсе килә.

– Безнең гаскәр башында Бөдерчәк атлы нүкәр торачак, ди...

– Исеме телне сындырырлык, – дип елмайган итте Суздаль кенәзе. – Без аны үзара Федорчук дип йөртәбез. Алай рус колагына ятышлырак яңгырый... Иван кенәз, әгәр андый-мондый эшләрең юк икән, сине үземнең утарыма чакырам. Моннан ерак түгел, табыннарыбыз корылган. Без абыем белән чиркәүгә кереп, шәм яндырып кына чыгабыз. Әгәр көтеп торсаң, сине кадерле кунагым итеп күрү минем кәефемне бераз күтәрер кебек...

– Әлбәттә, бик рәхәтләнеп, – дип ризалашты Иван кенәз. Аларның һәммәсенә авыр хисләрдән, үзләрен битәрләгән уйлардан арынырга кирәк.

**6**

Идел буйлап, өскә таба олы гаскәр кузгалды. Үзбәк хан аларны үзе хәер-фатихасын биреп озатып калды. Биш төмәнгә канлы сугышларда даны чыккан, дошманга карата кызгану хисе белмәгән биш төмәнбашы билгеләнде. Кенәзләрнең дружиналары Урда нүкәрләренә рус олысына җиткәч кушылырга тиеш иде.

Тверь җирендә тәртип салырга тиешле гаскәр кышкы салкыннан шартлап каткан Идел бозы өстеннән җитез адымнар белән ханның әмерен үтәргә ашыкты.

Озакламый яу кырыннан бер-бер артлы хәбәрләр дә килә башлады. Тверь кенәзе Александр, башка рус хакимнәренә ярдәм сорап, илчеләр җибәреп караса, берсе тарафыннан да яклау тапмаган. Олы яуга каршы ялгызы калуын аңлаган Александр һәм аның туганнары, Тверьне ташлап, кайсы кая таралышканнар. Үзбәк хан җибәргән олы гаскәргә гади халык, берән-сәрән дружиначылар төркемнәре каршы торып караса да, моннан, әлбәттә, рәт чыкмаган.

Чапкыннар ханга барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп торды. Рус олысындагы вакыйгалар Сарай Әл-Җәдидтә дә сизелә – аның коллар базары Тверь ягыннан китерелгән әсир ир-атлар, хатын-кызлар, балалар белән шыплап тулды. Үзбәк ханның күңеленә хуш килгәне – Бөдерчәккә ияреп киткән рус кенәзләре, бигрәк тә Мәскәү кенәзе Иван Кәлитә кардәшләренә каршы

сугышта аеруча зур тырышлык күрсәтте. Чапкыннар аның дружиначылары Тверь җирендә кылган «батырлыклар» хакында бигрәк тә җәелеп китеп сөйләделәр. Хан ишетелгәннән канәгать иде – димәк, Кәлитәгә ул курыкмыйча таяна ала...

Әмма Урда яугирләре Александрны кулга төшерә алмады – ул, Псков шәһәренә качып, шунда сыену урыны тапты. Үзбәк хан Бөдерчәк гаскәрен, аның белән бергә сугышта катнашкан кенәзләрне дә үз тарафына чакырды.

Александрга ачуы яман иде, ләкин Тверьне чит-ятларга тапшырырга теләмәде Үзбәк хан. Анда хакимлеккә качкын кенәзнең энекәше Константинны, Кашин шәһәренә исә икенче бертуганы Василийны билгеләде. Хәер, Тверьдән хәзер бернинди яманлык та көтәсе юк – Бөдерчәк яу белән үткәннән соң, әле озак еллар буе андагы халык аңга килә алмаячак.

Бөек кенәзлеккә килгәндә, Үзбәк рус олысын ике өлешкә бүлеп, берьюлы ике хакимгә бөек кенәзлек ярлыгы тапшырды. Владимир, Новгород һәм Суздаль җирләренә бөек кенәз Александр Васильевич хуҗа булса, Мәскәү, Кострома, Новгород, Ростовның ярты өлеше Иван Кәлитәгә бирелде. Икесе дә бертигез дәрәҗәгә ия, шул ук вакытта биләмәләренең чикләре аермачык билгеләнде, беркем дә бер-берсенең өлешенә керергә тиеш түгел иде. Мондый карар, бер яктан, рус олысында үзара ызгышларны туктатса, икенче яктан, Тверь фетнәчеләрен «кыйнауда» аеруча зур тырышлык күрсәткән ике кенәзгә ханның рәхмәте билгесе дә булды.

Иван Кәлитә ханның әмерләрен тыңлаган мәлдә мәрхүм Пётр митрополит белән сөйләшкән сүзләрен исенә төшерде. Үзбәкнең кәефе үтә дә яхшы. Әлбәттә, ул Тверь кенәзе Александрның качып котылуына бераз ачулы, әмма иртәме-соңмы аңа да чират җитәсен белә. Мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырырга ярамый иде. Җай чыгу белән Иван Үзбәккә мөрәҗәгать итте:

– Бөек хан, минем бер гозеремне тыңлап карарга, зинһар, авырсынма. – Рөхсәт алгач та, бар кыюлыгын җыеп, сүзен дәвам итте: – Бүген рус олысында хезмәт итүче кенәзләр һәммәсе дә сиңа үзенең тугрылыгын кан һәм тир түгеп раслады. Синең хакимлегең безнең өчен бәхәссез, моны үз күзең белән күрдең. Безгә, кенәзләргә бераз гына ышанычыңны арттырсаң, бу халык алдында да дәрәҗәңне үстерер, сиңа түләнә торган ясак күләме дә бермә-бер күбәер иде.

Янәшәсендә тез чүккән Суздаль кенәзе Иван Кәлитәгә, ни сөйлисең син, дигәндәй, күзенең агы белән акаеп карады. Әмма Мәскәү кенәзенең сүзләре Үзбәк ханның игътибарын җәлеп итә алды.

– Дәвам ит, Иван кенәз.

– Рус олысындагы синең илчеләрең – баскаклар халыкны нык өркетә. Алардан малларын яшерәләр, ят кешеләр дипме, тиешле күләмдә түләү кертмиләр. Әгәр ясак җыйнау белән кенәзләр үзләре, арадашчысыз шөгыльләнсә, бу синең казнага күбрәк файда китерер иде.

– Баскаклар гомер-гомергә рус олысында торган, бөек ханым, алар – безнең колакларыбыз һәм күзләребез... – дип сүз башлаган иде Исабәк вәзир, әмма кисәк кенә кулын өскә күтәреп, Үзбәк хан аны туктатты.

– Әгәр ясак күләмен арттыра аласың икән, минем казначыларга тәгаен әйтеп бир – күпмегә?

– Бер бояр башыннан алтмыш тәңкә, бер крәстиян башыннан ун тәңкә түләргә әзермен, бөек хан! – Иван шул мизгелдә генә уена килгән саннарны әйтеп ташлады.

Үзбәк казначысына таба борылды.

– Бөек ханым, әгәр Мәскәү кенәзе бу шартны үти ала икән, синең казнага рус олысыннан килгән керем бер ярым тапкырга диярлек артачак, – диде казначы, тиз генә кулындагы күпсанлы кәгазьләрне актарырга һәм исәп-хисап ясарга ашыгып.

– Син ни әйтерсең, Суздаль кенәзе?

– Риза, бөек ханым, Иван кенәз әйткән шартларны без дә үти алачакбыз, – диде Александр Васильевич, Үзбәк каршында үзен Мәскәү кенәзе кебек үк булдыклы итеп күрсәтергә тырышып. Гәрчә, мондый түләүләрнең халык җилкәсенә авыр йөк булып төшкәнен яхшы аңласа да, килеште ул.

– Хуш. Әгәр шушы шартлар үтәлә икән, рус олысларындагы минем илчелекләрне кире кайтарырга әмер бирәм. Кенәзләр казначы белән килешү төзесен. Килешү үтәлмәсә, киләсе елга баскакларны да юллыйбыз, ясакны да икеләтә күләмдә алабыз. Хан үз сүзен әйтте!

Хансарайдан ераклашкач кына, Суздаль кенәзе Александр Васильевич Иван Кәлитәгә сүз катарга кыйды.

– Үз акылыңдамы син, Иван кенәз?! Әле генә өстебезгә күтәрә алмаслык бурыч алдык бит!

– Аның каравы, Александр Васильевич, баскаклардан котылабыз. Монысын акчага сатып алып булмый. Ә инде ясак түләүгә килгәндә... Акыл белән эш итсәң, мал табыла ул. Бу мөмкинлекне кулдан ычкындырмыйча, аны туган җиребез файдасына кулланырга кирәк.

Иван Кәлитә үзенең сүзләрен ышандырып әйтте, ләкин Суздаль кенәзенең генә шикләре зур иде. Тарих алга таба Иванның хаклы булуын раслар – тырышлыгы һәм үҗәтлеге бәрабәренә ул Мәскәүне рус җирләренең үзәгенә әйләндерәчәк, бермә-бер тынычлык урнаштырып, баскаклыктан арынып, дәүләтен ныгытачак. Үзбәк хан, Мәскәү кенәзе Иванга хәерхаһлык күрсәтеп, үзе дә аңышмыйча, Урда дәүләтенең нигезен дә какшатты. Шактый еллар үткәч, Мәскәү тирәсендә Урда басымын күтәреп бәрерлек көч барлыкка килде. Ул көчнең шытып чыгуында, һичшиксез, Кәлитә кушаматы йөртүче Иванның өлеше әйтеп бетергесез зур иде...

### 7

Балалары үсә төшү белән, хансарайда Тайдула хакимлеген киңәйтә барды. Барлык йомышларын үтәүче Мостафа әвнухтан тыш, бавырчыларны, башка хезмәтчеләрне дә үзенә якынайтты. Хан тирәлегендә барган сөйләшүләр хакында аңа түкми-чәчми җиткереп торган кешеләр ишәйде. Башка хатыннары кыз балалар гына тапканга, төнге уеннарда әллә ни осталык күрсәтә белмәгәнгә, Тайдула белән тиңләшердәй нәфис зат Үзбәк хан янәшәсендә әлегә табылмады.

Әмма Тайдуланың күңеле барыбер тыныч түгел иде. Төн йокыларын качырган бәндә – ханның олы улы Тимербәк. Күпсанлы орышларда ул чарланып бетте, хан гаскәре аны хакимен каршылаган төсле сәламли. Хәрәземдәге хуҗалык эшләрен дә бик оста алып бара, диләр. Сирәк

очрашулары вакытында Үзбәк бар дөньясын оныта, улы белән озын-озак сөйләшеп утыра, диван утырышларында күкләргә чөеп мактый. Ничә тапкыр Тайдула аны Тимербәккә каршы котыртырга, күңеленә шик салырга маташып карады – Үзбәк шунда ук яман ачуланып, авызын ябарга мәҗбүр итте. Үзбәк улының дәрәҗәсеннән курыкмый, киресенчә, үзенә шундый алмаш үстерүе белән чиксез горурлана иде. Елан теле белән ике арага керә алмавын, ахыр чиктә, Тайдула да аңлады.

Тайдуланың сатып алынган шымчылары күп, тик менә яшерен эшләр башкарырлык бәндә генә алар арасында юк. Хәтерендә, Баялун хатын андый кешене дә кулына ияләштерде. Исемен дә белми, йөзен дә күргәне юк, берничә тапкыр Баялун ягыннан чыгып килгән шәүләгә генә юлыкканы бар. Усал телләр әлеге шәүләне Баялунның төрле кырын эшләре белән бәйләп сөйлиләр иде. Андый шәүләне кайдан табасы соң?!

Атнага бер тапкыр Тайдула җарияләре һәм әвнухлар озатуында Сарай Әл-Җәдиднең олы базарына чыгып, озаклап йөрергә гадәтләнде. Биредә ул дөньяның төрле почмакларыннан китерелгән парчалар, затлы хушбуйлар, бизәнү әйберләре сайларга ярата иде. Шәхси казнасы мул, Үзбәк хан аңа акчаны да, башка төр байлыкларны да кызганмый бирә. Базарда сайланып йөрү хансарайдагы күңелсез тормыштан качу, үзгә бер шөгыль төсмеренә әверелде. Базар сәүдәгәрләре аны ерактан ук таный, иң шәп, иң кыйммәтле товарларын тәкъдим итә. Зәркәнчылар ханбикәнең зәвыгын өйрәнергә өлгерде, кайберләре хәтта махсус аңа атап затлы эшләнмәләр ясап көтә иде.

Ул көнне юлга кузгалгач та, Тайдула хатын үзен озата баручы сак хезмәтендә моңарчы күрмәгән яңа нүкәрне абайлады. Егет башкаларыннан нык аерылып тора. Бүтән яугирләр сыман хиссез, төссез түгел, үзенә кереп бикләнмәгән. Яшьлеге, буй-сыны да сокланырлык. Кыягы калганнарыныкы төсле капчык сыман салынып төшмәгән, нечкә билләренә сыланып тора. Сакал-мыегын да бик иплəп кырыккан. Тайдула моңарчы мондый чибәр Урда егетен күрмәгән кебек иде. Алар аңа барысы да бер үк төсле тоелды – шул ук кысык күзләр, кояшта кара янып чыккан кырыс йөз, бит сөякләре як-якка тырпаеп тора. Ә бу егет үзгә дөньядан иңгән, диярсең.

Кинәт йөрәген кысып алган хистән Тайдула үзе дә оялып куйды. Үзбәк хан янәшәсендә яшәп, ул чит ирләргә игътибар бирү турында уйламый да иде бит. Калган ир затлары аңа йә гайрәтеннән мәхрүм ителгән әвнух, йә казан алдында кайнашучы бавырчы, йә инде ханбикәнең иминлеген тәэмин итәргә тиешле нүкәр генә, җансыз хезмәтчеләр.

Бер мәлне аларның күзләре кара-каршы очрашты. Тайдула хатынның йөрәге ешрак тибә башлады. Тере, хисле күзләр иде бу! Ул кинәт үзен янәдән унбиш яшьлек кыз сыман тойды. Сакчы нүкәр аңа елмайды да шикелле. Әмма ханбикәгә сер бирергә ярамый иде. Ул үзе утырган арбаның тәрәзәсенә кисәк кенә чаршау тартып куйды, урам якка бүтән карамаска карар кылды.

Базарда йөргәндә яшь нүкәр аның яныннан китмәде. Тайдулага егет аның һәр адымын күзәткән кебек тоелды. Шуңа ул нык кабаланды, кулына нәрсә төртсәләр, шуны сатулашмый гына алды, акчасын санамый, уңлы-суллы сипте. Кире арбага утырганда, әлеге дә баягы яшь нүкәр аңа ярдәмгә йөгереп килде, ханбикәгә терәк итеп кулын сузды.

Нүкәрнең кулына таянгач, ханбикәнең бөтен тәне калтыранып куйды. Барлык батырлыгын җыеп, ул, ниһаять, тез чүккән нүкәргә сүз катарга җөрьәт итте:

– Ни атлы син, баһадир, моңарчы күргәнем юк иде? – диде ул, арба катында бер мәлгә тукталып. Егет карашын күтәрде.

– Җамбыл атлы булам, сөекле ханбикәм! Хан хезмәтенә Хаҗитархан якларыннан чакырылдым, бер атна элек мине синең шәхси сак хезмәтенә билгеләделәр.

– Уңышлы хезмәт ит, Җамбыл нүкәр! – Малайларча әзерлек белән яңгыраган җавап Тайдулага тынычлык өстәде, ул янә үзенең ханбикә икәнлеген искә төшерде, үз дәрәҗәсенә кайтты кебек. – Синең кулыңда Урда ханының иң кадерле кешесе, аны яхшылап сакларсың дип өметләнәм.

– Синең өчен мин үз гомеремне бирергә әзермен! – Кинәт авызыннан атылып чыккан бу сүзләрдән Җамбыл да уңайсызланып куйды, кызарынып, як-ягына каранды. Әмма беркем дә бу кыска гына сөйләшүдән тискәре мәгънә тапмады, аларга аерым игътибар бирүче юк иде.

Ул төнне Тайдула йоклый алмады. Яшь егетнең учына кагылган бармак очлары ут кебек янып тордылар. Күңелендә кинәт моңарчы мәгълүм булмаган хисләр уянды. Әллә шушыны мәхәббәт дип йөртәләрме?! Өч бала анасы, кодрәтле Урда ханбикәсе, аңа сөю шулай соңарып килдемени?! Үзбәкне яратамы соң ул? Башта ул Үзбәктән курыкты, аннары ияләште кебек, хәзер инде мөнәсәбәтләре алыш-бирешкә әверелде. Тәннәр якынлыгы вакытында күңел җилкенеп ала да, ә аннары? Аннары хан үз эшләренә чума, ә ул үз ягында вак-төяк мәшәкатьләр белән вакыт үткәреп гомер итә. Ә бу егетнең күзләре... Аларда ялкын, аларда кайнарлык, мәңге сүнмәс-сүрелмәс яшьлек дәрте!

Таң атып килә иде инде, Тайдула тынычлана төште. Үзен тиргәсә дә, битәрләсә дә, Җамбыл баһадирны янә күрәсе, аның янында буласы килде. Ахыр чиктә, Урданың иң зур хакимлеккә ия хатын-кызы янәшәсендә күңеленә ятышлы кешеләрне тотарга, алар белән һәр көнне күрешеп торырга хаклыдыр бит?! Егет тә аңа битараф түгел. Ә моны үз максатларында да кулланырга ярый. Чөнки ихлас тугрылык бернинди акчага да сатылмый. Ә инде баһадирның йөрәгенә бераз өмет күмерләре дә ташласаң... Тәмам арып, йокыга талганда, Тайдула хатын үзе өчен билгеле бер карарга килгән иде инде...

Үзбәк хан Тайдуланы үз янына төн кунарга чакырганда, шактый гына кәефле күренде. Бүлмәсендә табын да корган, хаким, гайрәтен тынычландыргач, хатынын авыз чылатып алырга дәште.

– Балалар ничек, Сөенбикә сау-сәламәтме, Тәнибәк белән Җанибәк белем алуга хирысмы? – диде хан, куе кашлары астыннан хатынына карап.

– Бик хирыс, сөекле ханым, алар ул яктан сиңа тартым, барысын да тиз эләктереп алалар. Сиңа рәхмәт, укытучыларның иң шәпләрен сайлагансың! Бер нәрсә генә күңелемне борчып тора... Сиңа күптән әйтәсе идем дә, җае чыкмады...

– Сөйлә, Тайдула, мин балаларым хакында барысын да белеп торырга тиеш.

– Мөгаллимнәребез бик белемле, итагатьле, хәтта артыгы белән дә.

Алар егетләрне чамадан тыш йомшаклыкка өйрәтеп, ир-ат кырыслыгыннан мәхрүм калдырмасмы? Урда җәмгыятендә үзгәрәк тәртипләр бит, моны син яхшы беләсең.

– Анысы хак, Тайдула. Берәр тәкъдимең бармы?

– Әйе. Егетләрне сугыш һөнәренә өйрәтер өчен акыллы һәм булдыклы нүкәрне билгеләсәң, ул алар белән көн саен шөгыльләнеп, тәннәрен һәм холыкларын ныгытыр иде, сөекле ханым.

– Яхшы, тәкъдимең бик дөрес! Табарбыз андый баһадирны.

– Мин бер егетне сайлап куйдым инде, бөек ханым... Ул минем тәнсакчылары исәбеннән... Җамбыл атлы, Хаҗитархан якларыннан... Мин, мескен хатын-кыз, аның нәрсәгә сәләтле икәнлеген белеп бетермим. Үзең аны чакырып сөйләшсәң, яхшырак булыр. Синнән узып, карар чыгарасым килми, бәлки, аны сайлап, мин ялгышканмындыр.

– Җамбыл дисең алайса... Иртәгә үк сөйләшермен, бергә яныбызга чакыртырбыз. Син ялгышмагансың дип уйлыйм, чөнки ана кешенең сизгерлеге – ир-ат акылы һәм зирәклегеннән дә көчлерәк. Тыныч бул, улларыбыз этисенә һәм әнисенә тиңдәш егетләр булып үсеп җитәр.

– Мине ишеткәнең өчен рәхмәт сиңа, бөек ханым!

Җамбыл хан каршына баскач та, үзен бик дөрес тотты. Сорауларга кыска һәм Үзбәк ишетергә теләгән рәвештә җавап кайтарды. Егетнең Хаҗитархандагы гади итекче гаиләсендә туып-үсүе мәгълүм булды. Шәһәрдә яшәгәнгә, азмы-күпме итагать тәртипләрен дә үзләштергән, яшьтән бертуган абыйлары ярдәмендә хәрби һөнәргә дә өйрәтелгән. Үзбәк хан, барысын да бәйнә-бәйнә сораштыргач, Җамбылны ике улының тәрбиячесе итеп раслады. Моны ишеткән егет, саклык турында онытып җибәреп, Тайдулага ап-ак тешләрен күрсәтеп, ихлас елмайды. Тайдула сер бирмәде, җитдилеген югалтмады.

Шул көннән Тайдула өчен икенче тормыш башланды. Ул көн саен Җамбыл белән көрешү мизгелләрен көтә, ике улын һәрвакыт үзе озата бара. Егет хансарай бакчасында Тәнибәк һәм Җанибәк белән шөгыльләнгәнне кызы Сөенбикә янәшәсендә игътибар белән күзәтә. Карашы һәрвакыт Җамбылга барып төртелә. Тегесе, кайвакыт, тирләп-пешеп чыгып, өстендәге кыягын салып ташлый, җиңел күлмәктән генә кала. Күлмәк астыннан егетнең нык тәне абайлана, шабырдап аккан тирдән күлмәге тәненә ябышкач, Тайдула үзенең нык дулкынлануын тоемлый.

Кылыч белән сугышу, сөңге ташлау, арканлау, уктан ату буенча күнегүләр тәмамлангач, Тайдула, балаларын тәрбиячеләр кулына тапшырып, Җамбылны чәй табынына чакыра. Алар анда озаклап сөйләшеп утыралар. Башлыча, балаларның сәләте, корал, сугыш тәртибе турында. Тайдула Җамбылның күңел кылларына кагылмаска, әңгәмәне рәсми рәвештә алып барырга тырышты. Тайдулага егетнең сөйләм рәвеше, тавышы ошады, ул аны бертуктамый тыңлар да тыңлар төсле иде. Хәтта сирәк төннәрдә Үзбәк хан кочагына кергән мизгелләрдә дә ул, күзләрен йомып, үзен Җамбыл назлавы хакында хыяллана башлады...

Кайвакыт Җамбыл, балаларны атка атландырып, Сарай Әл-Җәдидтән читкә, далага алып чыгарга гадәтләнде. Ирләргә Тайдула да кушылды. Аңа Үзбәк хан бүләк иткән айгырга тирә-юньдә тиңнәр юк – малкайны Урда

хакиме Мисырдан махсус кайтартты. Холкы тыныч иде, ләкин аның да киреләнгән көнен күрәсе булган икән.

Ирләр дошманны арканлау күнегүләрен үткәрәләр иде, Тайдула, алардан чак кына читтәрәк, атына атланган көе үз уйларына чумды. Куе үлән арасыннан әллә кинәт кенә куян йөгереп чыкты, әллә зәһәр елан пәйда булды – айгыр, сискәнеп, каты кешнәп җибәрде. Арт аякларына торып басып, ул чак кына ханбикәне җиргә мәтәлдермәде. Аннан соң, кире җиргә төшеп, кушаяклап чабарга кереште. Айгырның күзләре акайган, иреннәре күбекләнгән, тешләре өзәңгене бертуктаусыз чәйни. Ат белән идарә итү дә, аны чапкан җирдән туктату да мөмкин түгел иде. Гомеренең кыл өстендә калуын аңлаган Тайдула, күз яшьләренә буылып, иярдән егылып төшмәс өчен ике куллап, айгырның муенына ябышты.

Әлеге тамашаны күргән ирләр, ни эшләргә белми, үз урыннарында тораташтай катып калдылар. Бары Җамбыл гына ярдәмгә ыргылды. Ханбикәнең айгырын куып тотып, ул, чапкан шәпкә, тегенең өзәңгесен эләктереп алды. Гарәп айгыры кешедән мондый ук көч көтмәгән иде бугай, адымын акрынайтырга мәҗбүр булды. Ахыр чиктә, Җамбыл баһадирның басымына түзә алмады, туктады, һәм, үзенең ахмаклыгына үзе оялгандай, башын түбән иде.

Җамбыл Тайдулага иярдән төшәргә ярдәм итте. Шулай килеп чыкты ки, ханбикә капылт кына аның кочагына эләкте. Икесе дә тынсыз калдылар. Тайдула күзләрен егеткә төбәде.

– Рәхмәт сиңа, Җамбыл, син минем коткаручым, – дип пышылдады Тайдула һәм кайнар иреннәре белән аны үбеп алды.

– Мин синең яныңда гына бәхетлемен, бөек ханбикәм! – диде Җамбыл, Тайдуланың көтелмәгән бу гамәленнән бөтенләй каушап калып. – Синең өчен җанымны да фида кылырга әзермен! Минем өчен бу иң зур бәхет булачак!

– Җаныңны бирергә ашыкма, баһадир. Сабырлыгыңны җый. Әгәр ашыксак, моның ни белән бетәсе сиңа мәгълүм – синең генә түгел, минем дә җаным күкләргә ашар. – Тайдула күз чите белән үзләренә таба уллары һәм нүкәрләр төркеме якынлашуын күрде. – Ә хәзер каршыма тезлән, Җамбыл баһадир. Бүгенге гамәлебезне зур сер итеп сакларга ант ит!

– Ант итәм, бөек ханбикә!

– Минем һәрбер әмеремне тыңларга һәм җиренә җиткереп үтәргә әзерме син, Җамбыл баһадир?

– Әзермен, сөекле Тайдула хатын! Барлык әмерләреңне дә син кушканча үтәрмен, арабызга чит-ятларны кертмәм.

– Бик яхшы, – диде Тайдула, өс-башларын рәтләп. Аннан, тез чүгеп торган Җамбылдан аерылып, инде якын ук килеп җиткән балалары ягына атлады. – Сабырлыгың белән акылыңны гына жуйма, Җамбыл баһадир...

Җамбыл, Тайдуланың тәне исеннән, кайнар иреннәреннән бөтенләй һушсыз калды, фикерен җыя алмый, тезләнгән килеш тора бирде. Ул – гади итекче малае, данлыклы ханбикәгә шулай якынайсын әле! Үзенең мәхәббәте җавапсыз түгеллеген аңлау, аңа шундый кодрәтле хатынның күз төшерүе егетнең башын әйләндереп җибәрде. Әгәр беренче үбешү булган икән, дәвамына да өмет бар дигән сүз. Сабырлыкка өндәде бит ханбикә! Һәм

ул сабырлык белән күтәргә, җаны тартылган хатынның барлык теләкләрен үтәргә әзер. Хансарайда хезмәт аның өчен чын мәгънәсендә кызык, күңелне кытыклый торган уенга әверелеп бара иде...

Үзбәк ханга гарәп айгырының дулавы хакында түкми-чәчми җиткерделәр. Җамбыл баһадирның Тайдуланы үлемнән коткаруын ишеткән хаким шунда ук үзенең биленнән асылташлар белән бизәлгән затлы хәнҗәрен алып, егеткә бүләк итте, уч тутырып акча бирде. Айгырны исә үзгәсенә алмаштырырга боерды – шөкер, хан абзарында сайлау мөмкинлеге зур, берничә мең юртак ияр астына басарга әзер.

Бу күңелсез хәлнең бәхетсезлек белән тәмамланмавына дога кылып, Үзбәк хан яуга әзерлек башлады. Бу юлы аның карашы Балкан ярымутравына, Фракия тарафына юнәлгән иде. Соңгы вакытта Византия белән аралары суынды, Андроник патша Урдага хөрмәтнең ни икәнен оныта башлады. Фракиягә бәреп кереп, Үзбәк Константинопольгә кисәтү ясарга карар кылды.

– Яуны үзем җитәклим, – диде ул диван утырышында. – Хәрәзем якларында чит җирләрдән сәүдәгәрләр ияртеп килгән билгесез чир таралган, улым Тимербәк белән хатыным Нәзифә дә аны эләктергән булырга мөмкин. Аларны хәзер Котлы Тимернең иң шәп табиблары дәвалый, исән-сау савыгуларын теләп, көн саен догада торыйк. Шуңа күрә бу юлы Тимербәк хәрби сәфәрдә катнаша алмаячак.

– Исәнлектә әйләнеп кайтырга насыйп булсын, бөек ханым! – диештеләр диван әһелләре.

Озак та үтми, шәһәр халкы өчен зур мәҗлес корып, күмәк намаз укып, хан җитәкчелегендәге Урда гаскәре юлга кузгалды.

**8**

Тайдула хатын, ханны озаткач та, берничә төн рәтләп йоклый алмый, ятагында боргаланып ятты. Җамбыл белән күрешүләр дә кәефен күтәрмәде. Мескен егет, әллә гаеп миндәме икән дип, үзеннән сәбәп эзләргә маташса да, кыска гына чәй табыннары вакытында Тайдуланың күңелен күрергә тырышса да, хатынның уйлары кайдадыр еракта иде, гүя биредә тәне генә торып калган. Ул чыр-чу килеп үзара уйнаклашып йөргән балаларына текәлгән дә бер сүз дә дәшми...

Ниһаять, Тайдула бер фикергә килде. Башта ул Мостафа әвнух аша үз янына базарда дарулар, кершәннәр, хатын-кызлар йөзенә матурлык бирә торган төнәтмәләр һәм майлар сатучы Галибәк аганы чакыртты. Тегесе, ханбикәнең юмартлыгын белгәнгә, кешелләренә иң кыйммәтле товарын төяп килеп тә җитте. Ханбикә кырына керүгә, ул, әйберләрне чыгарып, туктаусыз мактарга, кайсы нинди сыйфатка ия булуын аңлатырга кереште. Ләкин Тайдула аны тыңламый иде.

– Мостафа ага, син чыгып тора аласың, – диде ханбикә, әвнухка кулы белән ишеккә таба ишарәләп. – Галибәк ага, якынрак кил, утыр.

Гаҗәпләнгән сәүдәгәр ханбикә күрсәткән төшкә утырды.

– Галибәк ага, синең һәрбер даруың, һәрбер маең кешенең гомерен озынайта, бусы бик хуп. Әмма миңа бүген киресенчә, гомерне кыскартучы дару кирәк. – Галибәк ни дип тә җавап бирергә белмәде, авызы ачылып

калды. – Шаяртмыйм мин, Галибәк ага. Синдә андый дару һичшиксез бар дип беләм. Башыңны юләргә салма.

– Кхм... Сөекле ханбикәм... Әмма андый матдә дару булмый, ул агу исемен йөртә...

– Яхшы, агу булсын, ди. Галибәк ага, көчле агуларың бармы синең?!

Галибәк тәмам кабалана башлады, ханбикә сүзләре артында мәкер ятамы, әллә ул чынлап торып сөйләшәме – һич аңларлык түгел.

– Сөекле ханбикә, әлбәттә, бик яхшылап эзләп карасам...

– Яхшылап эзлә, Галибәк ага. Иң көчлесен тап. – Тайдула кинәт шаркылдап көлеп җибәрде. – Карт юләр син, Галибәк ага! Әллә соң син мине кеше агуларга җыенды дип уйлыйсыңмы?! Мине дәҗҗалга тиңләмисеңдер бит?! Миңа ат егарлык агу кирәк, аңладыңмы? Бер айгыр күптән түгел үземне чак кына теге дөньяга олактырмады, шуннан үч алырга ниятем. Икенче юлы, җаен табып, өстемә менеп таптар дип куркам, шул гына...

Мондый аңлатмага әллә ни ышанып бетмәсә дә, Галибәк ага җиңел сулап куйды. Җавапка тартсалар, килешле генә әкият сөйләп булачак, димәк.

– Аңладым, сөекле ханбикәм, аңладым! Иртәгә кичкә син сораган дару кулыңа керер.

Тайдула тәңкәләр белән шыплап тулган янчыкны сәүдәгәргә ташлады:

– Даруыңны кызганма, ханбикәне кыерсытырга маташкан айгырлар тагын табылмас дип кем әйтә ала? Ашарга сорамас, ышанычлы урынга яшереп куярмын. Безнең сөйләшү хакында берәр кеше белсә...

– Юк-юк, сөекле ханбикә, бер дә борчылма, миннән беркайчан да сүз чыкмас!

– Ярый алайса, иртәгә көтәм үзеңне!

Агу кулына төшкәч тә, аны сынап та карарга мәслихәт. Айгыр турындагы уйдырма Галибәк аганы йомшартыр өчен капылт кына башына килсә дә, ул Тайдулага бик тә җайлы ысул төсле тоелды. Агуның да көчен белер, кара эшләрен йөкләргә җыенган бәндәсенең дә тугрылыгын тикшереп карар.

Чираттагы күнегүләрдән соң Тайдула Җамбылны үз янына чакыртты. Бүлмәсендә табын корылган, анда чәй генә түгел, кымыз-шәраб та күренә. Ханбикә күкрәк-муены күренеп торган кыска җиңле кытай халатын киде, чәчләрен тузгытып җибәрде. Җамбыл, аны бу кыяфәттә күргәч тә, бусагада телсез калды.

– Кер, Җамбыл баһадир, утыр, бер дә тартынма, – диде Тайдула, елмаеп.

Ханбикәнең кәефе әйбәт булуын күрүдән Җамбыл шатланып куйды – димәк, соңгы көннәрдәге халәтендә аның гаебе юк, башка берәрсе борчылырга мәҗбүр иткән.

Табынга утыру белән Тайдула аңа шәраб салып бирде, хәлләрен сораштырды. Җамбылның да авызы ерылды. Менә болай ханның хатыны бүлмәсендә утыру килешми дә кебек, әмма хаким еракта, куштаннары да ияреп киттеләр. Яман эш кылмый бит ул, ханбикә үзе чакыртты.

– Җамбыл, мин синең үземә карата аерым бер җылы мөнәсәбәтеңне тоям, – диде Тайдула, егетне кызарып чыгарга мәҗбүр итеп. – Беләсеңме, миңа синең яныңда рәхәт һәм...

Тайдула бармак очы белән егетнең борынына кагылды, аннан иреннәренә тиеп үтте.

– Син шундый чибәр, көчле... Минем гомеремне коткаручы да син бит...

Җамбыл шәраб тулы чәркәне бер йотымда эчеп куйды. Тайдула аңа тагын да якынрак утырды, баһадир аның озын толымнарының татлы исен сизде, шактый ачылып киткән күкрәкләрне күрүдән гайрәте кузгалды.

– Рәхмәт, сөекле ханбикәм, син дә минем өчен бик якын кеше, – дия генә алды егет калтыранган тавыш белән. – Сине коткару – минем бурычым.

– Син мине кыерсытканнарны һичшиксез җәзага тартачаксың бит, әйеме?

– Әйе, сөекле ханбикәм.

– Мине чак кына үтереп ташламаган айгыр... Ул әле дә абзарда...

– Хан абзары бит ул, сөекле Тайдула хатын. Андагы атларга хакимебез үзе генә хуҗа.

Тайдула кинәт үпкәләгән кыяфәт чыгарды, Җамбылдан читләште.

– Ни кызганыч, ханыбыз ул айгырны җәзага тартмады. Мин аңардан ялварып сорасам да, гозеремне ишетмәде. Соңгы көннәрдә кәефсез йөрүемә дә шул гына сәбәпче. Куркам мин ул айгырдан. Кем белә, бәлки аны сихерләп, мине, балаларымны үтерергә җибәргәннәрдер? Аның башына җитәргә кирәк, Җамбыл баһадир. Бу хөкемне бары тик син генә башкара аласың.

– Хан малына кул күтәргән кешегә – үлем икәнлеген беләсең бит, Тайдула хатын...

– Ә без ул хөкемне шыпырт кына, беркемгә дә әйтмичә башкарырбыз. – Тайдула кесәсеннән кечкенә генә төенчек чыгарды. – Кеше-кара күзенә күренми абзарга кереп, шушы онны айгырның иреннәренә, теленә сөртә аласыңмы? Тик сак бул, үзеңнең авызыңа каба күрмә.

Аптыраган Җамбыл төенчекне кулына алды. Тайдулага карата мәхәббәт хисен курку алмаштырды. Кай арада аның тозагына эләкте ул? Җинаятькә этәрә бит ханбикә!

– Ә хәзер бар, Җамбыл, юлыңда бул. Синнән яхшы хәбәрләр көтәм.

– Мин... Мин хан абзарына ничек үтеп керермен икән соң? Сакчылар эләктерсә?

– Син акыллы егет бит, җаен табарсың. Бусы инде куркуыннан ни эшләргә белмәгән ханбикәне кочаклап үбү генә түгел, биредә акыл һәм зирәклек тә кирәк. – Тайдула усал елмаеп куйды һәм, сөйләшүнең тәмам икәнлегенә ишарәләп, табыннан торды.

Бу сөйләшүдән соң берничә көн үтте. Тайдула, гадәтләнгәнчә, балаларын күнегүләр үткәрергә хансарай бакчасына алып чыкты. Җамбыл аңа авыз тутырып елмайды – соңгы сөйләшүдән соң бик киеренке халәттә йөргән егетнең бүген кәефе күтәренке иде. Тайдула да елмаеп җавап кайтарды.

Дәреснең урталары булгандыр, Тайдула янына ахылдап-ухылдап, Мостафа әвнух йөгереп килде.

– Бәла, ханбикәм, олы бәла! – диде ул, киләкилешкә кычкырып.

– Ни булды Мостафа ага?! Ник шәрран ярасың?

– Синең яраткан аргамагың... – Мостафа аганың ашыга-кабалана чабуыннан тыны кысылды. Ул, туктагач та, озаклап хәл алды. – Бөек

ханыбыз сиңа дип атап Мисырдан кайтарткан гарәп айгыры. Ул бүген төнлә үлеп киткән.

– Үлгән?! Йа Хода, ни сәбәпле?!

– Ярамаган нәрсә ашаганмы шунда. Ашказаны кара янып чыккан диделәр. Ат караучы аны үле килеш тапкан...

– Шундый шәп ат иде, кирәк бит, ә?! – Тайдула Җамбылга таба борылып, чак кына сизелерлек итеп башын какты. Тегесе исә уң кулын күкрәгенә куеп, ханбикәсенә хезмәткә әзерлеген раслады. – Язмаган булмас, Мостафа ага, шуннан олырак кайгы килә күрмәсен. Мин бу коточкыч хәбәрне үземнең хатымда бөек ханыбызга һичшиксез җиткерермен. Ә хәзер юлыңда бул, хәрәмдә синнән башка бер эш тә эшләнми, хезмәтчеләр таралып бетмәсен.

Җамбыл нүкәр Тайдуланың төп ниятен тормышка ашырырга әзер иде. Бер яктан баштанаяк ханбикәгә гашыйк, Тайдула аны әледән-әле котыртып тора. Икенчедән, хәзер инде кул-аяклары бәйләнгән, алай-болай киреләнә калса, ханбикә аны ике дә уйламый Урда хакиме хөкеменә тапшыра ала. Бөек хан Хаҗитархан итекчесе сүзен тыңламас, әлбәттә, хатынының әйткәне якынрак булыр. Җамбыл, үзе дә сизмәстән, куркыныч тозакка эләкте. Аннан ансат кына котылу мөмкин түгеллеген ул яхшы аңлый. Тайдулага тугры хезмәт күрсәтмәсә, бер мизгелдә кылычтан үткәрәчәкләр үзен.

Тайдула, егетне үзенә чакыртып, чираттагы әмерен җиткерде. Җамбыл, Хәрәземгә барып, Нәзифә ханбикә белән Тимербәк ханзадәнең даруларын агуга алмаштырырга тиеш иде. Моның өчен шактый акча бирде, ымсындырды, юмалады, кирәк урында куркытты да. Җамбыл килеште, кара төндә атына атланып, Яңа шәһәргә таба юл алды. Мескен әти-әнисенең догалары, бәлки, аны саклап калыр дип өметләнде. Ханбикә белән ханзадә авыру диләр бит, аларның үлемен шул зәхмәтле чиргә сылтарлар. Кем белә, бәлки, бу йомышны үтәгәч, Тайдула бүтән аны мондый кара эшләргә җәлеп итмәс? Һәрхәлдә, ханбикә тарафында калу үзе өчен хәтәр тәмамланырга мөмкин икәнлеген сизде Җамбыл. Бу гозерне башкаргач та, даими гаскәргә гади нүкәр булып күчәргә, пайтәхеттән ераккарак, әйтик, шул ук Хаҗитархан, йә булмаса, Кырымга ук җибәрүләрен үтенергә кирәк булыр...

**9**

«Сөекле ханым, күктәге якты кояшым, караңгы төндә юлымны яктыртучы якты аем, назлы төннәремнең падишаһы, керсез көннәремнең җылысы, газиз балаларымның яраткан әтисе! Синнән башка Сарай Әл-Җәдид, әйтерсең, ятим калды. Хансарай буйлап кая барып бәрелергә белми йөрим, йокым йокы түгел, ризыгымның тәме китте. Чит җирләрдә яуда үзеңне безнең өчен саклавыңны үтенәм, бу хакта бертуктаусыз догаларымда Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итәм. Кояш кадерен төнлә генә аңлаган төсле, синең миңа никадәр якын икәнлегеңне аерылгач кына тоям. Дошманнарыңны җиңеп, тизрәк безнең順ыбызга әйләнеп кайт, без сине нык сагындык!

Тәнибәк ханзадә аркан ташларга бөтенләй остарып бетте. Җамбыл

нүкәр тырышлыгы белән ул шулкадәр шомарды ки, җитезлектә хәтта аны да уздырып җибәрә. Җанибәк ханзадәгә хисап фәненнән тиңнәр юк. Ул, синең шикелле үк олы гыйлем иясе булып үсәргә охшаган.

Мәхәббәтем минем, бердәнбер падишаһым! Ни кызганыч, син миңа бүләк иткән Лачын аргамак һәлак булды. Күрәсең, болынга чыккач, берәр төрле ярамаган нәрсә ашагандыр – ат караучы Вәлиулла ага малкайның ашказаны кара янып чыккан, диде. Моңа бәйле хафам бик олы булды, ике көн елап чыктым. Бер тапкыр дуласа да, ул – синең миңа бүләгең, миңа карата чиксез сөю хисләрең билгесе бит. Җитез юртак кына түгел, җанлы дустым төсле, атланып барган вакытта мин аның белән серләшергә ярата идем. Ни кызганыч, бер генә җан иясе дә җир йөзенә мәңгелеккә килми, Ходай Тәгалә үз янына иң яхшыларын чакыртып ала...

Өзелеп сагындым үзеңне, падишаһым-солтаным, дөньяны дер селкеткән, күңелемне җилкеткән сөекле ханым! Уемда да, телемдә дә бары тик син генә! Тизрәк кайтуыңа өметләнәм, синең кайнар куеныңда гына мин җәннәт бакчалары җылысын тоя алам. Бердәнберең, сөекле хатының Тайдула.»

Үзбәк хан, чапкын алып килгән хатны инде ничәнче мәртәбә укып чыгып, борынына китерде. Кәгазьдән татлы ис аңкый иде. Тайдула исе. Әллә гаскәрне Исабәккә тапшырып, кайтып кына китәргәме? Фракия болай да каршылык күрсәтми, хан гаскәре барлык дошманнарны да изепсытып килә. Тик нигәдер күңелендә тынычлык кына юк. Менә инде икенче төн рәтле-юньле йоклый алмый. Төшләре тоташ бер саташу. Гадәттә, андый халәтеннән соң берәр төрле хәвеф-хәтәр килә торган иде. Хәзер дә ул шомланып, яман хәбәр көтә. Хәбәр генәме икән? Гаскәренә кинәт ябырылырга әзер торган көчле дошман явы түгелме?

Эссегә чыдый алмыйча, Үзбәк урамга чыкты. Төн караңгы, ә күк үзе, әйтерсең, җиргә шулкадәр якынайган ки, кулларыңны сузып, йолдызларны чүпләп булыр төсле.

Үзбәк хан караңгылыкка атлады. Үлән кыштырдавыннан сизде – тәнсакчылары аннан калмый, озата баралар. Аларга ул борылып карамады. Атлаган саен караңгылык куера, тирә-яктагы тынлыктан колаклар зыңгылдап куя.

Кинәт аның каршысында берьюлы тугыз пар күз пәйда булды. Алар да, күктәге йолдызлар төсле, караңгыда җемелдәп янып торалар иде. Үзбәк хан туктады, уң кулы белән кылычын капшады.

– Һай, бүреләрем, бер дә артымнан калмыйсыз, – дип пышылдады ул. – Көрәеп үскәнсез, дәҗҗал илчеләре. Сезне күрү бер дә хәерлегә түгел... Үземне бугазлагыз, минем тирәмдә вәхшилек кылып йөрмәгез, бәдбәхетләр!

Ничек кинәт кабынган булсалар, утлы күзләр шулай ук берьюлы сүнде һәм юкка чыкты. Йөрәгендә шомлы хисләре тагын да көчәйгән Үзбәк хан, башын ия төшеп, тирмәсенә таба борылды. Аны тагын бер йокысыз төн көтә иде...

Икенче көнне тирмә бусагасын Исабәк атлап кергәч, Үзбәк хан берәр төрле яман хәл булганлыгын бер караштан аңлады. Вәзиренең йөзе кара, иңнәре салынган, бөтен кыяфәтеннән курку катыш кайгы аңкып тора.

– Ни булды, Исабәк? – диде Үзбәк, яман хәбәргә әзерләнеп. Тавышы чак кына ишетелерлек чыкты.

– Бөек ханым, Котлы Тимердән чапкын килде, анның сиңа кичектерми әйтер сүзе бар...

Үзбәк ханның йөрәге кысылып куйды.

– Чакыр үзен.

Чапкын калтырана-курка тирмәгә керде, берьюлы ике тезенә чүкте, ханга башын күтәреп карарга да кыймады.

– Сөйлә, чапкын, нинди хәбәр белән килдең?

– Сөекле ханым, мине синең тарафка бәкләр-бәге Котлы Тимер җибәрде... – Чапкынның калтырануы тавышына да чыккан иде, әмма ул сүзен дәвам итәргә көч тапты. – Кайгылы хәбәр белән килдем, бөек хан, зинһар, кичерә күр. Ни кызганыч, бәкләр-бәге Котлы Тимернең табиблары синең хатының Нәзифә ханбикәне һәм синең улың Тимербәк ханзадәне зәхмәтле чирдән йолып кала алмады. Алар якты дөньядан китеп бардылар. Табиблар кулларыннан килгәннең барысын да эшләде, кыйммәтле дарулар, төнәтмәләр кулланды, тик аларның берсе дә ярдәм итә алмады. Котлы Тимер синнән гафу үтенергә һәм күтәрә алмаслык олы кайгыңны уртаклашырга боерды.

Үзбәк хан йөрәге чәнчеп алганын тойды. Башына шаулап кан йөгерде, тыны кысылды.

– Барыгыз да чыгып китегез, – дип пышылдады ул.

Тирмә бушап калгач, тәхетеннән торып, кинәт кибеп киткән тамагын чылатыр өчен читтәрәк торган өстәлгә бер адым ясаган иде, буыннарын кемдер кисеп җибәрдемени – идәнгә гөрселдәде. Үзбәк хан яткан көе аркасына әйләнде, тирән итеп сулыш алырга тырышты. Аннан соң тыела алмыйча үксеп елап җибәрде. Яманлыкны алдан сизүче күңеле бу юлы да алдамады. Тик нигә соң бу югалту шундый олы, шулкадәр үкенечле? Нигә Ходай Тәгалә аның улын, тормышка булган өметен, яшәү көчен тартып алды?! Нинди гөнаһлары өчен Аллаһы үзенең мескен бәндәсен шундый зур җәзага тарта?! Үзбәк әүлия түгел, анысы бәхәссез. Әмма Нәзифә, Тимербәк?! Икесе дә сабый күз яшедәй чиста, ихлас кешеләр иде бит...

Хәл кергәнче шактый идәндә ятты Үзбәк, аннан акрынлап торып, өсте-башын рәтләде, йотлыга-йотлыга кымыз эчте. Тәхетенә утыргач, тамагын кырып, сер бирмәскә тырышып:

– Исабәк! – дип дәште.

Вәзир бусага төбендә көтеп торган булса кирәк, шунда ук ишектә күренде.

– Гаскәрне җыегыз, син төмәннәребезне башкалага алып кайтырсың. Шуның белән сугышыбыз тәмам. Мин үз нүкәрләрем белән Хәрәземгә кузгалам. Хатыным һәм улым белән бәхилләшергә телим...

– Мондый халәттә сиңа атка атлану зыян китерер, бөек ханым! Бәлки, арба белән тирмәңдә барырсың?

– Юк, тирмәмне Сарай Әл-Җәдидкә миннән башка гына кайтарыгыз.

– Алай да, Ибраһим табибны чакыртыйк, ул сиңа тынычландыра торган төнәтмәләр әзерләр, сөекле хакимем!

– Чакыр...

Ибраһим да озак көттермәде. Артык сораулар бирми, ул, ризалык сорап, ханның уң кулындагы беләзек җирен бармаклары белән берара тотып

торды, каршына куелган ком сәгатеннән күзен алмый нидер исәпләде. «Әстагъфирулла!» – дип пышылдап, кыска гына торба чыгарып, ханның йөрәген тыңлады.

– Йөрәгең чабышка чыккан айгыр сыман сикерә, бөек ханым! Әгәр аңа тагын көчәнеш бирсәң, ул түзмәс. Сиңа берәр атна урын өстендә ятарга, тынычланырга мәслихәт.

– Синең бер төн вакытың бар, Ибраһим ага. Шул арада миңа теләсә нинди даруыңны, җаның теләгән төнәтмәңне бирә аласың. Аннан соң мин юлга кузгалам, бу карарымнан кире кайтырга уйламыйм да. Нәзифә белән Тимербәкнең кырыгына мин Хәрәземдә булырга тиеш – бүтән бәхәс куертмагыз!

**10**

Үзбәк хан өчен сәфәр авыр бирелде, әмма кайгылы уйларына чумган көе ул аны сизмәде дә төсле. Тәнгә килгән авырлык җан әрнүенә тиңдәш түгел. Нәзифә белән Тимербәк үлеме йөрәгендә электән саркыган башка яраларны да яңартып җибәрде. Бөтен гомере, кылган гамәлләре күз алдыннан үтте. Кыска ялга туктаган вакытта йокысы кермәде, кергән мәлдә дә бастырылып уяну белән төгәлләнде.

Хәрәзем чигендә ханны Котлы Тимер белән аның улы Харунбәк каршылады.

– Бөек ханым, синең олы кайгыңны уртаклашам! Кичерә күр, хатының белән улыңны үлемнән саклап кала алмадык. Ходай шаһиттыр – без кулыбыздан килгәннең барысын да эшләдек. Әмма сәүдәгәрләр көнбатыштан ияртеп килгән зәхмәт безнең догалардан һәм дарулардан көчлерәк булып чыкты. – Киң далада Урда хакиме каршына тез чүгеп, Котлы Тимер сүзен гафу сораудан башлады. Бәхәссез, ханның холкын яхшы белгән кеше, ул аның урынсыз дуамаллыгыннан әле дә куркып яши иде.

Ләкин хан бик тыныч күренде. Ул, ияреннән сикереп төшеп, Котлы Тимер белән Харунбәкне аякка бастырды, икесен дә кочып алды. Бәкләр бәге аның кулларында элеккеге егәре юклыгын тойды. Мөгаен, хаким юлдан нык алҗыгандыр, кара кайгы да эзсез үтмәгәндер. Һәрхәлдә, Үзбәкнең чәчләре, сакалы шактый чаларган, йөзен тирән җыерчыклар ярып узган. Шулай да, хан елмаерга көч тапты.

– Сезне күрүемә чиксез шатмын, Котлы Тимер, Харунбәк! Аллаһының язмышыннан узмыш юк. Тәкъдиребездән беркая да кача алмыйсың. Үлемең насыйп икән, ул гади бәндәне дә, ханбикәне дә аямый...

– Юлдан арыгансыңдыр, сөекле ханым, сине үземнең станыма тамак ялгарга, ял итәргә чакырам.

– Бары тик капкалап кына алырбыз да кузгалырбыз, бәкләр бәге. Минем иң беренче эш итеп якыннарым каберенә барып, дога кыласым килә...

– Без аларны олылап, Үргәнечтә җирләдек.

– Ашыгыйк, Котлы Тимер! Исән чакларында әйтә алмаган сүзләремне бүген аларның өстендәге салкын ташларга булса да җиткерергә телим...

Каберлеккә Үзбәк хан ялгызы керде. Салмак кына атлап, ул, як-ягына карамый, Нәзифә белән Тимербәк каберенә юнәлде. Ана белән улы янәшә җирләнгән, тормышта бер-берсеннән ничек аерылгысыз булсалар, соңгы

сыену урынын да бергә тапканнар. Үзбәк хан, дисбесен тартып, дога укырга кереште. Һәрбер сүзне пышылдаган саен күз алдында хатирәләр яңарды. Нәзифәне беренче тапкыр күрүе, беренче төннәре, Тимербәк дөньяга килгәч кичергән шатлыклары... Тимербәкнең бишектә килеш тәүге елмаюы, әтисенең кылычын күтәрергә маташкан мизгелләре, яу кырында үзе артыннан нукәрләрне әйдәве... Бу кыска гына вакыйгалар тулы бер манзарага тоташты, Үзбәкнең йөрәге кысылды. Иң бәхетле көннәре тәхеткә утырганчы, Нәзифә белән Тимербәк янәшәсендә үткән түгелме соң?! Тәхеткә ия булып, кешеләргә хас шатлану, ихласлык, шәфкать-мәрхәмәтлелек сыйфатларын югалтмадымы икән ул?!

Еламаска тырышса да, күз яшьләре, аны тыңламыйча, үз ихтыярлары белән йөгереште. Үзбәк хан ике кабер ташы каршына тезләнде. Уң кулы Нәзифәнең җәсаде өстенә корылган мәрмәрне назлап сыйпады.

– Гафу ит мине, сөйгәнем Нәзифә! Яхшы хан булырга омтылып, сиңа лаеклы ир вазифасын онытканым өчен кичер мине! Сиңа әйтелмәгән ихлас сүзләрем, ялкынлы мәхәббәтем генә калды. Мин гомерем буе сине генә өзелеп яраттым, әмма бөек хаким хисләрен күрсәтергә тиеш түгел дип, үземне бастырып яшәдем. Авыр сүзләрем дә, кырыс гамәлләрем дә явызлыктан түгел, болар барысы да – тәхеттән исерү галәмәте генә. Әгәр син хәзер мине ишетәсең икән, сүзләремнең ялган түгеллеген аңлыйсыңдыр. Кодрәтемнән килсә, барлык хакимлек елларын сезнең белән бергә булуга алмаштырыр идем дә, юк шул, юк... Үткәннәрне кайтарырга беркемнең дә хәленнән килми, хәтта ярты дөньяны кулында тоткан солтанның да моңа кодрәте җитми... Минем сиңа әйтелмәгән бик күп назлы сүзләрем калды. Синнән урлап, башкаларга өләшкән күңел җылым калды. Ләкин башкалар белән уен гына иде ул, алар да мине гомер буе алдап, хисләнгән төсле кыландылар. Ә синең сөю чын иде, Нәзифә. Һәм мин андый мөнәсәбәтне җир йөзендә бүтән беркемнән дә тоя алмаячакмын. Сине, улым Тимербәкне саклап кала алмаганым өчен гафу кыл. Мин Ходайдан үземә тизрәк үлем җибәрүен сорыйм. Җәннәт бакчаларында синең белән, баһадирым Тимербәк белән һичшиксез очрашырмын! Син анда да мине зарыгып, сагынып көтеп торуыңа бер генә дә шигем юк... Тимербәк... Өметем, ышанычым, терәгем Тимербәк! Синең иярдә җилдерткәнең һаман да күз алдымда. Гаскәремдә ихтирам казандың, дистәләрчә яу узган нукәрләрем дә синең җитез акылыңа, төмәннәр белән идарә итү сәләтеңә соклануларын яшермәде. Гадел, ихлас, булдыклы егет идең. Бөек Урда тәхетенә лаеклы бердәнбер балам...

Аһ, бу чиксез газапны ничекләр генә җиңеп чыгарга, йөрәккә нинди дәва табарга?! Ходаем, бир түземлек, бир сабырлык...

Каберлектән кире чыкканда, Үргәнеч өстенә караңгы төшеп килә иде инде. Үзбәк хан, авыр адымнар белән атлап, үз уйларына баткан көе ияренә менде. Алар нукәрләр озатуында Котлы Тимер утарына юнәлделәр.

Хан авыр уйларыннан аннан соңгы көннәрдә дә арынмады. Тимербәкнең балаларын күргәч, янә күз яшьләрен тыя алмады, аларны кочып, белгән догаларын укый-укый, изге теләкләрен теләде.

Тимербәкнең хатыны Гөлзәһрә балалар белән Яңа шәһәрдә яшәп калачак дип килештеләр. Әтисе Борһанетдин имам кызына һәм оныкларына һәр

яклап ярдәм күрсәтәчәгенә, балаларга төпле тәрбия бирәчәгенә ышандырды. Хан мәрхүм улының гаиләсенә казнадан һәрдаим мул итеп акча җибәреп торырга боерды. Сарай Әл-Җәдидкә кузгалыр алдыннан ул Котлы Тимерне янына чакыртып алды.

– Үзеңнең сәламәтлекләрең ничегрәк, Котлы Тимер? Бераз чирле күренәсең, димме?

– Яшь бара бит, бөек ханым. Синең дә чәчләрең агарып килә, мин генә яшәреп калмамын. Аяклар белән интегәм, алардан дәва юк, ди табиблар. Вакыт-вакыт шулкадәр сызлыйлар ки, урыннан да тора алмыйм. Бигрәк тә яз-көз бимазалый. Ә калганы исә түзәрлек.

– Минем сиңа бер гозерем бар, Котлы Тимер. Үргәнечтә бик матур мәчет төзетеп чык. Аның исеме Нәзифә булыр. Төзелешкә акча кызганма, мин казнамнан күпме кирәк, шулкадәр бирермен.

– Баш өсте, бөек ханым. Иң шәп ташчылар җәлеп ителер, син дигәнчә булыр!

– Янәшәсенә манара күтәр. Ул Тимербәк манарасы дип йөртелсен.

– Аллаһы Тәгалә синең бу гамәлләреңнән разый булсын, бөек ханым!

– Ярлыкау кирәк миңа, Котлы Тимер... Гөнаһларымны ярлыкау...

...Фракиягә яуга бер төрле Үзбәк хан чыгып киткән булса, аннан бөтенләй үзгә кеше әйләнеп кайтты төсле. Ул дөньяга гамен югалтты, күбрәк вакытын ялгызы үткәререгә гадәтләнде, китаплар укудан ял иткән чакларда Ногъманетдин имам янына барып, аның белән озын-озак фәлсәфи сөйләшүләр алып барырга гадәтләнде. Имам да ханның күңелендәге үзгәрешләрне яхшы аңлады – моңа кадәр Үзбәккә кискен җавап кайтарса, усал сүзләрен кызганмаса, хәзер йомшарды, ханның яралы җанына каты бәрелмәскә тырышты.

Хәтта Тайдуланың назлары да ханның үз эченә йомылган күңеленә ачкыч таба алмады. Яудан кайтканнан соң Үзбәк хан аны бер генә тапкыр да үз янына төн кунарга чакырмады. Хәер, Мостафа әвнух җиткергәнчә, хан бер генә җариясен дә китертми, әйтерсең, мәхәббәт уеннарына карата ул бөтенләй дә суынды...

Тайдуланың исә тагын бер баш бәласе артты. Хәрәземнән аның йомышын үтәп кайтканнан соң, Җамбылның да тышкы һәм эчке халәте үзгәрде. Үз-үзенә сокланып яшәүче нык беләкле баһадир кинәт умыртка баганасы сынган мескен рәвешенә төште. Аның күзләрендә инде элеккеге очкыннар уйнакламый, ул үзенә кереп бикләнде, бакчада аның көр тавышы, кычкырып көлүе ишетелмәс булды. Тайдула өчен болар куркыныч билгеләр иде. Артык яшь егет белән багланышларга кереп, аңа олы эшне ышанып тапшырып, ул нык ялгышты бугай. Күңелен эчтән кимергән кортларга Җамбыл күпме түзәр? Тайдуланы сатып, күңеленә җиңеллек табарга тырышмасмы?! Моңа кичекмәстән чик куярга кирәк.

Җаен туры китереп, балаларын тәрбиячеләре хозурына озатып, Тайдула Җамбылны бакчадагы ачык тирмәсенә чәйгә чакырды. Җамбыл теләмичә генә утырды, касәне дә бик кыенсынып, уңайсызланып кына кабул итте.

– Күңелең тыныч түгел, Җамбыл, ни булды сиңа? – Тайдула турыдан бәреп сорарга карар кылды.

– Әллә ничек шунда, ханбикәм... Авырыйм, ахрысы...

– Тән авыруымы бу, баһадирым, әллә җан ачысымы?

– Икесе бергә бугай, сөекле ханбикәм...

– Аңлашылды... Туган якларыңнан аерылу сагышы гына түгелме соң?

– Бәлки... – Җамбыл ханбикәгә туры карамады, ул аннан әллә курка, әллә ояла.

– Хаҗитарханга кайтып, әти-әниеңне күреп килсәң, бәлки, тынычлык иңәр үзеңә?

– Ханга хезмәттә бу мөмкин түгел, сөекле Тайдула хатын.

– Һии, юләр! Исабәк вәзир белән үзем сөйләшермен, бер дә борчылма. Балаларга синнән башка күңелсез булыр, әлбәттә... Тик, син мәңгелеккә китмисең, шулай бит? – Тайдула елмаеп куйды, Җамбыл да, ике арадагы пәрдәне ачып, аңа туры карады.

– Ә син, сөекле ханбикәм? Син мине сагынырсыңмы?

Тайдула як-ягына каранып алды. Бакчада чит-ят беркем дә юк, Сөенбикә, Тәнибәк белән Җанибәк үзара уен белән мавыккан, аларны бар дип тә белмиләр. Тайдула, кулын сузып, егетнең көчле йодрыгын кысып тотты.

– Мин сине сагынган беренче кеше, Җамбыл. Син моны әлегә кадәр аңламыйсың, бу соравың белән мине үпкәләттең генә...

– Гафу ит, сөекле ханбикәм, соңгы вакыйгалар...

– Бернинди вакыйгалар да булмады, Җамбыл! – дип кырт кисте Тайдула. Аннан янә йомшады: – Миңа бер-ике көн вакыт бир, барысын да хәл итәрмен. Тик, зинһар, ата-анаң тарафында озаклама, юкса, мин бөтенләй саргаермын...

Тайдула сүзендә торды – икенче көнне йөзе шатлыктан балкыган Җамбыл юлга җыена иде. Ханбикә үз янына кече улы Җанибәкне чакырып алды:

– Улым, син Җамбыл баһадирны яратасыңмы?

– Яратам, әни, ул – бик әйбәт кеше.

– Менә, тот әле шушы букчаны. Шыпырт кына бар да, Җамбыл баһадирга тапшыр. Җанибәк белән Тәнибәктән күчтәнәч, диген. Үзебез сиңа атап җыйдык дип әйт.

– Әни бирде, димәскәме?

– Юуук, ул синең инде зур егет икәнлегеңне аңласын өчен үзем җыйдым, абыем булышты диген. Берүк, букчаны ача күрмә, яме?! Син үзең дә баһадир бит, әниеңнең сүзен тыңларсың, шулаймы?

– Тыңлыйм, әнием!

Җанибәк, казылык салынган букчаны күтәреп, бакча буенда йөргән Җамбыл баһадир янына йөгерде. Алар ягына карамаса да, Тайдула хатын сөйләшүләрен ишетеп торды, күз чите белән күзәтте. Җамбыл букчаны гаҗәпләнеп һәм шатланып кабул итте, Җанибәкне көчле һәм булдыклы яугир дип тә атады бугай. Иң мөһиме – күчтәнәчне ул бернинди шик-шөбһәсез алды, юл кирәк-яраклары янына салып куйды.

Җамбыл баһадирның хәбәрсез югалуы хансарайда әллә ни зур тавыш куптармады. Хаҗитарханга бару юлында далада төн кунарга туктагач, аны бүреләр ботарлаган дип сөйләделәр. Бары тик Тайдула гына ачы хакыйкатьне белә иде.

Юлда бүреләр ботарлаган баһадирны беркем дә искә алмады диярлек. Тайдуланың йөрәгенә шом салып, нечкә күңелле Җанибәк кенә әледәнәле аның язмышы турында, ник әйләнеп кайтмавы хакында сораштырды. «Син аңа бирергә кушкан төенчектәге казылыкларны авыз итә алдымы икән?!» – дигән сүзләреннән соң әни кеше баласына ул вакыйга хакында онытырга һәм башка Җамбыл исемен беркайчан да телгә алмаска кушты...

## ҖИДЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1

И вакыт! Син теләсә нинди авыр җан яраларын да җөйләргә сәләтле! Күңелдә ачы хатирәләр генә калдырып, алга таба яшәргә көч бирәсең, сәгать текелдәве тавышына акрынлап дәвалый беләсең! Авырлыклар артта кала барган саен, аларның михнәте дә кими төсле, ачыргаланып Ходай каршында әйткән әманәт-тәүбәләр дә үз көчен җуя башлый. Артка әйләнеп карагач, ничек шулкадәр көчсез, мескен булуыңа шаккатасың. Шаккатасың да, тәүбәләреңне читкә куеп, яңа шатлыкларга, назларга үреләсең. Вакыт, вакыт... Син – үзең бер могҗиза, көтә белгәннәргә һәрвакыт җимешләреңне юмарт өләшәсең.

Үзбәк хан да акрынлап элеккеге халәтенә кайта башлады. Диван утырышларында сүзе торган саен ныграк яңгырый, карарлары да кырыслана бара. Берәүләр хакимнең җанлануына шатланса, икенчеләре хафалануын яшермәде – Нәзифә белән Тимербәкнең үлеме аны түшәккә егып салыр дип өметләнүчеләр тәхет тирәсендә җитәрлек иде. Яман күзләр телгәләсә дә, Үзбәк хан бирешмәде.

Тормышның алга таба дәвам иткәнлеген күрсәтеп, Сарай Әл-Җәдидтә янә бер олы туй гөрләде. Бу юлы Котлы Тимернең улы Харунбәк Үзбәк ханның кызы Сөенбикәгә ярәште. Әлеге никах Үзбәк ханның да йөрәген җылытты, Тайдула белән Котлы Тимер арасындагы мөнәсәбәтләрне дә бераз җайлады шикелле.

Фракиягә яу белән барганнан соң, Византия белән Урда арасында тынычлык турындагы солых төзүне сорап, Константинополь патшасы Андроник Өченчедән илчелек килеп төште. Купшы киемнәргә төренгән Мануил атлы илче, хан каршына баскач та, озаклап болгана-болгана башын иде, Урда хакименә баллы мактау сүзләрен җиткерде. Аның гозерен тыңлаган Үзбәк Византия белән солыхка каршы түгеллеген җиткерде. Калганын бөек вәзир һәм диван әһелләре хәл итеп бетерергә тиеш иде. Илчене кабул итү тәмам булуын белдереп, кулын селтәгән ханны Мануил тагын бер үтенече белән туктатты.

– Бөек хан, сиңа Андроник патшадан олы йөкләмә алып килгән идем, – диде ул, әйтерсең лә бүлмәдәге халыкның күплегеннән оялып. – Ул бик нәзакәтле мәсьәлә, бу кадәр кеше алдында әйтсәм, килешерме икән?

– Сөйлә, Мануил илче, минем беркемнән дә яшерә торган серләрем юк.

Мануил, шикләнеп, хан кырында утырган хатыннарга, ханзадәләр белән ханбикәләргә күз ташлады. Аннан, кыюлыгын җыеп, янә ханга текәлде, авызын киң итеп ерып җибәрде.

– Бөек хан, Византия хакиме Андроник Өченче синең белән солых төзеп кенә калмый, туганлашырга да тели!

– Кызык, – Үзбәк ханның куе кашлары өскә күтәрелеп куйды. – Ничек итеп туганлашмакчы була инде ул?

– Бөек хан, Андроник патшаның күз явын алырлык чибәр кызы Мария буйга үсеп җитте. Ул, һичшиксез, синең янәшәңдә үзеңә тиң пар булыр иде...

– Мария дисең... – Үзбәк хан Тайдулага күз ташлап алды. Тегесе шартлар дәрәҗәгә җитсә дә, сер бирмәде, тыныч утыра иде. – Исабәк вәзир, хәзер үк яучылар әзерлә. Аның башында, Бәдретдин казый, син торырсың. Моңа осталыгың зур, бер кызыбызны Мисырга кадәр илтеп, солтанбикә иткән кеше бит син.

Соңгы җөмләсен Үзбәк усал төрттерү белән әйтте – Толымбайны Мисыр солтаны аерып җибәреп, гади бер сугышчыга кияүгә бирүе Урдада һәркемгә дә мәгълүм иде. Моның өчен хан кайвакыт Бәдретдин казыйны тиргәсә дә, башлыча, мыскыллап көләргә ярата.

– Баш өсте, бөек ханым! – дип, урыныннан торды Бәдретдин казый.

– Затлы бүләкләрне ала барыгыз, минем абзарымнан иң шәп атларны сайлагыз, ефәк-парчалар, келәмнәрне кызганмагыз. Патшаң ничек, ару гына хәлледер бит? – дип усал елмайды Үзбәк хан, Мануилга мөрәҗәгать итеп.

– Хәлле, бөек хан, бик хәлле! – дия генә алды каушап калган илче. Патшасын хәерче дип әйтә алмый бит, башка җавабы табылмады.

– Ишеттеңме, Бәдретдин казый?! Константинополь патшасы алтын-көмештә коена икән. Шуңа күрә безнең казнага да бераз өлеш чыгарсын ул байлыкларыннан! – Аннан, җитдиләнеп, янә Мануилга борылды. – Урда дәүләтенең мөселман динен тотуы Андроник патшага мәгълүмдер, шәт?

– Әлбәттә, бөек хан, әлбәттә, без бу хакта хәбәрдар.

– Бик яхшы. Сарай Әл-Җәдидкә килгәч тә, Андроник патшаның кызы ислам дине кабул итәргә, Мария урынына мөселман исемен йөртергә тиеш була. Кызын миңа димләгәнче, синең патшаң безнең тәртипләрне яхшылап өйрәнгәндер бит?

– Әйе, һичшиксез... – дип лепердәде Мануил. Дөресен әйткәндә, Андроник патша аның белән бу хакта фикерләшеп тормады. Әмма Урда ханы әйткәннең һәрбер сүзе белән ризалашу хәерлерәк икәнлеген Византия илчесе күптән аңлаган иде инде.

– Алайса, яучылар әзерләнә башласын. Сиңа, Мануил илче, ак юл телим! Яхшы хәбәр алып килгән өчен казначым сине мулдан бәхилләтер.

Үзбәк ханның күңеле җилкенеп китте. Ул үзен яшь егетләр төсле тоя башлады. Яучылар әйләнеп кайтканны көткән арада өстен-башын карарга кереште, күптән инде кулы тимәгән сакал-мыекларын үзе матур итеп кыскартты. Чапанын яңартырга әмер бирде, яшь хатынга затлы бүләкләр әзерләргә боерды.

Ханның мондый халәтен күргән Тайдула пошаманга төшсә дә, берни дә кыла алмады – хан, элеккечә үк, аны үз янына чакыртмады. Әллә инде аның белән очрашуны мәрхүмә Нәзифәгә хыянәт итеп күрәме? Алайга китсә, Тайдуланың хансарайдагы урыны ахыр чиктә какшарга мөмкин. Андроник патшаның кызы аннан да остарак, аннан да хәйләкәррәк булып чыкса, нишлисе? Бер нәрсә генә Тайдуланың күңелен җылытып тора – ханның ике улын, тәхеткә турыдан-туры варисларны нәкъ менә ул үстерә. Үзбәк, яшь

егетләрдәй, башын югалтып йөрсен, әмма иртәме-соңмы Тайдула барыбер йортта кем хуҗа икәнлеген күрсәтәчәк! Ул да хан төсле үк Константинополь килененең Сарай Әл-Җәдидкә килүен зарыгып көтәргә кереште.

**2**

Хан Марияне тәүге кабат күргәч тә телсез калды.

– Баялун!.. – дип пышылдады ул. Мария аны тәрбияләп үстергән хатынга шулкадәр охшаган иде ки, әйтерсең, ул үлмәгән, яшәреп, кире әйләнеп кайткан. Бүлмәсенең бусагасы төбендә кыяр-кыймас басып торган кыз янына килеп, Үзбәк хан саклык белән аның чәчләрен сыйпады, бармак очы белән иреннәренә кагылып үтте. – Баялун... Син Баялун булырсың...

Мария аны аңламады, юлдан арыганлыгы да сәбәпче булгандыр, тагын да ныграк курка төште. Урда ханын усал һәм кансыз дип сөйләгәннәр иде – килеш-килбәте, чыннан да, куркыныч булып чыкты. Сакал-мыегы, куе кашлары, уттай янып торган күзләре, тирән җыерчыклар белән яргаланган йөзе – бу кыяфәттә бер үк вакытта ир-атларга хас кырыслык та бөркеп тора, икенче яктан чиксез кодрәт һәм үз морадына теләсә нинди юл белән ирешергә әзерлек тә сизелә.

– Мостафа әвнух, тылмачны чакырып керт! – дип кычкырды Үзбәк хан.

Тылмач кергәнче, ул кызга ымлап, табынга утырырга өндәде. Тегесе, бераз икеләнеп торгач, ишеккә таба борылып карап алды да, тәкъдим ителгән урынга юнәлде.

– Ерак юлдан алҗымадыңмы, чибәр кыз? – дип сорады Үзбәк. Аның йөзендә елмаю күргәч, Мария янә гаҗәпләнде – Урда ханы һәрвакыт кырыс һәм усал дигәннәр иде бит.

– Юк, бөек хан, барысы да әйбәт үтте, син җибәргән кешеләр миңа һәрьяклап ярдәм иттеләр...

– Әтиең-әниең исәнлектә калдылармы?

Мария әтисе белән соңгы очрашуын исенә төшерде. Күпме генә елап ялвармасын, Андроник патша аның сүзләрен колагына да элмәде, Үзбәк ханга хатынлыкка җибәрү теләгеннән кире кайтмады.

– Исән-саулар, бөек хан, – дип җавап бирде ул, хатирәләр яңарудан күзләре яшьләнүен тоеп.

– Борчылма, барысы да әйбәт булыр. Минем янәшәмдә син үзеңне чын ханбикә итеп хис итәрсең. Дәүләтем дә, барча яраннарым да синең хозурыңда булыр. Хансараемда сиңа дип, иң шәп бүлмәне әзерләдем. Мәчеткә барып, иман китергәнче рәхәтләнеп ял ит.

Иман китерү хакында ишеткәч, Мария дерт итеп куйды. Үзен кызганудан кычкырып елап җибәрәсе килде. Әмма ул түшендәге хачны гына капшады – әнисенең бүләге, озакламый аны киеп йөрергә ярамаячак...

– Яңа исемең Баялун булыр. Ба-я-лун. Бик матур, үзеңә ятышлы. Сиңа кадәр аны бик булдыклы бер хатын йөртте, ул хәзер мәрхүм. Син аңа бик нык охшагансың. Үз исемен синдәй чибәр хатынга кушуга Баялун хатын рухы күкләрдән шатланып торыр.

– Зур рәхмәт сиңа, бөек хан... – дип пышылдый гына алды Мария.

– Сиңа кичекмәстән ял итәргә кирәк... Мостафа ага! Марияне озатып куй, тамагына ашасын, ни сораса, шуны бирергә әзер тор. – Үзбәк ашыга-

ашыга сикереп торган кызның кулына үрелде. – Никахтан соң зөфаф кичен түземсезлек белән көтәрмен, Баялун!

Мария чыгып киткәч тә, Үзбәк озак кына тынычлана алмый торды. Бүлмәсе буйлап арлы-бирле йөренде, хәмер эчеп карады, ләкин кузгалган гайрәтенә урын таба алмады. Ахыр чиктә ул Мостафа аша үз янына Тайдула хатынны чакыртты.

Йөгерә-йөгерә килгән Тайдула, бүлмәгә керергә өлгермәде, хан аңа яшь юлбарыс сыман ташланды, өстендәге күлмәген чак кына ертып ташламады, бөтен тәнен кайнар иреннәре белән назларга кереште. Үзбәкнең мондый кыланмышын күптән күргәне юк иде Тайдуланың. Үзенә карата шундый кайнар хисләр саклаганына чиксез шатланып, ул иренең кочагына елышты, аның көчле кулларына, ныклыгын югалтмаган тәненә сарылды. Әйтерсең, бүген Үзбәк тәненә шайтан оялаган – көчләре бетте дигәндә генә, янә әллә кайдан табыла, ул, башын югалтып, Тайдуланың сихри тәненә тартыла.

Алар, алҗып, урын өстендә ятканда, тәрәзәдән ай нурлары сирпелә иде.

– Сөекле ханым, мин сине бик нык сагынган идем, моңарчы күрешмәү бәрабәренә бүгенге гайрәтең мине шаккатырды һәм чиксез шатландырды, – дип пышылдады Тайдула, иренең күкрәгенә елышып.

– Мин дә сине сагындым, Тайдула. – Хан, торып утырып, чапанын бөркәнде, табынга юнәлде. – Кил, утыр, тамак ялгап алыйк.

Хатыны каршысына утыргач, ул аңа да, үзенә дә шәраб салды, янә тирән уйга калды.

– Син – минем улларымның әнисе, Тайдула. Олы хатыным дигән сүз.

– Минем өчен бу зур җаваплылык һәм дәрәҗә, сөекле ханым!

– Олы хатын – акыл һәм гыйлем иясе, ханның терәге һәм сердәше дә әле. Хан сиңа көтелмәгән тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, син моңа әзерме?

– Әзер, әлбәттә, әзермен, – Тайдула йөрәгенә шом йөгергәнен тойды, әмма ханга артык сораулар бирмәде.

– Алайса, синнән дустым буларак бер мәсьәләдә ярдәм сорыйм. Мария... Византия патшасының кызы. Ул миннән курка шикелле, мөгаен, Урда ханы турында җыен тузга язмаган сүз сөйләп өркетеп бетергәннәрдер. Зинһар, аны үз канатың астына ал, тынычландыр, акыллы һәм күндәм булырга өйрәт. Моны синнән дә остарак башкарырлык кешем юк.

Тайдула гарьлегеннән табыннан сикереп торып, ишекне шартлатып ябып чыгып китәргә әзер иде, әмма күп еллар буе тәрбияләнгән түземлек бу юләрлектән саклап калды. Аның тәнен назлаганда хан Византия себеркесен күз алдына китергән, димәк. Мария турында хыялланудан иренең гайрәте дә шулай чиктән ашкан. Моңа үпкәләми мөмкин түгел, әлбәттә. Әмма, акыл белән эш иткәндә, һәр нәрсәне дә үз файдаңа аударырга була.

– Әлбәттә, сөекле ханым! Марияне сеңлем төсле кабул итәрмен, үз канатым астына алырмын!

– Баялун.

– Нәрсә?! – Тайдула, аптырап, ханга текәлде.

– Иман китергәч, аның исеме Баялун булачак. Мария аңа нык охшаган.

– Ә... Әйе, мин дә игътибар иттем, сөекле ханым, – диде Тайдула, бераз тынычланып. Мәрхүмә тәрбиячесен ник кинәт искә төшерүен аңламаган

иде, үзенә карата Баялунның үлеменә бәйле шикаять бардыр дип коты алынды. Дөресен әйткәндә, Мариядә андый охшашлык сизмәде, әмма ханның күзенә күренгән икән, хуш, шулай булсын. – Баялун исеме аңа бик ятышлы булыр, синең зирәклегең һәрвакыттагыча таң калдырырлык!

Тайдула ханның әмереннән чыкмады, Мария белән һәрдаим очрашып, күрешеп торды. Дөрес, бер-берсен аңламыйлар, тел белмәү бәласе. Баштарак тылмач аша аралашырга туры килде. Мария шактый чая һәм тиз өйрәнүчән укучы булып чыкты. Акрынлап, ул Тайдула белән аңлаша да башлады.

Мариягә карата Тайдула күңелендә нәфрәт уянмады. Беренче мәлдә ачуы яман иде, әмма кызны якыннанрак белгән саен аны үз итте. Мария дә ханбикәгә күнекте, акрынлап, йөрәк серләрен дә ачты.

Әтисе аны бирегә мәҗбүриләп җибәргән. Мария ханга кияүгә чыгарга бер дә атлыгып тормый.

– Христиан динен мөселманлыкка алмаштырганчы, үлүем хәерлерәк, – диде ул беркөнне Тайдулага.

Тайдула мескен кызга текәлде. Үзенең бала чагы исенә төште. Коллык, аннан соңгы алтын читлек... Ул кесәсеннән букча алып, аның эченнән кечкенә генә агач хачны чыгарды. Учын ачып, Мариягә күрсәтте. Тегесе, шаккатып, бер хачка, бер Тайдулага карады, ни әйтергә белми аптырап калды.

– Динеңне сүздә түгел, күңелдә сакларга кирәк, Мария, – диде Тайдула. – Ходай биргән гомер бер генә, исән калыр өчен кайвакыт иблис белән дә килешү төзергә туры килә. Синең иман китерүеңнән бер җирең дә кителеп төшмәс. Әтиеңнең теләгенә, хан әмеренә каршы бара алмыйсың. Акыллы булсаң, мин сиңа ничек котылырга икәнлеген аңлатырмын. Хәзер исә син, мәчеткә барып, Баялун хатынга әверелергә тиеш. Хан моны түземсезлек белән көтә, ә аның кәефен җибәрергә һич ярамый.

Мария мышкылдап куйды.

– Бер нәрсәне колагыңа киртләп куй – хан, беренче чиратта, башкалар төсле гайрәтле ир-ат кына. Аңа синең бирнәң дә, байлыгың да кирәк түгел. Синең аңа бирерлек бер генә нәрсәң – хатын-кыз назы бар. Шуңа ия булгач та, ул тынычланачак. Ләкин беренче төннән үк үзеңнең салкынлыгыңны күрсәт.

– Нинди салкынлык?

– Кайбер хатын-кызлар салкын булып дөньяга килә. Алар ирләр белән йоклаудан ләззәт ала алмый, хиссез ята бирәләр. Чәбәләнеп, бераз елап алсаң, тагын да шәбрәк.

– Андыйларны хан, ат койрыгына бәйләп, далага озата, диләр...

– Һи, юләр! Тапкансың сөйләр сүз! Безнең хан хатын-кызга бармак очы белән дә тигән кеше түгел. Дошманнарын кансыз рәвештә юк итә, анысы бар. Әмма мин хансарайдагы бер генә хатынның да берәр төрле җәзага тартылганын күргәнем булмады. Тузга язмаган экиятләргә ышанып йөрмә. Күрдең бит, башында акылы, йөрәгендә аз гына намусы бар аның. Үпкәли дә белә, бүләкли дә ала...

– Ятакта файдасыз хатын аңа нигә кирәк соң? Ул мине берәр сугышчысына кулланырга бирмәсме?

– Юк, бу мөмкин эш түгел. Никах укытылганнан соң син – хан хатыны. Ятакта ошамасаң да, урының җылыда, тамагың тук, бер көтү хезмәтчең янәшәдә торыр. Ул яктан ханыбыз гадел һәм юмарт. – Тайдула, бүгенгә җитәр дип, сүзне икенчегә борды. – Муеныңдагы хач, кем бүләге ул?

– Әнием тугач та кидерткән...

– Минекен әти агачтан үз куллары белән уеп ясаган... – Тайдула моңсу күзләрен учына төшерде, аннан тиз генә хачны букчага тыкты. – Хачыңны салып, үзең генә белгән урынга яшереп куй. Вакыты җиткәч, син аны янәдән киеп йөри алырсың. Онытма – чын дини инану хач яисә догаларда түгел. Алланы ярату һәм аңа ышану йөрәк түрендә яшәргә тиеш, ул ялкынны бары тик үзең генә сүндерә аласың...

**3**

Җомга көнне, бәйрәмчә киенеп, нукәрләр һәм җарияләр озатуында мәчеткә барганда, Мариянең күңеле тынычланып калган кебек иде. Ул башын горур тота, тирә-юньгә үзен күреп калырга җыелган халыкка аларның хакиме рәвешендә караш ташлый. Яңа исем кушылганда да, иман китергәндә дә, ул шул халәтен югалтмады. Махсус тегелгән затлы күлмәкләре, асылташлар җемелдәгән муенсалар, алтын-көмештән үреп эшләнгән колак алкалары, һәрбер бармагына кидерелгән балдаклар, ике кулындагы киң алтын беләзек – болар барысы да Баялунга, аның табигый матурлыгына килешеп тора иде.

Үзбәк хан Мариянең Баялунга күчүен хансарайда көтеп торды, шуннан соң гына мәчеткә никах укытырга килде. Ул да бүгенге тантана өчен махсус тегелгән чапанга төренгән, биленә иң кыйммәтле кылычын аскан, башындагы бүреге затлы җәнлектән эшләнгән, баш түбәсе тоташ алтын белән чигүле.

Никахтан соң яшь пар үзәк мәйданга юл тотты. Биредә алар өчен махсус күтәртмә корылган иде. Бер ягы ачык тирмәләргә диван әһелләре, аксөякләр җыелган, каршыда гади халык өчен урыннар хәстәрләнгән. Сый-нигъмәт барча кешегә дә җитәрлек итеп әзерләнде. Үзбәк белән Баялун янына аның башка хатыннары һәм балалары да килгәч, мәйданда баһадирлар ярышуеннарга keреште. Һәрбер җиңүчегә бүләкне хан белән яшь ханбикә үзләре тапшырдылар. Ризык һәм кымыз агыла торды.

Мәйданга килгән һәркемгә яңа гаилә исеменнән бер күлмәклек затлы тукыма кисемтәсе тараттылар, казылык һәм уч тутырып киптерелгән җимеш тапшырдылар.

Вакыт кичкә авышкач, Үзбәк белән Баялун хатын мәйданнан китеп барды. Халык кәеф-сафа корырга калды.

Мостафа әвнух Баялун хатынны хан белән очрашуга әзерләргә кереште. Аңа ярдәмгә җарияләр килде. Киленне хуш исле үләннәр салынган сулар белән яхшылап юындырдылар, өстенә буй-сынын ассызыклап торган ефәк күлмәк кидерделәр. Чәчләрен үрергә маташсалар да, Баялун килешмәде – аларны тузгыткан килеш калдырды. Янында бөтерелгән кызларга ул бер генә сүз дә әйтмәде, кыяфәте таштай хиссез рәвештә кала бирде.

Хан бүлмәсе бусагасыннан да ул әнә шулай язмышына буйсынган халәттә шатлык яисә хафалану белдерми атлап керде. Үзбәк аны табынга

утырган килеш көтә иде. Урда хакиме, кулы белән ымлап, кызны янәшәсенә чакырды. Баялун әлеге әмерне карусыз үтәде.

– Шәрабның иң татлысын әзерләдем сиңа, Баялун хатын, – диде хан, үз куллары белән көмеш чәркәләргә эчемлек агызып.

– Рәхмәт, бөек ханым, синең юмартлыгың әйтеп бетергесез...

– Бүгенге тантана күңелеңә хуш килдеме? Мин һәммәсен дә затлы һәм купшы итеп оештырырга тырыштым, син тараткан бүләкләр хакында халык әле бик озак сокланып сөйләр.

– Хуш килде, сөекле ханым...

– Бүген, ниһаять, кавышуыбыз өчен, минем гүзәл ханбикәм! – Хан чәркәсен югары күтәрде, ләкин Баялун аңа кушылырга ашыкмады. Бераз дәшми торгач, кыз үксеп елап җибәрде. – Ни булды тагын, Баялун, ник елыйсың?!

Мария-Баялун аңа кияүгә чыгуына тәмам күнгән, Урда ханбикәсе урынын алуына күңеле белән ризалашкан дип уйлаган иде Үзбәк, тик ялгышкан булып чыкты. Ул, кәефе кырылып, чәркәсен өстәлгә куйды.

– Гафу ит, сөекле ханым, мин әлегә бүгенге вакыйгаларны башыма сыйдырып бетерә алмадым...

Үзбәк кызга тартылды, аны назларга маташты, әмма тегесеннән үзенә карата җавап хисләрен тоймады. Ул төн хан гомерендә иң авыры булгандыр, мөгаен. Күпме генә тырышмасын, нәзберек кыланырга теләмәсен, Баялун хатынның күңелен эретә алмады. Таң беленгәндә, ул үксеп елаудан йөзе шешенеп беткән кызны Мостафага тапшырды.

Әвнух кергәнче, Үзбәк хан, алай да, яшь хатынына үзен борчыган сорауны бирергә өлгерде:

– Баялун, мин синең өчен шулкадәр җирәнгеч кешемени? Бер генә талпынышыма да синең яктан хәерхаһлык күрмәдем...

– Гафу ит, сөекле ханым, сәбәп синдә түгел, минем үземдә. Ни кызганыч, мин тумыштан җенси уеннарга салкынмын, күрәсең, әтиемнең гөнаһлары өчен Ходай мине шул зәхмәт белән тамгалагандыр...

– Ләкин мондый нәрсә мөмкин түгел!

– Минем кебекләр табигатьтә сирәк очрый. Сине һич кенә дә үпкәләтәсем килмәде, әмма язмышыңа каршы барып, тәнеңне үзгәртеп булмый шул. Барлык шәфкать-мәрхәмәтең, миңа карата сакчыллыгың өчен олы рәхмәтем сиңа, бөек хан!

Кызны Мостафа алып киткәч тә, хан үз тарафына Ибраһим табибны дәште. Аңа барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде, Баялунны әйбәтләп дәваларга боерды. Тик табибның йөзе өметсез иде.

– Бөек ханым, кичерә күр, әмма Баялун әйткәннәр чыннан да була торган хәл. Хатын-кызның ир-атка карата салкынлыгына, гыйшык уеннарына битарафлыгына дәва әлегә кадәр табылмаган. Ул, мөгаен, Аллаһы Тәгалә җибәргән җәзадыр. Минем аңа ярдәм итәрлек кодрәтем юк...

Үзбәкнең күңеле янә төште. Яраткан тәрбиячесе Баялунга бер тамчы судай охшаш Мария аңа, киресенчә, Аллаһының рәхмәте билгесе булып тоелды бит. Ул аның янәшәсендә тынычлык табар, тәхеткә утырганнан бирле каударланган җанына шифа иңәр дип өметләнде. Ләкин бусы да юк хыяллар булып чыккан икән...

Тайдула хатын берничә көннән соң Баялун янына килде, кызның сөйләгәннәрен игътибар белән тыңлады. Византия патшасының кызы бик төпле шәкерт булып чыгуына эченнән генә чиксез шатланды. Ханның Баялунны башка үз янына төн кунарга чакырмавын да яхшыга юрады.

**4**

Чиксез далаларны, киң елгаларны кичеп, Урда ханы Бештау итәгенә чираттагы җәйләүгә юл алды. Юлда барганда да, олауларда тормыш кайный бирә. Зур көпчәкле арбаларга урнаштырылган күчмә мәчетләрдән азан тавышы яңгырый, асылмалы казаннарда таралып китеп, ит пешеп килә, бара-барышка халык алыш-биреш итәргә, гашыйк булырга, бала табарга өлгерә. Җәйгә чыгу – барысы өчен дә үзгә халәткә күчү вакыты. Дөнья җанлану белән кешеләр дә кышкы йокыдан уяна, кояш җылысы якты хыялларына, ак өметләренә үсенеп китәргә булыша сыман.

Хан, урдасы белән бергә юлда булуына карамастан, дәүләт эшләреннән һич кенә дә аерылмый. Аның алтын очламлы тирмәсе хәрәкәт итә бирә, бара-барышка ул чакырткан әмирләр җәһәт кенә арбага сикереп менәләр, тез чүгеп, хаким каршына басалар.

Үзбәк хан үз янына Бәдретдин казыйны чакыртты. Тегесе, икәүдән-икәү сөйләшү көтелгәнен аңлагач, сүзнең җитди, чит-ят колаклардан ерак торырга тиешлеген аңлады.

– Бәдретдин ага, сине бирегә дәшүем мәмләкәтәбез тормышына кагылмый. Шәхси эшем турында киңәшләшергә ниятлим.

– Бөек хан, миннән бер генә серең дә читкә чыкмас, бу мәсьәләдә тыныч була аласың.

– Беләм, Бәдретдин ага, нәкъ менә сине сайлавым да шуның билгесе. – Үзбәк хан көрсенеп куйды. – Баялун хатын хакында фикерең ничегрәк?

Бәдретдин ага бераз сүзсез торды. Чыннан да ни уйлаганын әйтергәме, әллә хан ишетергә теләгән баллы сүзләр белән генә чикләнергәме? Хакимнең алдан ук ачыктан-ачык сөйләшүгә өметен истә тотып, казый турысын ярып салырга карар кылды.

– Кызганыч ки, бөек ханым, Баялун хатын синең аңа карата кылган яхшылыкларны кабул итә белмәде кебек. Ул еш кына намазын калдыра, холыксызлана, җарияләренә үзенең кол хәлендә яшәвен дә әйтеп ташлаган вакытлары бар. Гәрчә син аны балда-майда йөздерсәң дә...

– Әлеге хәбәрләр миңа да килеп ирешә, Бәдретдин ага.

– Алар хакында бөтен хансарай белә төсле, кара халык арасына да имеш-мимешләр таралуы мәгълүм. Һичшиксез, Баялун хатынның мондый кыланмышлары синең дәрәҗәңне төшерә. Туры әйткән туганына ярамаган ди, бөек ханым, тупаслыгым өчен гафу ит.

– Тупаслык түгел бу, Бәдретдин ага. Алдашу белән уяулыгымны бишектә йоклатырга маташкан бәндәләр болай да җитәрлек, синең кебек кешеләрем бармак белән генә санарлык... Бәдретдин ага, әгәр мин Баялунны талак әйтеп аерып җибәрсәм?!

– Коръәндә язылган шартлар үтәлгән очракта бу мөмкин гамәл, бөек ханым. Тик Византия патшасы ни дияр?!

– Византия патшасы каршында хисап тотасым юк, кызын тәрбиялисе

булган! Җәйләүгә тукталгач та, бу мәсьәләгә соңгы ноктаны куярмын, Аллаһы боерса. Хатын аеру өчен мин кемнәндер ризалык сорарга тиешме?

– Коръән таләпләре үтәлгән очракта син ризалыкны бары тик Ходайдан гына сорарга тиеш, бөек ханым.

– Рәхмәт үзеңә. Мине ялгыш карар кабул итте дип уйламыйсыңмы? Хатынын аерган хакимгә тискәре мөнәсәбәт тумасмы?

– Ирен ир, динен дин, телен тел итмәгән хатынан ваз кичү, киресенчә, синең даныңны гына арттырыр, бөек ханым!

Биштау итәге төбенә килеп җиткәндә, Үзбәк хан Баялун хатын мәсьәләсен үзе өчен ахыргача хәл иткән иде. Ханның эчке халәтен бик сизгер тойган Тайдула хатын да атлаган саен Баялунны яманлаудан туктады.

Җәйләүгә туктагач, бирегә чит җирләрдән Ибн Баттута атлы сәяхәтче килүе мәгълүм булды. Хан аны кадерле кунак рәвешендә кабул итте, һәрбер хатыны белән аерым-аерым очрашып гәпләшергә ризалыгын бирде. Баялун хатын бирeдә дә үзенең кире холкын күрсәтергә өлгерде – сәяхәтче кергәч тә, ул, туган ягын өзелеп сагынуын сөйли-сөйли, үксеп еларга кереште. Әлеге очрашудан соң Үзбәк хан Баялун хатынны үз тарафына чакыртты.

– Баялун, син Ибн Баттута каршында күз яшьләреңне агызып утыргансың, шул сүз дөресме? – дип сорады хан кырыс тавыш белән.

– Гафу ит, сөекле ханым, мин тыелып кала алмадым.

– Тыелмадың, димәк... Ни кызганыч, бөек хан өчен лаеклы хатын синнән барып чыкмады, Баялун. Сәяхәтче, белүемчә, Константинополь ягына кузгалырга ниятли. Мин сине аңа ияртеп, әтиең янына кайтарып җибәрергә карар кылдым. – Хан торып басты. Бүлмәдә Исабәк вәзир, Бәдретдин казый, уллары Тәнибәк белән Җанибәк кенә бар иде. Ул аларны күздән кичерде, аннан барысы да ишетерлек итеп:

– Талак! Талак! Талак! – диде.

Һәммәсе дә тын калдылар. Берни аңламаган Баялун хатын ханга зур итеп ачылган күзләрен төбәде. Аларда мөлдерәмә яшь иде. Аннан ул идәнгә егылып үкереп елый башлады.

– Зинһар, сөекле ханым, мине үлемгә юкка хөкем итәсең, кичер мине! Мине җәллад кулына тапшырма, үтенеп сорыйм.

– Торып бас, Баялун, тынычлан, – диде кырыс кыяфәтле хан, идәндә аунап яткан Баялунга өстән аска карап. – Мин сине үлемгә хөкем итмәдем. Син бу мизгелдән минем хатыным булудан туктыйсың. Әйберләреңне җый, юлга әзерлән. Син әтиең янына кайтасың, моннан ары Урда синең торган җирең булудан туктый. Исабәк вәзир, казначым Баялунга мул итеп алтын-көмеш, атлар, коллар бирсен. Андроник патшага да өлеш чыгарыгыз. Байдар әмир җитәкчелегендәге биш меңлек нүкәрләр төркеме Баялунны һәм Ибн Баттута сәяхәтчене Константинопольгә кадәр озатсын. Андроникка минем чиксез рәхмәт сүзләрем язылган хат әзерләгез. Византия хакиме борчылмасын – хатынлыкка холыксыз кызын җибәрүдән ике арадагы солыхыбыз бозылмас.

Үз колакларына үзе ышанмаган Баялун, мышкылдап, идәннән торды. Бүлмәдәгеләр каршында оят иде, әмма узган эшне кайтарырлык түгел.

– Бөек хан, гафу ит, мин ислам тәртипләрен белеп бетермәү аркасында сине дөрес аңламаганмын...

– Син ул тәртипләрне кабул итмәдең, гаеп үзеңдә генә. Юлыңда бул, Баялун хатын, бүтән сиңа әйтер сүзем юк.

Урда ханының хатын аеруы хәбәре стан буйлап яшен тизлегендә таралды. Мостафа әвнух яңалыкны сөйләп биргәч тә, Тайдула, бар эшен ташлап, Баялун тирмәсенә ашыкты.

Баялунны алыштырып куйганнар, диярсең – йөзенә нур иңгән, иреннәренә елмаю кунган. Тайдуланы күргәч тә, ул, дөньясын онытып, аны кысып кочаклап алды.

– Сабакларың өчен рәхмәт сиңа, Тайдула! – диде ул, аннан сандыгыннан затлы муенса чыгарып, ханның хатынына сузды. – Син мине тәрбияләмәсәң, бүгенге көнне күрү насыйп булмас иде!

Тайдула каушап калды. Аның өчен Үзбәкнең хатынын аерып, кире туган ягына кайтарып җибәрүе бөтенләй көтелмәгән, гайре табигый вакыйга бит. Баялунны яманлап, аннан ханның йөзен чөерергә генә теләде ул. Кире хатын янәшәсендә үзенең дәрәҗәсе тагын да арта, Баялун белән чагыштырып, Үзбәк Тайдуладан ничекләр уңганлыгына инана бара иде. Хәлләрнең бу кадәр үк кискен борылыш аласын башына да китермәде. Алтын читлектән котылган кызның шатлыгын күреп, йөрәге кысылып куйды. Баялун бирешмәде, иреккә омтылды, морадына иреште. Ә Тайдула? Тайдула да шул ук тозакта бәргәләнә бит, тик ул күндәмлек, бар нәрсәгә буйсыну юлын сайлады. Үзе дә искәрмәстән, Тайдула йөрәген Баялунга карата көнләшү хисе телгәләп үткәнлеген сизде. Кара көнләшү иде бу...

– Баялун хатын, синең шатлыгыңны уртаклашам, халәтеңне бик әйбәт аңлыйм, – дип кенә әйтә алды фикерләре чуалып киткән Тайдула. Аннары ул, юлга җыенырга комачауламыйм, дигән булып, үз тирмәсенә атлады...

Зур кәрван рәвешендә төзелгән Баялун олауларын Үзбәк хан беренче ямчыларга кадәр озатты, сәяхәтче Ибн Баттута белән бик җылы саубуллашты, янә Урда җирләренә килергә чакырды. Баялунга саубуллашу сүзләрен әйткәндә, тавышы салкын иде. Аерып җибәргән хатынының күкрәгендә янәдән ялтырап торган хачны күргәч, сүзен озакка сузмый, атын борды һәм станына таба юл алды.

## 5

Үзенең күңелен кайтарган кешеләрне Үзбәк хан бик тиз йөрәк түреннән сызып ташлап, мәңгелеккә онытырга сәләтле иде. Бу сыйфаты аңа башыннан үткән күпсанлы канкоешларны җиңел генә кичерергә ярдәм итте. Баялун-Мария да, кирелек күрсәтеп, аның өчен якын кешеләр рәтеннән бик тиз төшеп калды.

Ул елгы кышны Хаҗитарханда үткәрергә карар кылган Үзбәк ханның башында инде бөтенләй үзгә уйлар өере купкан иде. Көннәрнең берендә Исабәк вәзир хан янына күзгә-күз очрашу өчен Хулагу илханнары илендә шактый зур кодрәткә ия нәсел вәкиле – Әмир Чәбәннең улы шәех Хөсәен талпынуын хәбәр итте. Үзбәк хан уйга калды. Әмир Чәбән – Урданың кан дошманы. Әмма ул, Хулагу Иранының хәзерге илханы Әбү Сәед белән сүзгә кереп, үлемгә хөкем ителгән иде. Әбү Сәед аның улларын да аямаган. Дөрес, дүртесенең икесе качып котыла алган – шуларның берсе, шәех Хөсәен, Урдада сыену урыны тапты.

Әмир Чәбәннең тагын бер гүзәлләрдән гүзәл кызы бар – чибәрлеге белән бөтен дөньяны таң калдырган Баһдад хатын. Аны, яшьли гашыйк булып, Әбү Сәед үзенә хатынлыкка алган. Баһдад хатынны бик кодрәтле һәм ирен учында биетеп тора торган ханбикә дип сөйлиләр. Менә хәзер шәех Хөсәен шул Баһдад хатыннан Үзбәккә генә ирештереләсе хат алып килүен җиткергән.

Үзбәк хан Хөсәенне үз тарафына кертергә әмер бирде.

Бусагадан атлау белән тез чүгеп, Хөсәен Урда ханына чиксез мактау һәм соклану сүзләрен ирештерде.

– Ни йомыш белән йөрүең, шәех Хөсәен? Урдада үзеңне кыерсытучы юктыр бит? – диде йокымсыраган кыяфәтле хан, кызыксынуын күрсәтмәскә тырышып.

– Мөхтәрәм ханым, сиңа үземнең сеңлем Баһдад хатыннан хат алып килдем. Аны сиңа үз кулларым белән тапшырырга тиешмен.

– Укы хатыңны.

Шәех Хөсәен Исабәк вәзиргә караш ташлады, ни әйтергә белми берара таптанып торды, аннан соң ханга куркулы күзләрен юнәлтте.

– Бөек хан, синең янәшәңдә иң ышанычлы кешеләр генә җыелганы мескен колыңа яхшы мәгълүм. Әмма сеңлем бу хат бары тик синең колакларыңа гына ирештерелергә тиеш дип үтенде.

Хан уйга калды, аннан Исабәккә борылды.

– Синнән серем юк, бөек вәзир, әмма гүзәл хатын-кызларның гозеренә хәтта бөек хан да каршы килә алмый. Авыр булмаса, чыгып тор, аннан дәшәрмен үзеңне.

Исабәк киткәч, шәех Хөсәен, хатны чыгарып, пышылдап диярлек укырга кереште:

– «Дөньядагы хакимнәр арасында иң бөек хаким, җир йөзендәге ирләр арасында иң гайрәтле ир, тиңе булмаган Урда ханы Үзбәк хан! Ошбу хатны сиңа Иран илханының хәләл җефете Баһдад хатын яза. Мәгълүмдер ки, дәүләтебездә бүген бер генә тыныч көн дә юк. Әбү Сәеди илхан башта минем әтием Әмир Чәбәнне астыртын рәвештә үлемгә дучар итте. Гәрчә, Әбү Сәед әтиемә мәңге бурычлы булса да. Минем ике бертуганым да аның җәлладлары кылычыннан һәлак булдылар. Син гомер-гомергә безнең җирләргә битараф калмадың. Хактыр ки, Хулагу биләмәләре Урданың бер өлеше. Һәм, хакыйкатьне торгызып, аларны синең хакимлеккә кайтарыр вакыт җитте. Мин үз тарафымнан барлык мөмкинлекне дә кулланырмын, сиңа илханнар пайтәхетендә торып ярдәм итәргә тырышырмын. Әгәр безгә яу белән кузгалсаң, синең өчен тәхетне бушатып куярмын. Илханнар тәхете сине зарыгып көтә, мөхтәрәм Үзбәк хан!»

Хат тәмам булгач, Хөсәен шәех Үзбәккә текәлде. Тегесе почмактагы бер ноктага карап, тирән уйга баткан иде.

– Ничек итеп тәхетне бушатырга тели ул? – дип сорады, ниһаять, Урда хакиме.

– Нәселебезнең Әбү Сәедкә карата үпкә-ачуы бик зур, бөек ханым. Ул безнең асыл ир-атларыбызны, дәүләткә армый-талмый хезмәт иткән әтиебезне үтерде. Үлемгә үлем белән генә җавап бирергә мөмкин. Минем сеңлем Баһдад хатын Әбү Сәед янәшәсендә, ул кулай вакыт килеп җиткәнен

генә көтеп торды. Хәзер илханның җанын җәһәннәмгә олактыру өчен иң җайлы мохиттер...

– Әгәр аның теләге барып чыкмаса? Минем шымчыларга ышансаң, Әбү Сәед Баһдад хатынга элеккечә җылылык күрсәтми, шашып сөюнең эзе дә калмаган, диләр. Ялгышмасам, илханыгыз хәзер Дөлшат атлы бер хатын белән чуала икән...

– Анысы хак, бөек ханым. Әмма Баһдад – илханның олы хатыны, һәм бу дәрәҗәдән читләштерелмәде. Аның өчен сарайдагы һәрбер ишек ачык...

– Син арадашчы буларак килдеңме?

– Әйе, минем илханнар җирендә күпсанлы тарафдарларым бар. Алар Әбү Сәеднең үлемен зарыгып көтеп торалар. Тәхеттә сине күрергә теләрләр иде.

– Исабәк! – дип кычкырды хан. Вәзир шунда ук бусагадан атылып кереп җитте. – Гаскәрне җый. Без Иран илханнарына яу белән барабыз. Һөҗүмне үзем җитәклим, уң канатка Тәнибәкне билгелә.

– Сөекле ханым, кышка кергәндә сугыш башлау дөресме икән... – дип лепердәргә маташкан Исабәкне Үзбәк бер күз карашы белән туктатты.

– Хөсәен шәехкә казнадан акча бирегез. Ул бүгеннән дәүләт эшенә алына.

Үзбәк күңелендә чиксез дулкынлану хисен тойды. Аның мәңгелек хыялы – илханнар җирен яулап, Урдага кушу – янәдән яңарды, онытылган төсле тоелса да, янә тормыш мәгънәсенә әверелде. Үзбәкне, чиксез байлыклары белән дан казанган җирләрдән тыш, күпсанлы бәяннарда телгә алынган, ымсындыргыч Баһдад хатын да көтә иде. Кара көзгә карамый, Урда ханы, берничә йөз меңлек гаскәрен ияртеп, янә Кавказ аръягына таба кузгалды.

Саубуллашканда, Тайдула күз яшьләрен яшермәде:

– Тәнибәкне хәзердән үк сугышка ияртеп, гаскәр башы итеп билгеләп ашыкмадыңмы, сөекле ханым? – диде ул, сулкылдый-сулкылдый ханның күкрәгенә елышып. – Ул әле бала гына бит...

– Нинди бала булсын, чын ир-егет, күрче, төмәннәр каршында атын ничек биетә! – Үзбәк, сокланып, Тәнибәккә карады. Үзенең яшь чагын исенә төшерде – ул да беренче сугышына әнә шулай дулкынланып, дөньясын онытып әзерләнде ләбаса. Тәнибәктә аның чалымнары бик аермачык күренә – төз гәүдәсен кыягы кысып алган, кулындагы чукмары өскә күтәрелгән саен беләкләрендәге көч уйнаклаганы күренә. – Ул – минем олы улым, Тайдула. Без синең белән яшәрмибез, гомер уза. Хәрби һөнәргә дә өйрәнә торсын.

– Бөек хан, мине кайчан сугышка алып барырсың икән? – дип, сүзгә кушылды Җанибәк. Үзбәк хан, авыр хәрби киемнәре комачаулауга да карамастан, кечкенә улы каршында чүмәште.

– Сиңа да чират җитәр, Җанибәк ханзадә. Ә хәзергә син әниең янәшәсендә, Урда ханы урынына каласың. Мин югында син хаким булырсың, аңладыңмы?

Ханның шаяртуын Җанибәк әллә аңлады, әллә юк, әмма хан урынына калып торуын ишеткәч, бермә-бер җанланды, күкрәкләрен киереп куйды.

Кавказдагы Тимер Капка янына Урданың төрле якларыннан Үзбәк чакыруы буенча төмәннәр агылды. Әйтерсең, бу ташкын таулардагы тарлавыкларга сыймас, аларны ватып-җимереп, үзенә юл ачар.

Баһдад хатын белән хат алышулар Үзбәк хан өчен мавыктыргыч

бер уенга әверелде. Гүя аларның аралашуы кәгазь битендә түгел, ә чынбарлыкта, кара-каршы утырган рәвештә бара. Үзе дә сизмәстән, Урда хакиме ерактагы Баһдадка гашыйк булды төсле, аның кыяфәтен күз алдына китереп, төннәрен саташып чыга, Хөсәен шәехне чакырып, озын-озаклап бертуганы хакында сораштыра. Тегесе ханның күңелен тагын да ымсындырырга маташа шикелле – тасвирлау чараларында шәрыкча купшы сүзләрне кызганмый кыстыра.

Озакламый Үзбәк хан станына Баһдад хатыннан чираттагы хәбәр килеп төште – Әбү Сәед кинәт вафат булган, Илханнар дәүләтендәге әмирләр аның урынына кемне утыртасын хәл итә алмый, бәхәсләргә батып беткән.

– Сер итеп кенә әйтим, бөек ханым, – дип пышылдады Хөсәен шәех, – Әбү Сәеднең үлеме бер дә очраклы түгел. Синең белән көрешүне тизләтер өчен минем бертуганым Баһдад хатын аның ризыгына агу кушкан.

– Синең нәселнең хезмәтен онытмам, Хөсәен шәех. Хәзер исә, Әбү Сәеднең үлеменә бәйле ыгы-зыгы чорын кулдан ычкындырырга һич тә ярамый. Кичекмәстән Тимер Капка аша чыгып, илханнар дәүләтенең гаскәрләрен тар-мар итәргә кирәк.

Үзбәк хан гаскәре якын тору илханнар илендәге әмирләрне акылга килергә, үзара ызгышларын читкә куеп, дәүләт хакына килешергә мәҗбүр иткән бугай. Бушап калган тәхеткә Арпа-ханны утырткannar, ашык-пошык күтәрмә тантанасы үткәргәннәр. Арты белән илханнар тәхетен җылытырга өлгермәгән Арпа-хан, гаскәрен җыеп, Кавказ якларына, Үзбәк хан төмәннәренә каршы кузгалды.

Арпа-хан туплаган сугышчылар Үзбәк хан төмәннәренә караганда азрак иде. Әмма таулар арасындагы тарлавыкларда сугыш алып бару санга түгел, ә бәлки хәрби осталыкка нигезләнгән. Киң далаларда эш итәргә күнеккән Урда нүкәрләре өчен мондый шартлар ят, алар иркенлекне ярата. Беренче бәрелешкә шактый зур тигезлектә кергәч, Үзбәк хан эченнән генә шатланып куйды.

Үзе ул орышны калкулыктан күзәтә. Биредән барысы да уч төбендә төсле. Менә аның атлы яугирләре, олы бер түгәрәккә басып, бөтерелергә керешге. Алдагылары, атта юртаклап килгән шәпкә укларын дошман өстенә юллый, алардан соң килүчеләре дә шул ук гамәлне кабатлый. Бер урында әйләнеп торып, бертуктаусыз ук яңгыры яудыручы олы боҗра барлыкка килә. Моңа түзә алмый, Арпа-ханның алдынгы рәтләре какшады, алар акрынлап чигенергә мәҗбүр булды.

– Уң канат белән сул канатны сугышка кертегез, – дип боерды Үзбәк хан.

Янәшәсендәге сөрәнче, олы мөгезне күтәреп, өч тапкыр яман каты тавыш чыгарды. Ул, як-яктагы тауларга бәрелеп, мең төрле кайтавазга әйләнеп, яу кырындагы нүкәрләр колагына ирешге. Укчылар шунда ук артка борылдылар. Моны күргән Арпа-хан яугирләре аларны куа китте. Шул ук мизгелдә уң һәм сул канатта поскында торган Урда нүкәрләре аларга ике яктан һөҗүм итте. Укчыларны куа чыккан дошман атлыларының язмышы хәл ителгән иде. Камалышта калган яугирләрне кысрыклап китереп, тураклап ташладылар.

Үзбәк хан елмаеп куйды. Беренче кечкенә генә җиңү аның ягында иде.

Кинәт уң канат, төп гаскәрдән аерылып, чигенгән Арпа-хан сугышчыларына таба юнәлде.

– Әстәгъфирулла, нишлиләр болар?! – дип, коты алынып пышылдады Үзбәк хан. Иң алда очламында кызыллы-сарылы чуклар җилфердәгән сәргаскәрне күргәч, бөтенләй дә һушсыз калды. – Тәнибәк! – дип, яман тавыш белән кычкырды хан, биредән улы аны ишетмәвен белсә дә. – Гаскәреңне бор, Тәнибәк!

Сөрәнче, хан әмерен үтәп, мөгез тавышы белән хәбәр җибәрде, әмма кан исен тойган уң канат әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә, колак салмаска булды. Ул арада Арпа-ханның поскындагы атлылары ике яктан килеп чыгып, Урда нүкәрләренә таба яшен тизлеге белән якынлаша башладылар. Әлегә кадәр орышта катнашмаган сугышчыларның көче ташып тора, мәрхүм иптәшләре өчен үч алу теләге каннарын кыздырган.

– Тотлак-Тимергә әмер бир, уң канатны коткарсын! – дип, җан ачысы белән кычкырды Үзбәк хан.

Мөгез-быргы янә телгә килде. Тотлак-Тимер Тәнибәкнең бер өлеш гаскәре белән инде тәмам камалышта калуын күрде. Мондый очракта нүкәрләргә, гадәттә, ясин гына чыгасы да бит, уң канат башында хан углы торганлыгын әмир бик яхшы белә. Ул, Урда хакименең әмерен үтәргә ашыгып, яугирләрен үз артыннан дәште.

Күп кан агуын, шактый нүкәрләренең һәлак булуын Үзбәк хан югарыдан сүзсез генә күзәтте. Тәнибәкне көч-хәл белән камалыштан алып чыга алдылар. Моның өчен шактый Урда егете яу кырында башын салды. Уң канат та, сул канат та йончыган, дошман тарафыннан нык таланган иде. Ике гаскәр дә кире үз станнарына кайтты. Тауларга тиз арада караңгылык, аның белән салкын һава иңде. Әле анда, әле монда учаклар кабынды, сәргаскәрләр, төмәнбашлар бу көннең югалтуларын санарга, яралыларны барларга кереште.

– Исабәк вәзир, мин уң канат станына барам, – диде Үзбәк хан, атына атланып. Үзенә бирелгән ризыктан ул авыз итмәде, йөзе кара, ачулы иде. – Беркемгә дә әйтмәгез, Тәнибәк тирмәсенә кисәтүсез керәсем килә.

Уң канатның төп тирмәсе янына җиткәч, Үзбәк ияреннән төште, башкаларга шауламаска боерып, уң кулын өскә күтәрде. Аннан, шымчылардай сак кына басып, тирмә ишеге төбенә килде. Ике сакчы нүкәр тез чүгәр алдыннан, Үзбәк, бармагын ирененә китереп, дәшмәскә кушты. Тегеләре, гаҗәпләнсә дә, ханның әмеренә буйсынды.

Төп тирмәдә, әйтерсең, бүгенге канкоешны күрми дә калганнар. Аннан килгән тавышларга караганда, кәеф-сафа коруның кызган чагы, гаскәр башлыклары нindидер зур җиңүгә чиксез шатланалар төсле.

– Ханзадә Тәнибәк, син бүген үзеңне чын яугир, курку белмәс сугышчы итеп күрсәттең! Без синең кул астында теләсә кайсы дошманны тар-мар итәргә әзер! – диде берсе, калганнары да аңа кушылды.

– Бераз гына җитмәде, сиңа күбрәк төмән бирсәләр, Арпа-ханны әллә кайчан куып җибәрер идек. Тотлак-Тимер әмиргә төмәннәрне кызганмаганнар әнә...

– Яңа җиңүләребез алда әле, Тәнибәк ханзадә!

Тәмам шартлар дәрәҗәгә җиткән Үзбәк хан тирмә бусагасын атлап

керде. Аны күргәч, эчтәгеләрнең йөзендәге елмаю юк булды. Агарынган Тәнибәкнең кулындагы чәркәсе төшеп китте. Ул, калтыранып, хан каршында тез чүгәргә ашыкты. Тирмәдәгеләр дә башларын иеп, идәнгә егылдылар.

– Барыгыз да күземнән югалыгыз! – дип боерды Үзбәк хан. Гаскәр башлыклары, абына-сөртенә, тирмәдән чыгып китәргә ашыктылар.

Урда хакиме улына якынлашты. Аның чал төшкән кашлары җыерылган, йөзендәге җирәнү катыш ачу хисе усал төсмер алган. Менә хәзер билендәге хәнҗәрен тартып чыгарыр да баласын суеп ташлар төсле.

Тәнибәк әтисенә яшьле күзләрен күтәрде.

– Гафу ит, бөек ханым, сабыйлыгым белән мавыгып китүемне сизми дә калганмын...

– Сабыйлык?! – Үзбәк ханның борынына Тәнибәк авызыннан хәмер исе китереп бәрде. – Сабыйлар хәмер эчәмени, тинтәк?! Синең гаеп белән башларын салган нүкәрләрне җирләргә дә өлгермәдек бит! Нинди җиңүне бәйрәм итәсең, мөртәт?!

– Җиңү түгел, бөек ханым, кайгыдан хәмер эчтек...

– Хәмердән бигрәк янәшәндәгеләрнең баллы мактау сүзләре куркынычрак, сарык мие! Алар синең колакларыңны чукрак, күзләреңне сукыр итә. Дөньяда бихисап кеше шундый буш мактауга ышанып, үзләрен, гомерләрен, дәүләтләрен югалтты. Син ишәк төсле колакларыңны салындырып, авызыңны ерып, шуларны тыңлап утырасың, дала күсесе! Бүген үк әниең итәге астына кайтарып җибәрәм, миңа мондый сәргаскәр кирәк түгел! Син – дошманнан да куркынычрак! Минем әмерләрне үтәмисең, нүкәрләрне үлемгә ияртеп барасың, аннан башыңны югалтып, ләх булганчы хәмер чөмерәсең!

– Бөек ханым, үтенеп сорыйм, бу ялгышлыгымны гафу ит! Бүтән синең сүзеңнән чыкмам, хәмергә кагылмам!.. – Тәнибәк, үксеп елап, Үзбәкнең күн читегенә ике куллап ябышты. Хан, улының мондый мәсхәрә хәлдә ятуына чирканыч караш ташлады, аннан Тәнибәккә тибеп җибәрде.

– Син дәүләтебез тәхетенә менеп утыргансың бугай инде. Ханыңны санга сугу да юк. Бүгенге орыш тәмамлангач та, башыңны иеп, минем тарафка гафу үтенергә килергә тиеш идең. Тотлак Тимернең аяк астындагы җирне үбә-үбә, аңгыра башыңны коткарып калганы өчен рәхмәт укырга иде. Ә син, кәеф-сафа корып, мактанып, шатланып ятасың. Синең өчен миңа гаскәрем алдында оят, Тәнибәк!

– Бүтән кабатланмас, бөек ханым, ант итәм! Әгәр берәр ялгышлык кылсам, миннән ваз кичә аласың, үпкәләмәм. Әмма олы ялгышымны яу кырындагы гамәлләрем, сиңа тугрылыгым белән төзәтергә мөмкинлек бирә күр!

Үзбәк хан, улының ихлас күз яшьләрен күреп, эри төште. Баласыннан ваз кичмәс ул, әлбәттә. Аның сүзләре Тәнибәкнең йөрәгенә сеңде шикелле.

– Соңгы мөмкинлек, Тәнибәк! – Үзбәк ханзадәне үз куллары белән идәнгә бастырды. – Хәмердән айны, сул ягыңнан котыртып торучы шайтаннан да куркынычрак куштаннарның сүзен тыңлаудан тукта. Мин сине уң канатка сәргаскәр итеп калдырам, ләкин кабат ялгышсаң, кичерү юк!

Тирмәдән Урда хакиме тынычланган төсле чыкты. Бусага төбендә тезләнгән түмән башларын күздән кичерде дә сүзсез генә үзенең атына

юнәлде. Аны озата килгән аксөякләр сораулар бирмәде, хакимнәренә иярделәр.

Алдагы көннәрдә уңыш Үзбәк хан ягында иде. Аның гаскәре, Арпа-ханны кысрыклап, чиктән ары куа бирде. Барысы да җайлана төсле. Тик Үзбәкнең генә күңелендә тынычлык юк. Дистә еллар буе чарланган тою хисе беркайчан да алдамый, хәвеф-хәтәр киләсен сизә, төн йокысын ала, күңелен бимазалый.

Башта Хөсәен шәех Баһдад хатынның үлеме турында яман хәбәр алып килде. Күрәсең, Үзбәк хан белән язышкан хатларының берсе дошман кулына кергән, аның Урда хакиме тарафдары икәнлеген ачыклаганнар. Шулай да, тавыш-тын чыкмасын, эшне озакка сузмаска дипме, хөкем итеп тормаганнар, мәкер белән башына җиткәннәр. Баһдад хатынның канга баткан мәетен мунчада табып алганнар – милләте белән грек булган Лулу кушаматлы җариясе аны таш белән кыйнап үтергән, диделәр.

Бер кайгыдан аңына килергә өлгермәде – Үзбәк ханга икенчесен дә җиткерделәр. Хәрәземдә, шактый вакыт авырып ятканнан соң, бәкләр бәге Котлы Тимер бакыйлыкка күчкән. Бусы Урда хакименең йөрәгенә авыр йөк сыман ишелеп төште.

– Гаскәрне җыегыз, – дип боерды ул, Исабәк вәзирне тирмәсенә чакырып. – Без кире Урдага кайтабыз. Мин, Хәрәземгә барып, якын дустым Котлы Тимер каберендә дога кылырга телим. Ул биредәге сугышларга һәрвакыт каршы иде. Аның якты рухын истә тотыйк, илханнар дәүләте белән орышны хәзергә туктатып торыйк. Ходай үзе, Котлы Тимерне янына алып, безгә кисәтү җибәрә шикелле...

Арпа-хан Урданың кинәт чигенүен шаккатып күзәтеп торды. Баштарак моны Үзбәкнең чираттагы хәйләсе дип уйлады, тик шымчылар җиткергән мәгълүмат киресен раслады. Йөзләрчә мең нүкәрдән торган хан гаскәре, бүтән бәрелешләргә кермичә, кире Кавказның аргы ягына юнәлде. Аларны күзәтеп озата барган Арпа-хан, соңгы нүкәр Тимер Капканы чыккач кына, ихлас күңеленнән җиңел сулап куйды...

**6**

Тайдула хатынның көннән-көн борчуы арта торды, ул үзен кая куярга белми бәргәләнә иде. Ничек кенә тырышмасын, олы улы Тәнибәкне ана кеше үз кулына ияләштерә алмады. Төпчеге Җанибәк, әнә, ни кушсаң, шуны эшләргә әзер, күзенә генә карап тора. Ә менә Тәнибәк андый булып чыкмады.

Олы улының бар нәрсәгә үз фикере бар, әнисе әйткәнне колагына да элми. Әйтерсең, икенче анадан туган бала. Тайдула Тәнибәкнең болай үзеннән читләшүенең, ятсынуының сәбәпләрен бераз аңлый иде. Олы улына назы бик аз эләкте бит. Үзенең яшьлеге беләнме, аны күбрәк тәрбиячеләр кулында үстерде, буй-сыны нәфислеген югалтудан куркып, имезүен дә бик иртә ташлаттырды, читтән бер күкрәк анасы табып китертте. Икенчедән, Тәнибәк әтисе Үзбәккә бик нык охшаш иде. Монысы да Тайдуланың күпмедер дәрәҗәдә гайрәтен чигертте. Ничек кенә тырышмасын, урдалыларга карата йөрәгендәге нәфрәт-каргышын ул һич кенә дә җиңә алмады. Аларның һәрберсе – әтисен үтерүчеләр, әнисен коллыкка сатучы

ерткычлар булып кала бирде. Үзбәк исә шул вәхшиләрнең башлыгы, аларның барлык кодрәт-көчен, холык-фигылен үзенә туплаган бәндә сыман. Менә шул бәндәнең дәвамчысын көн дә күрү Тайдуланың бәгыренә кадала торды. Яшьли бала табып, чын ана булып җитлекмәгәнлеге дә үз йогынтысын ясагандыр.

Тәнибәкнең анасыннан читләшүенә сеңлесе Сөенбикә белән Җанибәк ханзадә дә тәэсир иткәндер. Башта кызы, аннан соң төпчек улы тугач, Тайдула хатын аларны тәрбияләү эшенә баштанаяк кереп чумды, дөньясын онытты. Тәнибәк анасының сеңелкәшен һәм энесен назлавын читтән күзәтеп торгандыр, Тайдулага карата үпкә-ачуы тумый калмагандыр. Сабый күңеле барысын да сеңдерә, һәммә нәрсәне дә исәпләп, хәтергә салып бара бит. Ничек кенә булмасын, тормыш үзенекен итте – Тайдула белән Тәнибәк арасында ана белән бала мөнәсәбәте сизелер-сизелмәс кенә дәрәҗәдә булды, еллар узу белән исә алар бөтенләй дә уалып юкка чыкты. Сирәк очрашкан вакытларда Тайдула хатын олы улының күңел кылларын тарткалап карарга маташса да, таштан корылган калканга гына килеп бәрелә. Тәнибәк аның бер генә сүзенә дә колак салмый. Ә соңгы вакытта исә ханзадә әнисенә ничектер көлемсерәп, өстән карый сыман тоела.

Шулай карарлык хәле дә бар шул. Котлы Тимер вафатыннан соң Хәрәзем олысы хуҗасы итеп Үзбәк хан олы улы Тәнибәкне билгеләде. Үзбәк үзе нык бетеште. Бер-бер артлы яраткан кешеләрен, шул исәптән рухи таянычы Ногъманетдин хәзрәтне дә югалткан Урда хакименең сәламәтлеге бөтенләй какшады. Аның башы шаулый, күбрәк урын өстендә ята, җомга намазларына да сирәк кенә чыга, халык каршында исә бөтенләй күренми диярлек. Мондый шартларда, әлбәттә, озакламый Тәнибәкнең Урда тәхетенә менеп утырасы көн кебек ачык. Үзбәкнең көннәре санаулы, олы ханзадә моны бик яхшы белә. Һәм үзенең вакыты килеп җитүен сизеп тора.

Тайдула Тәнибәкне үз ягына аударуның, сүзенә колак салырлык итүнең соңгы, сыналган ысулына алынды. Ханны хатын-кыз пышылдавы аша әсир итәргә мөмкин. Үзбәкнең Тайдуласы булган шикелле, Тәнибәккә дә аңа тиң сылу зат кирәк. Һәм аның бер үк вакытта ханзадәнең әнисен тыңлый торган кыз булуы мәслихәт. Шул очракта гына Тайдула ханлыкта үзенең дәрәҗәле урынын саклап кала алачак, Җанибәккә тидермәячәк, үз карарларын тормышка ашырачак.

Андый кызны җарияләре арасыннан озак эзләде Тайдула. Ниһаять, тапты кебек. Кырым якларыннан китерелгән Әсма атлы кыз чибәрлеге белән теләсә кайсы егетнең күңелен яуларлык, акылы да бар, Тайдулага мөнәсәбәте дә бик җылы. Ханбикә, аны сайлап алгач та, берничә ел дәвамында тәрбияләде, төрле сынаулар аша тугрылыгын тикшерде. Бары тик Әсмага тулысынча ышанырга мөмкин икәнлеккә инангач кына, ханнан хәер-фатиха алырга юнәлде.

Үзбәк хан да ошатты бу кызны. Улына күптән башлы-күзле булырга вакыт. Әсма аның дуамал холкын авызлыклап торырдай хатынга охшаган. Әледән-әле Тәнибәкнең яшьлеге белән кылган юләрлекләре турында хәбәрләр килеп ирешкәли. Ханзадәгә акылга утырырга кирәк, гаилә коргач, ул, бәлки, тормышка җаваплырак карый башлар.

Якты өметләргә төренеп, Тайдула олы кәрван белән Хәрәземгә таба

кузгалды. Тәнибәктән тыш, анда кызы Сөенбикә һәм оныклары да көтеп тора, аларга да мул итеп күчтәнәчләр җыйналды. Юлда барган чакта Әсманы үз арбасына утыртты, кызны улы белән очрашуга әзерләүне бер генә мизгелгә дә туктатып тормады.

Тәнибәк аларны Хәрәзем олысы чигендә каршылады. Арбадан чыккач та, Тайдула каршысында басып торган егетне башта танымады. Улы үскән, ир чалымнары кергән. Шул ук вакытта үзенә генә хас сөйкемлелеген дә саклап калган. Башындагы бүреге астыннан кыска толымга үрелгән чем-кара, тыңлаусыз чәчләре иңенә сарылган. Кашлары юка, озын керфекләре астыннан ялтырап торган күзләре шаян елмая. Мыек-сакалы чак кына күренеп торырлык тасмалардай бик җентекләп кыркылган. Кыяфәте Тайдула ягына тартым – ике яктан бит сөякләре тырпаеп тормый, тәне дә, кояшта озак йөрүенә карамастан, кара-чутыр түгел, бик килешле генә кызынган. Буй-сынын әйтәсе дә юк – нечкә билләренә теләсә кайсы кыз кызыгырлык, иңнәре исә киң, әйтерсең, бөтен тәне астан өскә таба җәелеп үсә.

– Саумы, бөек ханбикәм, сине үземнең олысымда күрүемә чиксез шатмын! – дип елмайды ул, уң кулын күкрәгенә куеп чак кына иелә төшеп.

– Ханзадәм, исән-сау, сине сагынып килеп җиттем! – диде Тайдула. Балачактагы төсле кочаклап аласы килсә дә, анысына ук кыймады, нүкәрләре алдында Тәнибәкне оялтасы килмәде. – Бөек ханыбыз да сиңа сәламнәрен җиткерде, Урда дәүләтенә хезмәтең өчен рәхмәтен әйтергә боерды.

– Бөек ханыбызның мондый югары бәясе минем өчен олы дәрәҗә! Рөхсәт итсәң, мин сине үземнең утарымда кунакка чакырыр идем!

Үргәнечтә Тәнибәк тарафында затлы бүлмәләргә урнашкач, Тайдуланы олыс бәге табынга дәште.

– Тәнибәк ханзадәгә җиткерегез, минем белән бергә Әсмабикә атлы кыз да киләчәк, – диде Тайдула хатын, көзгедән үзенең кыяфәтен барлаудан аерылмый гына. Хезмәтче боерыкны үтәргә ашыкты.

Тәнибәк әнисе килү хөрмәтенә олы табын корган, бирегә, сеңлесе Сөенбикә белән кияве Харунбәк, аларның балаларыннан тыш, Үргәнечнең дәрәҗәле кешеләре, имамнары, казыйлар да чакырулы иде. Тайдула, Әсманы ияртеп, ханзадә янындагы урынга атлады.

Халык җыелып беткәч, Тәнибәк үзе дә күренде. Хәрби киемнәрен салып, затлы чапанын кигәч, ул тагын да яшәреп, матураеп калган. Билендәге асылташлар белән чигүле билбавы тарттырып бәйләнгән. Йөзендә ихлас елмаю. Ул табындагы һәммә кунак белән аерым килеп исәнләште, аннары әнисе кырына барып утырды. Хезмәтчесенең колагына нидер пышылдагач, тегесе тиз генә йөгереп китеп юк булды. Озак та үтми, ханзадә янына яшь кыз килде, Тәнибәк аны күрү белән торып ук басты.

– Тайдула ханбикә, таныш бул, бу – Зәйтүнә. – Әнисенә кызны тәкъдим иткәндә, Тайдуланың йөрәге чәнчеп куйган төсле булды. Әмма тәҗрибәле хатын сер бирмәде, чак кына елмайган рәвештә башын ия төште.

Кич буе Тәнибәк Зәйтүнәдән аерылмады, алар гәпләшеп, елмаешып утырдылар, ханзадә әнисенә әледән-әле мөрәҗәгать итеп кенә алды. Мәҗлес тәмамлангач, Тайдула хатын улына сүз катарга карар кылды:

– Тәнибәк ханзадә, рөхсәт итсәң, синең белән икәүдән-икәү генә сөйләшер идек. Бөек хан миңа олы йомыш йөкләп җибәрде, аны сиңа кичекмәстән җиткерергә тиешмен.

– Әлбәттә, сөекле ханбикә, барча халык таралышкач та, гозереңне җиткерерсең, – диде ханзадә. Болай хуҗаларча сүз тотуыннан Тайдула гарьләнеп үк куйды – әле кайчан гына ул шушы баланы имезеп, бишектә йоклатып үстерде бит!

Икәү генә калгач, Тәнибәк әнисенә чәй салып бирде, үзенең касәсен дә хуш исле кытай эчемлеге белән тутырды.

– Сүземне нидән дә башларга белмим, Тәнибәк ханзадә, – дип уңайсызланган итте Тайдула.

– Тартынма, сөйлә, сөекле ханбикә! Минем өем – синең өй, биредә чит-ят колаклар тыңлап тормый. Бөек ханнан миңа нинди әмер алып килдең?

– Бөек хан да, мин дә синең буйдак йөрүеңә нык борчылабыз, Тәнибәк ханзадә... Сиңа башлы-күзле булырга вакыт.

Тәнибәк, касәсен өстәлгә куеп, шаркылдап көлеп җибәрде:

– Мине өйләнергә өндәргә җибәрдемени бөек хан?! Дәүләтебездә башка эш беткәнме?!

– Безнең өчен бүген аннан да мөһиме юктыр. Син – гади олыс бәге генә түгел бит, ханның олы углы.

– Ханбикә, икегез дә минем уйларымны укып торасыз төсле. Үзем барып, сиңа һәм бөек ханыбызга никах укытырга ризалык алырга йөргән идем. Шөкер, йөрәгемне яуларлык кызны таба алдым, сөекле ханбикәм!

Тайдуланың башы әйләнеп китте, әмма ул тынычлыгын югалтмады. Улы исә, берни булмагандай, шатлыгын яшерми дәвам итте:

– Син ул кызны бүген күрдең, аның белән таныштың. Исеме Зәйтүнә. Аның белән никахлашырга сезнең хәер-фатихагызны сорарга җыенам.

– Кайдан килгән кыз инде ул, нинди нәселдән?

– Мин аны поляк җирләренә яу сәфәреннән кайтканда, Кавказ таулары тирәсендә очраттым. Очраттым да гашыйк булдым. Син моның ни икәнлеген миннән яхшырак беләсең, сөекле ханбикәм, бөек ханыбызга карата мәхәббәтең турында халык риваятьләр сөйли...

– Алай икән... – дия генә алды Тайдула хатын. Затлы нәсел турында сүз куертып торуы мәгънәсез иде – үзенекен казып карасаң, адәм көлкесенә калырлык. – Шулай да, сөекле ханзадә, уең-карарың төплеме? Бер дә белмәгән кызга өйләнеп, ялгышлык кылмассыңмы? Беренче хатын – иренең терәге, дәүләт эшләрендә ярдәмчесе буласы кеше.

– Мин аның холкын бик әйбәтләп өйрәндем, сөекле ханбикә. Аннан соң, мин хәрәм тутырып хатыннар җыярга теләмим. Хатыным бер һәм бердәнбер булыр. – Аптырашта калган, ни әйтергә белми утырган әнисенә улы җылы караш ташлады, аннан аның кулын учына алды. – Бер дә борчылма, әнием, синең балаң башын югалтмас. Зәйтүнәне мин кайвакыт сиңа тиңлим, син дә безнең этине шулай ук кайгыртасың, бер караштан аңлыйсың бит. Йөрәгем мине алдамыйдыр. Зинһар, минем хәлемә кереп, карарымны кабул итә күрегез.

– Төшендем, ханзадә, – дип коры гына җавап кайтарды Тайдула.

– Ә теге син ияртеп килгән кыз, ни атлы әле?

– Әсмабикә...

– Әсмабикә синең белән кире кайтсын, үпкәләп калмасын. Ул да яхшы бәндәдер, әмма йөрәгемдә аңа урын юк.

– Хәрәмеңә дә алып калмыйсыңмы?

– Юк, сөекле ханбикә. Үргәнечтә хәрәм тотучыларга кырын карыйлар, гафу итә күр...

Күпме генә тырышмасын, Тайдула хатын теләгенә ирешә алмады. Тәнибәкне берничек тә үз дигәненә күндереп булмады. Ханзадә киребеткән, әнисенең сүзенә колак салуны кирәк тапмады.

Әсмабикәне арбага утыртып, кире кайту юлында Тайдуланың кәефе бөтенләй дә юк иде. Ул үз эченә бикләнде, Үргәнечтәге хәлләрне әле алай, әле болай уеннан кичерде. Ана йөрәге кысылып куйды. Кычкырып елыйсы килде. Тайдула бер нәрсәне аңлады – Үзбәк үлеп, Тәнибәк тәхеткә утыру белән ул да барлык кодрәтен югалтачак. Бизмәннең бер ягында үзе күнеккән хакимлек булса, икенчесендә – олы улының гомере. Хисләренә ничек кенә карышмасын, бизмән хакимлек ягына авышты. Шушы гомер интегеп яшәп, бар нәрсәдән ваз кичеп, Үзбәк ханның көен көйләп үткәргән Тайдула үз кулына керергә торган хакимлектән ансат кына ваз кичәргә теләмәгәнлеген аңлады. Моның хакы нинди буласын аңлап, ул, тыела алмый, ирексездән елап җибәрде...

**7**

Өйләдән соң халык мәчетләрдән янә Азак шәһәренең үзәк базарына агылды. Намаз вакытына бераз тынып торган мәйдан кабаттан гөж килә башлады. Ул арада яңа гына килеп туктаган көймәләрдән мичкә-мичкә балык китерделәр. Хатын-кызлар, симезрәген эләктереп калыйк дип, шунда ашыкты. Ир-атлар исә, ышык урыннар табып, чәй, каһвә кайнатып җибәрде, базар өстенә татлы тәмәке төтене таралды.

Мәйдан уртасында төрле игъланнар җиткерү, явыз җинаятьчеләрне бар халык алдында җәзага тарту өчен агач күтәртмә корылган иде. Базарга килеп кушылган тар тыкрыкта сәер төркем күренде. Йөзләп кеше, битләре чалма очлары белән капланган, үзләре баштанаяк коралланган. Ләкин бу – хан нүкәрләре түгел. Юлбасарлар дисәң, алар көпә-көндез шәһәр уртасында йөрмәс. Теге төркем, ышанычлы адымнар белән кызу-кызу атлап, күтәртмәгә юнәлде. Алар арасыннан яшь кенә егет аерылды, ул җәһәт кенә өскә сикереп менде.

Монысының өсте-башы затлы, йөзе ачык, билендәге хәнҗәре асылташлар белән мул итеп бизәлгән. Уң як күкрәгендәге тамганы күргәч, якынрак торган ир-атлар аһ итте, пышылдашып, күтәртмәгә таба атлады. Егет исә, тураеп басып, нидер көтә, әйтерсең, халыкның һичшиксез аның тирәсенә җыеласын белә.

– Туктай хан тамгасы, – диде бер сәүдәгәр, кулындагы каһвә салынган чәшкәсен читкә куеп. Аннан, көр тавыш белән бөтен мәйданны тутырып кычкырып җибәрде: – Күрегезче, егетнең күкрәгендә Туктай хан тамгасы!

Базар халкы күтәртмә янына ашыкты. Чибәр, төз буйлы, нык егет аларны өстән аска караган килеш чак кына елмаеп күзәтте. Кешеләр пышылдаша,

бармаклары белән аңа төрткәләп күрсәтә. Тынычлык таләп итеп, егет уң кулын өскә күтәрде. Әйтерсең, бу бәндәдән бер сихри көч бөркелә – мәйдан шып булды.

– Азак шәһәренең ирекле халкы! – диде егет яңгырап торган куе тавыш белән. – Мин – Туктай ханның оныгы Икъсар булам!

Мәйдан янә «аһ!» итте. «Әллә кабердән торып чыкканмы?!» «Үзбәк хан куштаннары аны үтергән диделәр түгелме соң?!» «Карале, ничек буйга җиткән, күз явын алырлык!» дигән сүзләр әле аннан, әле моннан ишетелде.

– Мин, Үзбәк хан яраннарының мәкеренә дә карамастан, исән калдым. Мәрхүмә әнием, үзенең җанын фида кылып, мине саклый алды. Шушы көнгә кадәр мин Үзбәк ханның хаиннарыннан яшеренеп яшәдем. Бүген, ниһаять, газиз халкым каршына чыгарга булдым. Үзбәк хан – мине тәхеттән мәхрүм иткән залим. Урда һәм Яса кануннары нигезендә, мәмләкәтебез ханы мин булырга тиеш идем. Ләкин канлы хаким моңа комачаулады. Бүген исә хакыйкать җиңеп чыгарга тиеш. Мин – Икъсар хан, явызларча тәхеткә менеп утырган Үзбәкне бәреп төшерергә чакырам. Минем белән бергә Урдабызга тынычлык, гаделлек кайтыр. Сезне бөлгенлеккә чыгаручы салымнар бетәр, улларыгызны көчләп сугышка олактыру туктатылыр! Һәркем үзе теләгән дингә табынып, ата-бабалары рухы каршында намусын саклап яшәр. Мин – Икъсар хан, мин Сарай Әл-Җәдидкә бөек ханыбыз, минем бабам Туктай хан тугърасы астында барам!

Халык ни әйтергә дә белми торганда, мәйданга шәһәр саклауга куелган атлы нүкәрләр атылып керде. Алар, кешеләрне эткәли-төрткәли, күтәртмәгә таба ашыктылар, аяк астында буталганнарны камчыларга керештеләр.

– Үзегезне мәсхәрәләүгә, кыйнауга чик куегыз, газиз кардәшләрем! Берләшеп, Үзбәк ханны җәһәннәмгә җибәрик! Аның янәшәсендә сихер белән эш итүче Тайдула хатыннан дөньяны арындырыйк!

Әлеге сүзләрне кычкыра-кычкыра, үзен Икъсар дип атаган егет күтәртмәдән сикереп төште һәм юлбасарлары озатуында тар тыкрыкларның берсенә кереп югалды.

Нүкәрләр исә халык арасында буталып калды. Тагын бер тапкыр камчы сызгырып үтте. Әле генә ишетелгәннән каны кызган ирләр, сакчыларның аякларыннан тотып, атларыннан өстерәп төшерделәр һәм типкәләргә керештеләр. Өстәмә көчләр килеп җитмәсә, нүкәрләрне, һичшиксез, таптап үтерәчәкләр иде.

Үзен Икъсар ханзадә дип атаучы бәндә Урданың әле бер шәһәрендә, әле икенчесендә калкып чыга торды. Аның ялкынлы сүзләре халыкның күңеленә шик салды. Картайган, озак еллар буе тәхеттә утырган Үзбәктән туйганнар да иде – ә Икъсар исә үзгәрешләр вәгъдә итә, салымнарны да киметергә җыена. Тайдуланы сихерче дип атау да кара халык күңеленә хуш килде. Аның тирәсенә торган саен күбрәк кеше туплана башлады. Алар хан казнасына акча йөртүче кәрваннарны таларга керештеләр, нүкәрләргә һөҗүмнәр оештыра тордылар.

Әмирләр җибәргән чапкыннарның хәбәрләрен Исабәк вәзир моңаеп тыңлады. Сүз дә юк, ил өстенә афәт килә. Әмма бу хакта ханга ничек

әйтергә? Болай да холыксыз хаким соңгы вакытта тагын да киреләнә төште, аның белән сөйләшү көннән-көн авырая. Туктаусыз баш авыртулары, тәне сызлаулар да хәлне катлауландыра. Исабәк вәзир, киңәш сорарга дип, Тайдула янына китте.

Тайдула аны тыныч кына тыңлады.

– Соңгы тапкыр Икъсарны кайда күргәннәр?

– Сарайчыкта, газиз ханбикәм.

– Димәк, ул башкалага таба юл алган, озакламый бирегә килеп җитәчәк... Минем исемне дә болгата дисеңме?

– Әйе, сөекле ханбикәм, сине сихерче дип атый икән.

– Аңлашылды... Менә нәрсә, Исабәк вәзир. Башкаланың сак хезмәтен көчәйтегез, беркем дә тикшерелми кертелмәсен.

– Сарай Әл-Җәдид иләк шикелле бит, бөек ханбикәм. Аның диварлары юк, теләсә кайдан кер дә чык...

– Һәрхәлдә, башкалага илтүче юлларны ныклап сакларга кирәк. Хансарай сагын да өстәмә нукәрләр белән ныгытыгыз. Мин хан белән үзем сөйләшермен, син бер дә борчылма.

– Баш өсте, бөек ханбикәм.

Исабәк вәзир киткәч тә, Тайдула, ашыга-ашыга, хан тарафына юнәлде. Үзбәк аны тәхеттә утырган көе каршылады, ләкин кыяфәте качкан, тәне сызлаудан йөзе чытылган. Шулай да ул торып басып, хатынын сәламләргә көч тапты, аны янәшәсенә утырырга чакырды.

– Бөек ханым, сүзне нидән башларга да белмим, – дип, ихлас кыенсынып әйтте Тайдула.

– Сөйлә, Тайдула, бер дә тартынма. Ни борчый үзеңне?

Тайдула, тотлыга-тотлыга, әле генә Исабәк вәзирдән ишеткәннәрен ханга җиткерде. Ни гаҗәп, хан котырмады, тыныч кына тыңлап бетерде. Күзләре генә тирән сагышка батты, уйлары үткәннәргә юнәлде шикелле.

– Икъсарның исән калмавы миңа тәгаен билгеле, – диде ул, бераз дәшми торгач. – Кара кулыннан үткән кеше кире кайта алмый. Күрәсең, бу берәр залимнең гамәледер. Безгә аны кулга төшереп, кемлеген ачыкларга кирәк. Күптән барамы бу хорафат?

– Күптән, сөекле ханым...

– Исабәк вәзир берни белмәгәнме?

– Башта игътибар бирмәгәннәр, берәрсенең усал шаяртуы дип уйлаганнар. Сине борчыйсы килмәгәндер, күрәсең.

– Исабәк вәзир дә картая, миннән элеккедән дә күбрәк курка икән, – диде Үзбәк үз-үзенә.

Хатыны аңа Исабәккә әйткән киңәшләре хакында сөйләгәч, Үзбәк хан елмаеп куйды.

– Ашыкма әле син, хатын. Мин исән бит әле. – Аннан, тавышына көрлеген җыеп, ишеккә таба борылды. – Кайсыгыз бар анда, Исабәк вәзирне чакыртыгыз!

Калтыранып кергән Исабәккә Үзбәк ачуын күрсәтмәде, берни булмагандай янәшәсенә утырырга кушты.

– Юлларга сак куймагыз, үзен Икъсар дип атаган бәндә башкалага үтеп керсен. Шымчылар гына күбрәк кирәк, алар фетнәчеләрнең бирегә килүен

алдан хәбәр итсеннәр. Хансарайның сак хезмәтен нығытыгыз, монысы дөрес. Икъсар исеме артына яшеренгән мөртәтне исән килеш кулга алып, каршыма китерерсез.

– Ул башкалага кереп, халыкны бөтенләй бутамасмы соң?

– Бутасын. Кемнең кемлеге ачыкланыр. Гаскәремнең миңа тугры калачагына шигем юк. Ә менә аксөякләр, яраннар, янәшәмдә минем кулымнан ашаучы мәхлуклар ни кыланыр – анысын карап карарбыз. – Үзбәк хан, гүя, савыгып киткән төсле булды, йөзләре алсуланып китте. – Ә син, Исабәк вәзир, картаясың бугай. Ханга тугрылык – ул курку түгел. Хатыннар аша эш йөртә башлау бер дә хәерлегә илтми...

Хан яныннан чыккач, Тайдула Үзбәк әйткән сүзләрне янә бер кат башында әйләндерде. Исабәк вәзирнең үз хәле хәл булса, ханбикәнең уенда бөтенләй үзгә фикерләр өере шаулады.

– Исабәк вәзир, ханның сүзләренә игътибар итмә, ачу белән әйтмәде ул аларны. – Тайдула беренче эш итеп карт вәзирне тынычландырырга кирәк тапты. – Син хәзер үк Тәнибәккә чапкын җибәр, ул, гаскәрен алып, башкалага кузгалсын. Биредәге нүкәрләр генә фетнәчеләрне җиңә алмаса, аның көчләре безгә ярдәмгә ашыгыр. Мин әйтте димә, хан бу акыллы уй синең башыңа килгән дип уйласын.

– Яхшы, сөекле ханбикәм, хәзер үк Тәнибәк ханзадәгә хат язам...

– Нинди хат, Исабәк вәзир?! Бөтен җиргә фетнәчеләр тулган! Телдән генә әйт, чапкының сүзен сүзгә ханзадәгә кабатласын!

– Сүзләрең хак, зирәк ханбикәм! Барысын да син кушканча эшләрмен!

1339 елда Сарай әл-Җәдидтә Үзбәк ханга каршы олы фетнә купты. Икъсар дип аталган бәндә кулы астына аннан-моннан коралланган гади халык һәм сәүдәгәрләр басты. Башкала урамнарында суеш-канкоеш оештырып, алар хансарай ишегалдына бәреп керделәр. Тик биредә аларны кораллы нүкәрләр көтеп тора иде. Хансарайның биек диварларындагы тәрәзәдән Үзбәк әлеге бәрелешне үз күзе белән күзәтеп торды. Канлы орыш озакка сузылмады – эчтән һәм тыштан камап алынган фетнәчеләр шәһәрнең үзәк мәйданына чигенде. Ике сәгать дигәндә барысы да тәмам, мәйдан өсте туракланган мәетләргә күмелеп калды.

Ханның әмерен җиренә җиткереп үткәрделәр – фетнә башында торган бәндәне исән килеш кулга төшерделәр. Бик әтәчләнсә дә, хан нүкәрләре барыбер аның телен ачу чарасын тапты.

– Фетнәче мөртәт үзенең исемен әйтергә әзер, бөек ханым, – диде Исабәк вәзир, хан каршында башын иеп.

– Сезгә әйтмәдемени?

– Юк, минем сүзләрем бары тик хан колагы өчен генә, ди.

– Олы башымны кече итеп зинданга барыйммыни? – Үзбәк хан көрсенеп куйды. – Йә, ярый, киттек әйдә.

Зинданда караңгылык хөкем сөрә, саран шәм яктысында Урда хакиме саклык белән таш тарлыклар аша атлады.

Үзен Икъсар дип атаган бәндәнең өсте-башы канга баткан, ныклап кыйналган, аяк-кул бармакларындагы тырнаклары суырылган. Ул еш-еш сулый, идәндә бөгәрләнгән килеш аунап ята. Шулай да, Үзбәк хан кергәч, башын күтәрә алды, елмайган кебек тә булды.

– Килдеңме, канлы ханыбыз, мәет карчыгасы Үзбәк? – диде ул, телен көчкә әйләндереп.

– Кем син, шуны ишетер өчен генә килдем, – диде Үзбәк, сабырлыгын югалтмыйча.

– Мин – синең тынычлыгыңны алыр өчен теге дөньядан җибәрелгән шайтан. – Фетнәче төкереп куйды, кан белән бергә чәрдәкләнеп беткән тешләре дә идәнгә очты.

– Җәһәннәм әһеле икәнлегең болай да мәгълүм. Исемеңне әйт, юкса, китәм, синең белән вакыт уздырып торыр хәлем юк.

– Кадак дигән кешене хәтерлисеңме син?

Хәтерли Үзбәк хан, ничек хәтерләмәсен? Туктай ханның уң кулы, беренче көннән үк Үзбәкне кан дошманыдай күргән, аның канын агызырга кызыгып йөргән кешене ничек онытсын ул?

– Кадакның җаны күптән җәһәннәмдә.

– Анысын бер Ходай гына белә, Урда ханы, үз өстеңә аның вазифаларын да алып, гөнаһ җыя күрмә. Хәер, гөнаһларың болай да байтак, мең җәһәннәмгә җитәрлек.

– Сүзне читкә борма. Кадакны беләм, шуннан ни?

– Мин – аның улы булам. Даян исемлемен. Син – минем әтиемнең җанын кыйган дошманым. Гомерем буе аның өчен үч алырга хыялланып яшәдем.

Үзбәк ханга идәндә аунап яткан бу бәндәнең сүзләре бүтән кызык түгел иде. Ул ишеккә борылды:

– Бер атнадан бу мөртәтне үлем җәзасына тартыгыз. Шәһәрнең үзәк мәйданында күкрәгеннән йөрәген йолкып алырга боерам. Хөкемне хан үзе чыгара, гаебен тикшереп тору кирәкмәс.

– Баш өсте, галиҗәнап ханыбыз! – дип гөрелдәде зиндандагы яраннары.

Хан, җил-җил атлап, үз бүлмәсенә таба китте. Кирәк бит, ә?! Кайчандыр башы киселгән Кадакның улы бөтен Урданы аякка бастырган. Дәүләтендә нәрсәдер дөрес түгел, димәк. Әгәр, шулкадәр кодрәткә ия Исабәк вәзир бер ялганчыдан өркеп калган икән, картаюы җиткәндер. Әмма фетнәчегә ияргән халык хакында ни диясе? Бер атнадан ул үзе мәйданга чыгачак, Урда каршына басачак. Күрсеннәр, таза-сау икәнлегенә соклансыннар! Аңа каршы баш күтәргән теләсә кемне нинди язмыш көтәчәгенә шаһит булып, телдән-телгә сөйләсеннәр! Ул әле карт түгел, беләгендә егәрлеге, күңелендә ялкыны җитәрлек! Кадак улы Даянны үлем җәзасына тарту моның дәлиленә әверелергә тиеш.

Үзбәк ул көннең авыр сынаулары тәмамланган дип уйлаган иде – ялгышкан булып чыкты. Бүлмәгә кереп, тәхетенә утырырга өлгермәде, әмир Тотлак Тимернең ханны күрергә теләвен әйттеләр.

– Бөек ханым, синең кәефеңне янә бозасым килми, ләкин мин җитди хәбәр алып килдем, – диде Тотлак Тимер, борчылуын яшермичә.

– Сөйлә, тартынма. Бүген нинди кәеф турында сүз алып барырга мөмкин тагын...

– Бөек ханым, башкалага таба олы гаскәр якынлаша. Минем чапкыным хәбәр иткәнчә, алар хәзер моннан унбиш чакрым ераклыкта.

Хан тәхетеннән сикереп үк торды.

– Нинди гаскәр?! Кем безгә һөҗүм итте? Хулагу илханнарымы?!

– Юк, ханым, гаскәр башында синең улың Тәнибәк ханзадә...

Хан телсез калды.

– Тәнибәк?! Мин аны чакырмадым бит, гаскәре турында әйткән дә юк...

– Ни белсәм, шуны гына әйтәм, ханым...

– Хәзер үк атлы нукәрләрне алып, каршысына юнәл. Тәнибәк гаскәрен синең белән очрашкан урында туктатсын. Үзен минем каршыма китер. Сәргаскәрләренә әйт – урыннарыннан кузгалу хан әмерен үтәмәүгә тиңләшә.

Хәлләрнең куера баруын аңлаган Исабәк вәзир хафага төште. Хан аны әлегә үз янына чакыртмады, әмма Тотлак Тимернең нинди йомыш белән атылып чыкканын ул белеп калды. Вәзир, аяклары туктаусыз сызлавын да онытып, Тайдула янына йөгерде.

Вәзирнең сөйләгәнен Тайдула үтә дә тыныч тыңлап торды.

– Син барысын да мин әйткәнчә эшләдеңме, чапкынга әмерне телдән генә бирдеңме? – дип сорады ул, Исабәкнең сүзе тәмамлангач.

– Әйе, нәкъ син кушканча, сөекле ханбикәм.

– Алай булгач, Тәнибәкне гаскәре белән син чакыртты дип кем әйтә ала?

– Тәнибәк ханзадә үзе...

– Моны дәлилләүче хаты кулында бармы соң?

– Юк та, ләкин чапкыннан сорау алырга мөмкин бит...

– Ханның эше беткән, ди. – Исабәк вәзир Тайдуланың салкынлыгыннан имәнеп китте. Ни генә булмасын, сүз аның улы – Тәнибәк турында бара бит. Әмма әни кешегә ул кинәт, нигәдер, җиде ятка әйләнеп куйды. – Тәнибәккә бернинди чапкын да җибәрмәдем, беркая да дәшмәдем диген. Кирәк икән, мин ханны тынычландырырмын. Күңелем беркайчан да ялгышмый минем, Исабәк вәзир. Ә аңа ышансаң, хан бүтән Тәнибәк ягына басмаячак. Шуңа күрә тынычлан да берни булмагандай йөр. Синең белән миңа түгел, Тәнибәккә хан хөкеменнән куркырга кирәк.

Киеренкелек тойгысы хансарайның һавасында зеңгелдәп торган төсле иде. Төн инде, бөтен шәһәр йокыга талды. Коеп явып киткән яңгыр үзәк мәйдан өстенә аккан кан эзләрен юып төшерде. Әмма бу озын көн тәмамланырга уйламый да шикелле. Күктә ай калыккан вакыт иде, хан кичекмәстән диван утырышын җыйды.

Хансарайга җиткәч тә, Тәнибәк ханзадәнең бөтен коралларын алып калдылар, затлы хәнҗәрләренә кадәр салдырдылар. Ханзадәнең сорау тулы карашына Тотлак Тимер сүзсез, иңен сикертеп куеп, кулларын җәйде – хан әмере, үз теләгебез белән болай кыланмас идек, янәсе.

Хан янына кергәч тә, Тәнибәк биредә үзенә карата яман мөнәсәбәт хөкем сөргәнлеген аңлады. Әтисе аңа бөтенләй дә туры карамый, аның янәшәсендә утырган әнисенең күзләрендә исә усал очкыннар уйнаклый.

– Бөек ханым, синең әмереңне үтәп, башкалага килеп җиттем! Соңга калган булсам, гафу ит, мин бар көчемнән ашыктым, – диде Тәнибәк, хан каршында тез чүгеп.

– Нинди әмер тагын?

– Соң, башкалада фетнә чыгарга тора, гаскәрең белән кил дип чакырттың түгелме соң?

– Хан тамгасы сугылган боерыгың бармы?

– Юк... Әмереңне телдән җиткерделәр... Чапкын үзен Исабәк вәзирдән дип таныштырды.

Үзбәк хан, бер кашын гына күтәреп, Исабәк вәзиргә күз салды.

– Ялган, бөек ханым! Мин бернинди чапкын да җибәрмәдем!

Вәзирнең җавабы ханның күңеленә хуш килде.

– Гаскәрне урыныннан кузгату өчен безнең Урдада сүз генә җитми, Тәнибәк ханзадә. Аның тәртибен син беләсең. Хан тамгасы салынган боерыксыз бер генә нүкәр дә билгеләнгән җирдән китә алмый. – Үзбәк ханның тавышында усаллык та, ачыну да сизелде. – Әллә соң моны хыянәт дип бәяләргәме?!

– Бөек ханым, син нәрсә?! Нинди хыянәт турында сөйлисең син?! Мин – синең тугры улың! Киресенчә, фетнәчеләрне бастырырга гаскәр алып килдем бит...

– Җитәр, Тәнибәк ханзадә. Урыныңа утыр. – Үзбәк хан торып басты. Тәнибәкнең кәефе киткән рәвештә тәхет кырына барып утыруын сүзсез генә күзәтеп торды. Кайсыдыр бер мизгелдә йөрәген баласына карата кызгану хисе дә өшетеп үтте. Әмма Тәнибәккә ачуы һәм үпкәсе артык зур иде. – Хан әмерләрен тыңлагыз. Бүгеннән минем улым, Хәрәзем әмире Тәнибәк хәрби көчләр белән идарә итүдән читләштерелә. Аның олысындагы барлык төмәннәр Котлы Буга әмир карамагына тапшырыла. Котлы Буга, дәүләтебез чикләрен дошманнардан саклап, хан әмере ирешкән очракта минем гаскәремә кушылырга әзер тор! Шул ук вакытта хуҗалык эшләре идарәсендә минем улым Тәнибәк ханзадә үз урынында калачак. Аңа Әмирләргә тиешле дәрәҗәне алга таба да күрсәтергә боерам!

Тәнибәкнең гарьлегеннән күзеннән яшьләр бәреп чыкты, аның янәшәсендәге Җанибәк исә елмаеп куйды. Тайдуланың йөзе тораташтай катып калган, хиссез иде.

– Чираттагы әмерем Исабәк вәзиргә кагыла. – Исабәк вәзир урыныннан сикереп торды. – Ул озак еллар дәвамында минем терәгем, уң кулым булды, һәрбер ышанычымны аклап торды. Әмма вакыт аяусыз, сәламәтлегебез яшь бару белән бер дә ныгымый. Бүгеннән мин аны киңәшчем вазифасына билгелим. Аның барлык чыгымнары казна хисабына капланырга тиеш, ул – дәүләтебезгә армый-талмый хезмәт иткән лаеклы шәхес. Вәзирлек хезмәтендә күргән михнәтләре өчен аны казнадан мул итеп бүләкләргә боерам. – Үзбәк хан Исабәккә тиешле байлыкларны санап киткәндә, тегесе, ханның аягына егылып, елый-елый рәхмәт укырга кереште. Аның шыңшуыннан Урда хакиме барысын да аермачык аңлады – бу үпкәле күз яшьләре иде, Исабәк үзен әнә шулай кисәтүсез, барча диван алдында вәзирлектән ваз кичтерүне һич көтмәде, бу вакыйга башкача булыр дип хыялланды, ә бәлки, үлгәнче вәзир булып торырга хыялланды. Тик ханның карары катгый, сүзләре уйланылган иде.

– Моннан соң бөек вәзирлеккә минем киявем Харунбәк әмир билгеләнә. Исабәк, үзеңә алмашка килгән әмиргә барысын да яхшылап аңлатырсың, аңа авыр хезмәткә кереп китәргә ярдәм күрсәтерсең дип өметләнәм.

Хан авызыннан әмерләр яңгыраган саен дивандагы әмирләр берәм-берәм җылы урыннарын югалта торды. Озак еллар дәвамында үз

тирәсендә кайнашкан аксөякләрне тузгытып, Үзбәк алар урынына яшьләрне билгели барды. Инде тәмам йокыга чумып барган хансарайга көтелмәгән җанлылык керде, янәдән тормыш агышы кайтты сыман. Мәңгелеккә килгәнмен дип уйлаган түрәләр, кирәк-яракларын тиз-тиз җыештыргалап, чыгып китү ягын карадылар. Сәргаскәрләр рәтен дә Үзбәк бик әйбәтләп чистартты. Ялган Икъсар фетнәсе аның үзен дә уятып җибәрде төсле. Хакимлекне кулдан-кулга бирү мөмкин түгел, аны бары тик яулап алырга гына мөмкин. Картлык көнендә Үзбәк бу гыйбарәне янәдән искә төшерергә мәҗбүр булды...

Диван әһелләре сүзсез генә урыннарыннан торды, ишеккә кузгалды. Иң соңгысы булып бөкшәеп калган Тәнибәк атлый иде. Үзбәк хан аны карашы белән озата барды. Кинәт, тәхетеннән сикереп торып, улына эндәште:

– Тәнибәк ханзадә!

Тәнибәк аңа борылды. Маңгаена сарылган чем-кара чәчләре күз яшьләренә чыланып, битенә ябышкан, ханзадә, тавыш-тын чыгармый сулкылдап елый иде.

– Бире кил, балам! – диде Үзбәк, үзе дә елап җибәрмәс өчен барлык ихтыярын җыеп.

Ханзадә кыяр-кыймас кына хан тарафына атлады. Үзбәк тә аңа юнәлде. Тәхет бүлмәсеннән соңгы кеше чыгып киткәч, йөгереп диярлек килеп, улын кысып кочаклап алды. Тәнибәк, әтисе кочагына кергәч тә тыела алмый үксергә кереште. Үзбәк калтыранган кулы белән улының ат ялыдай тыңлаусыз чәчләрен сыйпады, күкрәгенә кысты.

– Тормыш сабаклары бик кырыс, улым! Бирешмә, нык бул! Минем тәхетем барыбер синеке. Һәрбер гамәлеңнән тиешле нәтиҗә чыгар. Әтиеңә тиң хан дәрәҗәсенә күтәрел! Вакыт, балам, сиңа күптән вакыт, – дип пышылдады ул, үзе дә күңелендә таш булып каткан хисләренә эреп китәргә ирек биреп...

## ЭПИЛОГ

...Үзбәк хан янәдән шабыр тиргә баткан көе уянып китте. Беренче мәлдә ул үзен баштанаяк канга буялган төсле хис итте. Нәкъ әле генә күргән төшендәге шикелле...

Көч-хәл белән урыныннан торып, йомшак читекләрен киде, бүлмәсендәге көзгегә бакты. Аңа күптән сакал-мыегын рәтләмәгән куркыныч йонлач бер карт карап тора иде.

– Кайсыгыз бар анда?! Юынырга су китерегез! – дип кычкырды ул, көзгедәге картлачның үзе булуына инангач.

Ишек ачылды, шалтыр-шолтыр табаклар, тустаганнар китерелде. Хезмәтчеләр кирәк- яракларны керткәч тә, Үзбәк хан аларны куып чыгарды. Бүген ул барысын үзе эшләячәк. Башта кырынды, мыегын кыскартты. Чал төшкән чәчләр бик тыңлаусыз, үз җаена тырпаеп тора. Аларны да җыйнә алды. Аннан соң бөтен тәнен тәһарәтләндерде. Бүлмәсендә хуҗасын көтеп торган киемнәр арасыннан иң затлысын сайлады – барысы да алтын йөгертелгән, һәрберсенә Үзбәкнең үз тамгасы төшерелгән. Киенгәч, утырып, дога кылды. Соңгы вакытта намазга баса

алмый иде инде ул – бераз гына иелдеме, башы әйләнеп китә, менә-менә мәтәлер төсле.

Затлы таягына таянып, бүлмәсеннән чыкты. Ишек катында аны хезмәтчесе Сөләйман көтә иде. Хакимен күргәч тә, аңа таба ашыкты, әмма хан ярдәмнән баш тартты.

– Харунбәк вәзирне чакырт, – дип пышылдады ул, таягына таянган көе хәл алып. – Аннан Тайдула да булсын. Бәдретдин казый. Җәмигъ мәчете имамы Әбделхәмид хәзрәт килсен. Баш казначы. Сәргаскәрләр. Ханның сүзе бар, диген.

– Җанибәк ханзадәне, кызларыгызны, хатыннарыгызны дәшимме?

– Мин кемнәрне кабул итәргә теләвемне әйттем.

– Гафу итә күр, бөек хан!

– Бу юлыга кичерәм. Минем атымны әзерли торсыннар. Диван утырышыннан соң мин далага кузгалам. Нукәрләрне Харунбәк ияртсен.

– Аңладым, сөекле хакимем!

Тәхетенә ул көч-хәл белән менеп утырды. Яшьлегеннән омтылган, хыялланган әлеге урын аңа кинәт бик уңайсыз һәм кысан булып тоелды. Шушы тәхет аркасында ул гади кеше шатлыгын тоя алмады, ашаган татлы ризыклары беркайчан да йөрәгенә ятмады, өстән аска яраннарын күзәтеп, кемнең нинди мәкер коруы хакында шик тулы уйларга батып, гомере үтеп тә китте.

Бүлмәгә бер-бер артлы ул чакырган кешеләр керә торды. Һәрберсе елмая, баш ия, кайберләре тез чүгә. Аңа түгел, затлы агачлардан эшләнгән, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән, алтын-көмеш белән чуарланган Тәхеткә табына алар. Тәхет иясе алмашыныр, ә менә бу гамәлләр яши бирер. Ул гадәтләр Мәңгелеккә сузылыр төсле...

Барысы да җыелып беткәнлеген күргәч, Үзбәк хан торып басты.

– Мөхтәрәм җәмәгать! – диде ул, тавышының никадәр мескен чыгуына үзе дә гаҗәпләнеп. Тамагын кырып карады, әмма файдасыз. – Мөхтәрәм диван әһелләре! Урда дәүләте – дөньяның иң кодрәтле мәмләкәте. Моңа һәрберегезнең өлеше кергән. Һәм мин һәркайсыгызга рәхмәтлемен! Сез янәшәдә булганда, Урда ханы теләсә нинди дошманны җиңәргә сәләтле. Ләкин хәтта минем дә көчем җитмәгән бер көндәшем бар. Ул да булса – Вакыт галиҗәнаплары. Сез күптән аның көчен һәм кодрәтен сизеп-күреп торасыз. Вакыт миңа болай да бик күпне бирде. Егерме сигез җәйне һәм егерме сигез кышны мин Урда тәхетендә үткәрдем. Күңелем сизә, минем гомер сәгатемдә Ходай насыйп иткән ком бөртекләре санаулы гына калды... Мин сезгә соңгы әманәтем белән мөрәҗәгать итәм. Моннан ары Урда дәүләтендә бертуганнар арасында канкоешка юл куймагыз! Мин – шундый кансыз гамәлләрнең корбаны, үземнән соң тәхетне әрвахлар каргышына катнаштырасым килмәс иде. Миңа күп калмады, мөхтәрәм кардәшләрем. Миннән соң тәхетемә ир затыннан турыдан-туры туганым, яше буенча беренче варисым утырсын. Беләсез ки, ул – Тәнибәк ханзадә. Үземнән соң Урда ханы итеп Тәнибәкне күтәрүегезне боерам. Хәзер һәркайсыгыз, каршыма килеп, васыятемне үтәргә ант эчегез!

Диван әһелләре, берәм-берәм килеп, тез чүгеп, ханның кулын үбә-үбә аның изге васыятеннән чыкмаска ант иттеләр. Иң соңыннан Тайдула килде. Нигәдер хатынының карашы моңсу, кулы салкын иде.

– Син шатмы, Тайдула? Безнең улыбыз Урда ханы булачак! – дип пышылдады Үзбәк хан.

– Чиксез шатмын, бөек ханым. Тәнибәкне тәхеткә утыртуга бөтен көчемне куячакмын! Рәхмәт сиңа!

Үзбәк хансарай мәйданына чыкты. Аңа алтын белән чигелгән келәмнәр ябылган атына менәргә ярдәм иттеләр. Күптән инде атта йөргәне юк иде Урда хакименең. Тик шулай да элеккеге күнекмәләр тиз кайтты, урын өстендә ятып хәлсезләнгән тәне, атны тоемлап, уянып китте шикелле. Урамда аны күргән халык шау-гөр килеп бөек ханын сәламли, моннан Үзбәкнең күңеле сабыйларныкыдай җилкенә.

Ниһаять, Сарай Әл-Җәдид артта калды. Үзбәк үзе торгызган калага борылып карады. Аның исеменә, аның дәрәҗәсенә, омтылышларына тиң шәһәр иде бу. Горурлык хисеннән тыны кысылды.

Тик күңел нечкәрүгә бирелергә ярамый. Ул атын киң далага юрттырды. Хәтсез генә чаптыргач, тыныч адымга күчте.

– Харунбәк! – диде ул, тирә-якта кышкы йокысыннан уянып килүче чиксез даладан берни дә күренмәвенә инангач. – Нукәрләрең белән миннән илле адым артта калыгыз. Ялгыз барасым килә.

– Аңладым, бөек ханым!

– Харунбәк! Бүген әйткән әманәтем синең өстә. Үтәмәсәң, каберемнән чыгып җавапка тартырмын.

– Төшендем, бөек ханым...

– Хәзер күземнән югал!

Үзбәк хан Харунбәк атының тояклары тавышы тынганчы алдына караган көе иярендә утырды, аннан соң тезгенне тартты. Кайчандыр ул шушылай ук киң дала буйлап әтисе янәшәсендә юрттырган иде. Әле дә хәтерендә – хан булу турындагы хыялын әйткәч, әткәе кайдандыр йөгереп чыккан куянны күреп алды, игътибарны шуңа юнәлтте. Ләкин ул күңел түрендәге иң татлы теләген куян артыннан чапканда да онытмады. Һәм менә, морадына иреште. Тик нәрсә бәрабәренә?!

Салмак кына атлап барган көе Үзбәк хан башын күккә, офыктагы кояшка күтәрде.

«Йа Раббым, Ходаем, бердәнберем, мине саклаган Аллаһым! Миңа озын гомер биргән өчен сиңа чиксез рәхмәтлемен! Ул гомер эчендә минем янәшәмдәге дусларым-иптәшләрем барысы да үлеп беттеләр. Болай да гомерлек ялгызлыкка дучар бәндәң бүген ятим хәлендә. Минем тәхет сорап ялваруларымны ишеттең, барча теләкләремне кабуллардан кылдың. Ләкин хакимлек өчен шушындый бәя түләргә кирәклеген ул чакта белгән булсам, синнән үзгә язмыш турында ялварыр идем... Юлым ак, шул ук вакытта тоташ канлы. Синең каршыңа баргач та, барысы өчен дә җәзасын алырмын. Ничек кенә булмасын, үземнән соң хөр мәмләкәт, таш сарайлар, синең исемеңне олылаучы мәчет-мәдрәсәләр калкып кала. Хәзер инде минем ашыгырлык җирем юк. Синнән бары тик тизрәк Газраил җибәрүеңне генә үтенәм. Мине мондый көчсез халәттә интектермә, гөнаһларымны ярлыка, үз яныңа кабул итеп ал. Миннән соң килгән балаларыма рәхим-шәфкать, игелек-тәүфикъ бирә күр. Алар минем ялгышларны кабатламасын, минем баштан узган михнәтләр үзләрен урап үтсен иде!»

Үзбәк хан уйларыннан бүленергә мәҗбүр булды, атын туктатты. Ун адым ераклыкта, аңа усал күзләрен төбәп, тугыз бүре тезелешеп утырган иде. Алар, телләрен салындырып, еш-еш сулыйлар, тик урыннарыннан кузгалмыйлар, әйтерсең, нидер көтәләр.


– Көпә-көндез йөри башладыгызмыни, мөртәтләр?! – дип пышылдады Үзбәк хан. Аннан, борылып, артка таба күз салды. Харунбәк нүкәрләре белән якында гына, тик аңа ярдәмгә килергә ашыкмыйлар. – Тизрәк атлагыз инде, күз көекләре, бүреләрне күрмисезмени?!

Тик тегеләре салмак атлауларын дәвам итте. Үзбәк хан акрын гына кылычын тартып чыгарды. Хәлсез кулы белән аны өскә күтәреп, атын алга ыргылдырды. Әмма көче генә җитмәде. Кисәк кенә юрттырып киткән атында утырырлык та хәле калмады, бөтен тәнен көчле авырту сыдырып үтте, кылычы җиргә мәтәлде. Икенче мәлдә Үзбәк хан ияреннән җиргә гөрселдәде. Харунбәк нүкәрләре белән ашыга-йөгерә килеп җиткәндә, ул әле кайбер сүзләрне әйтә ала иде.

– Бүреләр, күрәсезме сез аларны, ник бүреләрне үтермисез, хәзер мине бугазлыйлар бит алар!.. – дип пышылдады Урда хакиме үзен күтәрергә маташкан вәзиренә.

Харунбәк Үзбәк хан күрсәткән тарафка карады – дала буш, анда берни юк, тик кипкән дуңгәләкләрне генә язгы салкын җил арлы-бирле типкәләп йөртә иде...

...Дәүләтен Алтын Урда дәрәҗәсенә күтәргән Үзбәк ханның хәлсез тәненнән акрынлап яшәү көче китә торды. Күзләре мәңгелеккә йомылгач, ул мәмләкәте һәм ыруы өстенә килгән афәтләрне күкләрдән ачынып күзәткәндер. Тәнибәкне Тайдула тарафыннан явызларча үтертеп, аның урынына Җанибәкне тәхеткә утыртуны да, соңрак дәүләте, ул торгызган шәһәр-калалар, мәчет-мәдрәсәләр, сарайлар җимерелүне дә аның рухы ачынып карап торгандыр. Тик ул күккә ашкач та, берни дә үзгәртә алмый иде инде. Тарих үзенең сәхифәләрен яза бирде. Җир йөзендә Үзбәк әмере белән төзелгән таш калалар да, олы дәүләт тә калмады. Әмма Хәтер барыбер кайчандыр дөньяның кендеген үз кулында тоткан, җир йөзен калтыранып торырга мәҗбүр иткән Урда ханы Үзбәкне Мәңгелеккә теркәп куйган иде инде...



Роберт
Сәлахиев

# БАШЫМДА ХЫЯЛЛАР КӘРВАНЫ...

## Ышанам

Күпмегә сузылыр бу афәт?
Китмәскә уйлады, ахрысы...
Күк шаһит – меңәрләп йотса да,
Әҗәлнең туйганы бармы соң?..

Карашлар офыкка төбәлгән.
Көн туса – хәвефле хәбәрләр.
Сәфәрдән ваз кичкән бу көннәр
Өзелгән гомергә бәрабәр.

Максатлар, өметләр баглаган
Дөньякай нигә соң болгавыр?
«Болганчык» кемгәдер уңайлы,
Сүз дә юк, кемгәдер бик авыр.

Хәбәрдән сулышлар кысыла.
Каргалдык ни гамәл, ни өчен?
Әллә соң кичегеп тудыкмы,
Кай заман туасын белмичә?

Хәл-әхвәл шөбһәле булса да,
Күңел гел яхшыга омтыла.
«Саф дөнья бар ул», – дип ашкына
«Каядыр офыклар артында».

Ышанам: Җиһан бер чистарыр,
Яңгырдан хушланган даладай.
Дөньяга яңача карарбыз,
Бер нәни гөнаһсыз баладай!..

---

Роберт СӘЛАХИЕВ (1951) – *шагыйрь, популяр җырлар авторы; «Офыкларга карап», «Өмет таңнарым», «Йөрәгемдә яшисең» исемле китаплар авторы. Актаныш районының Татар Суыксуы авылында яши.*

## Туган җир тарта ул

Башымда хыяллар кәрваны,
Дөньяга юл тоткан чак иде.
Йөрәктә уянган уйларым
Ак бәхет эзләргә чакырды.
Мин исәр, хыялый юләрдәй,
Күкләргә чөйдем дә уйларны,
Җиде юл чатына атладым,
Учыма йомарлап хыялны.
Ярсудан саркыган ярсу кан,
Җанымның диварын буяды...
Хыялым күгендә күрсәм дә,
Бәхетнең алтындай гәүдәсен,
Күзалдым җуймады офыктан
Иң газиз туган як шәүләсен...
Туган ил, туган як, туган җир!
Ирендә – суының тәмнәре!
Кадерле икән ул шулкадәр,
Килсә дә бер генә хәбәре.
Хәбәрдән кузгалды язларның,
Яшьлектә уелган гамьнәре.
Гыйффәтле мөселман кызына
Тиңләрлек суының сафлыгы.
Битләрне иркәли җилләре,
Аяз күк, болытлар аклыгы.
...Кемгә дә хас түгел ят җирдә,
Сагынып, саргаеп картаю.
Бәгырьне телгәләп, барыбер
Туган як туфрагы тарта ул!..
Туган җир тарта ул!..

## Йөрәкләрдә яз иде

Фасыл угы алтын көздә иде...
Ә җаннарда җылы яз иде...
Айлы төндә ике яшь йөрәкнең
Керсез сөю җыры язылды!

Төн пәрдәсен ертып, ай нурлары
Яратудан янган битләрне,
Үбә, үбә назлап иркәләде.
Әмма бу наз гына җитмәде...

Күчәрендә, аһ, әйләнде дөнья!..
Хушланды да... тагын әйләнде...
Онытылды дөнья борчулары,
Бар ямьнәре үткән җәйләрнең.

Онытылды шөбһә, шикле уйлар,
Ул сөйләде, ә кыз дәшмәде.
Буталышып бетеп уралдылар,
Ике җанның ефәк чәчләре...

И Илаһым! «Бу бит гөнаһ!» – димә!
Шашкын бу хисләрне тыймаслык.
Битәрләмәс һич тә җан газабы –
Уртак булгач сөю, ихласлык.

Вакыт теле алтын көздә иде...
Ә чынлыкта көзге төн иде...
...Фәрештәләр канат кагынганда,
Дөнья шундый татлы, тын иде...

## Кайтам, дисә...

Өзгәләнә җаным, бәргәләнә
Яшьлек искә төшкән чагында.
Кемнәр кемне күтеп ала микән
Без очрашкан урам чатында?

«Эх-ма!» – дим дә авыр сулап куям,
Кайда диеп егет чакларым!
Кемнәр кемне кочып уза микән
Без очрашкан урам чатларын?

Кызын кысып кочып, күктә очып,
Нәкъ тә бүген – кичке салкында,
Кемнәр кемгә вәгъдә бирә икән
Без кавышкан урам чатында?

Яшьлек, яшьлек! Бер могҗиза туып,
Кайтам, дисә әгәр тагын да,
Хәзер торып чыгып чабар идем,
Нәкъ шул җиргә – урам чатына!..

## Сине уйлаганда

Җаным тыныч. Белмим, ни өчендер
Кич булса ни миңа, иртә ни –
Сине уйлаганда якты гамьнәр,
Күңел гөлләремне иркәли.

Урамда төн. Күктә ай елмая.
Ак нурлары җиргә түгелә.
Минем халәт, минем күңелемне,
Аңлый кебек бары төн генә.

Көз уртасы. Бар табигать тоташ
Сары төскә чумган шул чорда

Башка килгән якты хыялларым,
Күңелемне күккә очыра!..

Җанга рәхәт. Чөнки көзге төн дә,
Тулган ай да – якын сердәшем.
Сине уйлаганда гүзәл гамьнәр
Үзләренә тора гел дәшеп...

## Чишмә юлың

Телсез калган суга йөргән юлың.
Чишмә суы челтери улакта...
Ялгыз каен тын да алмый тора,
Күләгәсен салып сукмакка.

Үзгәрмәгән... Шул ук сөзәк ярлар,
Шул ук өянкеләр үскән җир!
...Кайда икән, кайда, битләреңнән
Назлап үбә-үбә искән җил?..

Синең күзләр шаян, ә үзләре,
Мәрхәмәтле, изге иделәр.
...Уйлау белән бөтен чалымнарың
Күзалдыма йөзеп килделәр...

Бәхет юрап яну-ашкынулар
Калды бары булып бер хыял.
...Бал исләре килә юкәләрдән –
Чәчәкләрен аның кем җыяр?..

Качкансың да килеп чыгарсың күк,
Көлә-көлә каен артыннан...
Ә мин җебек үсмер егет кебек
Кочакларга сине тартынам...

Сукмак дәшми... Синең эзләреңне,
Кат-кат итеп вакыт каплаган.
Синнән, миннән башка ничә язда,
Күпме карлар эреп акмаган?..

Кайчан гына... Сыешалмый таңга,
Йөргән идек сөю илендә!
...Белгәнемне укып дога кылам,
Менә тагын шушы килүдә...

Күрче, дисәм... Их, син күрмисең шул, –
Былбыл сайрап талда талпына!
...Учларыма кысып йөрәгемне,
Тыңладым мин кошны тын гына...

## Аһ, вакыт тар

Тылсымчыдай хәтерләрне айкап атып,
Ник соң әле үзенә тарта ал офыклар?
Артларыннан нурлар бөркеп ялкын кебек
Кабарышып торгангамы ак болытлар?

Кояш бата... Җаннан нидер өзелгәндәй,
Кич җиттеме, күңел кинәт сагышлана.
Өзгәләнә, ахры, ул да судай аккан,
Гомерләрнең бертуктаусыз агышына...

Өзгәләнми нишләсен соң, нишләсен соң?
Әллә ниләр хәтерләтә ал офыклар...
Өзгәләнмәс иде, бәлки, бәгырьләр дә,
Сагышларны баса алса ак болытлар.

Хәтерләрне айкап ала хатирәләр,
Офыкларда кызарганда ак болытлар.
Очып кына үткәннәрдән урар идем,
Еллар җитмәс – вакыт кыса, аһ, вакыт тар...

## Синең хакта

Синең хакта бары җылы сүзләр
Каләмемнән саркып тамалар.
Хәрефләрне терким иҗекләргә
Җил үтмәслек итеп арадан.

Язмышларны тәкъдир язган чакта,
Үкси, диләр бары үксез җан.
Мышкылдаштык без дә, күреп белгәч,
Узып булмаганын язмыштан.

Язмышлармы? Безнең язмышкайлар
Туганчы ук күктә каралган...
Чалымнарны чагыштырыр чәчләр
Бер төсләләр – күптән агарган...

Ниләр языйм?!. Минем бәхетемә
Тукталды күк җанның сыкравы.
Урамнарга яткан мин яраткан
Салкын кышның сыкы-кыравы..

Синең хакта җылы сүзләр генә,
Йөрәгемнән бүген тамалар.
Иҗекләрдән төзим җөмләләрне,
Җил үтмәслек итеп арадан...

## Үз язмышы икән һәркемнең

Күк күкрәп яшен яшьнәде дә,
Аяк асты кинәт убылды.
Яңгыр койды, елый-елый койды,
Бар болытны җыеп быелгы.


Давыл үтте... Яңгырдан соң нәрсә,
Табигатьне кочты җылы яз!
Җир өстенә кояш чыкты да соң...
Бирәлерме кояш җанга наз?

Көннәр тыныч. Тормыш дәвам итә,
Дөньясы да түгел болгавыр.
Тик бар тереклек парын тапкан язда,
Ялгыз калганнарга бик авыр.

Кыр казлары кайта... Бер-берсенә
Каңгылдашып, дәшеп очалар.
Моңсуланып, күккә карап тордым,
Сагышларга юк шул чаралар...

Очалардыр бергә җитәр өчен
Гомер юлларының очына.
Очсын алар, ләкин китмәсеннәр,
Әверелеп оҗмах кошына.

Ә кешеләр матур каршы алсын
Язган гомеренең һәр көнен.
Ничек кенә җирдә яшәсә дә,
Үз язмышы икән һәркемнең...



Ринат Мөхәммәдиев

# ГАЛИМӘ ТУТАШ

хикәя

Җәй башының ямьле бер көнендә без – бер төркем язучылар, Мамадыш якларына, Шәйхи Маннурның туган авылы Тулбайга барып чыктык. 1995 ел иде булса кирәк. Районнан автобус белән килеп алдылар һәм кайтарып куйдылар. Ә инде туксанны узып киткән Гомәр Бәширов белән туксанга якынлашып килгән Әмирхан Еникине мин «Волга» машинасында алып кайттым. Ул заманда район җирләренә бик чыгып йөрмәсәләр дә, алар ахирәт дуслары төзеп калдырган китапханә белән соң мәртәбә танышып, аның мәңгелек йорты каршында чал башларын иеп, хушлашып кайтуны үзләренең изге бурычы санады.

Мамадышта әдәбиятка һәм язучыларга хөрмәт элек-электән гаять зур. Ә инде якташыбыз Шәйхи Маннур истәлегенә ихтирам, гомумән, үрнәк булып тора. Кунакчыллык турында сөйләп тә торасы юк...

Кире кайтырга без шактый кичегә төшеп, кояш баер вакыт якынлашкан минутларда гына чыктык. Кунактан кайтып килгәнгәме, дөнья тагы да матурайган, юлның як-ягындагы табигатьнең ямьлелеген сөйләп бетерерлек түгел. Иртәнге якта әйләнә-тирәне үзалларына гына күздән кичереп, вакыт-вакыт йокымсырап килгән аксакалларның телләре телгә йокмый. Әледән-әле бер кызык табып яисә уен-көлке сөйләп, шаяртып та алалар.

Кирмән суына таба сузылган үрдән төшеп килүебез. Җиде-сигез чакрым чамасы ераклыкта уң тарафта калачак туган авылымны искә алып, үзалдыма моңсуланып барам. Авылым читеннән кайчан да булса, шул рәвешле тукталмыйча да машинада узып китәргә туры килер дип, кем уйлаган...

– Әмирхан, күр әле, кара әле, бу уң тарафтагы тау башына... – дип, кинәт сүз башлады Гомәр Бәширов. – Аның уйсулыкка сузылып төшкән итәкләренә бер күз сал әле син, нинди матурлык... Яшел хәтфә булып җәелгән чирәм, җиләк чәчәкләре...

---

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ (1948) – *язучы һәм җәмәгать эшлеклесе; Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе, Төркиянең әдәбият һәм мәдәният өлкәсендәге Халыкара әдәби премиясе лауреаты. Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. «Кенәри – читлек кошы», «Сират күпере», «Утлы таба өстендә» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Мәскәүдә яши.*

«Туган ягым – яшел бишек» романын һәм «Җидегән чишмә» җырының сүзләрен язган әдип авызыннан мондый сүзләр ишетү гаҗәп түгел, әлбәттә. Әмирхан Еникинең дә дөнья матурлыгы, урман-кырларның яме белән хозурланып барган мәле иде кебек.

– Кояш баеп килгән минутларда җәйге табигать бермә-бер серле матурлыкка чума, – диде ул, замандашы сүзләрен хуплап.

– Эх, шушы тау итәгендәге хәтфәдәй яшел чирәм өстендә бер туйганчы аунарга иде... – дип калкынып куйды шунда Гомәр ага.

Әмирхан абый шундук замандашының сүзләрен күтәреп алды.

– Аунасаң иде, димә, Гомәр, аунатсаң иде диген... – диде ул, сүзләренә серле мәгънә өстәргә теләгәндәй, һәр иҗекне бермә-бер суза төшеп. Серле генә елмаеп, бер очтан үзалдына кет-кет көлеп тә җибәрде.

Гомәр ага да рәхәтләнеп, аңарга кушылып көлде. Онытылып көлүдән аның хәтта күзләре яшьләнде.

Әмирхан Еникинең әлеге шаяруы минем өчен дә көтелмәгән яңалык булды. Үтә дә инсафлы, үтә дә тыйнак һәм зәвыклы әдип авызыннан шундый шаяру ишетермен дип кем уйлаган?

– Әйтсәң әйтеп тә куясың инде син, Әмирхан... – дип йомгаклады, кесәсеннән ак кульяулык чыгарып, күз төпләрен сөртү белән мәшгуль булган Гомәр ага. Үзе һаман шырык-шырык көлүеннән арына алмый азапланды.

Еники ул арада җитдиләнеп тә өлгергән. Сүзен җәт кенә Шәйхи Маннур турындагы истәлекләргә борды. Һәм ипле генә әллә кай заманнарда булып узган вакыйгаларны барларга кереште.

– Без бит Шәйхелислам абзый белән тәү мәртәбә бик еракта – Донбасста күрештек. Егерме сигезнең ахырындамы, әллә егерме тугызларда булдымы икән... Ярар, анысы ул кадәрле мөһим түгелдер, – дип, ул бер тын уйга калып торды. Сөйләве дә безнең өчен түгел, әйтерсең, башыннан кичкән хатирәләрен үзалдына искә төшереп утыруы иде аның. – Уналты яшь тулыр-тулмас көннәремдә зур хыял вә өметләр белән Казанга килгән идем бит мин. Язучы йә булмаса журналист булу иде хыялым. Китапчылар тирәсендә йөри торгач, университет каршындагы рабфакка керү бәхетенә дә ия булдым. Әмма, пнимаете ли, бәхет кошын тоткан сыман куанып йөргән көннәремнең берсендә, артыма ук типмәсәләр дә, аннан куып та чыгардылар... – Ул тагын сөйләвеннән туктап, бер мәл, үзалдына уйга калып барды. Көрсенгәндәй, кабат-кабат тамагын кырып куйды. – Сәбәбе, билгеле инде, тиешле җиргә, әлеге дә баягы шул морзалар затыннан булуым турындагы хәбәр барып ирешкән булып чыкты. Хыяллар челпәрәмә килде дә куйды. Башкортстаннан Казанга килүемнең дә сәбәбе шул иде бит инде: укып, кеше булу... Кая барма, артыңнан кара сакалың ияреп бара, дигәндәй, «морза калдыгы» яисә «князь» дип, бармак төртеп күрсәтүчеләрдән котылырга теләп килгән идем бит. Казан ерак, Казан зур кала, анда мине танучы-белүче юк, кызыксынучы-фәлән булмас, белмәсләр, дип уйлаган идем дә... Җиткергәннәр... Үз якташым җиткергән булып чыкты...

Киңәш-табыш итәр кешем юк, башны кашып, уйга калдым. Казан тирәсендә буталып йөрүдән эш чыкмас болай булгач, ераккарак китеп торырга кирәк булыр, дигән нәтиҗәгә килдем. Вакытлыча булса да китеп

торырга... Әмма, кай тарафка дигән сорау да бар бит әле. Ул заманнарда татар авылыннан ир-ат, егет-җилән заты бәхет эзләп, Донбасс якларына, шахтага агыла иде. Мин дә, тәвәккәлләп, шул якларга барып чыктым.

…Барып чыктым чыгуын, әмма эшкә дә урнашырга кирәк бит әле. Минем кебек бәхет эзләп килүчеләр белән дөнья тулган. Тагы шунысы гаҗәп: ике кешенең берсе дисәм, аз булыр, кая карама, анда татарча сөйләшәләр. Идел һәм Агыйдел буйларындагы авылларны монда күчереп куйганнар, диярсең. Ачлыктан, җитмәүчелектән генә түгел, төрле кимсетү, урынсыз рәнҗетүләрдән кача иде халык. Күпчелеге авыл егетләре, чабаталы мужиклар. Ә мин исә, бер дә харап, үземне кала кешесе итеп хис иткәнмен.

Шау-шу килеп, татарча гәпләшеп торган бер төркем янына килдем дә тыйнак кына сорау бирдем:

– Бер-бер эшкә урнашасы иде бит, егетләр, кемгә мөрәҗәгать итеп булыр икән?..

Сәерсенеп карады болар миңа. Өс-башымны, аягымдагы күн ботинканы күздән кичерделәр кебек. Кайсы-берсе килеш-килбәтемне күреп, үзалдына елмаеп та куйды, булса кирәк... Шулай да чит итмәделәр, арадан берсе кай яклардан булуым, монда ничек килүем белән кызыксынып, хәлемә кереп сөйләшергә кереште.

Мин ничек бар, шулай җавап бирдем, гәзитәче булу турындагы хыялымны да яшермәдем кебек.

– Монда шахтёрлар гына шул, каләмеңне кәйләгә алмаштырып, җир астында күмер чабарга туры килер, якташ, – диде ул.

– Ә син җир астына төшәргә курыкмыйсыңмы соң? – ди, черт-черт көнбагыш чиертеп торган икенче берәве.

– Белмим шул, – дигәнмен, күрәсең. Алар дәррәү көлешеп алдылар...

– Шахтёр чыкмас кебек синнән, – диде араларыннан кайсыдыр.

Мин, табигый инде, ни әйтергә белми, тәмам югалып калдым. «Шахтёр чыкмас» дигән хөкем белән авыр булса да, килешми хәлем булмагандыр. Эштән курыкмасам да, турысын әйтергә кирәк, җир асларына төшеп, кәйлә белән күмер чабарлык гайрәт һәм тәвәккәллек юк иде кебек үземдә дә...

– Ярдәм итсә, сиңа Сәгыйдулла абзый гына ярдәм итәр, – диде, хәлемә кереп, иң әүвәл үз итеп дәшкән агай. Аның киңәшен башкалар да хуплады кебек, күтәреп алдылар.

«Сәгыйдулла абзый гына... Сәгыйдулла абзыйга барып кара...» – дип, киңәш итте алар. «Ул кем була инде?» дигән сорау бирергә өлгермәдем, аңлаттылар. Ул үзе бу якларга Казан артындагы ниндидер авылдан бәхет эзләп килеп чыккан гади бер шахтёр икән. Үз вакытында ару-талуны белмичә, көн дими, төн дими, икешәр смена җир астыннан чыкмый эшләгән. Белеме юк, русчасы да ипилек-тозлык кына, имеш. Аның каравы, гаиләсе ишле, хатынын да алып килгән, балаларны ел аралаш «штамповать итеп кенә торалар» икән. Сөйләүләренә караганда, мин аны әкиятләрдә генә очрый торган баһадир гәүдәле бер каһарман итеп күз алдына китердем. Шул Сәгыйдулла абзый хәзер шахта начальнигының урынбасары булып эшли икән.

Сәгыйдулла абзыйга бармый хәлем юк иде. Шахта идарәсе саналган баракның ишеге янында, бар кыюлыгымны җыеп, тәвәккәлләргә дип

торганда, каршыма аксап-туксап дигәндәй, аягына таушалып беткән иске күнитек, башына колакчынлы бүрек, өстенә ямаулы бишмәт кигән, җыйнак кына гәүдәле бер кеше килеп чыкты. Ул килә-килешкә саф татар телендә:

– Кемне көтәсең, энекәш? Кай яклардан килеп чыктың? – дип дәште.

– Эшкә урнашырга кирәк иде, – дидем, тартынып кына. – Сәгыйдулла абзый исемле кеше янына керергә киңәш иткәннәр иде...

– Әйдә алайса, кире борылырга туры килә инде, – дип, бу мине үзе артыннан ишеккә таба ияртеп алып китте.

– Рәхмәт, сез аны ничек табарга икәнлеген генә әйтегез. Мин үзем... – дип әйтеп карыйм. Ә ул, сүзләремә колак салмый.

Такта белән тышланган бер катлы озын баракның ерак почмагында урнашкан тар гына кабинетка узып, түрдәге өстәл артына кереп утырды. Шунда гына чамаладым, Сәгыйдулла абзый дигәннәре шул үзе булып чыга түгелме соң?..

Махоркасын көйрәтеп җибәргәч, ул бер мәл үземә сынап карап торды.

– Мә, төрәсеңме? – дип, миңа да гәҗит кисәге сузды.

– Тартмыйм шул, рәхмәт...

– Анысы яхшы. Җүнле нәрсә түгел, тәмәкене әйтәм, – дигәч, буыла язып йөткеренеп алды. Һәм шул арада минем хакта нәтиҗә дә чыгарып куйды. – Бер дә шахтада күмер чабарга килгәнгә охшамыйсың бит әле син, егет...

– Башыңа төшсә – башмакчы булырсың, дигән бит өлкәннәр. Башка эш булмаса, нишләмәк кирәк, – дидем, сер бирергә теләмичә.

– Башмакчының да кирәге чыга анысы, – диде ул, маңгаена сузылып төшкән чал чәчләрен биш бармагы белән артка таба тараган сыман итеп.

Шунда гына бу абзыйның аягы гына түгел, бер кулы да зәгыйфь, ягъни чулак икәнлекне чамалап калдым. Нигә, нидән, дип сорап булмый бит инде. Соңрак, шактый көннәр узгач кына, аның шахтада берничә тапкыр һәлакәткә юлыгып, очраклы рәвештә генә исән калуы турында ишеттем. Гомумән, Сәгыйдулла абзый турында легендаларның ниндиен генә ишетергә туры килмәде анда.

...Шахта ишелеп, йөздән артык әзмәвердәй ир-ат җир астында бикләнеп калган бер заман. Махсус коткару төркемнәре күпме тырышып та коткара алмаган үзләрен. Ә Сәгыйдулла абзый, кулсыз-аяксыз килеш дигәндәй, һичкемнән рөхсәт-фәлән сорамыйча, берүзе тәвәккәлләп, җир астына төшеп киткән, күптән онытылган һәм җимерелгән әйләнгеч юллар аша җаен табып, коткарып алып чыккан, диләр, теге шахтёрларны...

Сөйләшә-аңлаша торгач, хәлемә кереп, «ликбез» курсларына укытучы итеп билгеләде ул мине. Ризалашмый хәлем юк, килештем: «Монысы минеке», – дидем.

Сәгыйдулла абзый сүзне озакка сузып тормады, башын күтәрә төшеп, стенада эленеп торган сәгатькә күз төшереп алды да капылт кына урыныннан торды.

– Әйдә, – диде ул, үзе артыннан чакырып, – сүз сөйләшеп утырудан эш чыкмас, коллектив белән, шахтёрлар белән таныштырып чыгыйм үзеңне... Укучыларың, тыңлаучыларың белән...

Бераз каушый төшеп, аңарга иярдем. Аксак күп йөрер, сукыр күп күрер, дигәндәй, чак җитешеп бардым Сәгыйдулла абзыйның артыннан.

Күп йөгерергә туры килмәде, бер барак аша гына урнашкан булып чыкты «ликбез» дигәннәре. Иң әүвәл мөдир янына алып керде. Сәгыйдулла абзый ватып-сындырып, русчага күчте:

– Татар курсларына укытучы җитми дип зарланган идең. Менә дигән егет алып килдем үзеңә... Казан университетында укыган егет.

– Мин бит... – дип, сүз башлаган идем, туктатты. Үземнең университетта түгел, рабфакта гына берничә ай укуымны искәртмәкче идем. Шул арада тагы: «Казан университеты профессорларыннан белем алган егет!» – дип тә өстәп куймасынмы?

Бу юлы инде дәшмәдем. Авыз ачсам, сизеп торам, Сәгыйдулла абзый барыбер миңа сүземне әйтеп бетерергә ирек бирмәячәк.

Мөдир, кирәксә-кирәкмәсә дә, маңгаендагы күзлеген бер салып, бер киеп, ватык пластинка кебек берөзлексез: «Хорошо... хорошо», – дип кенә кабатлап торды.

Озын булып сузылган тар гына коридор буйлап алып китте болар мине. Кайсыдыр ишектән русча сөйләшкән тавышлар ишетелеп калды, кемдер лекция-фәлән укый иде булса кирәк...

Чү, икенче бер ишектән тын гына, ипле генә музыка агыла түгелме соң? Хәйран калдым, татар музыкасы... Нинди көй икәнен генә искә төшерә алмыйм, таныш та, түгел дә кебек. Әмма шул тикле дә күңелгә ятышлы. Кинәт аякларым сөрлегеп куйды. Эсселе-суыклы булып китте. Тәнем буйлап кырмыскалар йөгерешкәндәй булды, дип әйтимме? Байтактан, бик күптән ишеткән юк иде шул кадәрле дә зывык белән, үзәкләрне өздереп уйнаганнарын. Нинди инструментта уйныйлар диген әле. Фортепьянода!.. Адымнарымны сагайта төштем, тукталып, уйнаучының кем булуын ишек ярыгыннан гына булса да күреп каласым, күзәтәсем килде. Үзем бер нәрсәдә уйный белмәсәм дә, гомер буе музыкага, үзебезнең татар-башкорт көйләренә гашыйк булып яшәдем бит мин. Төш күрсәм дә, музыкалы булды, саташсам да – колак очымда музыка, моң яңгырап торды...

– Әмирхан! – дигән, шелтәле аваздан сискәнеп куйдым. Бу Сәгыйдулла абзый тавышы иде, әлбәттә. Бу аның: «Нигә артта каласың, җәтрәк бул», – дип кисәтүе иде.

Әле генә музыка һәм милли моң дулкынында канатларын җилпеп очып барган бәхетле бер кош идем, ул да түгел, канатларым каерылып, шапылдап, таш идәнгә килеп төшкәндәй булдым...

Шау-гөр килеп, татарча сөйләшеп утырган шахтёрлар янына килеп кердек. Сәгыйдулла абзый белән мөдирне күргәчтен шым булдылар. Ә минем колак төбемдә исә әле һаман теге музыка авазы яңгырап тора.

– Якташларым, – дип, шахтёрларга олы хөрмәт белән, ягымлы һәм үз итеп сүз башлады Сәгыйдулла абзый. – Менә сезгә яңа укытучы килде. Казанның үзеннән! Казан университетыннан! Профессор, – дип тә өстәп җибәрмәсенме?

Башым әйләнеп китте, ул каян килгән «профессор» инде тагын. Күр инде, шыттырыпмы шыттыра бит. «Әле студент та була алганым юк, нишләвең бу, Сәгыйдулла абзый?..» дип әйтәсем килде дә, әйтеп булмый бит. Үземнән бигрәк Сәгыйдулла абзыйның репутациясен төшерүдән курыктым. Ул бит чын күңелдән ианып сөйли иде кебек, теле телгә йокмый. Профессорның

кем булуын, ул дәрәҗәгә җитү, күтәрелү өчен күпме укып, күпме лаеш шулпасы эчәргә кирәклекне авылдан килеп, гомер буе җир астында кәйлә белән күмер чапкан абзый каян белсен инде? Хәер, ул вакытта мин үзем дә профессор-фәлән күргән кеше түгел.

Ликбез курсларының мөдире бу юлы да, татарча бер авыз сүз белмәвенә карамастан, Сәгыйдулла абзыйны, «Хорошо... хорошо...», – дип хуплап кына торды. Шул рәвешле, залны тутырып шау-гөр килеп утырган шахтёрлар каршында бер ялгызымны калдырып чыгып та китте болар. Нишлим, сүзне нәрсәдән башлыйм икән соң, дип югалып тордым бер кавым, лекция-фәлән укыган кеше түгел бит. Ни сөйләргә кирәклеген, тыңлаучыларныниләр кызыксындырганлыгын да белмим. Өстәвенә, әле булса колагымда теге фортепьянодан яңгыраган милли моң авазы эленеп тора...

– Әмирхан, – дип, шул мизгелдә залдан исемем атап дәшмәгән булсалар, белмим, бу халәттән ничек чыккан булыр идем икән. – Казанда, безнең туган якларыбызда хәлләр ничек соң, иң башта шуларны сөйлә әле?

Бу, рәхмәт яугыры, теге, әле бая гына урамда очрашып, мине Сәгыйдулла абзый янына барырга киңәш итеп җибәргән егетләрнең берсе булып чыкты. Тынычлана төштем, шул рәвешле, сүз иярә сүз чыгып, ипле генә аңлашырга да керештек төсле.

Хәзерге яшьләр аңлап та бетерми торгандыр, «Ликбез» дигәнебез «Хезмәт ияләренең белемен күтәрү курслары» булып чыга. Мин тукталган бистәдә шахтёрларның яртысы татар-башкортлар иде, дисәм, һич арттыру булмастыр. Авыл кешеләре... Уналты-унҗиде яшьлек үсмерләрдән башлап, илле-алтмышка җиткән абзыйларга кадәр йөрергә тиеш икән ул курсларга. Йөрү мәҗбүри. Җир астында күмер чабып, кара күмер тузаны иснәп, тугыз-ун сәгатъ эшләп кайтканнан соң адәм баласында уку кайгысы калгандырмы, ул кадәресен белмим. Минем эш – дәресләр алып бару, наданлык белән көрәшү. Шахтёрларга Совет иленең гөрләп чәчәк атуы турында мәгълүмат җиткерү...

Арада тормыш тәҗрибәсе минекеннән күпкә зуррак булган, зирәк акыллы агайлар шактый булганга, бу курслар минем өчен дә үзенә күрә бер университет булды кебек. Сирәк-мирәк кенә булса да хатын-кызлар да йөри торган иде бу дәресләргә. Алар, зур булмаган аерым төркем булып, бер читтәнрәк урын ала...

Шул урында сүзсез калып торды Әмирхан абый. «Эһем-эһем» дип, ияләнгән гадәте буенча бер тын йөткеренгән атлы булып барды. Аннары, ниләрнедер искә төшереп, үзалдына серле генә елмаеп та куйды.

– Нидер яшерәсең түгелме, Әмирхан? Сер итеп кенә безгә дә сөйлә инде, – дип мөрәҗәгать итте аңарга Гомәр ага.

– Хатирәләрдә генә булса да, үземне яшьлегемә кайткан кебек хис иттем әле менә. Егермесе дә тулмаган егет чакларым бит.

Эштән арып кайткан шахтёрлар, билгеле инде, курслар бетәр-бетмәс үк, торган җирләренә, баракларына тарала. Ашау якларын кайгыртасылары бар, юыну-чистарыну, кием-салымны тәртипкә китерү дигәндәй, чыпчык чүпләп бетерә алмаслык эшләре бар. Бик сирәкләрен генә гаиләсе көтә. Гаиләсе, бала-чагасы белән күчеп килүчеләр бармак белән генә санарлык иде кебек әле ул елларда. Беренче көннәрдә артык күзгә чалынмасалар да,

тора-бара яшь кызлар да күренгәли торган булып китте. Кайсыберләре күзләрен чекерәйтеп, иң алгы рәтләргә килеп утыралар да, үзара пышпыш хәбәрләшкән атлы булып, игътибарымны җәлеп итәләр. Бер очтан уңайсызлык тудыралар, кәнишне. Шелтә-фәлән белдерергә кыюлык җитми. Минем бит әле кызлар белән мөнәсәбәттә тәҗрибә-фәлән юк, кыюсыз гына түгел, оялчан да булганмындыр. Хәер, ул кыюсызлык дигәннәреннән, мин гомер буе арына алмадым кебек.

Яшьләр, чибәрләр, корт чаккырлары... Карамыйм, дисәм дә, күз төшә бит кызларга. Өстәвенә, берсеннән-берсе матурлар да бит әле. Болар инде безнең яклардагы кебек иске-москы чүпрәккә төренгән чабаталы авыл кызлары түгел. Бит урталары кызыл алма, ә күзләре утлы күмердәй янып тора.

Менә шул кызларның берничәсе курслар тәмамлангач та, төрле хәйлә һәм сәбәпләр табып, мине тоткарлый торган булып киттеләр. Сорауларын да табалар. Эһем-эһем... Кайсыберләре өйгә кайтырга чыккачтын да, юлда очрый торган булып китте... Өй, дигәнем шул – шахтёрлар яши торган бaрактан бер ятак табып биргәннәр иде...

– Әнә шул, «эһем-эһем» дигәне, кызыклы да инде аның. Син, Әмирхан, шунысын сөйлә булмаса безгә, җентекләбрәк сөйлә, – дип, чираттагы мәртәбә шаярган атлы булып сорашуын дәвам итте Гомәр ага.

– Сөйлә дисең инде алай булгач... – Тагы бер мәл, «эһем-эһем...» килеп тукталып торды ул.

– Әнә шул, «эһем-эһем»ен төшереп калдыра күрмә...

Бу юлы инде, алдан сүз берләшкәндәй, һәммәбез берьюлы көлешеп куйдык. Хәтта бер авыз татарча сүз белмәгән шофёрыбыз рус егете Володя да кушылып көлде кебек.

Ниһаять, Әмирхан Еники тәвәккәлләргә булды. Гадәтенчә, сүзен бераз урый төшебрәк башлап китте.

– Күз алдына китерә аласызмы-юкмы, анысы сезнең эш. Мин гомеремдә һичкайчан хатын-кыз затына беренче булып дәшә алган кеше түгел. Күзләремне майландырып, авыз суларымны йотып калган чакларым булгандыр, әмма башлап сүз әйтә алмадым. Кызлар чибәр, яшьләр, дидем кебек инде. Бер кадәр тәҗрибә туплап өлгергәннәре дә булгандыр. Табигый ки, миннән бер-бер җылы сүз өмет итүчеләре дә булуы бик ихтимал.

Көннәрнең берендә, кичке эңгер-меңгер төшеп килгән чакны, гадәтләнелгәнчә, үз уйларыма бирелеп, бер ялгызым тору урыныма кайтып барам шулай. Көтмәгәндә-уйламаганда, бер үтә дә чая кыз каршыма килеп чыкмасынмы? Мин укыта торган курсларга соңгы араларда гына килеп кушылган иде әле ул. Әмма беренче күрүдә үк күзгә ташланып, хәтергә кереп калган.

– Абый, – ди бу миңа. Юкса, сизәм, бер дә абый түгел мин моңарга. Үземнән өч-дүрт яшькә өлкәнрәк тә булмадымы икән әле. Күзгә кереп торган әрсезләрдән булмаса да, кыюсызлардан түгел. – Сез Казанның үзеннән үк килдегезме? – ди.

– Шулай, – мин әйтәм, – Казанның үзеннән килдем, университетта укыган җиремнән...

– О-о-о, – ди бу, – университетта укыдыгызмы?

– Укыдым, – мин әйтәм. Кызларга университет каршындагы рабфактан куып чыгардылар, дип әйтеп булмый бит инде. Марканы сакларга кирәк! Берочтан Сәгыйдулла абзый сүзләрен дә аяк астына салып таптап булмый...

Сүз артыннан сүз ияреп, матур гына әңгәмә корып кайтып киләбез без моның белән. Кызның теле телгә йокмый, үзе турында да сөйли, миннән дә тегесен-монысын сораштырган була. Гел көтмәгәндә, тик үзенә генә хас мөлаемлык белән балкып көлеп тә җибәрә. Кыскасы, берөзлексез салкын яңгыр пыскаклап торган көзге моңсулыкны әллә ни арада таратып, нурландырып җибәргән кебек булды бу кыз. Әмма, гөнаһ шомлыгы, икебез ике тарафта яшәү сәбәпле, чираттагы урам чатында без аерылышырга мәҗбүр идек. Туктап калдык...

– Син бит мине шулай урам уртасында берьялгызымны калдырып китмәссең, дип уйлыйм, – ди бу миңа.

– Юк-юк, – мин әйтәм, – булмаса, озатып куя алам үзегезне. Ашыгыр җирем юк...

– Ә сез чын егет икән. Миңа әнә ул тарафка, – дип, үзе артыннан әйдәп алып китте бу мине.

Буйсынмый хәлем юк, иярдем мин моңарга. Ерак барырга туры килмәде, бер-бер артлы тезелеп киткән баракларның соңгысын узгачтын да, шәхси йортлар башлана. Кыз шуларның берсе каршында туктап калды.

– Менә кайтып та җиттек, – диде ул, тирән сулыш алып. Кинәт җитдиләнеп калды. Очраклы рәвештә генә булса кирәк, үз иткәндәй, бармак очлары белән кулыма кагылып куйды. Һәм зур зәңгәр күзләрен мөлдерәтеп, миңа текәлде.

Бармак очлары уттай кайнар иде аның. Ялгышып кына кагылуыннан да миңа эсселе-суыклы булып китте, гүя тәнемнән бер оя кырмыска йөгерешеп узды. Ә үзем, чарасыз калып, тәмам коелып ук төштем.

– Абау, кулларың бигрәк суык, күшеккәнсең түгелме? – диде ул, минем авыздан бер-бер җылы сүз чыкканын көтеп-көтеп тә ишетмәгәч. Һәм тагы да серлерәк итеп, янә үтә дә ягымлы, зәңгәр карашын сирпеп алды. Сынаулы караш иде булса кирәк. Юк-юк, җилбәзәклек яисә әрсезлекнең заты да юк иде аның ул карашында. Хәтта, әйтер идем, ниндидер моңсулык төсмерләре дә булмадымы икән әле. – Кермисеңме соң? Өйдә кеше юк, әти дә, әни дә бүген төнге сменада эшлиләр. Кайнар чәй эчеп китәрсең. Берочтан Казан турында да сөйләрсең.

Минем өчен бөтенләй көтелмәгән тәкъдим иде бу. Бәлки, чәй эчәсем дә килгәндер. Әмма беренче кат күргән кыз артыннан ияреп, аның өенә үк барып керү уема да килмәслек тәрбиясезлек булыр иде, үземне баш тартырга мәҗбүр итә алдым. Йә, шунда керден дә, ди. Чәен дә эчтең, ди. Шуның белән генә тәмамланыр идеме икән соң ул кич? Тәҗрибә яклары бик сай булса да, чамалыйм. Дәрт бар да, дәрман юк бит, диләрме әле?

Кыз алай дип тә, болай дип тә юмалап карады. Мин фәкыйрегезне бик тә, бик тә чәй белән сыйлыйсы килә иде, күрәсең. Кирелегем җитәрлек, бирешмәдем.

– Сине чәйгә чакыра-чакыра, иреннәрем туңа башлады инде, – дип тә әйтте кебек әле. Һәм чираттагы мәртәбә серле генә елмаеп та куйды.

Күрсәгез икән аның ул елмаюын... Ә мин, берни тоймаганга, аңламаганга сабыштым.

– Бармак очларың уттай яна, әнә, иреннәрең туңган икән – җылыт, – дип тә әйтеп ташладым булса кирәк әле. Шул сүзләрем өчен әле дә оят булып китә кайчак.

Кыскасы, хушлаштык. Үз сүзен сүз итә алмаудан ачуы чыгыпмы, әллә миңа гына шулай тоелган, ул үзе артыннан капканың тимер keләсен нык шапылдатып япты. Мин, җебегән авыз, аның исемен дә сорарга онытып, борынымны салындырып, салкын җил-яңгыр астында үзем тукталган баракка таба салмак кына атлап китеп бардым.

Кызның бармак очларындагы кайнарлык һәм «иреннәрем туңды» дигән сүзләрен оныта алмыйча төне буе урынымда боргаланып чыксам чыктым, әмма һич кенә дә үземнең кыланышларыма үкенмәдем. Белер-белмәс чит кешенең бусагасыннан атлап керергә хакым бар идеме соң? Юк иде, әлбәттә.

Иртәгәсен эш урыныма гадәттәгедән дә иртәрәк барырга булдым. Баракта, ягъни торган җиремдә, тынычлык юк, берәүләре төнге сменадан кайтып йокларга ята, икенчеләре таң тишегеннән эшкә китү мәшәкатьләре белән мәшгуль, уен-көлке белән шау-шу килеп, кәрт сугучылар да табыла. Ә миңа китапханәгә кереп, гәҗит-журналлар караштырырга, чираттагы дәресләргә әзерләнергә кирәк. Авылга хат язасым бар. Уфа һәм Казандагы таныш-белешләремә дә берничә юл язып җибәрү зыян итмәс иде. Юкса, хәбәр-хәтерсез кайда югалды бу, дип уйлый торганнардыр.

Китапханә дигәнем шул безнең курслар урнашкан бинада. Тышкы ишекләрне ипле генә ачып керүем булды, янә колакка фортепьяно авазы килеп уралды. Күңел төшенкелегем шундук юкка да чыкты, кичәге теге кыз да онытылды. Монда бит татар моңы яңгырап тора... Күңелгә бик тә ятышлы көй... Таныш та кебек ул көй, түгел дә кебек. Әмма искиткеч зәвыклы көй, бәгырьнең әллә кай җирләренә үтеп, җанның иң нечкә кылларына кагылып үрсәләндерә торган көй. Тукта... Кемдер, ниндидер бер кыз, тыныч кына, үзалдына җырлый да түгелме соң?

Җырлый, дидем, әмма җырлау гына идеме икән бу? Гүя татар моңы зәңгәр күк йөзендә тургай булып тибрәнә. Шул моңда туып-үскән якларның чишмәләре челтерәгән аваз, урман шавы, баш күтәрми урак урган әниләрнең, каерылып-каерылып печән чапкан агайларның йөрәк тибеше ишетелеп калган кебек тоелды. Шул рәвешле әлеге моң, иркәли-тибрәтә, үземне туган якларыма, ямьле Агыйдел буйларына алып кайтып китте. Сүзләрен ачык кына ишетеп тә җиткермим ләбаса, җырчы кем өчен дә булса түгел, үзалдына гына көйли. Әмма ул шулкадәрле дә саф вә самими бер җыр иде кебек. Китапханәгә юлны оныттым, бар мәшәкатьләр юкка чыкты, татар моңы мине шул музыка, җыр яңгыраган ишек янына гүя җитәкләп үк алып килде.

Ишек ябык. Баксаң, бөтенләй үк ябылып та бетмәгән, борын сыярлык кына ярык та калган икән. Шул ярыкка текәлдем. Бераз ача төшеп, кем уйнаганын, кем җырлаганын бик тә, бик тә күрәсем, беләсем килсә дә, кыюлыгым җитмәде. Көтмәгәндә, ишек шыгырдап куяр да, бары да кинәт юкка чыгар – музыка авазы да, җыры да, моңы да.

Бүлмәдә башка һичкем юк, инструментта уйнаучы япа-ялгызы моңлана... Ул үзе уйный, үзе үк җырлый да иде булса кирәк. Әмма, кем дә булса башка бер кеше тыңласын, алкышласын өчен түгел, бары үзалдына, үзе өчен генә моңлануы иде. Тагы, шунысы яман, ишектәге ярык бик кечкенә, аның кем булуы күренми. Үзе күренмәсә күренмәсен дә, ди, һич югында ул гүзәл затның чәч толымнарын гына булса да бер күрергә иде бит. Аның үтә дә бер чибәр һәм нәзакәтле бер зат булуында минем һич шигем калмаган иде инде. Ялгыш тирән сулыш алып куйсам, яисә тамак-фәлән кырсам да, сизенәм, җыр тукталачак. Юк-юк, мондый моң, мондый җыр һичкайчан тукталырга тиеш түгел. Ул бар дөньяга мәңге-мәңге яңгырап торсын иде шулай. Бу моңны ишеткән, бу җырны тыңлаган һичбер адәм заты һичбер вакыт дорфалыкка, кешене рәнҗетергә, башка берәүгә бәла-каза китерергә базмас иде. Дөньяда ягымлы сүзләр, җылы караш, иркә һәм наз, сөю-сөелү генә тантана итәр иде, бу җыр, бу моң һәрдаим яңгырап торса.

Чү, җырның сүзләре дә ишетелә иде түгелме. Отып калырга теләп, сулыш алуымнан тукталып тыңларга тырыштым:

Өздереп гармун уйныйлар
Наласа авылында.
Йөрәгемә утлар яктың –
Янам мин ялкынында...

– дип моңлана түгелме соң? Наласа... Ул нинди авыл, кай тарафларда урнашкан? Күргән-ишеткән җирем түгел. Үзем күрмәгән, хәтта андый авылның булуы турында шул көнгәчә ишетмәгән булсам да, аның әкияткә тиң матур табигате, урман-кырлары, калкулыктан сузылып төшкән урамнары, мул сулы елгалары күз алдыма килеп басты.

Әй, ул көе... Ул музыка, ул моң... Ә сүзләре... Сүзләре дисбегә тезелгән энҗе бөртекләренә тиң! Уйнаучысы, тын гына җырлаучысы исә гүя җир кызы түгел, бер алиһә булса кирәк. Айлы һәм йолдызлы чиксез галәмнән чиләк-көянтәсен иңнәренә салып, шул Наласа авылының чишмәсеннән шифалы су алырга гына төшкәндер кебек ул. Эх, шул кызны, моң чишмәсенә тиң кызны бер күрсәң иде ул...

Төнбоеклы тирән күлдә
Тезелеп йөзә аккошлар.
Үсеп җиткәч, чит җирләрдә
Йөртә безне язмышлар...

Нәкъ минем турыда, минем язмышым, күңелемдә йөреп тә әлегәчә тормышка ашыра алмаган хыялларым турында җырлый түгелме ул? Сүзләрен белсәм, тавышым бармы-юкмы, шул мизгелдә аңарга кушылып җырламый кала алыр идемме икән?

Бала чагым гөрләп үтте
Наласа кырларында.
Сагынуларым, сагышларым
Бу моңлы җырларымда...

– Әмирхан, – дип, кинәт үземә дәшкән көр тавыштан сискәнеп куйдым. – Ишек ярыгына борыныңны кысмасыннар тагы.

Утсыз караңгы коридорның аргы башыннан дәшүче әлеге дә баягы Сәгыйдулла абзый булып чыкты. Аның директор кабинетыннан чыгып килүе булган. Ни дип җавап бирергә белмичә, ишектән читкә тайпылырга мәҗбүр булдым. Шулай да:

– Мин бит болай гына, үтеп барышлый гына, – дип, җавап кайтара алдым. – Җыры бик матур...

– Җырымы, әллә җырлаучысымы, – дип, серле генә елмаеп, күз кысып алды ул.

Бу юлы инде җавапка сүз таба алмадым. Ул да куертып тормады, мине үзенә ияртеп, китапханәгә алып кереп китте. Җитди сүзе булган икән. Журналист яисә язучы булу турындагы хыялымны истә тотып, ул миңа Казан һәм Уфада чыга торган татар матбугатына шахтёрлар турында мәкаләләр язарга киңәш итте. «Илгә күмер кирәк, яңа шахталар ачылачак, эшче көчләр җитми. Безнең мондагы тормыш турында, аның өстен яклары, яхшы хезмәт хакы турында ишетсеннәр, килсеннәр. Үзләре өчен дә, туган ил өчен дә файдалы бер эш булыр», – диде Сәгыйдулла абзый.

Билгеле инде, бик теләп риза булдым. Бер очтан татар дөньясына үзем хакында искә төшереп тору өчен дә бик кулай булачак бит әле бу.

Ә теге үзләренә чәйгә чакырган кыз, үпкәләде булса кирәк, шул көннән башлап, минем курсларга йөрмәс булды ул, эзе суынды, башкача күренмәде. Дәресләр башландымы, мин нигәдер, залдан һәрчак аны эзләдем. Нигә эзлим, сәбәбен һич белмим...

Хәер, аның кайгысы идемени соң миндә? Җырчы кыз! Анысы менә бөтенләй башка. Шул җырчыны бер күрер өчен әллә ниләр бирергә риза булыр идем. Юк сүзне бар итеп, бер-бер сәбәп табып, ишеген кагарга кыюлыгым җитми йөргән көннәрем күп булды. Шул ишеккә якынайдыммы, ике көннең берендә музыка авазыннан чарасыз торып калам. Ишеген кагармын да, җеп өзелеп, дисбе төймәләре идәнгә сибелгәндәй, милли моң кинәт өзелер, туктап калыр. Һәм башка һичкайчан яңармас, ялганып китмәс кебек тоела иде.

Тормыш якларына килгәндә, анысы тора-бара үз эзенә төште, җайга салына башлады дип әйтергә була. Курсларга йөрүчеләр дә үз итеп кабул иттеләр. Казан һәм Уфада чыга торган гәҗитләрдә мәкаләләрем күренгәли башлавы да иңнәремә канат өстәде. Бер яктан, анда минем исемем чыгып, барлыгымны белеп торулары яхшы. «Кызыл Татарстан» гәҗитендә беренче мәкаләм чыккан көнне башым күккә тигәндәй булды хәтта. Икенчедән, үзебезнең шахтёрлар арасында да дәрәҗәм күзгә күренеп күтәрелә иде бит. Хезмәтемне күреп, миңа үзебез яшәгән баракның почмагыннан, тар гына булса да, аерым бүлмә дә юнәтеп бирделәр хәтта. Язу, тынычлап иҗат итү өчен менә дигән шартлар тудырылды. Кәрт сугучылардан да, шау-гөр килеп шәраб эчүләрдән, һәм иң мөһиме, тәмәке төтененнән дә котылдым. Инде хәзер йомыш-фәлән белән йөрүчеләр дә, ишегемне шакып, рөхсәт сорап кына керәләр яныма...

Шул рәвешле уйламаган-көтмәгәндә, шахтёрлар бистәсендә, күз өстендә кара каш ук булмасам да, үземә күрә кәттә генә бер егет кисәге булып

киттем бит әле мин. Кызыл почмакта бер-бер киңәшмә-фәлән яисә нотык сөйләргә кирәк булса да, мине чакыра торган булдылар. Татар мәдәнияте һәм әдәбиятына мөнәсәбәте булган вакыйгалар турында инде әйтеп тә торасы юк.

Ә көннәрдән бер көнне, үзем комсомол булмасам да, шул оешманың ничәнчедер еллыгына багышлап, татар яшьләре оештырган тантаналы кичәгә дәштеләр. Клуб шыгрым тулган. Күпчелеге шахтёр егетләр, әлбәттә. Арада берсеннән-берсе чибәр кызлар да байтак. Ялкынлы нотыклар сөйләнгәннән соң, җыр-бию, шобага салу һәм түгәрәкле уен, заманча әйтсәк, танцы-мансылар башланып китте, мин сиңа әйтим.

Үземә калса, шау-шулы, ыгы-зыгылы чараларны, гомумән, яратмадым. Бу юлы да, гадәтемчә, кеше күзенә артык ташланырга теләмичә бер читтәнрәк урын алып күзәтеп утырам. Чираттагы биюләрдән соң тамашаны алып баручы комсомол егет уртага чыгып басты, нидер игълан итәргә җыена иде булса кирәк. Шау-шулы зал бер мәлгә киеренке тынлыкта калды.

– Хәзер, – дип башлады ул сүзен, – сезнең каршыга бүгенге кичәбезнең зур кунагы, Донбассның данлыклы металлургия комбинатында прокатчы булып эшләүче танылган шагыйрь Шәйхи Маннурны чакырабыз...

Бу хәбәрне дәррәү кул чабып каршыладылар. Кәттә егетләр арасыннан кайсыберләре, күн итек үкчәләре белән идәнне дөп-дөп кагып, сызгырып ук җибәрделәр. Мин дә урынымнан ничек сикереп торганлыгымны сизми калдым. Шагыйрь тикле шагыйрь килсен инде, ә. Сикереп тә торма, имеш. Әдәбият минем иң зур хыялым бит... Әлегә тормышка ашмаган хыялым. Шигырьләр дә аз язмадым түгел, матбугатка бирергә, кешегә күрсәтергә генә базмадым. Ә инде Шәйхи Маннурга килсәк, күргән-белгән кешем булмаса да, Казанда чакларымда аның хакында бик еш ишетергә туры килә иде. Гәҗит-журналлардан шигырьләрен дә укыганым бар.

Карап торышка бер дә башкалардан аерылып тормый иде кебек ул. Өстендә, авыл җирләреннән килгән шахтёр егетләрнеке кебек үк, кулдан бәйләнгән йон свитер, аягында күн итек. Күренеп тора, авыл егете. Үзен игълан иткәчтен дә, ипле генә атлап уртага чыгып басты шагыйрь. Маңгай астыннан сөзеп, бер мәл дәшми-нитми үзен урап алган шахтёр егетләргә карап торды. Маңгаена төшеп торган чем-кара чәчләрен биш бармагы белән артка таба сыпырып куйды һәм, көтмәгәндә, балкып елмаеп җибәрде. Күрсәгез иде аны шунда, күзләрен хәйләкәр генә йома төшеп, шул кадәрле дә ихлас һәм эчкерсез елмайды ки, шундук күптән таныш үз кешегә әверелде дә куйды. Ара-тирә күзгә чалынган кызларның берсе, шул мизгелдә гел тәкатьсез калып, басып торган җирендә тыпырдап, кулларын чәбәкләргә кереште.

– Мин сезгә нинди шигырь укыйм икән соң? – дип, шагыйрь колак артын кашып алды. – Күрәм, сез дә минем кебек авыл җирләреннән килгән егетләр һәм кызлар. Туган якларны сагынып язылганнарын укыйм, булмаса.

– Укы... Укы... Без дә сагынабаз туып-үскән якларны, – дигән авазлар ишетелде һәр тарафтан.

Тыныч кына, ипле генә яңгырады аның калын һәм көр тавышы. Укыган һәр шигыре белән ул тыңлаучыларга тагы да якыная, үз кеше була барды.

Мин дә тын да алмыйча тыңладым. Шигырьләре дә, бер карасаң, үзе кебек үк гади һәм гадәти кебек. Ә шундый күңелгә ятышлы, һичкемне битараф калдырырлык түгел. Төрле тарафлардан җыелган татар-башкорт егетләренең күңелендә йөреп тә әлегәчә әйтелмәгән хис һәм тойгылардан гыйбарәт иде ул укыган шигырьләр. Шуңа күрә бер-ике шигырь укырга дип чыккан шагыйрьне мәйдан уртасында шактый озак тоттылар. Инде тәмамладым дип тукталгачтын да, аяк тибә-тибә кул чаптылар үзенә, кабат-кабат: «Тагы берне генә, тагы бер генә шигырь булса да укыгыз инде?» – дигән сүзләр яңгырады.

Шәйхи Маннурны элек-электән укыган һәм танып белгән яшьләр дә байтак булып чыкты. Якташлары, хәтта авылдашлары да бар иде түгелме икән әле, һәрхәлдә миңа шулай тоелды. Үзен урап алып, кемнәрнедер искә алулары,ниндидер миңа таныш булмаган авыл исемнәрен искә төшереп сөйләшүләреннән чыгып әйтүем.

Алып баручы егет шагыйрь тирәсендә башланып киткән ыгы-зыгыга вакытында киртә куярга өлгерде.

– Егетләр, кызлар, тынычланыйк... Әле шагыйрь белән хушлашмыйбыз, ул безгә тагы да зуррак бүләк алып килгән... Тынычланыгыз...

Шау-шу, чыш-пыш беркадәр басыла төште. Нинди бүләк икән ул тагы, дигән сорауга җавап ишетәсе бар икән бит әле.

– Хәзер безнең каршыда, әле яңа табадан төшкән дигәндәй, өр-яңа җыр башкарылачак. Аның сүзләрен бүгенге кунагыбыз шагыйрь Шәйхи Маннур язган. Ә музыкасын үзебезнең моң чишмәсе – Галимә.

Алып баручының соңгы сүзләрен кинәт дәррәү кузгалып киткән алкыш, хуплау авазлары, сызгырулар күмде. Икенче берәүләре: «Галимә! Галимә!» – дип, аның исемен такмаклый-такмаклый күтәреп алды. Күренеп тора, минем өчен әлегәчә таныш та булмаган бу туташ, залны тутырып кайнашкан яшьләр өчен бик тә үз кеше иде булса кирәк.

«Галимә! Галимә туташ!» дип, бу исемне хәтеремдә калдырырга теләп, мин дә үзалдыма кат-кат кабатладым. Мине беренче ишетүдә үк сихерләгән, әлегәчә күземә-фәлән чалынмаган, серле бер моң чишмәсе генә булып кала биргән кыз үзе түгелдер ләбаса? Аны бер күрү өчен әллә ниләр бирергә дә әзер идем түгелме мин?

Алкышлар беркадәр басыла төшкәч, алып баручы үзе ясаган игъланга ачыклык кертүне кирәк тапты:

– Безнең шахтёрларга багышлап язылган бу яңа җырын Галимә үзе башкара...

Киереп ачылган ишектән, иңсәсенә салынган тальян гармунны бар көченә уйнатып, җыйнак кына гәүдәле бер мөлаем кыз килеп керде. Як-якка этәрелеп, аңарга юл ачтылар. Мин бер читтә, ерактарак утырганга, әле аның үзен ачык кына күреп тә өлгермәдем. Әмма кызның гармунда уйнавына һәм тын гына җыр башлап җибәрүенә битараф калу мөмкин булмагандыр, урынымнан калыктым. Баксаң, минем өчен күпме вакытлардан бирле илһам чыганагы һәм бер сер булып яшәгән җырчы һәм музыкант Галимә атлы булып чыга икән бит... Үзе! Мине хәйран калдырган, мине яулап алган, хисләндергән, йокысыз калдырган, үземә туган якларым, иң кадерле туганнарым, әти-әниемнең күңел җылылыгын бүләк иткән, җаныма

сеңдергән җырчы һәм музыкачы шул үзе булып чыга икән бит. Галимә туташ!.. Үз-үземне белештермичә, тын калып, җыр тыңлаган шахтёрларны этә-төртә, шул тарафка сөрлегеп куйганмын...

Ә үзен күргәчтен, ничек егылып китмәгәнмен, артка чигеп куйдым. Җанымны иләсләндергән музыкачы кем булып чыкты, дисезме? Күзгә яңгырлы кичтә капка төпләренә кадәр мин озатып кайткан кыз! Үземне чәйгә чакырган кыз. Әле булса кулларымда, юк, кулда гына түгел, җанымда аның очраклы рәвештә кагылып киткән бармак очларындагы кайнарлык саклана. Димәк, Галимә туташ... Моң чишмәсе булып, күңелемдә инде менә күпме гомер яшәгән һәм мине милли моң дөньясында яшәткән алиһә Галимә туташ булып чыга! Үзем озатып кайткан кызны кабатланмас тавышы, җыры-моңы белән оныттыра язган кеше Галимә туташ үзе үк булып чыга. Аны барысы да таный, белә, олылый, аны үз итәләр, таланты алдында баш ияләр. Ә мин, юеш борын, аның кем икәнлеген дә белмәгәнмен, ул гынамы, аңардан качканмын да бит әле.

Тальян гармун, белмим, әллә уйный, әллә елый. Гармун тавышы шулкадәр дә моңлы булыр икән. Залны тутырып, җыр яңгырый. Күңел халкыбыз бәгырендә туып, чишмә булып аккан татар моңыннан үрсәләнә. Йөрәк күкрәк читлегенә сыеша алмый тибә. Күпме күңел бер дулкында тибрәлә, күпме йөрәк бер дулкында тибә.

Китә җаныем, китә җаныем,
Китә җаныем Донбасска;
Ул китә инде Донбасска,
Сүз бирдек ташлашмаска...

– Шәп җырлый бит, ә... безнең Галимә... – дип, шулчак берәү аркама кулын салды. Борылып карасам, минем курсларга йөрүче танышым, Башкортстан егете Салават булып чыкты.

– Үзәкләрне өздереп җырлый шул, моңлы җырлый, – дидем. – Шул тикле моң каян килә диген үзенә?..

– Әллә белмисеңме, – диде ул пышылдап, – аның бит ярәшелгән егете шахтадан кире кайтмады. Шуңа моңлы ул. Шуңа җырлый. Шуңарга күпме гомер үз-үзен кая куярга белми өзгәләнә. Кайгы-хәсрәтен сөйләр кешесе юк, шуңарга бәргәләнә. Юк, җырламый, елый һәм елата...

– Менә ничек! – дип кенә әйтә алдым. Чигәмә яшен ташы китереп суккандай булды. Ә мин аның турында бөтенләй ялгыш уйлаганмын булып чыга түгелме? Ялгызлыктан, күңеле тулып, бер бушанып сөйләшеп утырасы килгәндер аның теге чакта. Үземә ышанып, мине фикер уртаклашыр кешегә санап дәшүе булгандыр... Ә мин, әллә ниләр гөманлап, качып китеп барганмын...

Галимә туташ җырлый. Бар дөньясын онытып җырлый. Җырның сүзләре генә түгел, көе, бар моңы ургылып, саркылып чыга иде аның күңеленнән...

Шахталарга син төшәрсең,
Җырлап күмер кисәрсең;
Әмма мине бик сагынсаң,
Бик саргайсаң, нишләрсең...

Чынлыкта, үзе сагына, үзе саргая булып чыга түгелме соң ул? Хәер, юк, аның халәтен сагыну яисә саргаю дип кенә әйтеп булмый торгандыр... Ул халәтне аңлатырлык сүзләрне табу мөмкинме, андый сүз бармы икән? Бары моң, күңел түреннән чыккан моң гына аңлата торгандыр кызның кичерешләрен... Чү, ул әнә күлмәк кесәсеннән кулъяулык чыгарып, күз читләрендә мөлдерәгән кайнар тамчыларны сөртә түгелме?

Җыр тәмамлангач, зал бер мәл тып-тын калып торды, аннан бар әйләнә-тирәне дәррәү кул чабулар күмде. Якында гына, башын кыңгыр салып, җырны хәйран калып тыңлап торган шагыйрь дә, күпмедер вакыт хәрәкәтсез калып торды. Галимә туташның җырлавы аңарга да көчле тәэсир иткән иде булса кирәк. Ә бераздан кызның каршына ук килеп, аның кулын кысты Шәйхи Маннур, башын иеп, кат-кат рәхмәтләрен әйтте. Һәм тагы ниндидер сораулар да бирде кебек, танышулары булдымы... Бер-беренә күз яшьләре аша мөлаем караш ташлап хушлашулары да булды кебек...

Залдагыларның тараласы килми. Кызның тагы, тагы җырлавын сорадылар. Әле бер, әле икенче тарафтан:

– Галимә туташ, зинһар, тагы бер кат җырлагызчы шул җырны? Яңа җырны безнең дә отып каласыбыз килә. Без дә кушылып җырлар идек, – дигән сүзләр яңгырады.

Кыз кыстатмады, гармун күрекләрен бар көченә тартып, тагы уйнап җибәрде. Аның моңлы, йомшак тавышына ир-егетләр, кызлар кушылды. Шул мәлдә күзем сирпеп, залга карасам, исем-акылым китте, әле кайчан гына өр-яңа дип игълан ителгән җырны яшьләр бердәм күтәреп алды. Үз-үземне белешмәстән, тавышым, моңым булмаса да, мин үзем дә җырга кушылганмын булып чыкты...

Бик сагынсаң, бик саргайсаң,
Йөрәккәең тынмаса,
Сагынуларың чиктән ашса,
Чакыртырсың Донбасска...

Күмәк җыр тәмамланды. Әмма ул каядыр китеп онытылмады, күңелләрдә эленеп калды, колак очларында әле озак яңгырап торды. Яшьләр тора-бара шау-гөр килеп, кайсы кая таралыша да башлады. Мин ашыкмадым, яныма килеп сәлам бирүче, хәл-әхвал сораучылар белән аралашкан атлы булып, берөзлексез Галимә туташны күзәттем, аның үзе генә торып калган мизгелен көттем. Янына барып кулын кысасым, соклануымны белдерәсем һәм берочтан теге чактагы кыланышым өчен гафу да үтенәсем килгәндер. Шактый ук якынлашып килә идем үзенә. Ә Галимә туташ, әллә мине күрмәде, әллә күрмәмешкә үк салынды, әйтеп булмый, карашын башка тарафка юнәлтте.

Шәйхи Маннурның үзе белән дә танышып калу зыян итмәс иде. Минем дә бит язучы булырга хыялланып йөргән көннәрем. Тик менә, гөнаһ шомлыгы, җае чыкмый. Әлеге дә баягы шул, әрсезлек юк, кыюсызлык чамадан тыш. Форсат чыкканын күпме генә көтсәм дә, мин аларның берсе янына да килә алмадым. Балтасы суга төшкән кешедәй үз юлым белән китеп барырга мәҗбүр идем...

Баракка кайтсам, анда үземне хат көтә икән. Кайдан диген әле. «Кызыл

Татарстан» гәҗитеннән. Алар мине Казанга кайтырга чакырганнар. Штаттан тыш кына булса да, хәбәрче булып эшләргә. Ул вакытта минем өчен моннан да зуррак бәхет юктыр сыман тоела иде бит.

Донбасстан китмәскә үгетләүчеләр күп булды. Үземнең дә шулай капылт кына китеп барасым килмәгәндер. Әмма Казанның тарту көче, татар әдәбиятына булган омтылыш бар нәрсәдән, хәтта Галимә туташның үзеннән дә, көчлерәк, мөһимрәк тоелган минем өчен. Бик китәсем килмәсә дә, киттем...


Китүен киттем, тик ике нәрсә үкенечкә калды. Татар шагыйре Шәйхи Маннур белән күрешеп таныша алмый калдым. Монысы бер. Әмма бусын үкенеч үк дип әйтмәс тә идем, чөнки Шәйхи абзый белән без кичегебрәк булса да таныштык, озак еллар үзара аралашып, дустанә фикер алмашып гомер кичердек.

Ә менә Галимә туташ... Турысын әйтим, мин аны гомерем буе оныта алмадым. Эзләгән, сораштырган кешеләрем дә күп булды, ярдәм итүче табылмады. Яшел чирәм өсләренә ятып елыйсым килгән чакларым да булды... Хатлар язып карадым, җавап килмәде... Хәтта сугыштан соң орден-медальләремне тагып, бер барып та чыктым бит әле мин Донбасстагы ул бистәгә. Сәгыйдулла абзыйны таптым... Ә менә Галимәне юк... Ул исәнме-юкмы, исән булса, кай тарафларда һәм ничек гомер кичергән? Шул сорауларга гына булса да җавап табасым килгән иде. Кайчан, кайда күченеп киткәннәрен дә белүче булмады... Архив-фәләннәр сугыш вакытында янып көл булган, юкка чыккан...

Минем өчен Галимә туташ шул рәвешле эзсез югалды. Югалды... – дип, авыр көрсенеп, кабатлап куйды әдип. – Әмма минем күңелдән ул һичкайчан җуелмады, җыр булып, моң булып яшәвендә дәвам итте. Әле дә булса яши... Аның моңлы тавышы, тальянда, фортепьянода уйнаганнары бүген дә, менә хәзер дә колак төбемдә яңгырап тора... Радиодан «Наласа»ны ишетсәм дә, «Шахта» көе яңгыраса да, мин Галимә туташны искә ала торган булдым. Бу җырларны халык көе, диләр, әмма мин аларны беренче тапкыр Галимә туташ башкаруында ишеттем. Ул чыгарган көй дип игълан итүләрен ишеттем, аның күңел түреннән бөркелгән моң дип кабул иттем...

Әмирхан абый тагы бер мәртәбә көрсенеп алды. Без ни әйтергә белми тынып калганбыз...

Машинабыз исә Казанга кайтып җитеп, Еникинең Чехов базары янындагы фатиры урнашкан йорт каршына килеп тукталган булып чыкты...



*Муса Чахархан Чахоровский (1953) – шагыйрь, тәрҗемәче, журналист. Польшаның Вроцлав шәһәрендә Польша татарлары гаиләсендә дөньяга килә. Поляк телендә чыга торган «Татар күзәтүе» иҗтимагый-мәдәни журналының баш мөхәррире, «Польша татарларының еллык басмасы»нда әйдәп баручы мөхәррир. 16 шигырь китабы, Коръәннең поляк теленә соңгы тәрҗемәсе авторы. Шигырьләре татар, рус, төрек, венгр, хорват телләренә тәрҗемә ителгән.*

Муса
Чахоровский

# МИНЕМ ГОМЕР – ЕРАК БЕР ИЛ...

## Әле генә

Еш кына далага кайтам, елганың бормасында
Ак тирмәләр канат кага, яшәеш башы – шунда.
Ат арбасына салынган үлән өстенә ятып,
Бер малай йокыга талган, булмый аны уятып.
Ә абыйсының байталы, дөньяның ямен җыйнап,
Йөртә аны елга, зират, җәелгән җиһан буйлап.
Өйдән аны төшке ашка чакыралар, ә монда
Ишетелми, ул сүзләрне һава йота бер тында.
Малай төштә болын күрә, елгадан ат кайтканын.
Ул белми шул, ничек вакыт һәммәсен картайтканын.
Беркая барыр урын юк, еракта калган еллар.
Үткәннәр турында уйлап, тын гына дала елар.

* * *

Мин башка дөньядан инде, чит җирдә тудым, үстем.
Җиде ятлар арасында елларым буйлап күчтем.
Телләрен яхшы белсәм дә, сүзләрнең тирәнлеген
Әле һаман аңлый алмыйм, бәлки бер өйрәнермен.
Иң гади сүзләре белән мин читләргә тоташам.
Нәрсәнедер якын итәм җан әрнүләрем аша.
Минем гомер – ерак бер ил. Тиз-тиз шунда омтылам.
Анда никтер бар да өнсез... Күзләремә күк тула.

* * *

Тарих өчен олы хәсрәт – кыюлык нәтиҗәсе.
Төсен югалткан зиннәт күк – батырлык хатирәсе.

Бар мәрхүмнәр иза чигә – чәнечкеле тадж башта.
Укылыр-укылмас язу күренеп китә ташта.
Туктаусыз кан саркып тора, дәшә алмый, юк сүзе...
Бу – бакый ил хәтеренең атудан калган эзе.

* * *

Без булдык, хәзер дә барбыз, китәбез дә киләбез,
Чиксез вакыт киңлегендә гел үзгәрә бирәбез.
Башкалык һәм... бертуктаусыз бертөрлелек – үзгә эш.
Хәтердә, дәвамлылыкта һәрчак бара үзгәреш.
Без яшәдек, көн итәбез – җан түрендә күргәне.
Хатын-кызлар учак саклый, ирендә – дала тәме.
Ат кешнәве, тояк чыңы, бөркет канат кагышы...
Ишетәсеңме, и Тәңре, безнең оран тавышын:
Без – татарлар! Дөнья буйлап тузан туздырып үтик...
Кайда гына башны куйыйк, кайсы өндә ял итик?
Җилдерәбез. Үлән шаулый... Җир чәчрәп кала артта...
Ә без мәңге!.. Дала буйлап юыртып киләбез атта!..

* * *

Күзләрем, минем күзләрем, сез мине күрәсезме?
Сездән өстә – зәп-зәңгәр күк, ә аста – бары дала.
Мин үләндә йоклап ятам, үзгәрешсез манзара
Хәтеремне төшләндерә. Күк кала, дала кала...
Меңьеллыклар арасыннан нур булып кисеп узам,
Беркем күрмәгәнне күрәм, шәүләләргә эндәшәм.
Мин тоям һәм җаным белән ал таңны якынайтам...
Бөркет канатларын җилпи рухым белән янәшә.
Җилдереп очып китик без, ат ялларын кушучлап,
Ерак тарафка чаптырыйк, мәгърур Кояшка тикле!
Әй, Тәңре, галәмнәрне ач, ач безгә мәңгелекне!

## Минем атым

*Әмир Гыйсмәтуллинга*

Кайчакларда төшләремә керә
Тояклар һәм яллар көтүе;
Ат ялларын канат итеп шулай,
Җайдакларның очып үтүе.

Дала иңләп чабышкылар килә,
Күзгә тула офык, ялтырап.
Тупырдаган тояк асларында
Тапталган җир тора калтырап.

Учак тирәсенә җыелышкан
Кешеләр дә чума борчуга.
Кичке эңгер тула офыкларга,
Тынгысызлык әллә... гел шуңа?..

Өлгергән кан исе килә җилдән,
Үткен уклар – гүя җил очы...
Һәм уята мине кискен оран:
Кайда атым, кайда кылычым?!

* * *

Яшь бер татар чыккан юлга кара-туры чабышкыда.
Козгын кебек кара юрга.Төнне ярып ат пошкыра...
Бу яшь татар бик еракка – киң далага юлын сызган,
чиксез яшел дала буйлап бер көн, әллә бер ел узган.
Тиз узганмы ул, озакмы? Белә бары Тәңре үзе.

Күренмәгән беркемгә ул. Юкка чыккан аның эзе.
Бермәл егет пәйда булган усак урманы каршында,
түргә узган... игътибарын чишмә җәлеп иткән шунда.
Аты калган, ул таң калып, чишмәгә багып утырган.
Суда озын толым күргән, дулкынланып җыр агылган:
мин сине бик озак көттем, мин сине сагынып беттем,
минеке бит син, минеке! Анда кара күзләр күргән,
иреннәре... кан шикелле кызыл миләш булган анда.
Кулын сузган безнең егет. Нидер тоткан, ә нәрсәне:
Озын чәчле кәләшнеме? Кемдер әйткән сүзләрнеме?
Әллә кызыл миләшнеме? Әллә су хәйләләгәнме?
Чиста һәм ак суның йөзе... Бу хәл әллә булмаганмы?
Белә бары Тәңре үзе...

## Башлам

*Онычыма*

Көннең башы була, һәм шулай ук
төнне кичкән чиста тротуарда
калган тәүге эзләр иртә таңнан,
сары агач йортның каршысында
ир-ат белән сабый басып тора
сүзсез генә, кулны кулга алган.

Нәни малай карый йортка таба,
агачларга, якты зәңгәр күккә –
һәммәсе дә җанга сеңә барыр;
юлдан узып киткән кешеләрне,
очып узган кошны, саф һаваны,
еллар узгач, кабат искә алыр.

Чал кояшка ир-ат карап ала,
күзнең карасына бәргәләнгән
кара канның тып-тын дулкыннары
күренәдер моңсу күзләрендә,
мизгел гасырында уйчан йөзе
караңгыга чума һәм аннары…

Бер дәкыйка гына үткән кебек,
йөз яктысын сибеп бер-берсенә…
гүя җир – ул алар торган кораб…
теге малай минем онык була,
тиздән кулын алыр минем кулдан,
үз юлыннан китәр, алга карап.

* * *

*Иоаннага*

Утырып ак чәй эчәбез. Хәер, ничек ак булсын!
Без әйтмәгән ап-ак сүзләр Ак төн буйлап агылсын.
Тормышыбыз актан гына, күз салмыйбыз түренә,
Бу аклыкта барысы да аермачык күренә –
Адашырга мөмкин түгел, хәтта бик теләсәк тә.
Ак йолдыз, юлны яктыртып, озата киләчәккә.

* * *

Елганың акканын карыйм, туктамый, гел агышта.
Берни көтми. Елга түгел, агач, кош, хәтта таш та.
Таш – бары таш, агач – агач, кош та – кош гадәтендә.
Галәм белән килешәләр – бар да үз халәтендә.
Кеше генә үзгәрала, елга була – көталмый,
Агач, таш, хәтта кош була, үзе булып беталмый.

**Ленар ШӘЕХ** *тәрҗемәләре*





Ркаил
Зәйдулла

# КАНИ КАЛДЫ НИШАПУР...

ХИКӘЯ

Кичкә таба Айдарга авылдан энесе шалтыратты. Ул бик сирәк элемтәгә чыга, шуңа күрә Айдарның күңеленә сызлавык шом йөгергәндәй булды. Әниләре өзлегеп киттеме соң әллә? Ул инде аксап-туксап, туксанын ваклап матавыклана, язмыштан узмыш юк – Айдар да тиздән, бик тиздән котылгысыз тәкъдир каршында чарасыз каласын кырык яшьлек акылы белән аңлый иде. Бернишли алмыйсың, дөнья – буялган йомгак, вакыты җиткәч, буявы уңа, җепләре чуала... Шөкер, әниләренең хәле әйбәт кенә икән әле. Үз акылында, шунысы мөһим. Айдар ишетмәгән әллә нинди гәҗитләр алдыра Казаннан, шуларны укып рәхәтләнә, шалтыратып, редакция хезмәткәрләренә үз фикерен дә белдерә икән әле. Үзе дә гәҗит герое булып алган, «тулы канлы тормыш белән яши», дип язып чыкканнар, имеш.

– Абый, Шәйхулла агайның хәле начар, – диде энесе.

– Ничә яшьтә әле ул? – дип сорады нигәдер Айдар. Әйтерсең, моның нindидер әһәмияте бар! Япь-яшьләрнең дә хәле кинәт начараеп китә, бернишли алмыйсың. Әнә, яңарак кына күпләрне гаҗәпләндереп, сәламәтлек саклау министры илле өч яше тулуга ук вафат булды да куйды. Нишли дә алмыйсың, тәкъдиреңә шулай язылса...

– Кем белгән инде аны... Байтак. Әле үз акылында ул... Сине чакыра. Айдар кайтмаса, үлмим, ди.

– Алайса кайтмавым хәерле икән, – диде Айдар.

– Юлга чыгасы кешене алай интектерергә ярамый, – дип энесе сүзне фәлсәфи төстә төгәлләп куйды. Аз сөйләшә торган кеше ул...

Әйе, кайтмыйча ярамый иде. Шәйхулла абыйның соңгы гозеренә колак салмасаң, Аллаһның каргышы төшәр. Кайчандыр ул Айдарның яраткан укытучысы иде. Остазы! Абруе да олы иде аның. Райондагы иң зур мәктәпнең директоры, республикада атказанган кеше. Аны остаз санаучылар күп иде, ә менә үзе шәкерте итеп, Айдарны гына таныды шикелле, һәрхәлдә

аңа өметләр баглады, үз эшен дәвам итәр дип ышанды. Ләкин Айдар башка юлдан китте, остазыннан йөз чөерде. Менә бит, мәктәпне тәмамлаганнан бирле элекке остазы белән күрешкәне дә юк икән. Бер киселгән икмәк кире ябышмый инде ул. Нигә соң алайса Шәйхулла абыйсының соңгы сулышында аның белән күрешәсе килә? Хатасын таныганмы? Үкенәме? Кичерү сорыймы? Юк, мөгаен, ул үзен гөнаһлы санамас... Бәхилләшәсе киләдер, шул гына. Әҗәл якаңнан алганда бик табигый теләк.

Аралары кинәт бозылды аларның. Шәйхулла абый мәктәптә татар әдәбиятын, тарихны укытты. Ул кайчандыр Казан университетында белем алган, студент елларын искә төшергәндә яшәреп китә, ике бит алмасына җиңелчә кызыллык йөгерә, күзе очкынлана.

– Җәвад Алмаз! – дип кычкыра ул, имән бармагын түшәмгә төбәп. – Җәвад Алмаз! Менә кем чын галим иде! Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын аңын кебек аңлатучы дөньяда юк. Аның белән Габдерәхим Утыз-Имәнине генә чагыштырып буладыр. Җәвад Алмаз! Хәзер кайда ул? Казанның көнчел, мәкерле мөтәгалимнәре, яла ягып, аны Казаннан куып җибәрде.

Ни дигән сүз ул мөтәгалим, Алла белә... Һәрхәлдә, җүнле кеше түгелдер. Хәер, Айдардан башка бу турыда баш ватучы булдымы икән?

Ләкин мәктәпне тәмамлаганда, ул яраткан укытучысы сызган юлдан бармаска карар итте. Әти-әнисе дә каршы иде, аякта нык басып торырлык профессия сайларга кирәк, диделәр.

– Мөтәгалимнәр кулына каласым килми, – диде Айдар Шәйхулла абыйга. – Анда бит инде Җәвад Алмаз юк!

– Ялгышасың, ялгышасың, – дип гаҗизләнде укытучы. – Анда әле чын галимнәр җитәрлек. Менә алардан соң чын наданнар киләчәк. Синең кебекләр бармагач, кайдан чыксын фидакярләр?! И-их, үземнең дә балам юк бит... – Ул ике учы белән йөзен каплады, әрнүен күз тирәсендәге җыерчыклар эченә яшерде.

Алар биология укытучысы Әнисә апа белән икәү генә торалар, бала-чагалары юк, нишлисең, андый хәлләр дә була. Шуңамы икесе дә мәктәптән кайтып керми диярлек.

– Укырга каядыр керәсеңдер бит?

– Мәскәүгә китәм. Мәскәү университетына...

Шәйхулла абый беравык тын калды. Мәскәү инде ул – Мәскәү. Совет вакытында ул бигрәк тә аерым бер тылсымлы шәһәр булып тоела иде. Һәркем белә, анда ашау-эчү дә башкача! Кибет киштәләре тулы. Өйләрендә тартма тышына фил рәсеме төшергән һинд чәе генә эчеп яталар булса кирәк, әрәмтамаклар. Ә ул заманда совет кешесенең төп хыялы кайда да булса әрәмтамак булып урнашу иде. Хәер, хәзер дә без әллә кая ерак китмәгәнбез. Тик әлеге урын гына теләсә кемгә тәтеми.

Айдарны мондыйлар рәтенә кертеп булмый иде, әлбәттә. Алар ягында тырыш халык яши. Ә кая барасың? Тик торганда, кем китереп бирә? Алар гасырлар дәвамында кысанлыкта яшәргә күнеккән. Кысан җир, кысан һава, кысан ил. Иксез-чиксез киң инде ул анысы, тик үги балалары өчен түгел... Айдар да ышанычлы, урыс дәүләтенә кирәкле һөнәр алырга җыенды. Ә татар теленең киләчәге ул дәүләткә кирәкме? Коммунизм җиткәч, илдә бер генә тел калачак дип, юксәк карарларда акка кара белән яздылар бит.

Ә аның татар теле түгел икәне Мәнди анасына да билгеле. Юкны бушка аударып йөрергә Айдарның башына тай типмәгән ләбаса. Яшь булса да, җилнең кайсы якка искәнен чамалый алырлык малай иде ул.

Тик җилгә каршы төкерүчеләр дә бетмәгән дөнья йөзләрендә. Шәйхулла абый шундый кешеләрнең берсе иде. Дөресрәге, әлеге җилнең кайсы якка исүен ул бөтенләй искә алмый иде булса кирәк. Мантыйгын да аңлап була – караңгыдан караңгы чорларда авыр сынауларны җиңеп исән калган халык ничек инде Ильич лампалары яктысында юкка чыксын?!

Шәйхулла абыйның кыяфәте дә күңелдә өмет уята, аңа карап, нindидер горурлык хисләре очкынлана иде. Озын буй, каратут йөз, чем кара күз, төз борын, кысык иренле зур авыз. Кайдандыр көньяктан – борынгы күк төркләр биләмәсеннән килгән илтәбәрләр каны иде, ахрысы, аңарда. Кieme яңа гына энәдән төшкән кебек, чалбарындагы үтүк эзе бармакны кисәрдәй булып ярылып ята, түфли йөзен көзге итеп файдалансаң да, артык түгел, ап-ак күлмәк якасы крахмаллап катырылган... Кыскасы, бик ыспай киенә иде Шәйхулла абый. Мәктәптә. Ә менә мәктәптән читтә, авылда ул бөтенләй башка. Монда аның кыланмышлары авыл халкы өчен теш агартырга менә дигән сылтау! Бигрәк тә җәй көннәрендә... Ул үзе тукыган киндер күлмәк, киндер ыштан киеп йөрер, аягы һәрвакыт ялангач... Мондый сәерлеккә инде барысы да күнеккән, авылда кемнәр генә юк! Бер диванасы булмаса, авыл авылмыни инде ул?! Шәйхулла абый биредә иң абруйлы мөгаллим, иң абруйлы дивана иде. Тик бит... болар икесе ике нәрсә, мәктәп директорын районга чакырып сөйләшеп тә караганнар, имеш. Аннары кул селтәгәннәр булса кирәк: ул бит районга сымбатлы, ыспай булып бара, ә өй эчендә, ишегалдында, урман-кырга чыкканда, кеше үз иркендә. Яланаяк йөрмәскә дигән закон юк. Киресенчә, яланаяк йөрүнең файдасы турында ул заманнарда газетага да язып чыктылар – җирнең энергиясен шул рәвешле тоткарлыксыз сеңдерергә була икән. Каладан килеп, кайсыдыр газета өчен Шәйхулла абыйны фотога да төшереп киттеләр.

Ат ярата иде тагын Шәйхулла абый. Айдар хәтерли әле, ул елларда елкычы булып, Чышмыш абзый эшли иде. Чын исеме ничек булгандыр. Аны инде җәй көннәрендә һәрвакыт бот буе малайлар сырып алган булыр. Шуларны ул берәм-берәм юашрак атка атландыра, тегеләр күндәм генә ат абзарында бер әйләнеш ясый. Бөтенләй бушка түгел, әлбәттә. Атка менү хакына юеш борынлы малайлар икешәр йомырка алып килә. Анысы гына инде аның пүчтәк. Авылда ул заманнарда йомырканың бетәсе юк.

Ә төннәрен болынга ат сакларга чыгулар! Гадәттә, Чышмыш абзый атларны Тимәш болынына алып чыга иде. Малайлардан инде анда теләсә кем чыга алмый. Ат җене кагылганнар гына. Айдар шундый малайлар арасында иде. Чышмыш белән Шәйхулла абый якын дуслар, ара-тирә ул да атлар янына төнгелеккә чыга, әкият сөйләп, малайларны авызына карата.

Шундый төннәрнең берсен һич онытмый Айдар. Йолдызлар шундый якын иде. Төн карасын кызыл учлары белән капшап, салмак кына учак яна; күмер төшкәч, көлгә күмәргә әзерләп куелган бәрәңге чирәмгә сибелгән; болында утлап йөргән атлар ара-тирә пошкырып куя; кайчак үз кадерен

белеп кенә, йолдыз атыла. Төтен исе, салдырылган иярләрдән бөркелгән әчкелтем ат тире исе... Ерактагы сазлыкта тәкәрлек кычкырып ала. Төнге авазларны, борынны кытыклаган төрле исләрне басып, Шәйхулла абыйның тонык тавышы ишетелә:

– Чура батырның биләмәләре бит безнең якта булган. Кем белә, менә шушы  болынлыкта аунап үскәндер әле ул... Менә сезгә аңа кагылышлы бер тарих сөйлим әле... Бервакыт ул үз кәнизәгенә гашыйк була. Булмаслык та түгел, шулкадәр чибәр икән кәнизәк – сап-сары чәчле, зәп-зәңгәр күзле, ул көнгә чыкканда, кояш та, көнләшеп, йөзен читкә бора, имеш.  Чын менә, иске китапларда шулай язылган. Ә кәнизәк еракта калган туган илен, якын кардәшләрен оныта алмый, аларның Казан ханыннан өстен чыгуы турында хыяллана, шуңа Чура батырны ханга каршы котырта икән. Ниһаять, морадына ирешә, чөнки дә шуны онытмагыз, балалар, ятканда әйткән сүз аягөсте әйткән сүздән көчлерәк, тәэсирлерәк; хатын-кыз белән ир-ат арасындагы сүзне әйтүем... Ә андый чакта хатын-кыз гына сөйләмчәк була. Шул... Ханга каршы кылыч күтәрә Чура батыр, аңа яраннары кушыла. Алар арасында Чураның аталыгы да бар икән... – Шәйхулла абый бу урында аңлатып үтүне кирәк тапты: –   Аталык ул ата урынына калган кеше, тәрбияче, остаз...

Айдар кайбер сүзләрне аңлап та бетерми, тик шулар Шәйхулла абый хикәятенә тагын да серлелек өсти, әкияти дөньяга тартып китерә.

– Ләкин җиңелә Чура батыр; яраннары үтерелә, аталыгы гына исән кала. Болар теге кәнизәкнең иленә качалар.

– Кәнизәк үзе исән калганмы соң? – дип түземсезләнеп сорый Айдар.

– Ансыз булмый. Алайса юлны кем күрсәтә? – дип, сорауга сорау белән җавап бирә Шәйхулла абый.

Бер читтә инде башын печән тутырган капчыкка салып, Чышмыш абзый йокы симертә, офыкта сизелер-сизелмәс таң сызылып килә. Айдарның гына йокысы качкан, әкиятнең ахырын беләсе килә. Бераз чамалый да ул аны: кәнизәк үз илендә патша кызы булган, мөгаен; барып җитүгә үк аңа өйләнеп, Чура батыр үзе патша булыр, пажалый...

– Мин әкият сөйләмим, – ди Шәйхулла абый, аның уен укыгандай. – Булган хәлләр бу, таем. Безнең тарих бу!

Айдар әле дә яхшы хәтерли: нәкъ шушы урында сүзен тәмамлый алмады укытучысы, якында гына тояк тавышлары ишетелде. Озакламый өч җайдак учак янына килеп тә туктады. Икесе ат өстендә калды, берсе – кара сакаллы, башына чалма ураганы – җәһәт кенә ияртән төште.

– Әссәламегаләйкем! – дип ул Шәйхулла абый янына чүгәләде, ике учын битенә китерде.

– Вәгаләйкем әссәлам! – дип сәлам кайтарды укытучы.

– Төннәр тынычмы, шәех?

– Аллага шөкер! Юлыгыз еракмы? – Шәйхулла абый кымыз тулы корҗынны юлчыга сузды.

– Тау[1] сезгә! – дип, юлчы чөмердәп торган кымызны кара сакалы арасына койды. Аннары, торып, корҗынны юлдашларына сузды. Нишләптер алары аттан төшмәде. Айдар ул ике җайдакның йөзен дә төсмерли алмады,

[1] Тау – элгәре  рәхмәт сүзе урынына әйтелгән.

битләренә күз тиңентен кара япма каплаганнар идеме соң? Әйе, әйе, япманы күтәреп, йотлыга-йотлыга кымыз эчүләре әле дә күз алдында.

Кымыздан кәефе күтәрелгән кара сакалның учак яктысында ап-ак тешләре балкып алды.

– Нишләп бик моңсу утырасыз? – дип сорады ул. – Думбрагыз да юк.
– Шулай дип әйтүе булды, ат өстендәгеләрнең берсе аңа думбра суздды.

– Мин бер җыр эзләп йөрим, – диде кара сакаллы. – Атам мирас итеп калдырган иде, онытттым! Юк, дөрес түгел, онытмадым. Бер орышта ул чәлпәрәмә килде. Кылыч җиле кыйпылчыкларын дөнья буйлап сипте. Бер юлын хәтерлим, калганнарын – юк! Менә, могтәбәр шәех, шул юлны җырлап бирәм, калганнарын бәлки син беләсеңдер? Җырны тулаем җыеп алмыйча, тынычлык юк миңа!

Һәм ул, думбра чалып, җыр сузды:

– Кани Бохара-и-шәриф, кани калды Нишапур?

Бармаклары, төнге күк йөзен ярдәмгә чакыргандай, ашыгып, думбра

кыллары өстендә биеде.

– Кани Бохара-и-шәриф, кани калды Нишапур?

Әмма җыр дәвам итмәде. Думбра өстендәге кул чугы сунарчының өлгер угы тигән киек муены кебек аска салынды, өметсезлек кебек хәрәкәтсез калды. Кара сакалның йөзенә кәфен бәзе йөгергәндәй булды, шулкадәр бичара, кызганыч иде ул. Шәйхулла абый эндәшмәде. Юлчы, өметләнеп, Айдарга карады:

– Онытма бу җырны! Юлың ерак, бәлки, калган өлешен сиңа табарга насыйп булыр.

– Кани Бохара-и-шәриф, кани калды Нишапур?

Кузгалырга алгысынып, юлчыларның атлары тояклары белән җирне тырнады. Шәп чаптарлар иде болар! Танауларын киереп, сулыш алуларыннан ук затлы токымнан икәннәре күренеп тора.

– Юлдагыларның юлда булуы яхшы, – диде кара сакал, урыныннан кузгалып. – Чүтигә юл шушыннанмы?

– Уңга каерып, чикләвек урманы аша ун чакрымнар баргач, Нугай юлына килеп чыгарсыз. Анда инде Казанга да ерак калмый...

Җайдаклар, алардан аерылып, чикләвек урманына таба юыртты. Кемнәр иде алар? Айдар Шәйхулла абыйдан сорарга кыймады. Ә ул, берни булмагандай, Чура батыр турындагы хикәятен дәвам итте. Чышмыш абзый, төшләнеп, нидер кычкырды. Төшен качырмас өчен җәтмәсен ыргытуы булгандыр. Ул атларын арканлаганда да шулай кычкырып ала.

– Ил чиген узып, хәйран гына баргач, дошманның башкаласына җитәрәк урман авызында алар бер алачыкка туктаганнар. Кәнизәк ятып йоклаган, ә Чура батыр аталыгы белән соңгы коржыннан кымыз эчәргә утырган. Утыра торгач, шактый гына кызган болар. «Җаныңны күрсәт миңа, – дигән Чура батырга аталыгы. – Җаныңны күрәсем килә!» Чура батыр аның бу теләгенә аптыраган, моңарчы әле беркемгә дә җанын ачып күрсәткәне булмаган икән. «Юк, – дигән ул, – күрсәтмим. Ул коточкыч, аны күргән кеше куркудан үләргә мөмкин!» Аталык көлгән, янәсе, аны куркытырлык нәрсә дөньяда бармыни? Һаман үзенекен тукыган: «Җаныңы күрсәт миңа, җаныңны күрәсем килә!» Ниһаять, Чура батыр аталыгының сүзенә күнгән, җанын

ачкан... – Шәйхулла абый, кулындагы таягы белән янып беткән учакның көлен актаргалады. – Булган бу... Бәрәңгеләрне күмәргә кирәк.

Айдар, түземсезләнеп, бәрәңгеләрне кайнар көлгә күмде дә, Шәйхулла абыйсының авызына карап, хикәятнең дәвамын көтте. Тегесе генә ашыкмады, инде тәмам яктырган офыкка карап киерелде, хикәяте турында оныткандай: «Көн аяз булырга охшаган...» – дип, учак өстендәге таганга чәйнек асты.

– Шуннан, шуннан, – дип аны ашыктырды Айдар.

– Шуннан шул, Чура батырның җаны ике башлы аждаһа булып очып чыккан да, бер башы Чураны, икенчесе аталыкны капкан да йоткан! Һәм үз иленә очып та киткән. Кәнизәк иртән уянса, якын-тирәдә беркем дә юк, почмакта Чура батырның җәясе генә аунап ята... Өенә берүзе генә кайтып киткән кәнизәк. Дөресен генә әйткәндә, Чура батырны бик үк яратмаган да бугай ул...

...Дәвамчысы булудан баш тарткач, Шәйхулла абыйның Айдарга карата мөнәсәбәте үзгәрде. Сөйләшү түгел, ул аны бөтенләй күрми дә иде кебек. Моңа сөенүчеләр булды. Иң сәере – яраткан фәне математикадан ул уртача билгеләр генә ала башлады, имтиханын да дүртлегә генә бирде. Әмма Айдар максатчан, чырыш үсмер иде, мең мәшәкатьләр белән, армиядән соң булса да, Мәскәү университетына керә алды. Укуы авыр булды, авылдан да әллә ни ярдәм килми, үзе кебек провинциядән килгән мохтаҗ егетләр белән еш кына вагон бушатырга да йөрделәр. Ләкин ул түзде. Сабыр төбе – сары алтын, укуын тәмамлагач, Мәскәүгә ябышып калды, мондагы сары чәчле бер чибәргә өйләнде. Кызның әтисе зур гына урында утыра иде, төшемле эшкә урнашу да кыен булмады. Дөньялар үзгәргәч, Айдар бөтенләй канат җәйде, заман хәзер – аның заманы!

Шәйхулла абый турында инде ул бөтенләй онытткан иде, эше төшеп Көньяк Казакъстанга, борынгы Төркестан шәһәренә барып чыккач, көтмәгәндә, күңелен актарып салган истәлекләргә тап булды. Миен кайнатырлык эссе сүрелгәч, кунакханәдән ерак та түгел бер борынгы бинаны зиярәт итәргә китте ул. Борынгы төркиләрнең рухи юлбашчысы, бөек шагыйрь Хуҗа Әхмәд Ясәвинең Аксак Тимер салдырган төрбәсе икән бу! Әлбәттә, Ясәви турында аның ишеткәне бар иде. Аның фәлсәфә, нәсыйхәт белән тулы хикмәтләрен дә элегрәк укыганы бар иде кебек. «Мең ел элек күчмә төрки кабиләләрен исламлаштыруда әлеге суфи шагыйрьнең роле бәяләп бетергесез, – диде гид. – Юкка гынамы «Мәккәдә – Мөхәммәд, Төркестанда – Әхмәд» димәгәннәр».

Туристлар төркеменнән аерылып, Айдар төрбәне әйләнеп чыгарга булды. Төрбәнең артында бөтенләй караңгы иде, ләкин ул борынгы диварга сыланып утырган бер шәүләне шәйләп алды. Яшен анык кына билгеләп тә булмый, коточкыч ябык; башына түбәтәй чәпәгән, өстендә ертык җилән... Ул, дөньясын онытып, нидер көйли иде. Көйлиме, мыгырдыймы шунда. Кинәт, таныш сүзләр ишетеп, Айдар туктап калды.

Кани Бохара-и-шәриф, кани калды Нишапур?
Гыйшрәт тулы мисрагыма хазир кемнәр ышаныр...

Айдар яшь колындай сикереп куйганын үзе дә сизми калды. Төн

караңгысын ярып, гүя аның өстенә нур көлтәсе коелды. Менә кайда качып яткан икән теге борынгы җырның икенче сәтыры!

Гыйшрәт тулы мисрагыма хазир кемнәр ышаныр...

Бәлки бу дәрвиш җырның башка юлларын да белә торгандыр? Ышанычлы, шатлыклы адымнар белән ул тавыш килгән якка атлады. Тик анда инде беркем дә юк иде. Дәрвиш, әйтерсең лә, өрәк кебек эреп юкка чыккан. Тик ул торган урын гына мондагы эссе, бөркү һавадан аермалы буларак салкынча, җиләс иде. Айдар борынгы диварга сыланып, таш идәнгә чүмәште дә җырлап җибәрде:

Кани Бохара-и-шәриф, кани калды-ы Нишапур?
Гыйшрәт тулы мисрагыма хазир кемнә-әр ышаныр...

Кунакханәгә кайтканда, Айдар үз гәүдәсен тоймады, гүяки әлеге җыр аны үзе күтәреп бара иде. Ни кызганыч, әлеге олы шатлыгын ул элекке остазы белән бүлешмәде бит! Хәер, бераздан табылдык мисрагъ үзе дә көндәлек мәшәкатьләр чүплеге астында күмелеп калды. Чит шәһәр ыгы-зыгысы, иялəнгән тоташ гөрелте астында борынгы моң да эреде, юкка чыкты. Юк, үз вакытын көтеп яткан икән! Авылдан энесе шалтыраткач, ул кабат пәйда булды, бөтен җәсәденә янә тулып, тамырларына таралып, әрнүле бер гүләүгә әверелде.

Авылга ул иртәнге якта кайтып төште. Кырык эшен кырык якка ташлап... Хатынының да төксе чырае һаман күз алдында тора. Әйе, төксе чыраен чыгарып күрсәтте дә үз бүлмәсенә кереп китте... Аралары күптән суынган булса да, ул аның «деревнялыгын» нигәдер һаман күтәрә алмый, авыл белән элемтәсе һәмишә өзелмәвен авыр кичерә, югыйсә илгә кайтмавына бишбылтыр бит инде. Туганнары да хатынының мөнәсәбәтен белгәнгә Мәскәүгә килсәләр дә, керми китә. Айдар алар белән кафеларда, кунакханәләрдә генә күрешә. Дөресен әйткәндә, Айдар үзе дә иң кәттә байлар яши торган бистәдәге бу алагаем йортка гадәт буенча гына кайтып куна, хатыны белән дә атнага берничә мәртәбә әһәмиятсез сүз алышудан ары китми. Бердәнбер кызлары Майя Англиядә колледжда укый, акча кирәксә генә шалтырата, Айдар үзе шалтыратса, гел вакыты булмый иде.

Урамда беркем дә юк, тып-тын. Хан сарайларына биргесез таш йортлар шомлы бер кисәтү кебек дәшми-тынмый катып калган. Айдар санап барды – дүрт өйнең генә тәрәзендә ут бар иде. Бу йортлар янәшәсендә Шәйхулла абыйның авыл уртасыннан агарга маташкан Келкерәү инешенә төшеп китәргә ашыккандай янтайган өе бик өтек күренә. Авышкан капкадан кергәндә, икеләнеп, Айдар туктап та алды. Күпме еллар үткән, күпме сулар аккан, ни йөз белән хәзер элекке остаз каршына басасың? Танырмы ул аны? Айдар үзе танырмы Шәйхулла абыйсын?

Шулай да шик-шөбһәләрен басып искереп тузган өйнең бусагасыннан эчкә атлады. Ишек тавышына түсе уңган чаршау артыннан һәрвакыттагыча ачулы Әнисә апа чыкты. Картайган икән ул да, бетәшкән. Айдарны кичә

генә күргәндәй, бер дә гаҗәпләнмичә, күчтәнәчен алды, коргаксыган кулы белән түр бүлмәгә ишарәләп:

– Инде өченче көн сине көтә, – диде. – Китәсе кешене шулай көттерергә ярыймыни?

Караватта кечерәеп ятучы Шәйхулла абыйны чак таныды Айдар. Хәтта чырае да бер учка сыярлык кына калган.

– Кайттыңмы? – дип пышылдады ул. – Менә сине көттем. Сине күрмичә китә алмадым.

Айдар, күңеле тулып, остазының җиңеләеп калган кулын маңгаена китерде.

– Кичер, остазым...

– Бәхил... – диде Шәйхулла абый. – Син дә мине кичер...

Алар, элеккечә, бер-берсен ярты сүздән аңлыйлар иде. Шәйхулла абый баш очында эленеп торган думбрага ымлады. Айдар җиңел генә торып, думбраны алды, бармаклары, Мәңгелек Күк Тәңрене ярдәмгә чакыргандай, ашыгып, думбра кыллары өстендә биеде.

Кани Бохара-и-шәриф, кани калды Нишапур?
Гыйшрәт тулы мисрагыма хазир кемнәр ышаныр...

– Тапкансың, – дип пышылдады остаз. – Киләсе юлны инде шәкертең табар...

Айдар сагышлы йөзен Шәйхулла абыйга борды. Нинди шәкерт? Нинди борынгы җыр? Ул эшендәге үзенә буйсынган яшьләрне күңеленнән генә күздән кичерде. Һи-и... Күзенә ирексездән яшь тулды.

– Сиңа инде кырык яшь, – дип, кыенлык белән сүзен дәвам итте остаз.– Тормышыңны башларга вакыт. Чын тормышны... Әле соң түгел.

Айдар эндәшмәде.

– Кайт авылга! Күрмисеңмени, авылның мамыгы коелды, рухы югалды. Мин ышанам, син кайтсаң, аңа җан керер. – Кинәт Шәйхулла абый калтыранган тавышы белән көйләп куйды: – Керфегемне Хәйямның гүр туфрагы сөрмәләгән... Нишапур монда ул!

Саташа, дип уйлады Айдар. Тик остазның чайпалырга торган күзләре искиткеч аяз иде.

– Сүз бир! – диде ул. – Кайтасыңа ант ит!

– Сүз бирәм, – диде Айдар, үзе дә сизмичә. – Ант!

Ул урамга чыкты да, машинасын калдырып, җәяү генә югары очтагы Буга тавына юл алды. Март аеның нечкә билле җиле муенына уралды. Тау башында анда-санда, ертып ташланган кәгазь битләре кебек кар эзләре калган, инде кардан ачылган урыннарда яшь чирәм шытып киләдер... Шунда ятып ауныйсы килде Айдарның. Колагынаерактагы язның беренче күкрәве чалынды.

# ӘДИПЛӘР ИҢЕНДӘ ХАЛЫК СҮЗЕ ҺӘМ КАКШАМАС НАМУС ЯТА

«АГЫЙДЕЛ» ЖУРНАЛЫНА – 100 ЕЛ

*«Агыйдел» исемле айлык әдәби-нәфис һәм публицистик журналыбыз 1923 елның мартында «Яңа юл» исеме белән чыга башлый.*



Башкорт халкы борынгыдан сүз кадерен, моң аһәңен белеп-тоеп яшәгән, шуңа аның авыз иҗаты да искиткеч бай. Күпләр башкортларны балы, курае, аты-кымызы белән генә түгел, меңәр еллык «Урал батыр», «Акбүзат», «Заятүләк менән Сусылу» кебек эпослары, феноменаль күренеш булган озын көйләре, сеңләүләре, тылсымлы көчкә ия булган кобаер-әкиятләре, мәкаль-әйтемнәре аша да яхшы белә. Соңрак Идел-Урал төбәгендә яшәгән халыкларның бөек шагыйре Кол Гали, милли батырыбыз, шагыйребез Салават Юлаев, мәгърифәтчеләребез Акмулла, Мөхәммәтсәлим Өметбаев, Буранбай-Яркәй, Ерәнсә, Ишмөхәммәт Мырзакаев, Габит Аргынбаев, Мөхәммәтша Буранголов һ.б. чәчәннәребез, Таҗеддин Ялчыгол, Мәнди Котош-Кыпчаки, Әбделмәних Каргалы, Һибәтулла Салихов, Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый кебек суфиларның иҗаты да халкыбызның күңел вә зиһен гөмбәзләрен бермә-бер яктыртып, балкытып торган, тора. XX гасыр башында милли матбугат эше ныклап үсә башлагач та, сүз, авыз иҗатын үз иткән халкыбыз алдында әдәби югарылыктагы басма чыгару зарурлыгы тууына аптырыйсы юк. Аңа кадәр Акмулла, Мәҗит Гафури, Габдулла Тукай, Шәехзадә Бабич һәм башка каләм осталарының шигырьләрен, тезмә әсәрләрен татар, башкорт халкы телдән-телгә күчереп яттан сөйләгән, үзара язма рәвештә дә таратылган.

Журналыбыз әүвәл – «Яңа юл», аннары «Белем», «Сәсән» исеме белән басыла. Заманга яраклашам дип, «Үктәбер» исеме белән дә йөреп ала әле ул. Бөек Ватан сугышыннан соң «Әдәби Башкортстан» булып китә, ә инде соңгы алтмыш елда иң гүзәл, иң мул сулы төп елгабыз исеме астында дөнья күрә.

Башкорт әдәбиятының яңарып-балкуы да, үрләр артыннан үрләр яулап, Россия, дөнья күләмендә танылуы да, халкыбызның күңел юанычына һәм таянычына әверелә алуы да тулысынча журнал тарихына бәйле. Үткән гасырның унҗиденче елыннан соң әдәбият мәйданына килгән кайсы гына язучыны алма, ул иҗаты белән дә, уңышлары һәм халыкка җиткән исеме




белән дә безнең журналга бурычлы. Әдәбиятыбызның бар алтын-энҗеләре дә, ком-ташлары да монда урын алган. Әдәбият байлыгы гына түгел, ил, халык тарихы сыйган «Агыйдел» исемле кадерле сандыкка. Рухи дөньябызны, мәдәниятебезне һәм әдәби зәвыкны төп әдәби басмасыз күз алдына да китерүе кыен. Журналның төп тәгаенләнеше – халыкны әдәбиятыбызның өр-яңа казанышлары белән таныштыра бару, укучыларда нәфис сүз ярдәмендә матурлык һәм ватанпәрвәрлек тойгылары тәрбияләү. Шулай булды, шулай булачак. Мостай Кәрим, Рәми Гарипов, Һәдия Дәүләтшина, Зәйнәп Биишева, Нажар Нәҗми, Ногъман Мусин, Равил Бикбаев, Рәмзилә Хисаметдинова, Рәшит Назаров, Рәис Түләк һәм башка күренекле әдипләребезнең бөек әсәрләренә мотлак рәвештә иң элек «Агыйдел» фатиха биргән. Бүген дә әдәбиятыбызның төп йөген тарткан Таңчулпан Гарипова, Кадим Аралбай, Хәсән Назар, Гөлфия Юнысова, Йомабикә Ильясова, Гөлсирә Гыйззәтуллина, Фәрзәнә Акбулатова, Әхмәр Үтәбай, Тамара Искәндәрия, Салават Әбүзәр, Зөлфия Ханнанова, Айсылу Гарифуллина, Лариса Абдуллина, Миләүшә Каһарманова, Айгиз Баймөхәммәтов, Гөлнара Хәлфетдинова, Айгөл Җәмилева һәм башка каләм осталары әсәрләрен «Агыйдел»дән ак җилкәнле көймә итеп кенә йөздереп җибәрәләр дә, алар халык күңеле-зиһене дәрьясына барып җитеп, олы корабка әвереләләр.

«Агыйдел» – оештыручы да. Безнең журнал эчендә борын төрткән нәниләр өчен тәгаенләнгән «Бәпембә» журналы бүген ата-аналарның да, балаларның да яраткан «Акбүзат» журналы булып китте. Яңарак бу канатлы «атыбыз» Россия хөкүмәтенең Дәүләт премиясен алып куандырды. Яшьләрнең «Шоңкар» журналы да тәүдә «Агыйдел» куенында туып, көч туплады, хәзер мөстәкыйль журнал булып чыга.

Һәр баш мөхәррир заман белән бергә атлаган, шул чорны журнал битләрендә

яктырткан. Без аларны хөрмәтләп искә алабыз. Имай Насыйри, Давыт Юлтый, Гобәй Дәүләтшин, Төхфәт Янәби, Булат Ишемголлар дәверен искә төшерикме, Әкрам Вәли, Сәгыйт Агиш, Нажар Нәҗми, Хәким Гыйләҗев, Рәис Низамов, Әмир Гәрәевлар чорын алыйкмы, йә Булат Рафиков, Сафуан Әлибай, Әмир Әминев, Рәлиф Кинйәбаевларның фидакарь хезмәте еллары булсынмы, журнал матбугат басмасы гына булмаган, ә республиканың әдәби-мәдәни йөзе, асылы, маягы икәнен елдан-ел исбатлый килгән. Киләчәктә дә шулай булачак!

Китап, журнал укучылар саны кими, сүз кадере, каләм кодрәте югала барган бер мәл кичергән кебек булсак та, күңелне төшермибез, романнар да, хикәяләр дә языла, поэмалар да, шигырьләр дә чыгып тора, сәхнәләрдә премьералар шаулый.

«Ике-өч» укыган кеше өчен булса да, иҗат итәбез. Соңыннан әнә шул «ике-өч» үз артыннан тоташ заманны, тоташ халыкны рухлы, аңлы киләчәккә ияртеп алып китәчәк. Шушы көнгәчә КЕШЕЛЕКнең АКЫЛЛЫ СҮЗДӘН, ЗИРӘК ФИКЕРДӘН баш тартканы юк әле. Халкыбыз гомер буе иҗат иткән. Тарих тәгәрмәчен барыбер матди байлык, көндәлек мәшәкать түгел, ә классик кабатланмас әдәби әсәрләр, сәнгать җәүһәрләре әйләндерә. Ә «Агыйдел» әнә шул басуда төрәнен батырып җир сөрә. Димәк, мәңгелек белән эш итә.

Сүзне йомгаклаганда, бер хикмәт. Бер авылда ир белән хатын яшәгән. Алар мал тотып, май язып көн күргәннәр. Хатын майны берешәр кило гына итеп йомарлап әзерләп тора икән, ә ир көн дә чыгарып сата, ди. Авыл башындагы бер сәүдәгәр, чынлап та, бу йомры май бер кило бар микән, бу мине алдамыйммы, дип үлчәргә булган.

Үлчәсә, күзе шардай моның: йомарлам май нибары 900 грамм гына тарта икән. Теге ирне чакырып, халык алдында оятка калдырып, фаш иткән бу.

– Гафу ит, бай әфәнде, минем өемдә килограммлап үлчи торган үлчәвем юк шул, – дигән ир. – Үз кулым белән эшләгән бизмән генә бар. Аның бер ягына сез 1 кило дип саткан тары ярмасын, икенче ягына хатыным маен йомарлап сала, – дигән.

Әнә шулай: һәркемнең үз бизмәне.

Безнең дә үз бизмәнебез бар. Журналның һәр санын чыгарган саен, бизмәннең уң ягында урын алган Халкым карашын, Замандашыбыз зәвыгын, Әдәбият кимәлен дә, күләмен дә, Кешеләрнең уй-гамьнәрен... чамалыйбыз да сул ягына «Агыйдел»ебезне – үзебез җитештергән товарны салып карыйбыз. Һәм 900 генә грамм түгелме дип борчылып та куябыз. Әйе, аның 900, 800, хәтта 700 грамм тарткан чаклары да бардыр, булгандыр, анысына алай ук борчылмыйбыз да. Иң мөһиме: уң яктагы бизмән – халкым теле, халкым рухы, халкым зәвыгы, халкым тарихы, безнең өчен бик тә кадерле булган кыйммәтләр яткан «тары ярмасы» ягы 999 грамм гына булмасын, дибез, кило икән – кило булсын. Ә сул ягы... Ул якта да йомарлам май гадел тартыр, чөнки намуслы, үз эшен яраткан, халкым дип өзелеп торган ир-азаматлар, гүзәл асыл затлар җитештерә аны! Беләбез: әдипләр иңендә халык теле, халык күзе, халык сүзе дәрәҗәсендәге олы йөк һәм какшамас намус ята.

**Мөнир КУНАФИН,**
*«Агыйдел» журналының баш мөхәррире*

*Хәсән НАЗАР (1942) – Башкортстанның халык шагыйре, журналист-публицист һәм тәрҗемәче. Башкортстан Республикасының Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*

## Нәтиҗә

Иң кыены – үз-үзеңне җиңү, –
Моны борынгыдан әйткән күпләр.
Язмышка мин ышанамын, әмма
Үз-үзеңнән ачыламы бикләр?
Иңнәреңне, тиңнәреңне сынар
Хисабы юк имтихан ул тормыш.
Гади максат белән типте йөрәк:
Сөеп-сөелеп яшәргә син тырыш.
Җыйган ризык, шөкер, хәләл булды,
Өстен булды һәрчак үз иманым.
Юлыксам да кайчак чытырманга,
Үзем булып калдым, юк, сынмадым.

Үземне мин үзем җиңәм икән,
Беләм икән – кем ул күзле бүкән,
Кояш кадерендә үтсә көнем,
Искитәрлек ни бар шуннан бүтән?!
Иңнәремдә минем гади җилән,
Янәшәмдә нинди зиннәт? Беләм.
Бирешмә, дим, үз-үземне җиңәм,
Иярмдә үз юлымнан җиләм.
Бу – үзенә күрә бер нәтиҗә,
Нигә әйтмәскә, ди, бераз алдан?!
Тик дәрвишләр генә моңсыз була,
Ә калганын белә бары Аллам.

*Гүзәл СИТДЫЙКОВА (1952) – Башкортстанның халык шагыйре, прозаик, публицист, тәрҗемәче һәм җәмәгать эшлеклесе. БРның Һәдия Дәүләтшина исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. БАССРы XII чакырылыш Югары Советының халык депутаты, БР 1–3 чакырылыш Дәүләт Җыены – Корылтай депутаты.*

## Ырашкы[1]

Ыңгыраша кебек таулар – ява ырашкы,
Ни булды соң, төягем, дип килә сорашкы.
Ни дисең соң – актарылып ята тамырлар.
Аталарын варислары ничек танырлар?!
Үз тамырын үзе чабып яши кешелек –
Иртәгәдән кадерлерәк бүген кәшилүк.
Алдан алып ашый тора варис өлешен.
Елар мәлләр ерак кебек, бүген – көлешү.
Ырашкыдай күз яшьләрем ага боз катыш:
Җаным өши – җир генәмне талау да сатыш.

*Кадим АРАЛБАЙ (1941) – Башкортстанның халык шагыйре, җәмәгать эшлеклесе. БР Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Салават Юлаев ордены кавалеры.*

* * *

«Күчтәнәчкә корот[2], май ал», – диде
Китүемдә, әнкәй, калага.
Ачыкмасымны да белә, әмма
Ризык белән чыксын, ди, бала.

«Азыклының аты арымас», – дип,
Әнкәй салды маен-коротын.

Юкка гына әйтмәгәннәр икән
Авызларның суын корытып:

Чыккан чакта ир-ат яу юлына
Кәрзиненә салган корот-май...
Тәгаенен генә алган алар,
Ил-йортның да котын корытмый.

---

[1] Ырашкы – эре, жепшек, бозлы кар бөртекләре.
[2] Корот – төркиләрнең киптерелгән сөзмәдән ясалган сөт ризыгы.

Каклаган ит, казы, куырдагын да,
Эремчеген, талкан... башкасын,
Авызынан өзеп биргән халкым,
Тик башкае гына сау кайтсын....

Кунак кайтмас бездән күчтәнәчсез...
Мин дә алам маен-коротын.
«Туганнарым! Рәхмәт инде!» – димен,
Авызымның суын корытып…

*Гөлфия ЮНЫСОВА (1948) – Башкортстанның халык шагыйре, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе. БРның Һәдия Дәүләтшина исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. РСФСРның XII чакырылыш (шулай ук Россия Федерациясенең) Югары Советы һәм Башкортстан Республикасының III чакырылыш Дәүләт Җыены – Корылтай депутаты.*

## Алай булмый

Яз һавасы дәртләндереп уяткан май коңгызын.
Кәләш эзләп күзәтә ул һәр төр бөҗәкнең кызын:

Менә бер кырмыска кызы йөген күтәреп узды,
Чикерткә кызы чәчкәдә илһамланып җыр сузды.

– Кайсысын соң сайларга? – дип баш вата май коңгызы.
Чөнки ул икесенә дә гашыйк булды да куйды.

– Әгәр кырмысканы алсам, гөрләтеп дөнья көтәр;
Чикерткәне кәләш итсәм, гомер күңелле үтәр.

Их, нигә кырмыска көләч, чикерткә эшчән түгел.
Шулай булса, кәләш сайлау булыр иде җип-җиңел.

Ул очракта һәр кияүгә булыр иде бик кулай...
Тик түгел эш хис затында, бу дөньяда бер хатын да
Кырмыска белән чикерткә була алмый бер уңай.

*Әхмәр ҮТӘБАЙ (1960) – шагыйрь, язучы, журналист. Башкортстан Хөкүмәтенең Шәһит Ходайбирдин исемендәге премиясе лауреаты. Салават Юлаев ордены кавалеры.*

## Милләтем

*Пычрак табан астында*
*Башкорт намусы ятмас...*
Шәехзадә Бабич

Милләтем!
Бишегендә Җирне тибрәтер,
Гамьлеләрнең җанын иңрәтер,
Гамьсезләрнең җанын көйрәтер,
Көйләгәндә тарих сөйләтер,
Сабырлыкка җанны өйрәтер
Моңнарың бар синең, милләтем!

Милләтем!
Толстой әйткән лә соң нигә дип?
Геродотлык аңкый синнән, дип.
Тарих аргамагын тирләтер
Кыйммәтләрдән кыйммәт һиммәтең.
Тарихларда күпме имгәтеп
Куйсалар да, барсың, милләтем!

Милләтем!
Күңелең ак, юк һич негатив, –
Син тик ихласлыкта фанатик.
«Урал» җыры – синең лейтмотив,
Уралтавың – үзе логотип.
Тик бер уйлы булса өммәтең,
Тугыз булмас иде дәүләтең.

[3] Куырдак – пешереп киптерелгән ит.

Милләтем!
Йөрәгең дә өнгә тиңгә-тиң,
«Аллаһ» диеп кенә тибә тик.
Көйләнгән ул шушы көйгә тик,
Көйләнгән ул шушы өнгә тик.
Яшәмисең, димәк, тикмә-тик,
Ходайга син кирәк, милләтем!

Милләтем!
Башкорт булуларым – җәннәтем,
Бер көн яшәүләрем меңгә тиң.
Киләчәктә урын сиңа дип
Әзерлимен, газиз милләтем,
Вакыт тулпарларын тизләтеп,
Җиһан капкаларын киңәйтеп.

Милләтем!

*Гөлнур ЯКУПОВА (1948) – шагыйрә, язучы, тәрҗемәче. БРның Һәдия Дәүләтшина исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Салават Юлаев ордены кавалеры.*

## Ил баласы

Мин сыналган инде, нык сыналган.
Халкым бирер хәләл бәһасен.
Энәсе дә түгел, имгәге дә,–
Илемнең бер серле баласы.

Зур яшьләргә җиттем, шөкер иттем.
Илкәемдә – минем даламның.
Иңсәсендә аның иркәләнеп,
Чал башымны кырын саламын.

Бер мизгелгә генә сабый булам...
Буын каткан, билем сыгылган.
Күңелемә Җиһан үзе сыйган,
Ил гамьнәре уйга сыгынган.

Мин чыныккан инде, нык чыныккан.
Ышанычлы, тугры йөрәкмен.
Үткер зиһен, туры сүзем белән
Илгә бүген ихлас кирәкмен.

Дөнья күрдем, ак-караны белдем.
Кайгы кичтем, бәхет кичердем.
Үзәгемнән үткәрдем дә барысын
Үз-үземә бергәй көч бирдем.

Көчем – булсын уртак. Ут кирәксә,
Шәмдәлемнән, илем, ялкын ал.
Янгыннарны сүндерәмен, дисәң,
Акылымнан сабыр салкын ал.

Мин – синеке. Рәхмәтле бер балаң.
Күңелемә минем, кил, сыен.
Чөнки беләм, ил чаклы илгә дә
Кай чак була кыен, бик кыен.
Күңелемә, илем, кил, сыен!

*Салават ӘБҮЗӘР (1967) – шагыйрь, драматург, журналист. БРның атказанган матбугат һәм массакүләм мәгълүмат хезмәткәре, Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*

* * *

Урысны без, өлкән агай, дибез,
Һәм әйтәбез, Рәсәй, диеп, әнкәй.
Бу халыкка безнең йөрәкләрдә
Ихтирамлы, әллә курку яшәй?!

Әнкәй, дисәм аны, Шүлгән рәнҗер,
Агай, дисәм, рәнҗер Аркаим.
Тарихыбыз меңәр еллар аша
Җәйрәп ята ла соң җыр саен.

Ишетмәдеңмени шул җырларны?
Сиңа әйтәм, башкорт оланы!
«Урал»ларны иҗат иткән халык
Кемнәрнеңдер дусты буламы?!

Йә, сез тыңлап үсмәдегезмени,
Аксакаллар, сездән сораем?
Балалайка чирттеләрме икән,
Уйнаганда башкорт кураен?!

Бөек булсын Рәсәй. Һич дәгъвам юк —
Булса да хет горур бер каен.
Ләкин, әнкәй, дисәм, Шүлгән рәнҗер,
Агай, дисәм, рәнҗер Аркаим!

*Йомабикә ИЛЬЯСОВА (1957) – шагыйрә, журналист, дәүләт эшлеклесе. 1999–2013 елларда «Башкортостан кызы» журналының баш мөхәррире. БР IV һәм V чакырылыш Дәүләт Җыены – Корылтай депутаты, Дәүләт Җыены – Корылтай Рәисе урынбасары.*

## Салават

Юк, башкача була алмый иде,
Башка юллар аңа юк иде,
Аның өчен хаклык яулау юлы
Җәясеннән очар ук иде.
Юк, башкача була алмый иде,
Кыркып алган чакта танавын,
Тыныч калу, горур калу белән
Үтте халык тарих сынавын.

Юк, башкача була алмый иде
Күрер газаплары, җәзасы,
Диңгез кыясына кадаклангач,
Туктамыйча сызлар ярасы.
Юк, башкача була алмый иде
Һәлакәтле яуга иңгәндә,
Белә иде: батырлыгы хакы
Маяк булып калыр илендә.

*Таңсылу КАРАМЫШЕВА (1948) – шагыйрә, журналист. БРның атказанган мәдәният хезмәткәре. Рәми Гарипов исемендәге әдәби премия лауреаты.*

## Бәхет

Буш вәгъдәләр сиңа бирмәдем мин,
Яратам, дип антлар итмәдем,
Бәйләмәдем сүзгә язмышыңны,
Тугрылыкны синнән көтмәдем,
Син бәхетле була алсын өчен
Бирдем сиңа бары мөмкинлек,
Мәҗбүр итмәдем һич мәҗнүнлеккә,
Күңелеңә бирдем иркенлек,

Диеп әйтте миңа берчак тормыш,
Азатлыктан азат итмәде,
Үз хөкемең үз кулыңда, диеп
Юл чатларын бикләп китмәде.
Кайда хаклык, шунда сәгадәттер!
Китә алдым тик шул тарафка.
Тугрылыклы булдым намуска тик,
Ант төшмәсен өчен чал башка…

*Лилия САКМАР (1962) – шагыйрә, драматург. Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

## Бәндә

Ходай шушы Җиргә кешеләрне
Бәхет кичсен өчен бар кылган,
Байлык, нигъмәтләрен җәлләмәгән,
Урман, елгаларын калдырган.
Күпме кирәк – шулча ал, дигән ул,
Бар тереклек синең кулыңда,
Авызлыклый алсаң, авызлыкла,
Мәкер белән нәфсе – юлыңда.
Кагылмасаң, һич зыянсыз алар –
Үлән сыман тыныч яланда,
Ә кагыла калсаң, чамасын бел –
Кизәнмә шул ике кабанга.
Мәкер белән нәфсе әйләнер дә
Сиңа табан килер үкереп…
Кабан яман… Тетеләсең килмәс:
Кача башларсың бер йөгереп,

Хәлдән таярсың да егылырсың,
Йөрәгеңне кысып кулыңа…
Алга бара идең. Ник борылдың?
Хак юлыңнан атла турыга!
Ходай Җиргә безне кеше түгел,
Бәндә генә итеп төшергән,
Ул күзәтә, кайчан шушы бәндә
Әйләнер лә диеп Кешегә?

*Хисмәтулла ЮЛДАШЕВ (1957) – шагыйрь, журналист. Башкортстан комсомолының Сәлам Галимов исемендәге яшьләр премиясе лауреаты. БРның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

## Үземә

Илем дисәң, илгә җиткер,
Халкым дисәң – халыкка.
Эндәшкән сыман булмасын
Ыкта йөзгән балыкка.
Сарык түгел лә ул халык –
Аңа аяк сөртергә.
Менә нәрсә хакында гел
Кирәк фикер йөртергә.

Хан булсам, халкым, дигәндә,
Күптән хан булыр идем.
Ил-кавемне toймас хәлгә
Калмаган булыр идем.
Илгә мәңге ирек кирәк,
Хаклык кирәк халыкка.
Әйләнмәсен яу байрагың
Сый бүлгән ашъяулыкка.

*Тамара ИСКӘНДӘРИЯ (1958) – шагыйрә, тәрҗемәче, журналист. Салават Юлаев ордены кавалеры. Башкортстан Республикасының атказанган матбугат һәм массакүләм мәгълүмат хезмәткәре.*

## Моң

Моң дигәнең ни ул? – озын көймә –
кылганнарның тузгып чайкалышы,
болытларның бетмәс чуалышы,
күкнең тирәнлеге, айкалышы?

Нәрсә ул моң – тирән елгаларның
йолдыз гына күренер чоңгылымы?
Яңа яфрак ярган бөреме ул,
качып кына үскән төн гөлеме?

Бәлки, дала, бәлки, ком бураны,
ә, бәлки, дүрт якты тарафымдыр?
Юк, юк! Моң ул – һәммәсенә тиңдәш
мәхәббәтле синең карашыңдыр…

*Айсылу ГАРИФУЛЛИНА (1968) – шагыйрә, журналист. Бөрҗән районының Самат Габидуллин исемендәге әдәби премиясе лауреаты.*

## Тибендәге атлар

Тибендәге атлар – ялан яме,
Үз ишләрен күрә, черәшеп.

Рухыбызның әллә чагылышы,
Әллә башкортлыкның көрәше...
Тибендәге атлар сак-уяулар –
Өеренә ятлар кералмый.
Кыргыйлыгы – саклар калканнары,
Теләгәне тотып меналмый.
Тибендәге атлар – елкы яме,
Туган җирнең асыл затлары.
Буйсынмаган холык, ирек хисе
Хайваннарда калган сак бары.
Тибендәге атлар – ак киңлекне
Чуарлаган асыл тап икән.
Кешелекнең кешелеге бетсә,
Малкайлардан акыл тап икән…

*Зөлфия ХАННАНОВА (1970) – шагыйрә, җәмәгать эшлеклесе. БРның Шәехзадә Бабич исемендәге Дәүләт яшьләр премиясе лауреаты. БРның атказанган мәдәният хезмәткәре.*

## Сөембикә манарасы янында

Кызыктырмый мине бер дә
Синең яшәгән өең,
Көч алыр өчен яныңа
Килдем мин, горур Сөем!

Манараңда ай елмая,
Аллаһтандыр кот аннан,
Милли рухың көчләрәктер
Хәтта тәмуг утыннан.

Син җаныңны фида кылдың
Саклап иман-ырысны,
Бүген ничә татар кызы
Куандыра урысны?

Сөем! Милли горурлыкның
Тарат җиргә кузларын,
Рухың белән дөресләп тор
Башкорт, татар кызларын!

Уңда тәре, сулда тәре...
Күреп милләт азганын,
Синең кебек манарадан
Ташланырга язмасын!

*Галия КӘЛИМУЛЛИНА (1964) – шагыйрә, педагог, журналист. Башкортстанның атказанган укытучысы.*

## Ай тотылды...

Ай тотылды... Шомлы... Читлегенә
Сыя алмый, йөрәк дулады.
Дөм караңгы дөнья болай да бит
Аны күпме тунап-тунады.
Инде Ае... Дөнья чикләренә
Тәгәрәде нәрсә артыннан?!
Йөрәк шартлап, ут чәчелер төсле –
Йөрәк – ут ул! Ул – ут затыннан!
Ул шартласа, дөньядан ни калыр?
Туфан калкыр – китер актарып...
Йөрәкләтә түләтә шул язмыш
Ай-Кояшсыз калу хакларын.

*Гөлназ КОТЫЕВА (1974) – шагыйрә, журналист, тәрҗемәче. БР Шәехзадә Бабич исемендәге Дәүләт яшьләр премиясе лауреаты. Башкортстанның атказанган матбугат һәм массакүләм мәгълүмат хезмәткәре.*

* * *

Таныш караңгылык! Шул кадәрем
Сине генә көткән мин булам!
Мин үземне синдә таныр өчен
синдә эреп, сиңа убылам!
Һәм мин беләм яктылыкның көчен!
Килешү юк шуңа, юк күнүем:
Төртке нокта – өмет, димә бу сөрт,
Юк тамчы дә, их, дип үкенүем.
Ә мин беләм ике якның тигез
көч сынавын һаман, һич туктамый.
Караңгылык яктылыктан хасил,
Яктылыкны караңгылык камый!
Калмаганда янда мыскал көчең,
Булмаганда торыр көчең гаярь,
Туң җиһанда җаның талпынышы –
Караңгылык ертыр үткер хәнҗәр!

*Лариса АБДУЛЛИНА (1975) – шагыйрә, журналист, тәрҗемәче. Башкортстан Хөкүмәтенең Шәһит Ходайбирдин исемендәге премиясе, БР Шәехзадә Бабич исемендәге Дәүләт яшьләр премиясе лауреаты.*

## Беренче рәссамга

*Шүлгәнташта тәүге сурәтләр*
*табылуның 60 еллыгын котлап*

Фанилыкның нинди могҗизасы!
Тантанасы тәүге тормышның!
Тәүге рәссам нинди буяу белән
Дөнья сурәтләргә тырышкан?
Нинди уйлар? Кылкаләме нинди?
Нинди булган аның хисләре?
Нәрсә диде бу сәнгатьне күреп,
Мәгарәдәш дусты? Сөйгәне?
Пикассо һәм Ван Гог сурәтләре
Бәһаләрен монда югалта.
Эрмитаждан кыйммәтрәк бүген –
Бу мәгарә белән каралты!
Борынгылык киңлегенә чумып,
Чыгып киләм, җанда тантана.
Дөнья тетрәтерлек хәбәрем бар,
Йөрәгем чак күккә очмагае:
«Кешелек Уралтаудан башлана!»

Рәшит
Солтангәрәев

# ТАТАР БЕЛӘН БАШКОРТ

хикәя

**1**

Аларны милиция бүлегенә алып кергәч, нык кына итеп тукмадылар. Кеше тукмау – үзе һөнәр, рәтен белеп бирделәр. Әллә ни арада аяк-кулларын бәйләделәр дә типкәләргә тотындылар. «Бавырын төй, бавырын!» – дип, бер-берсенә киңәш бирделәр. Шулай тукмаганда: «Тагын милициягә кул күтәрмәссеңме! Гомерлеккә исеңдә калдыр, кабахәт!» – дип ләззәтләнделәр.

Тукмалучылар, таза гәүдәле, көчле егетләр, бирешми маташтылар, погонлыларның бер-икесенә нык кына эләктереп тә өлгерделәр. Әмма тегеләр күмәк һәм оста, бүрене еккан этләр шикелле кылананалар. Тукмалучылар да, тукмаучылар да яшь ягыннан бер чама, шуңа да милиционерлар форсат чыгуына куанып кинәнделәр генә. Янәсе, мин синнән көчлерәк, мин сине җиңәм!

Тоткыннарның көч-гайрәте ташып тора да бит, аяк-кул бәйләүле, карышыр әмәл юк. Алга бөгелә төшеп, тик утыралар. Үзләре, ике авылдан килгән адәмнәрдәй, икесе ике кыяфәттә: берсе сап-сары чәчле, җете зәңгәр күзле, икенчесе тау читеннән табылган таштан юнып ясалгандай, кара-соры төстә һәм шул таш шикелле үк зур.

Сары чәчлесенең күлмәге ертылып киткән дә, ап-ак тәне күренеп-күренеп китә. Погонлылар авыр итекләре белән типкәндә, яшь тән нык тутырылган резина туп сыман ямьшәйми дә, хәтта егет авыртуны сизми дә кебек. Авыртуын авыртадыр, әлбәттә, тере тән бит, тик ул сиздерми, авызың тулы кан булса да, дошманың алдында төкермә диптер, ыңгырашмый да, ялвармый да, сүгенеп кенә куя. Сүгенү сүзләре, нигездә, русча чыга, ара-тирә татарча да ычкындыра. Чыгу белән үч алачагы турында ант итә. Ә тегеләр аның саен ныграк бирә: «Ты ещё ума не набрал?! Вот тогда!»

Икенчесе, кара, яссы битлесе, тынычрак, күзгә эләктереп куймасыннар диптер инде, башын игән дә тешләрен генә шыгырдата. Түзәргә тырыша. Күрәсең, көрәш белән шөгыльләнгән, тәне сеңердәй киерелгән. Тегеләр типкәндә, чырае сытылып китә, әмма тавыш чыгармый, кара күзләреннән очкыннар гына чәчрәтә.

Тоткыннар әлегә авыртуга чыдый: беренчедән, икесе дә ару гына

---

Рәшит СОЛТАНГӘРӘЕВ (1935–2000) – *прозаик, журналист. Россия Федерациясенең һәм БАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре. Башкортстан Республикасының Салават Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.*

төшергән, икенчедән, нык ярсудан сиземләү тойгылары калмаган. Әлегә генә шулай, хәтәре соңрак булыр. Хәер, тоткыннарда ул турыда уйлау юк, тизрәк бер-бер карарга килсеннәр, болай җәфаламасыннар иде. Нишләтерләр: төн кундырырлар да чыгарып җибәрерләрме, әллә унбиш көнгә ябарлармы? Ике атнага япсалар, эшләр харап: эшеңә дә, өеңә дә хәбәр киләчәк.

Ярар, эшне артык зурга җибәрмәсләр әле. Урлашмаганнар, кеше таламаганнар, үзләре килеп бәйләнгәч, җебеп тормадылар, җавап бирделәр. Шушы гәүдәләре белән шул салагалардан тукмалып торсыннармы?!

Әмма тегеләр эшне алай гына хәл итәргә ашыкмады, башта күңелләре булганчы тукмадылар, шуннан исем-фамилияләрен, кайдан икәнлекләрен язып алып, икесен ике камерага илтеп яптылар. Хәтта сорау-фәлән дә алып тормадылар. Следовательгә чакыртсалар, үзләрен ничек тукмаулары турында сөйли алырлар иде.

Күпме үткәндер, ниһаять, икесен дә бер бүлмәгә китерделәр. Капитан погонлы тәфтишче бите-башы күгәренгән, киемнәре ерткаланган, яраларыннан кан саркып торган бу ике мәхбүскә көтүеннән имин кайткан малын каршылаган хуҗа шикелле исе китми генә карады да: «Капитан Голубь», – дип, үзе белән таныштырды. Шуннан утырыгыз дигәнне аңлатып, стена буендагы ике утыргычка күрсәтте. Папкасыннан кәгазьләр алды, каләмен чыгарды һәм сары чәчкә карап:

– Исемең, фамилияң, эш урының? – дип сорады.

– Бер тапкыр яздылар бит инде! – Егетнең кәефе шәп түгел, аракы шаукымы үтеп маташа, авыз кипкән, тәне сызлый.

Тәфтишче тыныч калып, әмма баягыдан катырак итеп:

– Исемең, фамилияң, эшең, торган урының? – дип кабатлады. Тавышыннан, әйткәнне үтә, югыйсә начар булыр, дигән ым аңлашылып тора.

– Ну, Кальметов Мәснәви, ди! Уфадан, заводта эшлим...

Капитан үз гомерендә мондый адәмнәрне күп күргән, күп сорау алган, шуңа да барыбер чишелерсең, чишәрбез дигән шикелле үзен тыныч, ышанычлы тота. Сорашты-сорашты, язды-язды да кара чәчле егеткә карап дәвам итте:

– Ә син? – Капитан аңа тупасрак эндәште, чөнки монысының киеме, кыяфәте, хәтта күз карашыннан ук читтән – авыл тирәсеннән килгәнлеге күренеп тора иде. Ә тоткын, капитан хәзер үзләрен йодрык төеп кычкыра башлар дип шүрләп утырган кеше, офицерның син дә мин генә сорашуын күргәч, бераз иркенәйде:

– Мин Буранбаев Ишморза булам, Баймак районыныкы. Колхозда витаминный мука әзерлим... – диде. «Баймак районыннан» дигән сүзне ул бер дәрәҗә белән әйтте. Якын-тирәдә, хәтта Уфада гына да түгел, ә бөтен дөньяда Баймакның да, баймакларның да алданрак йөргәнен, һәрхәлдә, үзләренең шулай уйлаганлыгын яхшы белә иде. Гомумән, Буранбаев теге сары чәч шикелле каршы әйтеп маташмады, сораганнарына төгәл җавап биреп утырды. «Иелгән башны кылыч кисми, башка бу капитанны күрәсең бармы, күңеле булсын да тизрәк чыгарып җибәрсен», дип уйлады.

– Нигә җәмәгать тәртибен боздыгыз? Нигә сугыштыгыз? – Тәфтишче

пыяла күзләрен йөгертеп алды да, син башла дигәнне аңлатып, үзен Кальметов дип таныштырганына карады. Хикмәтнең башы шушы адәмдә кебек күренде, ахрысы. Ә сары чәч бирешә торганнардан түгел, иреннәннән саркып торган канны сөртеп алды да эндәшми утыра бирде.

– Кальметов, нәрсә, ишетмисеңме?! Нигә сугыштыгыз?

– Нәрсә, мин уң ягыма сукканда, сул ягымны куеп торырга тиешме әллә?! Кем башлаган бит!

– До этого ещё дойдем! – диде капитан Голубь. – Нигә кеше күп җыелган җирдә сугыш чыгардыгыз? Икәү башлагансыз. Менә аның белән! – Капитан Ишморза ягына ымлады. – Нинди максатта җәнҗал чыгардыгыз?

– Ул миңа «татар» диде... – Сары чәч каршысында утырган егеткә нәфрәт белән карап алды. Тәфтишче мондый җавапны көтмәгән иде шикелле, аптырап калгандай итте, әмма эчендәгесен тышка чыгармады.

– «Татар диде», – дип кабатлады. – Ә үзең кем соң?

– Ну, татар!..

– Соң, татар булгач?..

Мәснәви эндәшмәде, тәфтишче җавап көтеп тормады, эчтән генә нидер уйлап куйды шикелле. Шуннан Ишморзага борылды:

– Ни өчен сугыштың?

– Ул миңа «башкорт» диде.

– Ә син полякмыни? – Капитан моны мыскыл беләнрәк әйтте. Ишморза, әлбәттә, капитан Голубьның тел төбен аңламый түгел иде, бите тартышкандай итте, күзләрендә очкын биеп алды, ничек тә уңайга торырга тырышкан әзмәвернең төсе китте. Ниндидер бер Голубь мыскыл итеп маташа түгелме үзен?!

– Башкорт! – Ишморза каты итеп әйтте. – Мин аның шикелле, – Буранбаев сары чәчкә карады, – милләтемне әйткәнгә гарьләнмим, горурланып кына китәм!

– Ә горурлангач, нигә «башкорт» дигәнгә сугыша башладың?

– Ул килеп ябышкач, мин карап торырга тиешме? Үз илемдә теләсә кемнән тукмалып торырга! – Ишморза дигәненең йөзе агарып китте. Күрәсең, болай гына йомшак күренә, ачуын чыгарсаң, озак уйлап тормый торган кеше.

– Үз илеңдә?! – Капитанның күзләре тычкан күргән мәченеке шикелле булды, мыегы торып утыргандай итте.– Үз илеңдәме?! Ә мин, менә бу Кальметов кемнең, синең илеңдә яшибез булып чыгамы?!

Ишморза ярамаган сүз ычкындырганын, бу урында һәр сүзең өчен җавап бирергә туры киләчәген төшенде шикелле:

– Сезне белмим, мин үз илемдә яшим, – дип куйды. Тәфтишче егеттәге зиһенне сизде, сүзне сәяси якка борырга теләмәде.

– Уфага нинди максат белән килдең?

Бу сорау да ачуына тиде, һаман киреләнә бирде:

– Нигә, килергә ярамыймыни? Уфа – безнең башкалабыз!

– Син сорауга җавап бир, Буранбаев. Монда «Кызыл Байрак» колхозының конторасы түгел. Килүеңнең максаты бардыр бит?

– Максатмы? – Теге кинәяле эндәште. – Без үзебезгә суверенитет алырга килдек!

– Суверенитет?! – Капитан моңа мыскыллы карап алды. – Шуннан, алдыңмы суверенитетны?

Башкорт эндәшмәде, ни әйтергә белмәде, күрәсең. Маңгаена ябышкан чәчен сыпырды, ярасыннан тагын кан ага башлады.

– Электән таныш идегезме? – Тегеләр эндәшмәде.

– Моңа кадәр бер-берегезне беләидегезме? – Тәфтишче катырак эндәште.

– Белмим, белергә дә теләмим! – Җавапны Мәснәви бирде. – Мин – Уфаныкы, ә ул әнә кайдан ук килгән. Мин «Татарларга азатлык!» дип кычкырганда килде дә якадан алды.

Башкорт урыныннан торып басты, калын кашларын төеп, моңа текәлде.

– Нәрсә алдыйсың! Мин «Башкортстанга – суверенитет!» дип кычкырганда, үзең килеп ябыштың! Шунда авызыңны җимерергә кирәк булган да бит!

Мәснәви дә сикереп торды:

– Вот, нахал башкорт! Сез йөрдегез бит анда «суверенитет тик башкортларга гына!» дип!

Баш-битләре күгәргән, авыз-борыннары канга баткан бу ике куркыныч адәм күз уклары белән бер-берсен атып үтерердәй булып бер-берсенә карап басты. Очкын гына кирәк, милиция бар, дип тә тормаслар.

– Сержант! – Капитан ишек ягына кычкырды. Шуны гына көтеп торгандай, ике әзмәвер килеп басты.

– Ещё не протрезвели. Охладите!

Офицерның боеруы булды, сержантлар куянга өсләткән сунар этләре шикелле килеп тә ябышты:

– Руки назад!

Егетләр горур, үз теләкләре белән кулларын артка куеп йөрергә өйрәнмәгәннәр, синең аркада дигән шикелле бер-берсенә карап алдылар да тора бирделәр:

– Что, не слышите?! – Әзмәверләр ялт иттереп боларның кулларын артка каердылар да арт саннарына типтеләр.

– Марш!

Осталар. Хәер, аларның эше шул, тәртипсезләрне тәртипкә утырту, иминлек урнаштыру, закон саклау.

Коридорда тагы ике милиционер тора иде, дүртәү булып киттеләр. Берсе – алдан, шуннан Ишморза, тагы милиционер, шуннан Мәснәви бара. Арттан икәү, немец фашистларын әләктергәннәрмени?!

Бераз бардылар да уңга борылдылар. Тимер ишеккә җиткәч, алдагысы камераны ачты. Сержант әллә ни арада аягын ишеккә аркылы куйды да Ишморзаның җилкәсенә төртеп җибәрде: «Иди в Башкортстан!» Шундый көч белән төртте, манарадай озын егет йөзе белән бетон идәнне сөреп барып төште. Тимер ишек шалтырап ябылды.

Татар моны күреп торды: димәк, үзен дә шул ук хәл көтә. Тавышын йомшаграк чыгарырга тырышып:

– Слушай, син үзебезнең егеткә охшагансың... – диде.

– Молчи! – Сержантның бәләкәй яшел күзләре еланныкы кебек үтәли карый. Кулы ялт итеп кенә алды, ул-буга әзер торган Мәснәви дә бөгелеп төште.

– Сиңа азатлык әнә шунда! – Сержант бу сүзләрен татарча әйтте.

Ишекне япкач, янындагы яшьрәк милиционерга карады:

– Ну, ничек?

– Оста-а! – Теге соклануын яшермәде.

– Афганец! – Өлкән сержант тәкәббер елмайды. – Әйдә тартып алабыз.

Алар олы эш бетергән кыяфәттә чыгып киттеләр. Бүген артык зур эш булмастыр, митингка килүчеләр таралышкан, митинг беткән.

...Мәснәви камерага бикләүләре белән тимер ишекне типкәләргә тотынды:

– Ах, анагызны!.. Чыгыйм гына әле, җиде буын аналарыгызның җиде йөз җитмеш җиде ел яткан кабер такталарын!.. Бөтен токым-затларыгыз белән! Башым Себер китсә китәр, чукындырмый калмам! Сволочь, мөртәт, үзе татар бит әле! Чукынган татар! Юньле адәм милициядә эшлиме! Ә мин шушыларга азатлык алып бирәм дип йөргән булам! Ничего, чыгыйм гына әле, төсеңне таныдым мин синең! – Ул сүгенде-сүгенде дә тагы типкәләргә, дөбердәтергә тотынды. Тыштан кемдер: «И, ты там, ещё надо что ли!» – дип җикергәч, стена буендагы тар сәкегә барып ятты. Үзе эчтән генә: «Ну, теге башкортка нык эләкте! Анысы шәп булды!» – дип, канәгатьлек кичерде.

Мәснәви татар шулай дулады, ә Ишморза башкорт бая ауган килеш бетон идәндә ята бирде. Камера салкын, киемнәр юеш – тышта октябрь, яңгыр иде. Әмма анда кайгы юк, бетон салкынлыгы да беленми. Утызга да җитмәгән өрлектәй, үзенең кайчан елаганын да оныткан егетнең күзеннән яшь ага, тамак төбенә төер утырган.

Ишморза тукмалудан да, тәннәре сызланудан да түгел, ә гарьлегеннән әрни иде. Елавын чынлап торып еламый, тешен кысып түзәргә тырыша. Шушы гәүдәң, шушы гайрәтең белән шул маңкалардан тукмалып тор инде! Иректә туры килсә, бернинди коралсыз-нисез аларның унысын бергә әйләндереп сала алыр иде! Юкка гына өйрәттеләрмени армиядә! Атаң тукмаса, йә армиядә «дед»лардан эләксә, болай ук гарьлек булмас иде. Атаң тиеше өчен бирә, «дед»лар үз-үзеңне яклый алмаганга мыскыллый. Ә болар?!

Их, кичә генә бөтенләй икенче дөнья иде! Ишморза бит үзен авылда гына түгел, дөньяда хуҗа итеп тоя. Ни тели, шуны эшли, кая кирәк, шунда чыга да китә! Әнә, килеп әйттеләр Уфага барырга дип, утырды да китте. Гел аның кебек көчле, гайрәтле егетләр җыелган. Өр-яңа матур автобус бирделәр – баймаклар бит алар! Автобус алдына Зәки Вәлидинең яшелле-күкле әләмен элделәр. Ирәндеккә җитү белән җырлап та җибәрделәр:

Башкортлар китте сугышка,
Озатып калды күк Урал.
Ат уйнатып алдан бара
Шәйморатов генерал.

Күңелле бардылар, күмәк булгач, кызып та алгач, озын юл да бик кыска күренде. Уфага иртән сигездә үк килеп җиттеләр. Депутатлар җыелып сөйләшә торган зур сарайның алдына халык тулган. Төрле-төрле әләмнәр, шигарьләр язылган таяклар тотканнар. Күпчелеге Ишморза кебек

яшьләр. Депутатлар үткән саен кычкырып калалар: «Суверенитет!», «Башкортстан!», «Азатлык!» Башкорты – башкортча, русы – русча, татары татарча кычкыра. Мәрәкә инде, мондыйны күрү түгел, ишеткән дә юк. Халык ду килә, берсен дә тотып алып китмиләр, шуңадыр тагы да катырак сөрән салалар. Әйтерсең, караңгыда бикләп тотканнар да капыл яктыга чыгарганнар, шуннан болар нишләргә белми каңгырыша.

Монда кызык беткәч, мәйданга барып, митинг ясадылар. Сөйләделәр, кычкырдылар, сызгырдылар. Берсе сөйләгәнне икенчесе ишетмәде, тыңларга ирек бирмәде. Ишморза да кычкырды: «Азатлык!», «Долой!», «Отставка!» Аның тавышы шәп, әллә кайларга китә. Әйдә, кычкырып калсын, кайчан туры килә әле тагын. Кайткач, кызык итеп сөйләр.

Төнгә кадәр йөрерләр иде дә, яңгыр ява бит. Автобусларына кереп, «җылынып» алдылар. Анысын да күрүче, тыючы булмады. Хәер, хәзер хөррият, демократия, диләр.

Эш әйбәт кенә бара иде, әллә кайдан шушы Мәснәви дигән бәндә килеп чыкты. Янына килде дә сөйләнә башлады. «Башкортлар килгән, фәлән-төгән...» Эчеп тә алган. Ишморза кызды да китте. «Килсә, нәрсә булган!» – диде. Шуннан әрепләшеп киттеләр, әллә ни арада бер-берсен якаларыннан эләктереп алдылар. Кем башлаганын белерлек түгел. Ярый сугыша башламадылар. Ишморзадагы көч – бер сугуда айгыр үтерерлек! Ул арада арттан килеп каерып алдылар да машинага илтеп тыктылар. Болар хәтта аңламый да калды. Милиция-фәлән күренгән кебек тә түгел иде, шуңа үзләре дә иркен кыланды. Әллә болай кием киеп йөргәннәр, әллә Ишморза кебекләрне сагалап торганнар, милициягә алып та киттеләр. Менә сиңа демократия! Ишморза карышып маташкан иде дә, бер генә җикерделәр.

Машинадан төшкәч, икесе бер булып, милиция белән әүмәкләшеп алдылар. Нигә әле көпә-көндез шулардан мыскыл ителеп торырга! Шуннан соң кулларына богау салдылар да кинәнгәнче кирәкләрен бирделәр. Менә хәзер ята идәндә...

Иптәшләре кайтып киттеме икән инде? Әллә һаман йөриләрме икән?

Ташлап китмәсләр, баймаклар бит алар! Ишморзаны ничек чыгарырга дип җай эзләп йөриләрдер әле. МВДда үзләренең районыннан бер башкорт майоры эшли, диләр иде, шуны эзлиләрдер. Бүген табуын таба алмаслар, хәзер соң инде, мөгаен, иртәгә килерләр. Майор булгач, бер генә әйтер – чыгарырлар да җибәрерләр. Әрләвен әзрәк әрләрләр, ну, штраф салсыннар, ди! Ерунда!..

Хатыны Нәзифә, барма, йөрмә дип, күпме ялынган иде. «Горбачёв ясый алмаган перестройканы син ясармын, дисеңме? Әллә нинди бәлаләргә юлыгырсың!» – диде. «Юлыкмам! – диде Ишморза. – Хәзер застой заманы түгел, хөкүмәт үзе безнең кебекләрдән куркып тора!» Балаларга кием, күчтәнәч алып кайтырмын дип, акча да алган иде. Алдың! Кесәләре буп-буш. Әй, акчасы чукынып китсен иде әле, ничек тә тизрәк чыгып ычкынырга иде моннан. Гомердә дә бик эчендә утырганы юк аның. Нәсел-нәсәбендә булган эш түгел. Хәтәр икән! Әле һаман ышанып җитми, бөтенесе дә ялгыштыр, бәлки, төш кенәдер, ул авылында, өендә ятадыр сыман. Шуңа ышанып кыбырсып ала. Шунда ук кулы салкын бетонга тия,

күзен ачтымы, биектә янган тонык кына шәм күренә. Тәрәзә дә, ишек тә юк. Ишеге бар да, ачылмый.

Ничек төнне үткәрергә?! Тизрәк яктырсын иде. Яктырсын да, теге майор килеп алып китсен иде үзен. Ай, озак үтә вакыт!..

* * *

Ә эш Ишморза уйлаганча гына түгел иде. Теге җирән капитан Кальметов белән Буранбаевтан тагы бер тапкыр сорау алды да, шуннан Гоголь урамындагы төрмәгә илттеләр дә яптылар. Төрмә дигәч тә, чын төрмә түгел, халык белмичә генә шулай әйтә, имеш. Монда аны «изолятор» дип йөртәләр. Судка кадәр утырганнарны шунда тоталар икән. Ишморзаның тыштан гына карап үткәне бар иде, менә эчен дә күрергә туры килде. Димәк, эш зурга китте.

Монда эшләр хәтәр: чыгармыйлар да, эш тә эшләтмиләр, бикләп кенә тоталар. Камераның эче тулы гел бертөсле халык, гүя йоны алынган сарыклар. Чакыртсалар, сорау алу өчен генә килеп алалар. Анда да кулларын артка куйдырып, сак астында гына китерәләр. Шул кыяфәттә алып китәләр. Шушысы бигрәк гарьлек. Тизрәк хөкем итеп куйсыннар да инде... Нәрсәсенә кешенең башын катырырга!

Ишморза суд көненә кадәр өметләнде. Мөгаен, аны бу килеш калдырмаслар, йә колхоз председателе, йә райком секретаре килеп йолып алыр. Бик үрнәк кеше, колхозга кирәк кеше, диярләр, ансыз эш бармый, диярләр. Райком секретаре аны белергә тиеш, Ишморзаны бер түгел, ике тапкыр район газетасында мактап яздылар бит. Председатель дә, райком секретаре да төрмә начальнигы белән генә түгел, хәтта министрның үзе белән дә сөйләшә ала.

Ишморза шулай коридорда аяк тавышы ишетелгән, шалтырап ишек ачылган саен тилмереп, сорау алырга чакырганнарын көтте. Барып керү белән тәфтишче: «Буранбаев, синең эшең туктатыла, бар кайтып кит тә эшеңә тотын», – дип әйтер сыман иде. Юк, булмады, хыянәт иттеләр. Айдан артык утыра, председатель түгел, иптәшләре дә килеп күренмәде. Хәтта күчтәнәч тә җибәрмәделәр. Ишморза үзе булсамы, төрмә нигезен казып булса да, юлын таба иде. Бөтен кеше дә аның кебек түгел икән шул! «Ашап-эчкәндә, дуслар күп, башыңа бәла төшсә, берсе дә юк», дип, юкка җырламаганнардыр борын-борыннан. Ә ул әнә шулар өчен газап чигеп утыра, ахмак!

Аптырагач, Ишморза үзен-үзе юатып ала. Урлашып йә кеше талап утырмаган да инде, башкортымның ирекле тормышы өчен дип йөргән. Әнә Ленин белән Сталин, Дзержинскийлар да утырган. Бер генә тапкыр түгел, әллә ничә тапкыр утырып чыкканнар. Барыбер чыкканнар. Нинди дә кеше булып киткәннәр. Бәлки, берәр заман Ишморза Буранбаев турында да шулай сөйләп йөрерләр, хәтта китапка да язарлар. Хәзер түгел инде, берәр заман, үзе үлгәч. Башкортның азатлыгы өчен төрмәдә утырган, үзе теге Буранбай нәселеннән булган, диярләр. Килештерерләр, өстәп-өстәп язарлар...

Ә теге татар бирешмидер әле, Уфа кешесе бит. Әллә кемнәре бардыр, милициядә бит, кая карама, татарлар утыра. Иллә шәп иттеләр үзен, нык бирделәр тегеңә! Югыйсә әллә кем булып йөри иде! Хәер, аермадылар инде, икесенә дә бер чама эләктерделәр.

Нишләп шул милиция дигән җирендә башкортлар эшләми икән? Менә

шундый вакытта кирәк бит алар. Ят – ярлыкамый, үзеңнеке – үтерми, дигәннәр. Ишморза үзе шул тирәдә йөрсәме, бөтен башкортларга ярдәм итеп утырыр иде...

Ишморза Буранбаев нинди генә хыялларга бирелмәсен, берсе дә чынга ашмады: ике ай изоляторда тоттылар да шартлатып хөкем иттеләр дә куйдылар. Судта суверенитет-фәлән турында сүз булмады, «уголовный җинаять» дип таптылар. Баштарак Ишморза бәлки үзләрен сәяси тоткын итәрләр дип өметләнгән иде, анда шартлар әйбәтрәк була, арурак ашаталар да, имеш, диләр иде, алай итмәделәр, җәмәгать тәртибен бозган, милициягә кул күтәргән өчен дип чыгардылар хөкемне. Ярый, бәлки, хәерлегә булгандыр, сәясәт өчен дә озакка ябарлар йә сөргенгә үк җибәреп куярлар иде. Ә болай ике ел бирделәр дә холык төзәтү һәм хезмәт лагерена яптылар.

Теге Мәснәви татар белән башкача күрешмәделәр, күрәсең, икесен ике якка олактырдылар.

**2**

Колония дигәннәре изолятордан уңайлырак икән: арурак ашаталар, эшләтәләр, сарайдан ялан киртәгә чыккан мал шикелле ихата алдына чыгып йөреп тә була. Хат язарга да рөхсәт бар, хәтта кино да күрсәтәләр икән.

Иң коткарганы – эш инде. Югыйсә изоляторда чакта асылынып кына үләрдәй булды ласа! Берни кылар әмәл юк: ятасың сасы камерада сукыр тычкан кебек. Монда, ичмасам, үзеңне кеше итеп тоясың.

Ишморзалар ит турагыч ясый. Цехы да шушында киртә эчендә икән, көн дә санап, карап үткәрәләр. Бер завод сыман үзенчә. Ишморза ни, тимер-томыр арасында йөргән кеше, формовкасына да, станогына да тиз өйрәнде. Атна-ун көн дигәндә, куелган нормаларын тутыра, тагы бераздан арттырып та җибәрә башлады. Эшләгәнне монда да яраталар.

Шунысы гына яман: ит турагычы әзер булдымы, пилмән ашыйсы килә башлый. Өйдә чаклар, ит чыгарган, күмәкләп утырып, пилмән ясаган, шуннан ул пилмәнне туйганчы ашаган вакытлар күз алдына килә. Ашап туйгач, бергәләшеп, телевизор карыйлар, шуннан балалары йоклап киткәч, кәләшен кочаклап, юрган астына чума...

Булган бит заманнар! Хәзер хәтта ышанасы да килми. Ну, моннан исән-имин котылса, белер иде яшәвенең кадерен. Мондагы ашны алар этләренә дә бирми торган иде. Чын! Нихәл итәсең, килеп эләккәч, түзәргә генә кала, башка әмәле юк.

Ярар, менә шулай әйткәннәрен тыңлап, кушканнарын эшләп, тын гына көн күреп ята әле. Беркөн кулына «Агыйдел» журналы килеп эләкте. Күрәсең, аңа кадәр дә монда бер башкорт утырган. Чыкканда калдырып киткәндер. И куанды ул журналга. Башкортча бит! Туганы, авылдашы белән очрашкан кебек булып китте. Тавышы чыкмаса да, теле бар.

Авылда чакта алдырганы да, укыганы да юк иде аны. Хатыны «Крестьянка» белән «Башкортостан кызы»н, ә үзе «За рулём» белән «Подвиг»ны алдырды. Форсат калмый бит укырга, җәен дә, кышын да шул эш дип йөгерә. Ә монда вакыт бар. Яздырып та була икән, киләсе айдан үзенә алдыра башлар. Ә кайткач инде мотлак язылачак. Хәзер бер якын дустына әйләнде дә куйды шушы зәңгәр тышлы журнал.

Ишморза башта аның битләрен актарып, караштырып чыкты, мәхәббәт, гаилә тормышы турында язылганнарын эзләде. Матурларын гына укырга иде, ире төрмәгә эләгеп, хатыны авылда калып, бозылып киткән эшләр турында булып куймасын!

Ишморза ике-өч бит укыгач та шүрли төште: ах, нәкъ аның ише адәм турында язылган түгелме?! Хәтта исеме дә охшаш – Иштуган. Иштуган шофёр булып эшләгән, Уфада яшәгән. Хатыны, баласы булган. Машинасы белән юл йөри торгач, Иштуган бер яшь хатын белән танышып, эчкечегә, уйнашка чыга. Моны үз хатыны белеп кала. Ызгыш-талаш, җәнҗал чыга, бу өеннән чыгып китәргә мәҗбүр була. Ахыр чиктә төрмәгә эләгә.

Ишморза андый кеше түгел, ул бит бөтенләй икенче – изге юлда йөреп эләкте. Ә теге – ахмак, нигә ирекле тормышның кадерен белеп кенә яшәмәскә инде! Ишморза шуларны уйлап утыра-утыра да: «Ярар, бер тамагың белән бер арт саныңа баш булмагач, өйдә ят каңгырап», – дип куя.

Шушында Ишморзалар колониясендә түгелме икән ул адәм? Бәлки, очрап та куяр. Хәер, язучылар кешеләрнең исемен бутап яза, ди бит ул. Котылып чыккач, Уфада язучысын эзләп, Иштуган турында сорашыр әле.

Нәзифәсе ничек яшәп яткан була икән анда? «Зэк хатыны» дип рәнҗетмиләрме икән бахырны? Нәзифә бит еракта, бөтенләй икенче районнан төшкән килен, авылда туган-ыруы, серләшер кешесе дә юк, ялгызы йөридер. Бергә яшәгәндә, болары беленмәде, хәзер сиздерәдер. Болай усаллыгын усал гына инде, әллә ни бирешеп тә бармыйдыр, шулай да...

Нәзифәнең эше ир-ат янында – колхоз бухгатериясендә кассир. Аена ике-өч тапкыр акча алырга дип, районга бара. Күбрәк председатель шофёры илтә. Ул бушамаганда, икенчеләре дә алып китә. Парткомны йөрткән төлке танау Кинҗәбулат Нәзифәгә күзләрен ялтырата, имеш, диләр иде. Иманы юк бит ул бәндәнең, эчеп алса, әбиләргә дә ябышыр! Ул-бу булып, белеп калсамы!..

Нәзифәсе төскә бик чибәр – Мәснәви кебек үк сап-сары чәчле. Шундый сары, башына көнбагыш чәчкәсен ураган, дип торырсың. Ә күзе – зәп-зәңгәр. Карасаң, үз күзләрең камашыр. Баймак ягында андыйлар юк, шуңа да авылда ят яланнан күчереп утыртылган чәчкә кебек күренә. Кайткан көн урам әйләнделәр, бөтен авыл карап калды. Иртәгесенә үк хәбәр таралган: ну, Ишморза тапкан бит кәләшне!

Аптырарсың, Ишморза малайлары, әти-әнисенә караганда да, кәләшен ныграк сагына. Чын! Моны әйтүе түгел, уйлавы да оят, әмма шулай булгач, шулай инде. Сылу гына түгел, уңган да бит кәләше: эшләмәгән эше, пешермәгән ашы юк. Бер дә тик тора белми.

Йөгерә-йөгерә арып та китәдер – колхоз эше, йорт эше, бала-чага. Акча таратуга гына күпме нервы! Ят ирләр кайгысы, дисеңме анда! Чаба-чабадыр да, кайтадыр да тәгәридер.

Кәләше турында шулай яман уйлаганы өчен үзен әрләп ала, күңеленнән булса да, гафу үтенә Ишморза. Шуннан хат язарга тотына. Менә бераздан, Алла бирсә, күчтәнәчләрен төяп, үзе дә килеп җитәр әле. Икесен бер бүлмәгә, бер караватка салып, тыштан бикләп китәрләр. Тәртипле йөргән кешеләрне хатыннары белән шулай очраштыралар да! Бу төн тәү кушылган

төннән дә татлырак булачак! Йә, төрмә хәтле төрмәдә хатының белән кочаклашып ят әле! Башка сыярлык түгел! Әйтсәң, ышанмаслар да! Моны уйлап тапкан кеше бик әйбәттер. Кайчан килә инде ул көн?

...Көннәр шулай сагышлы да, өметле дә уйлар, хисләр белән үтә торды.

Ишморза теге журналны түшәге астына яшереп тота. Сере бар: бер аграк битенә сызык сызып бара. Бер көн үткән саен – бер сызык, сызыкны ул кич ятар алдыннан гына сыза. Бу – үзенчә бер тантаналы мәл: димәк, тагы бер көн үтте, рәшәткә эче тагы бер тәүлеккә кыскарды, дигән сүз. Тик шушы мәлне – кичне көтеп алуы гына авыр. Кайвакыт түзмичә иртән үк сызып куя. Иртән сызсаң, кичкә шатлык калмый, буш күңел белән ятып йоклаган кебек була. Һәр көн таякларны саный. Әлбәттә, исәбен болай да яттан белә, әмма санап куйсаң, тынычрак. Таяклар кайчак артыграк та чыга. Ишморза куанып, йөзе яктырып китә: әллә ялгышып йөргән дә, срогы бер көнгә булса да кыскарып куйганмы?! Шунда ук яңадан исәпләргә тотына. Юк инде, алдый алмассың дөньяны!

Ишморза төрмәдән август аенда чыгарга тиеш. Бөтенесе дә күз алдына килә. А-а, ул бит һавада очкан бөркет, болында җилдергән болан кебек яшәгән кеше! Ничегрәк йөри иде авылында! Кая гына бармасын – үз иле! Үз иле, үз кешеләре, дус-ишләре, бөтенесе дә күтәреп алырдай булып тора.

Ә андагы көч, очылык! Көрәшкә керсә, аркасы һичкайчан җир күрмәде. Тегеләр аһ та ух килә, ә бу тир дә чыгармый, җайлы чакны гына чамалый да алып сала, Сабан туе саен тәкәсез кайтмый иде. Кайтмый дигәч тә, өйгә алып кайтып тормый инде, кайдан килгән, шунда китә – Ирәндекнең иң күркәм җиренә баралар да учак ягалар, тәкәне суеп, шашлык пешерәләр...

Шулай төрмәдәге көннәрен санап, үткәннәрен уйлап яшәп ята иде, көтмәгәндә бер хәл килеп чыкты.

Атна уртасы, эш вакыты. Бер-берсенә охшаш адәмнәр цехта эш белән мәшгуль. Берәүләр көн узсын, чабата тузсын дип йөри, Ишморза кебекләр эшләгәч, эш булсын дип тырыша. Кинәт цехның теге башында гауга купты. «Зэк»лар үзара сугыша башлады. Алар сугышса – хәтәр инде. Яман алышалар бит. Берсе тондыра да, икенчесе чәчрәп барып төшә, шуннан торып, тегесе тондыра. Ә авызларыннан чыккан сүзне төрмәдә генә ишетергә мөмкин. Куркыныч! Икәү дөмбәсләшә, калганнары кысылмый, карап тора. Монда закон шулай: бәхәсне гладиаторлар сыман үзара хәл итәргә тиешләр.

Ишморза җәнҗалны күрмәмешкә салышты: барып кысылырга атасы туганы, кан кардәше түгел әле. Төрмәгә дә шул гыйсъян аркасында килеп капты, йә тагы бәлагә эләгеп куяр. Шунда таныш тавыш ишетеп, дерт итеп куйды. Кайдан таныш соң әле бу тавыш?! Һәм шул якка йөгергәнен сизми дә калды. Бәй, Мәснәви түгелме?! Шул бит?! Монда ничек килеп чыккан?!

Ишморза аны-моны уйлап тормады, формовка белән Мәснәвинең башын ярам дип сугарга торган озын буйлы «зэк»ның муеныннан эләктереп тә алды. Шундый итеп кысты: теге озын бер-ике тыпырчынды да шәлперәеп төште. Бу гына да җитмәде: Ишморза тегене үзенә таба борды да, башын идертеп, иягенә тубыгы белән тондырды. Әле генә гайрәт орып торган озын идәнгә ишелде.

«Цыган» кушаматлы бу блатнойны колониядә бөтенесе дә белә. Монда ул

патша, хаким! Үзе хаким, үзе җәллад. Бөтенесе дә аңардан курка, әйткәнен үтәп кенә тора. Үзе берни эшләми, хәтта эшкә дә чыкмый, менә дигән яши: ашарына да, эчәренә дә һәрвакыт бар. Табып китереп торалар. Хәтта контролёрлар да аның белән исәпләшә, каршы төшмиләр.

Ишморза менә шушы кешегә кул күтәрде. Мәснәвине күргәч, аны-моны уйлап тормады. Хәзер инде артка чигенү юк, югыйсә беттең, дигән сүз. Сине берәү дә якламаячак, теге сине йә үтерәчәк, үтермәсә, хайван хәлендә тотачак, монда инде закон – тайга, кем әйтмешли, көчле җиңә. Мәснәви дә эшне төшенде, бар нәфрәте белән озынга килеп ябышты. Әмма шул вакыт өчесен дә аерып алдылар да, болар аны-моны аңышканчы, алдылар да киттеләр.

«Зэк»ларның күзе Ишморзада гына: кара син аны, мыштым гына йөри иде, ничек яман булып чыкты. «Цыган» хәтле «Цыган»ны әйләндерде дә салды бит! Димәк, хәзер блатной булып, шушы кала икән. Төрмә законы шундый: кем көчле – шул башлык. Ә Ишморза үзен хәзер ни көткәнен сизсә дә, эчтән генә әллә кем иде. Бердән, үзенең кемлеген күрсәтте, икенчедән, якташын коткарып калды. «Башкорт түзә-түзә дә, бер кызса тыеп кара!» – дип эчтән горурланды. Төрмәдә андый абруй да кирәк.

Колониянең режим буенча начальник урынбасары озак сөйләшеп тормады. Эшнең нидә икәнен белеште дә «Цыган»га карап:

– Унбиш тәүлек! – диде.

Унбиш көнгә штраф изоляторы дигәнне аңлата бу. Бу төрмә эчендәге төрмә инде – чыгармыйлар да, юньләп ашатмыйлар да.

Начальник урынбасары алдындагы кәгазьләрне карап утырды да капыл Мәснәвигә борылды:

– Ә син, Кальметов, каян килеп эләктең монда?

– Кайдан килеп эләккәнне сез яхшырак беләсез инде, гражданин начальник. Кораллы сакчылар куйдылар да утырттылар да җибәрделәр. – Мәснәви һаман да шул икән, үзенчә телләште. Ә теге мондый сөйләшүләрне күп ишеткәндер, алдында торган байгышның дорфалыгына исе китмәде, Ишморзага карады:

– Ә син, Буранбаев? – Ишморзага ул йомшаграк эндәште, шуның белән бу «зэк»ны үз күрүен дә, син ару гына адәм идең түгелме соң, дигәнне дә аңлатты.

– Мин ни, цехта эшләп тора идем... – Ишморза эшнең ничек булганын сөйләп бирде.

– Икегезгә дә бишәр тәүлек! – диде начальник. – Ә син, Кальметов, юлга әзерлән!..

– Гражданин начальник, минем ни...

– Молчать! Сез, Буранбаев, Кальметов – «подельниклар», тәртипне беләсездер, не первый раз замужем! Бетте! Алып китегез! – диде.

Болар үзара сөйләшү түгел, юньләп бер-берсен күреп тә өлгермәделәр, карцерга алып та киттеләр.

Ә эш болай булган. Мәснәви Кальметов ике көн элек кенә этап белән элек утырган җиреннән шушы колониягә китерелгән. Эшкә чыккан. Яңа кешене күрүгә «вор» Мәснәвидән эшен үз исеменә яздырып барырга кушкан. Колониядә шулай инде, «вор» да, көчлерәкләре дә эшләми, эшләргә

теләми, ә акча, эш хакы кирәк. Шуңа да алар йомшагракларны куркытып, эш хакларын үзләренә язарга куша. Ишморзаны да ярты ел буена шулай интектергән иде.

Мондый хәлләрне контролёрлар да, колония начальнигы да белә, тик белмәмешкә салыша. Югарыга жалу-фәлән булмаса, теләсә нишләсеннәр. «Цыган» да Мәснәвине куркытып маташкан. Ә теге күп уйлап тормаган, салган да җибәргән. Киткән сугыш. Ишморза килеп чыкмаса, әллә ниләр булуы бар иде. Хәзер менә икесе ике камерада япа-ялгыз бер стакан салкын су эчеп утыра.

«Тагын шул татар аркасында», – дип, җаны көеп алды Ишморзаның. Кайдан килеп чыкты ул монда? Очрашулары әйбәт булды әле, «подельник» булсалар да, якташлар бит әле алар монда: татар белән башкорт. Ичмасам, сөйләшеп йөрерләр иде. Дошманлыклары үтте бит инде. Дошман дип, нинди дошман булсыннар, ахмаклар алар. Тизрәк очрашырга иде. Ә биш көн елдан да озаграк үтә.

**3**

Мәснәви белән Ишморзаны бер үк вакытта чыгардылар. Кинәт булды – кара-каршы очраштылар да телсез калдылар. Хәзер нишлибез инде, дигәндәй, бераз карашып тордылар. Күзләр яна, ә тел әйләнми, арада ниндидер киртә ята. Әллә нәрсәсенә җәнҗал килә дә чыга бит!

– Нихәл, Ишморза! – Беренче булып Мәснәви эндәште.

– Саумы...

Алар кул кысышты. Каты итеп кысыштылар. Мәгънәсе аңлашыла: бу сиңа Уфа түгел, хәл хәтәр, бер-беребезгә терәк булыйк! Сөйләшер сүз дә юк сыман. Дөресрәге, сүз бар, хәтта күп, тик кайсыннан башларга?

«Подельник»лар, ашыкмыйк әле, тәмлесен соңрак иркенләп ашарбыз, дигәндәй, тынчу, караңгы коридор буйлап дәшми генә атлыйлар. Биш көнлек карцер егетләрнең күңелен нык кырган, шулай да шатлар. Бу атлауларыннан ук күренә. Бер кинәнеч белән баралар.

Менә алар яктыга чыкты. Янә бер-берсенә карадылар. Моңсу күзләренә нур сирпелде, авызлары ерылды. Тагы бераз карашып тордылар. Шуннан капыл кочаклаштылар. Кысып, озак итеп кочаклаштылар.

– Шуннан, Ишморза? – Мәснәви зәңгәр күзләрен балкытып, якташына карады.

– Әйдә миңа чәй эчәргә! – диде Ишморза.

– Чәең бармы? – Мәснәвинең йөзе тагы да яктырып китте. – Мин монда яңа кеше.

– Бар, бар, әйдә! – Якташын чәйгә чакыру Ишморза өчен бер сөенеч иде. Алар, олы мәҗлескә чакырылган кешеләрдәй дәртләнеп, чәй эчәргә киттеләр. Төрмәдә чәй эчү, чәйгә чакыру – олы сый, олы дастархан. Ә биш көн штраф изоляторында утырып чыккан кешегә чәйдән артык тагы ни кирәк!

«Зэк»лар чәйне колония кибетеннән яздырып ала. Төрмә дигәч тә, монда чәе-шикәре, шырпы-тәмәкесе бар, эшләгән эшең хакына бирәләр. Күпләре чәйне алу белән чифир итеп эчеп бетерәләр дә йөриләр кеше күзенә карап. Ә Ишморза, бәләкәйдән чәй эчеп үскән кеше, аның кадерен белә. Әле дә шул бар, югыйсә бик авырга төшәр иде. Төрмә чәе чәймени инде!

Менә Ишморза олы кинәнеч белән каты итеп чәй пешерергә тотынды. Борынны кытыклап, хуш исе таралды. Иректә булсалар, мондый сыйга көлеп кенә куярлар иде дә, монда башкасы кирәкмәгән дә сыман. Якташлар кәнфит кабып, әче чәй эчәргә тотынды. Хәтта аракы эчкәндәге шикелле кәефләре күтәрелде, кызарышып киттеләр.

– Урлашмыйлармы? – диде Мәснәви.

– Юк, ул яктан бездә тәртип каты. Берәү генә урлашып маташкан иде дә, акылга тиз утырттылар. Шуннан кул озынайтканнары юк.

– Дөрес, урлашырга дәүләт милкемени ул? Беләсеңме, Ишморза дус, мин бит тегендә бөтен колонияне кулымда тотып тордым. План үтәлми башласа, колония начальнигы чакыртып ала иде. Чакыртып ала да: «Давай, Кальметов, помоги, Родина не забудет!» – ди. Үзең беләсең, алардан да план сорыйлар. Минем бер кычкыру җитә, кая, кычкырып та тормыйм, бер генә карап алсам, барысы да башын басып, эшкә тотына. Сездәге кебек «цыган»нарны тиз акылга утырттым! Монда исә мин эшкә чыгып җитмәгән, килде дә: «Эш хакыңны миңа яздырасың!» – ди. Бер пешмәгән олух дип уйлагандыр инде. Ә мин аның кемлеген цехка кергәч тә күреп алдым. Күп уйлап тормадым, салдым да җибәрдем. Менә шуннан китте. Ярый син килеп катнаштың, югыйсә бетерә идем мин аны!..

– Миңа да шулай итте... – диде Ишморза.

– Шуннан? – Мәснәвинең күзләре зураеп китте.

– Биш ай буена яздырдым инде.

– Синме?

– Әллә, кәсепкә килмәгән, дидем дә куйдым. Чукынып китсен, монда тәртибе шулайдыр, дип уйладым.

– Их син, дурак! Бирермен мин аңа эш хакын! Күрдеңме, ничегрәк салып очырдым!

– Очрашу бик шәп булды бит әле! Безне аерып куймасlargeмы икән? – Ишморза балалар кебек куана иде. – «Подельник»лар дип ычкындырды ласа!

Болар инде елдан артык утыралар, аны-моны, закон статьяларын гына аңлыйлар. Колония начальнигының режим буенча урынбасары теге вакыт «подельник»лар диде. Бу инде «по одному делу», ягъни бер үк эш буенча дигәнне аңлата. Андыйларны бер колониядә утыртмыйлар, икесен ике якка җибәрәләр. Җитмәсә, болар сугышып, үчләшеп утырган кешеләр, бергә тотарга ярамый, әллә ниләр кылып ташлаулары бар. Теге вакыт офицерның Мәснәвигә: «Син ничек килеп эләктең монда?» – дип аптыравының сәбәбе шунда иде. Димәк, йә берәр ялгышлык килеп чыккан, йә игътибар җитмәгән, бутаганнар. Шулай итеп, ике «дошман» бер колониягә, хәтта бер үк цехка килеп эләккән. Тәүге көндә үк җәнҗал чыгарып, карцерга каптылар. Боларны, чынлап та, озак тотмаслар, аерырлар.

Моңа бигрәк тә Ишморзаның эче пошты. Очрашканнарына шулкадәр шатланган иде. Ә Мәснәви Ишморзаның нindirәк кеше икәнен сорау алган чакларында ук сизгән иде инде, шуңа да баштан эрерәк җибәрергә, моның алдында зуррак булып кыланырга тырышты.

– Ярый, аермаслар, колония начальнигы белән үзем сөйләшермен, – диде.

– Колония начальнигы белән?! – Ишморза аптырап китте.

– Юкка исең киткән! Тегендә чакта мин начальникның кабинетыннан чыкмый идем. Атна саен чакыртып ала иде!

– Кабинетына?! Начальникмы?! – Колония начальнигын полк командирыннан да югарырак, хакимрәк күргән Ишморза ни әйтергә дә белмәде. Шыттыра дияр идең, очрашмас борын алдап торыр микәнни? Төрмәдә мактанып утыруның ни мәгънәсе? Алдамый дияр идең, бер дә ышанырлык түгел.

– Кабинетына булмый, үзе минем янга килмәс инде! Чакырта да корпустагы хәлләр, эш турында сораша башлый. Аларга да бит обстановканы белеп торырга кирәк. Эш азагында булса, шунда ашап, эчеп алабыз.

– Шунда кабинетындамы?! – Ишморзаның күзләре шардай булды.

– Бигрәк юкка аптырыйсың икән лә! Һәр начальникның – завод директорымы, обком секретаремы – кабинетының артында «бытовка» дигән бер бүлмәсе була. Иң төптә ул, ишеге күренми дә, беленми дә, хуҗа үзе генә ачып керә ала. Шунда кердеңме, җаныңа ни кирәк – ашау, эчү, сервант, диван, ванна һәм матур кыз! – Мәснәви үзе сөйләгәнгә үзе ышанып, шушыларның барысын да күз алдына китерде шикелле, йөзләре кызарган, зәңгәр күзләре шул кабинетта – аш-су, эчемлек, ашамлык һәм матур кыз янында утырган кешенекедәй яна.

– Син шул бытовкага кердеңме?

– Бәй, кермичә! Төшереп утырдык бергә!

– Төшердегез?! Колония начальнигы беләнме? – Ишморза шикле елмайды, йөзе күңелсезләнде. Иптәше ихлас кеше түгел, ахрысы.

– Син нәрсә, колония начальнигы дигәч тә, пәйгамбәр затыннан дисеңме? Синең белән миңа гына шулай күренә ул. Анысы да монда утырган чакта гына! Якыннан карадың исә, шул без сәлам дә бирмәслек бер тупой адәм! Җүнле кеше төрмә начальнигы булып эшлиме? Башка җирдә эш тапмаганга барып кергән бит инде ул.

Ишморза тагы ышана төште, алдамыйдыр, күпне күргәнгә охшаган бит. Ә Мәснәви моны сизде, Ишморзаның күңеле йомшара башлаганын күреп, борчакны сиптерде генә:

– Син шуңа аптырыйсың! Беләсең килсә, мин бит колония начальнигы белән ауга да чыктым. – Мәснәви, бүлдерә күрмә дигәндәй тын да алмый сөйли бирде: – Бервакыт шулай кабинетына чакыртып алды да бу: «Син, Михаил Михалыч, ничек атасың?» – ди. Мине анда шулай «Михаил Михалыч» дип йөртәләр иде. Урыска «Мәснәви Мәгънәвиевич» дип әйтүе авыр бит. Әйе, шулай, ничек атасың, дип сорый бу. Мин шүрли төштем, бар гөнаһларымны уйлап алдым. Ә теге: «Сине, Михаил Михалыч, «Ворошиловский стрелок» икән, диләр?» – ди. Аларда безнең «личное дело»лар бар бит инде, димәк, менә эш нидә. «Кандидат в мастера!» – мин әйтәм. «Кандидат в мастера булгач, әзерлән, киләсе шимбәдә ауга чыгабыз!» – димәсенме бу?

– Чыктыгызмы? Алдыгызмы берәр нәрсә? – Ишморзаның шиге бетте, бу кадәресен уйлап чыгару мөмкин түгел.

– Сорыйсың тагын! Дичь күп, яман күп иде ул якта. Боланнар, мараллар, бүреләр, аюлар, мә, башта мине ат дигән кебек, үзләре килеп баса алга! Ә куян, төлке-фәлән белән пычранып тормадык!

– Ахырдан эчкәнсездер инде? – Ишморза иренен ялап алды.

– Сорама аларны! Охотага эчәр өчен чыгалар бит инде! Безнең начальник якын-тирәдәге колхоз председательләре белән бик шәп яши иде, ниләр генә китермәгән тегеләр! Ул ат ите, ул каз ите, ул коньяк, ул спирт! Балык, уылдык!..

– Кикергәнче ашадыгыз инде?.. – Ишморза төкереген йотты.

– Андый ашны вольныйда да күргән юк иде. И-и, сөйли башласаң!.. Көн буена ауда йөрдек, кич урманчы йортына бардык. Исеме генә урманчы йорты инде – оҗмах! Әллә утызлаган бүлмә, ул җиһаз, саунасы, буфеты, чыгабыз да сыра чүмерәбез!

– Соң, алай булгач, начальник нигә җибәрде сине колониясеннән?

– Тукта әле, бүлдермә! Соң, җибәрми, мин бит хәзер артык күпне беләм. А вдруг сатар, дип уйлый бит инде бу. Ярар анысы. Ниләр генә ашамадык та ниләр генә эчмәдек инде! Главный, ашап эчкәч, исертми. Исертми дә, баш та авыртмый! Аз гына йоклап алдык та тагын тотындык. Мин башта сакланыбрак утыра идем, иртәгәсен кыен булыр дип. Аларга ял да, миңа бит – эшкә. Эч, ди бу, ике көн ял итәрсең, ди. Баш төзәтергә дип бер шешә акны, ике шешә сыраны кесәгә тыгып ук куйды.

– Аны нишләттең инде? – Ишморза күзен дә йоммый утыра.

– Нишләтим, кайткач җайлап кына, баш төзәттем.

Ишморзаның түземе бетте. Чәй эчеп алгач, тамак туйган кебек иде дә, шулкадәр сүзләрдән соң ашказаны яңадан ярсый башлады. Биш көн каты икмәк сыныгы белән су гына эчеп утырдылар бит. Ул төсен бозып, иптәшенә карады:

– Адәм ышанмастайны чын булса да сөйләмә, дигәннәр...

Мәснәви үзенең артыграк җибәрә башлаганын, абруен төшерердәй шыттырганын аңлап, сүзне икенчегә борырга ашыкты:

– Ярар, аларны бер иркенләп сөйләшербез әле. Безгә, Ишморза дус, берәр ярты табып утырырга иде, – диде.

– Ярты?! – Ишморза шаккатты. – Каян табасың аны?

– Ну, юкка аптырама, Ишморза дус! – Мәснәви якташының беркатлылыгына аптырый, шул ук вакытта куана да иде. – Акчаң гына булсын, монда водородный бомба да табып була!

– Акчасын табарбыз да ул! – Ишморзаның күзләре ныграк яна башлады.

– Тапсаң, калганын – үзем!

Ишморза матрас ертыгына кулын тыгып, акча чыгарды. Ул да тормышның рәтенә төшенә башлаган иде, иреккә чыгып йөргән кеше аша акча җибәргәннәр иде.

– Хәзер үк табасыңмы?

– Хәзер үк булмый инде, тик табарбыз. Башта мин обстановка белән танышып алыйм.

– Син бик сузма инде алай булгач. Тик аны кайда эчәсең, анысы бер бәла булыр әле.

Мәснәви кычкырып көлеп җибәрде:

– Анысына кайгырма, башта теге мәсьәләне хәл итәргә кирәк: безне аерып куймасыннар.

– Да, анысы шулай шул.

– Беләсеңме, без иртәгә үк начальникка приёмга язылабыз. Шунда икәүләп барып аңлатабыз. Монда инде икебезгә дә «тише воды, ниже травы» торып сөйләшергә туры киләчәк.

Шулай килештеләр. Утырып, гариза яздылар да контролёр аша колония начальнигына җибәрделәр. «Мөмкин булса, ашыгыч», дип өстәделәр.

Начальник «подельник»ларны иртәгесен үк чакыртты. Мәснәви – алдан, Ишморза арттан керде. Керделәр дә мескен генә кыяфәттә күзләрен башлыкка текәделәр, сүзне Мәснәви башлады. Чынлап та телгә оста икән, Ишморза сокланып тыңлап торды. Үзенә калса, ышандыра алмас иде, якташы белән очрашканга тагы да ныграк куанды. Дураклар, сугышып йөргән булдылар.

– Гражданин начальник, үзегез аңлыйсыз, теге вакыт бөтенесе дә эчү аркасында ялгыштан гына булган. Без ару кешеләр ул, ышанырсыз. Үзегезгә бер ярдәмче булырбыз. Калдырыгыз инде бергә, – диде. – Зинһар, мине икенче колониягә озатмагыз. Ул тик сездән тора.

– Ну что, татарин и башкир, чтобы подружиться надо было за решётку попасть, да? – Начальник мыскыллы елмайды.

– Век живи, век учись! – диде Мәснәви. И, теле дә теле! Начальник моның җавабын ошатты, үзенчә мәрәкәләп өстәде: «Дураком помрёшь, да?» Шуннан җитди төс алды: «Ладно, посмотрим», – диде.

Болар чыктылар. Биләмә буйлап бераз тын бардылар.

– Тәгаен әйтмәде бит әле, – дип пошынды Ишморза.

– Соң, шуннан артыгы ни кирәк? Алдыңа җәелеп төшмәс инде. Начальникның «посмотрим» дип әйтүе «эшләрмен» дигән сүзе була ул.

– Алайса, син тегене ашыктыр инде. Юарга кирәк бит.

Ишморза алдында Мәснәвинең абруе нык үсте хәзер. Ярый очраштылар әле, «бер яманның бер яхшысы» дигәннәре шушыдыр.

**4**

«Подельник»ларны аермадылар. Өч-дүрт көн кыңгыр-кыңгыр карап йөрделәр дә тынычландылар.

Атна үтте, болар бөтенләй кыюланып китте. Бер көн цехта Мәснәви дусты янына килде дә терсәге белән төртте. Ишморза нидер сизенеп, тегеңә текәлде. Дустының зәңгәр күзләре мәченеке кебек ялтырый.

– Әллә булдымы? – дип пышылдады Ишморза. Мәснәви төрмә киемен сиздермичә генә ычкындырды да итәген күтәрде; эчтә чалбар каешына кыстырылган яшел шешәнең сары башы алтындай елтырый иде.

Икесе дә тынып калды. Ишморза үз күзенә үзе ышанмый тора: төрмә эчендә аракы! Мәснәви канәгать. Әйләндергәләп карады, шуннан бөке тирәсеннән иснәп алды. Шешә нык бикләнгән булса да, исе килә, май чүлмәге тышыннан билгеле дип, юкка әйтмәгәннәр.

– Аракы-ы... – диде Ишморза, авызын ерып. – Каян алдың?

– Эчеп җибәр салганын, сорама каян алганын... Кая, бир әле! – Мәснәви шешәне кире алды.

– Шушында гына җибәрәбезме әллә?.. – Ишморза һаман үзенә урын таба алмый аптырый иде.

– Ресторан эзләп, Уфага китеп булмый инде! – Мәснәви шешәне ыргытып җибәрде дә тотып алды.

– Төшереп ватасың бит! – Ишморза ачуланып кычкырып җибәрде. Мәснәвигә менә шушы гына кирәк иде, тагы уйнатып алды да:

– Үзем ватылсам ватылам, шешә ватылмый инде ул! – диде.

Аракы табуы да, Ишморза башкортны үзенә каратып тотуы да аңа шундый ләззәт бирә иде.

– Кеше килеп, аппетитны бозмасмы икән соң?

– Нәрсә, озын-озакка сузып тормакчы буласыңмыни? Раз – и готово!

– Әзрәк сөйләшеп тә утырмагач... – Ишморза шулай диде дә, кайда утырырга соң, дигәндәй, тирә-якка каранып алды. – Ә стаканнар?..

– Их, син, Ишморза, нинди «зэк» стакан белән эчә инде аракыны! Бәлки, сиңа билле рюмка кирәктер? – Мәснәви чиста ак тешләрен шешәнең ялтырап торган калаена кадады. Икесе дә күзен ачылган шешәгә текәгән. Кайчаннан бирле көткән мәл якынлаша. – Йә, нәрсә өчен эчәбез? – Мәснәви күзләрен тантаналы ялтыратып, якташына карады.

Чынлап та, сорау сәер иде: дуслык өчен дияр идең, сугышып, төрмәгә утырган кешеләр, очрашу өчен дияр идең, очрашканнарына байтак вакыт үтеп китте. Ишморза кулын селтәде:

– Болай гына җибәреп куйыйк! – Үзе тәмам түземсезләнеп, шешәгә карады. Тегенең һаман сөйләнеп торуына ачуы килә башлады.

– Ярый, дай бог не первый, не последний раз! – Мәснәви «һуһ!» дип өреп куйды, башып артка җибәрде дә авызын ачты һәм шешәдән аракы коя башлады. Ул йотмый, ә бер савыттан икенче савытка бушаткан кебек кенә коя.

Ишморза карап тора, аптырый да, соклана да:ниләр генә белми бу татар. Әллә элек тә бер утырып чыкканмы икән? Борчыла башлады – коя да коя, бетерә бит! Кулыннан тотыйм дисә, йә төшереп җибәрер!

– И, җитәр, эчеп бетерәсең бит инде!

Мәснәви шушы сүзне көткән кебек тагы бераз койды да тураеп басты, шешәне баш бармагы белән тоткан урынын күрсәтте:

– Монда, брат, барысы да исәпләнгән!

Аракы, чынлап та, артык нык кимемәгән иде.

– Мин ни, яртысын койдың, дип торам! – дип елмайды Ишморза.

– Беләсеңме, дус, алкаш белән профессор спорить иткән, ди: кем тигезрәк бүлә! Профессор – мензурка, ә алкаш «булк-булк» белән исәпли, ди. Вот алкашныкы профессорныкыннан дөресрәк чыккан. Әйдә, җиффәр!

– Мин алай булдыра алмыйм.

– Алайса мин эчкәнне карап кына торасың инде! – Мәснәви көлеп җибәрде. – Йә столовый директорына барып, билле рюмка сорыйсың.

– Капыл эчсәң, исертер әле ул, ачлы-туклы йөргән кешегә күп кирәкмени... – Ишморза шешәне кулына алды. Ул Мәснәви шикелле коя белми, авызына капты да бозау шикелле имәргә тотынды. Бер-ике дә йота алмады, тончыкты. Кып-кызыл булды, күзеннән яшь чыкты. Аракы ялгыш юлга китте.

Мәснәви тиз генә шешәне тартып алды. Төшереп вата бит!

– Их син, башкорт, кымыз эчеп кенә яшәргә кирәк сиңа! – Ул кесәсеннән икмәк катысы чыгарды. – Шушыны чәйнәп йот!

– Әбрәкәйдә икмәк ашап тору гөнаһ инде... – Ишморза яшьле күзләре белән иптәшенә карады.

– Күп сөйләнмә, йот! Үтә ул. Алайса, аракы эчү дә гөнаһ!

Ишморза теләр-теләмәс кенә алды да тамагын кыра-кыра чәйнәргә тотынды. Шуннан аракы йотып куйды. Үтте, ахрысы.

Ишморза дөрес әйткән, аракы боларның башларына тиз китте: ашказаны хәмерне онытткан, ә үзләре ачлы-туклы йөргән кешеләр. Болар аңа пошмады, эчкәч исерәләр инде, шуның өчен тырышалар ласа. Аның каравы кәеф күтәрелде, тел чишелде – бер-берсен бүлә-бүлә сөйләшергә тотындылар.

Башта «цыган»ны акылга утыртулары белән мактаныштылар, суд хакында, тәфтишчеләрне искә төшерделәр. Шуннан сүз үзеннән-үзе былтыр көз боларның эләгешеп киткән мәлгә килеп терәлде. Шактый кызмача булсалар да, сүз шушында җиткәч, тел тотлыкты, бер-берсенә карамыйча гына тын тордылар. Икесе дә эчтән генә синең аркада эләктем шушы урынга дип уйлый иде кебек. Әмма берсенең дә сүз чыгарасы, мәҗлесне бозасы килмәде. Мәснәви ихлас кына итеп:

– Слушай, Ишморза дус, шул суверенитет дигәне нәрсә була соң ул? – диде.

– Әллә... – Ишморза көлеп куйды. – Килделәр дә әйттеләр, Уфага барырга кирәк, анда кеше күп булырга тиеш, диделәр. Синең тавыш шәп: «Башкортстан!», «Суверенитет!», «Долой!», «Отставка!» дип кычкырырга туры киләчәк, кеше нишли, шуны эшләрсең, диделәр. Утырдым да киттем, көз бит инде, эш беткән, бушлай Уфага барып кайтуы ни тора.

– Мин дә кешегә иярдем инде. Бераз салган идек. Минем күршедә бер елгыр гына адәм бар, шул котыртты. «Анда суверенитет бирәләр икән. Башкортлар үзләре генә алырга йөриләр, ди, әйдә!» – диде. Ярар, Ишморза дус, үкенмик, шушында килеп эләкмәсәк, бер-беребезне белми үлеп тә китәр идек. Шәп кешеләр булып чыктык бит!

– Анысы шулай... – Танышуларына, шушында килеп эләгеп, аракы табып эчеп, күңел бушатып торуларына Ишморза да канәгать иде. – Тик кайтасы килә...

– Кайтырбыз, беркая да качмас. Ирмен дигән кешегә төрмәсен дә күрергә кирәк аның, шулай түгелме? Кара әле, Ишморза дус, син башкорт бит, алай-болай, җырламыйсыңмы? Шул башкорт җырлары дип үләм бит мин!

Ишморза, чынлап та, җырлый, хәтта ару гына җырлый. Моң әле дә күкрәген ертып чыгып бара. Башка урында булса, әллә кайчан җырлап җибәргән булыр иде, монда тыелып кына тора.

– Болай җырлаштырам... – дигән булды ул.

– Чынмы?! Озын көйләрнеме?! Жибәр әле, дус, башкортның иң озынын!

– Монда ярамас ул, әй...

– Слушай, син никогда куркып яшәмә! Законга каршы эш эшләмисең бит, җыр җырлыйсың! Давай, түлке иң озынын!

Иптәшенең үзен шулай дәртләндереп торуы Ишморзага тәвәккәллек бирде. Аракы үзенекен эшләде – төрмә дә, әбрәкәе дә онытылды. Ишморза, нидер исенә төшерергә теләгәндәй, читкәрәк карап торды, кашлары язылды,

күзләре моңсуланды, еларга җыенгандай йөзен җыерды. Карашын бер такта ярыгына текәде дә җырлап җибәрде.

Таба-а-ак та гына, табак, ай, ак кагы-ыз,
Буранбайның язган хатлары-ы.

Сәер, сөйләшкәндә кешедән бер, ә җырлаганда бөтенләй икенче төрле тавыш чыга икән. Ишморзаның тавышы нечкәрде, нәфисләнде, гомердә уйламаган моң агыла башлады. Мәснәви зур, зәңгәр күзләрен текәгән дә ышанмаган кебек тора. Бар карашы: «Әйдә, давай, дәвам ит, өзә генә күрмә!..» – дип ялвара. Төрмә киеме кигән, чәчен такыр итеп алдырган бу байгыш кинәт кенә өстенә укалы җилән, башына камчат бүрек, аягына кызыл сафъян итек кигән буй җитмәслек затка әйләнде дә куйды.

Ишморза һаман җырлый. Кеше ишетмәсен дип, шым, сак кына башлаган иде да, җырны яшереп, куркып җырлап буламыни, «Буранбай» төрмә киртәсенә сыймады, тышка бәреп чыкты, күккә ашты. Ишморза тавышын шәбәйткәннән-шәбәйтә: җыр да, җырлау да сагындырган. Җитмәсә, онытылып китеп тыңлаучысы да бар. Җырчы өчен бер тыңлаучы булуы да җитә бит ул! Рәхмәт Мәснәви дустына, әле дә сүз чыгарды, югыйсә җыр онытылып бара иде.

Буранбайның язган хатын укып, ай,
Зар елыйлар авыл картлары-ы-ы...

Нечкә генә башланган җыр тамак төбеннән чыккан баһадирларча калын тавыш белән төгәлләнде. Хәтәр булды! Икесенә дә нык тәэсир итте. Моңы да, сүзләре дә.

Ишморза дустына карады. Ә теге зур күзләрен чылт-чылт йомгалап тора, керфекләрендә яшь тамчысы елтырый. Җырчының үзенең дә тамагына төер тыгылды. Икесе дә аска карадылар. Бераз торгач, Мәснәви дустын кочаклап алды.

– Их, Ишморза, кайларда әрәм булып ятмый безнең башлар! Дураклар инде!.. Зинһар, тагын берне җырла әле! Берне генә...

Ишморзага ялыну кирәкми иде инде, фатиха гына бирсеннәр. Чукынып китсен төрмәсе, «гражданин начальник»лары. Ул тамагын кырып алды да ярсуын баса алмаган ат шикелле тагы да көчлерәк тавыш белән җырлап җибәрде:

Кантон да гына, кантон килә,
Килгән кантоннардан какшадык.
Явыз кантоннарны куя да икән, әй,
Русия дә генәй дигән патшалык.

Җитте! Булды! Күңелләре тулган байгышлар бәдрәф ярыгыннан төшкән яктыга карап тордылар. Бер сүз әйтәсе килми, тик уйлар гына йөгерә. Мәснәви чалбар каешына кыстырган шешәне чыгарды, яктыга куеп, күпме калганын чамалады. Шуннан моңсу гына тавыш белән:

– Әйдә тагын берәрне салыйк әле! – диде. – Җыр өчен. – Алар, стакан-

фәлән булмаса да, гадәт буенча, «салыйк» дип сөйләшәләр иде. Аракының күпме калганын да, чамалабрак тотынып, озаграк сузарга кирәк икәнен дә аңлыйлар, берәр йотым гына йоттылар да, шешәне Мәснәви янә чалбар каешына тыгып куйды. «Закуска» дип, икмәк катысы кабып тормадылар, авызлары зәһәргә күнеккән иде.

– Бик хәтәр җырлар бит! Каян беләсең син аларны, Ишморза дус? – Мәснәви ихлас сорады.

– Халык чыгарган җырлар инде... – дигән булды Ишморза. – Кешедән ишетәсең дә җырлыйсың, һәрберсенең тарихы бар, тик мин аларны ныклап белмим. Буранбай патша заманында яшәгән, аны сөргенгә җибәргәннәр, шул кешегә шушы җырны чыгарганнар. Мин шул Буранбай токымыннан булам...

– Ну-у! – Мәснәвинең күзләре табактай булды. – Син шундый зур кешемени әле?!

– Төрмәдә утыргач, зур кеше буламыни! – Ишморза моңсу гына елмайды. – Әллә, картәтием без Буранбай нәселеннән, дип сөйли торган иде.

– Сөйләгәч, дөрестер инде, картлар белми сөйләми ул. Әнә бит, фамилияң да Буранбаев! Мин җырны бик яратам. Үзем дә җырлаштырам, дөрес, синең кебек үк түгел инде, мәҗлестә генә. Башкортлар җырчы халык бит инде!

– Мәснәви, давай, җырлашкач, җырлашыйк әле. Әйдә син дә берәр озынны...

– Һы... – Мәснәвинең күзләре янып китте, аңа да илһам килде. – Минем бик озыннан булмас инде. Алайса, бер авыз чылатып алыйк, – дип, берне йотып куйды. Шуннан Ишморза шикелле йөзен җыерып, әлеге такта ярыгына карады. Кинәт тәвәккәл тавыш белән кычкырып җырлап җибәрде:

Гори, гори, моя звезда-а,
Звезда любви, приветная-а!
Ты у меня одна заветная-я,
Другой не будет никогда-а-а!

Ул җырлый башлауга Ишморза әллә нишләп китте: каз тәннәре чыкты, маңгае җыерылып килде. Бу ни эш? Кем бу?! Татар дигәне рус булып чыктымыни?! Әнә бит, күзләре зәңгәр, чәче сап-сары, теле русча. Үзе дә рус! Әллә Ишморзаны, әллә Мәснәвине җен алыштырды?! Әллә исереп китеп, күзенә генә күренәме?! Әле генә шундый якын күренгән кеше бөтенләй икенче затка әверелде дә куйды.

Ә Мәснәви Ишморза кебек үк итеп кинәнеп җырлый бирде:

Умру ли я, и над могилою,
Гори, сияй, моя звезда-а-а!..

Җыр тәмам. Мәснәви, җырлап бетергәч, йә ничек дигәндәй, моңа карады. Ишморза беләә: җырчыны мактарга кирәк, һәр җырчы шуңа мохтаҗ.

Әмма ул һаман миңгерәп тора. Кем булды соң бу? Русмы, чукынган татармы?

Теге татарчалап: «Йә, ничек?» дигәч кенә, күңеленә җылы керде. Шулай да Ишморза аптыравын яшерә алмады:

– Нишләп русча җырлыйсың ул? Татарча җырлый алмыйсыңмыни?

– Кая сиңа җыр, сөйләшкәнгә дә рәхмәт әйт! Мин бит кечкенәдән Уфада үстем. Архирей жулигы!

– Өйдә дә русча сөйләшәсезме?

– Шулай инде, минем хатын да рус кызы!

– Ничек инде рус кызы?!

– Соң, рус түгел икән, марҗа! – Мәснәви елмайган булды.

– Балаларың да русмы? – Беркатлы Ишморза һаман аңламый иде.

Мәснәвинең түземе төкәнде:

– Әй, аптыраттың бит! Үзең әйтмешли, башымны катырма әле. Марҗадан тугач, рус була инде. Уфада тор да ещё! Мин әле ладно, анда татар белән татарның баласы рус булып туа!

Ишморза дустының кәефен бозмас өчен башкача ныкышмады. Бераз тын тордылар, тагы яртышар йотым йоттылар. Ишморза, онытылып киттеме, тагы сорады:

– Әй, марҗалар нинди була ул?

– Син нәрсә, марҗа күргәнең юкмы әллә?! Шул ук нәрсә инде!.. – Мәснәви ачу белән әйтте. – Сүзеңә караганда, башкорттан артыкны күргәнең юк, ахрысы!

– Нигә, минем бичә татар ул.

– Ә үзең миннән көлгән буласың!

– Всү-тәки дә татар рус түгел бит инде! – Ишморза җиңгән кеше кыяфәтендә әйтте.

– Анысы шулай... Ярар, болай да көйгән җанымны көйдереп торма әле. «Син марҗа» дигәнгә карап, ун ел торган хатынны куып чыгарыйммыни!

– Татар дип кимсетмиме соң үзеңне?

– Әйтеп карасын! Правда, башта бер абыйсы ычкындыргалый иде. Җилкәсеннән эләктереп алдым да моны: «А ну-ка, повтори!» – дидем. Шыр җибәрде. Шуннан соң берсенең дә авызыннан андый-мондый сүз чыкканы булмады. Ә болай хатын милләт аермый, аңарга лишь ир булсын. Ир булсын да, акча китерсен! Шулай, брат, менә син дә татарга каршы йөргән буласың, ә үзеңнең хатының татар булып чыкты.

– Кем каршы йөри, үзең килеп тотынгач, мин нәрсә!..

– Каян килеп тотынсын! Син үзен башладың! Мин бит сиңа ул вакыт шаяртып кына әйткән идем «башкорт» дип, син «татар» диден, шуннан китте инде. Ярар, Ишморза дус, судьялар очына чыга алмаганны, без икәү чыга алмабыз... Ә син ул татар кызын каян таптың соң? Сезнең якта башкортлар гына яши, диләр бит?

– Соң татарның таралмаган җире бармыни! Ә болай мин үзебезнең якныкын түгел, читтән барып алдым. Благовар районыннан.

– Благовар?! – Мәснәвинең күзләре тасрайды. – Кайсы авылдан?

– Белмисеңдер, Әрәмә дигән бер бәләкәй генә авыл ул. Елга буенда утыра.

– Белмәгән, ди! Ул бит безнең күрше авыл!

– Үзең әле мин Архирей жулигы дип мактана идең?

– Соң без бит Уфага күчеп кенә килгәнбез, мин кечкенә чакта. Әти-әниләр шунда яр башында ызба сатып алганнар. Телецентр тирәсендә ярда

ызбалар утыра бит, шунда инде. Ә син ул Әрәмәгә ничек барын чыктың? Кода да булып чыгарбыз әле, минем анда туганнар да бар!

– Бәлки, – дип елмайды Ишморза. – Без ни, корылык елны Благовар ягына салам әзерләргә барган идек, колхозга. Шунда бер әби белән бабайда тордым. Матур гына кызлары бар иде, кәләш иттем дә алдым... – Ишморзаның йөзләре яктырып, күзләре нурланып китте, ничек итеп кызны ярәшеп йөргән, кәләш итеп алып кайткан чакларын исенә төшерде булса кирәк. Моны Мәснәви дә тойды, тирән сулап куйды да:

– Да, брат, бар иде шәп чаклар... – диде. – Менә, Ишморза, земляк кына түгел, кода да булып чыктык. Ә ул синең хатының телен ташлаган, үзең кебек кара башкорт булып беткәндер бит инде. Син бит бик каты сөйләшәсең, телеңне аңлап бетереп булмый кайчакта.

– Ташлатырсың сезнең татардан телен! Авылда берүзе татарча сөйләшеп йөргән була. Безнең башкорт кына ул арага бер татар килеп күрендеме, телен бозып каңгыра. Күрерсең, минем Нәзифә үлгәнче үз телендә сөйләшәчәк. – Ишморзаның күз алдында һаман хатыны тора, күрәсең, авызы ерык. – Шәп ул минем кәләш, татар булса да!

– Нигә «татар булса да»? Татар чем хуже?

– Ай алла, юкка-барга бәйләнергә генә торасың? Болай гына әйтәм инде, гадәт буенча. Татарның кеме юк та, башкортның кеме юк! Син үзең дә чын татар түгелсеңдер әле: йә керәшен, йә рус токымыннандыр. Бичәң – рус кызы, фамилияң – рус!

– Каян рус булсын, ди! Кәлмәт дигән карт булган, без шуннан таралып киткәнбез. Белсәң, Кальметовлар барысы да дворяннар, дворян нәселеннән!

Ишморза бәдрәфне яңгыратып көлеп җибәрде:

– Дворяннар?! Нигә, ул Кәлмәт карт Ленинградта яшәгәнмени?

– Нигә, имынны Ленинград кына димәгән, безнең Благоварда да булган ул дворяннар. Үзләре татарлар. Әле күпне белмисең икән!

– Ә дворян булгач, нигә унҗиденче елда атмаганнар сезне? – Ишморза тегенең сүзләрен мәрәкәгә ала: йә, гадәтенчә, шыттыра, йә үзе надан. Ә Мәснәви аның саен тукый.

– Во-первых, атар өчен мин ул вакыт булмаганмын, во-вторых, ул Кәлмәт картларның исеме генә морза, ә үзләре бик ярлы булган. Шуңа аларны «чабаталы морза» дип йөрткәннәр. Шундый сүзне ишеткәнең юкмыни бер дә? Менә, Ишморза дус, икебез дә зур кешеләр булып чыктык: син – Буранбай, ә мин – морза токымыннан!..

«Кодалар» икесе дә елмаешты, шул туган-ырулыкны юар өчен дип, Мәснәви чалбар каешындагы яшел шешәне алды. Аракы беткән иде инде.

Ишморза да шешәне алып, әйләндереп карады да, буш икәненә инангач, шешәне идәндәге зур ярыкка ыргытты.

– Нишлисең?! – Мәснәвинең күзләре шакмак булды.

– Беткән бит...

– Бетсә соң, монда посуданың ничек кадерле икәнен беләсең бит!

– Куй әле, йә шешәне каян алдың дип таптырырлар... И, сәгать ничә булып китте икән?

Мәснәви сәгатенә карады:

– Анаңны! – Шулай диде дә кулын селтәде: – Көтәрләр...

– Ярыйсы гына башка китте әле бу...

Болар әбрәкәйдән чыкты. Чыктылар да шып туктап калдылар: цех алдына халык җыелган. Барысы бер үк төрле киенгәнгәме, бертөсле күренгән адәми затлар Ишморза белән Мәснәвигә баккан да авызларын ерып карап торалар. Болар күренүгә дәррәү кычкырып көлеп җибәрделәр.

Күрәсең, күптән күзәтеп торганнар.

– Ресторан ябылды! – диде берсе.

– Вот артисты, сначала подрались, а сейчас песни поют! – Тегеләр тел чарларга тотынды.

«Игътибар итмә!» – Мәснәви тыныч кына фәрман бирде дә шәп-шәп атлап, цех ягына китте. Ишморза аның артыннан иярде. Барып җиткәч, берсе тагы төрттереп маташкан иде дә, Мәснәви: «А тебе завидно, да?!» – дип җикергәч, теге шым булды. Ярый әле, Мәснәви дусты бар. Кала кешесе шул, кирәк чакта телгә аптырамый.

Тегеләр башкача эндәшмәде, «зэк»ның хәлен «зэк» аңлый.

Мәснәви белән Ишморзаның эшләре көйләнде хәзер. «Вор»дан котылдылар, колониядә абруйлары үсте, хәзер аларга ихтирам белән генә түгел, көнләшеп тә карыйлар. Якташлар буш вакытларында гел бергә. Үз телеңдә сөйләшерлек бер генә кеше булганда да, ул кадәр ят итеп тоймыйсың икән үзеңне! Шушындый чакларда бигрәк кадерле бит ул үзеңчә сөйләшү!

Шулай да төрмә – төрмә инде, бик эчендә генә тоталар, көненә әллә ничәмә тапкыр саныйлар – иректә малны да санаса, аена бер саный. Үзең кебек адәмнәргә «гражданин начальник», «осуждённый Буранбаев» дип торырга кирәк. Шунысы бигрәк җанны кимерә. Кайчак шушы бәндәләрне иманга утыртып аласы килсә дә, ни кылмак кирәк, телеңне тешләп түзәсең. Андый чакта Ишморза якташына барып зарланып ала. Ә тегенең исе дә китми!

– Төкер син шуларга! Мәңгегә кермәгән лә бу тишеккә! Иреккә чыгыйм әле, сөйләшә белермен!

Ишморза шулай көяләнеп йөри торгач, үзалдына әллә ниләр уйлап чыгара. Менә, имештер, төрмәдән исән-имин котылып, авылында син дә мин яшәп ята. Бөтенесе дә онытылган, тормыш моңа кадәр ничек булган, шулай бара. Имештер, Ишморза утынга дип, Ирәндек ягына юл тота. Көз, пычрак вакыт. Карамалы чокырын үтәм дигәндә, батып утырган зур машинаны күреп ала. Янында әллә нинди хәрби кеше. Тракторга каршы килә. «Машинаны чыгарыш әле! Бер ярты бирербез!» – ди. Ишморза ни күзе белән күрсен, алдында шушы колония начальнигы тора. Теге дә аптырап кала, хәтта каушап төшә. Кайчандыр мескен генә кыяфәттә «осуждённый Буранбаев» дип торган кеше ничек гөрләтеп яшәп ята! Ә бу шуңа йомышка килде. Менә бит дөньялар!

Тегеләр, бактың исә, халыктан бәрәңге җыярга килгәннәр дә кайтырга дип кузгалганда батканнар. Икенче юл барлыгын белмәгәннәр. Ишморзага ни, эһ тә итми, тарттырып чыгара боларны. Эчкерсез кеше ул, теге вакыттагы ачулары онытылган. Хәтта аларны үзләренә кунакка чакыра, кешене ничек итеп төнгә каршы чыгарып җибәрәсең инде. Болар ризалаша. Ишморза әллә кем булып китә. Даны ни тора бит: Ишморза

үзен төрмәдә бикләп торган адәмнәрне алып кайткан! Дуамал булса да, кара эчле түгел ул.

Башта дөньясы белән таныштыра – ихатасын, абзарын, келәтен, гаражын күрсәтә. Шуннан хатынына мунча ягарга куша да тегеләрне йортына алып керә. Бераз ял иткәндәй булгач, кунаклары алдында бер сарыгын егып суя. Бишбармак пешерәләр, күршеләрдән әҗәткә алып булса да, аракы юнәтә. Мунча кереп чыкканнан соң, төне буе кунак булалар. Эчеп алгач, колония начальнигы моны мактап бетә алмый: «Молодец Буранбаев, син тегендә дә үрнәк булдың!» – ди. Иртән инде Буранбаев аларны олы юлга кадәр озата бара.

Менә шулай үч ала ул үзен ике ел биктә тоткан кешеләрдән.

Бер көнне Ишморза шушы хыялларын Мәснәвигә сөйләде. Тегесе чәчрәп чыкты:

– Ордым шуларны, сыйлап торырмын тагын! Тотсыннар!.. Битләренә төкереп китәр идем! Аз издеваться иттеләрме!

Ишморза бәхәсләшеп тормады, болар хыял гына бит. Әле котылып чыгу өчен ике ай ярым вакыт бар. Гадәттә, өй якынайган саен юл озынрак күренә, кайтыр көн җиткән саен вакыт акрынрак үтә...

**5**

Никадәр генә хыялланмасыннар, дусларның икесен бер көнне азат итмәделәр. Хәтта искәртеп тә тормадылар, Ишморзаны чакырттылар да: «Буранбаев, син бүгеннән азат – тулы хокуклы граждан! Котлыйбыз!» – диделәр. Кара, сөйләшүләре бөтенләй икенче, болар да адәмчә була белә икән! Тиешле акчасын бирделәр, башка җинаять кылмаска әйтеп, матур тормыш теләп чыгып китәргә куштылар.

– Гражданин начальник, ә Кальметов? – диде Ишморза.

– Хәзер инде «гражданин начальник» түгел, «иптәш начальник», – диде офицер.

– Без бит Кальметов белән «подельниклар», бер үк эш буенча бер үк срокка хөкем ителдек, гражданин әй..., гражданин начальник...

– Беләсеңме, Буранбаев, ишек ачык чакта шылып кал. Калганы... – Иптәш начальник елмайды: – синең эш түгел.

Ишморзаның борыны салынды, бөтен хыяллары җимерелде. Котылгач, алай итәрбез, болай итәрбез дип, әллә нинди планнар корганнар иде, менә сиңа мә! Ни кылмакчы булалар икән, әллә Мәснәви бер-бер хәл кылып ташлаганмы? Ул-бу булса, ишетелер иде. Ни хәл итсен, теге «иптәш начальник» әйткәнчә, ишек ачык чакта чыгып шыларга кирәк иде.

Ни хикмәт, кайчан котылам шушыннан дип, күпме хыялланды, чыккан иде – ятимсерәде дә китте. Төенчеген тотып, төрмә капкасы төбендә торды, тегеләй әйләнде, болай әйләнде, аңа сүз кушу түгел, игътибар иткән кеше дә юк, теләсәң нишлә. Хәтта кайтасы да килмәгән кебек. Кайтасы килә килүен, тик әкияттәге кебек күз ачып йомганчы арада ишегалдында утырсаң иде ул. Ә ялгызы гына олы юлга кузгаласы килми. Бердән, дустыңны ташлап калдырган кебек, икенчедән, бергә кайтуы күңеллерәк. Икәү ышанычлырак та була, барасы юл байтак бит әле.

Ишморза поездга утырырга ашыкмады, Мәснәвине көтеп карарга

булды. Бәлки, «подельниклар» дип, бер юлы чыгармаска уйлаганнардыр дип, төшкә кадәр шушы колония тирәсендә йөрештерде, капкадан күзен алмады. Инде дә булмагач, колониядән унбиш чакрым тирәсендәге бистәгә юлланды. Моннан йөри торган автобус белән китте.

Башта ул ашханәгә кереп туйганчы ашады. Барынча иң затлы ризыкларны алырга тырышты. Ашап туйгач, әллә кем булып, урам буйлап китте. Бөтен халык аңа карыйдыр, менә иректә кеше китеп бара, дип сокланадыр сыман күренде. Арурак хатын-кызларны баштанаяк тикшереп үтте, кайберләренә сүз дә кушты. Үзе эчтән генә аптырап та куя: бер дә онытылмаган да, сүзе табыла бит! Әмма тегеләр Ишморзаның сүзенә җавап бирергә ашыгып тормады. Ә Ишморза гарьләнмәде, кирәгегез бар иде, менә Баймакка килә калсагыз, елмаерсыз да, мин сезнең кебек үтеп китәрмен ул чакта, дип горурланды.

Вакыт кына үтми иде. Ул кибеткә кереп, күп итеп ашарга, әбиләрдән кыйммәт хакка аракы алды. Очрашкач, бәйрәм итәргә кирәк бит азатлыкны. Төнне монда үткәрергә туры килер дип, автобуска утырды да бистәдән читкә чыгып китте. Бер тау битләвендә төшеп калды, тирә-юньне тикшереп чыккач, җәелеп төшеп йокларга ятты. Көн җылы, август ае, иркен дөньяда бер туйганчы йокласын әле! Куркып торасы юк хәзер!

Ишморза озак һәм каты йоклады. Әмма «зэк» гадәтенчә иртәнге алтыда уянып китте. Башта аптырап торды, үзенең кайда икәнен абайлагач, иркен сулап, тамак ялгап алды. Һай, кызык икән иректә тормыш, ни теләсәң, шуны эшлисең, хәтта бераз җайсыз да кебек. Нидер җитешми.

Ул бистәгә барды да яңадан колония ягына китте. Үзе китеп бара, үзе аптырый: чыгуын чыкты иреккә, ә дөнья ят! Менә бистәсе, урманнары, елгасы, машинасы, хәтта кешеләре дә. Иректә дөнья – ят, ә колония – якын. Никадәр генә хәсрәтләр кичермәсен, әле ул шушы ят дөньядан үз төягенә кайтып барган кеше сыман атлый. Анда – кешеләр. Төрлесе бар: ерткычы да, аруы да, дусты да, дошманы да, ачык күңеллесе дә, җәзалаучысы да, әмма, ни дисәң дә, кешеләр. Менә шулар белән ике ел гомерен үткәреп ташлады бит әле.

Ишморза бер көн иректә, әмма букчасын тотып, һаман колония тирәсендә бөтерелә. Эшкә килүчеләрнең кайсылары аптырап, ә төсмерләгәннәре елмаеп, таныш шофёрлар теләктәш караш ташлап үтеп китте. Әмма берсе бер сүз эндәшми – гадәт, тәртип шундый.

Ниһаять, Ишморза үзләренең цехына килеп йөри торган шофёрны очратты. Үзе дә аңлап тора икән. Ишморзаны күрү белән: «Дустың иртәгә чыга. Монда икәнеңне әйтермен!» – дип кычкырып китте. Ишморзаның эченә җылы йөгерде. Тагы бер көн көтәсе булса да, өметле булгач, эш икенче.

Ул янә бистәгә китте. Иректә төрмәдәгегә караганда да кыенрак кебек – вакыт үткәреп булмый. Китап сатып алды, укырга күңел төшми, газетасын әйләндергәләп карады да ыргытты, вакыйгаларны көннекен көнгә белеп бармагач, бүгенгесе генә кызык түгел. Икенче көн инде үзе белән өч шешә йөртә. Юк вакытта аракы дип исе китә иде, булгач, эчәсе килми.

Шешәгә карый да әбрәкәйдә эчеп утырганнарын исенә төшерә. Үзенчә күңелле вакытлар иде. Бүген ул хатын-кызга да күз салмый, тегеләр

үзалдына йөреп яткан тере зат ише генә күренә. Күрәсең, тормышның үз агышымы, тәртибеме, калыбымы бозылган, шуңа бернигә дә күңел ятмыйдыр дип фәлсәфә итте Ишморза. Адәм баласына рәтле яшәү өчен ниндидер кагыйдәләр, законнар, хәтта корып куелган киртәләр кирәктер.

Ниһаять, бәләкәй ишек ачылды да эчтән кулына букча тоткан кеше килеп чыкты. Ул ялт-йолт тирә-якка карады – Ишморзаны эзли, теге шофёр: «Дустың сине көтеп йөри», – дип әйткәндер.

Менә күреп алды:

– Ишморза! – Бер ел очрашмаганнармыни, бер-берсен кочаклап алдылар. Шуннан күрештеләр, тагы кочаклаштылар, аркаларыннан кагыштылар, бер берсенә карашып тордылар. Егет белән кыз очраштымыни! Хәер, аңардан да кадерлерәк, якынрак әле алар.

– Нәрсә булды? Нигә алай тоттылар? – диде Ишморза.

– Ах, җиде буын аналарының җиде йөз җитмеш җиде ел ятып черегән кабер такталарын орыймнар! – Мәснәви бөтен белгән яман сүзләре белән тегеләрне сүгәргә тотынды. Ләззәтләнеп, кинәнеп сүкте. – Менә кайтыйм гына әле, Верховный Совет председателенә керәм! Кирәкләрен бирдерәм мин аларның! – Мәснәви әллә кайда төптә утырган төрмә башлыкларын сүгә, ә Ишморза шушыларга ышанмый тора: кара, курыкмыйча, бөтенесен дә әрли. Хөррият, суверенитет дигәне шушыдыр!

Чукынып китсен ул колониясе да, колония начальниклары да, ярар, барыбер чыктылар, котылдылар, морадларына ирештеләр.

– Сине көттем, ялгызымның гына кайтасы килмәде! – диде Ишморза.

– Көтеп торуыңны гомеремдә дә онытмам, Ишморза дус! Бик зур рәхмәт инде.

Минем үземә дә бик авыр булыр иде! Шту син, күз алдыңа китер! – Мәснәви лач итеп колония ягына төкерде дә дустының иңбашыннан кочаклап алды. – Киттек, дус, без хәзер – вольный птица!

Башкорт Ишморза белән татар Мәснәви бик канәгать, хәтта тәкәббер кыяфәттә акрын гына басып, бистә ягына киттеләр.

**6**

...Поезд Уфага иртән килеп җитте. Бер купеда икәүдән-икәү генә баручы такыр башлы адәмнәрне проводница сәгать ярым алдан уятты. Үтеп китә күрмәсеннәр, котылыйм, дигәндер. Әллә нинди котсыз затлар, икесенә дүрт билет сатып алганнар да купеларына башка берәүне дә кертмичә, үзләре генә кайттылар. Кеше дә кертмәделәр, чыгып та күренмәделәр, купеларыннан тәмәке дә, аракы исе генә аңкыды. Әйтсәң, колакларына элмәделәр. Тавыш күтәрергә курыкты.

Станциягә җитәр алдыннан ул тагы ачкычы белән шакылдатты:

– Уфа!

Уфа икән, Уфа инде, бу ике такыр баш, теләр-теләмәс кенә урыннарыннан торып, мыштыр-мыштыр әзерләнергә тотынды. Хәер, әзерләнәсе дә түгел инде, киемеңне киеп, букчаңны алдыңмы, бетте. Юлдашларның кәефе шәп түгел. Аптырарсың, Уфа дип кайчаннан бирле көттеләр, килеп җиткәч, тәрәзәдән дә карыйсылары килми.

Ә юлны күңелле үттеләр. Төрмәдә тапкан акча җәл түгел дип,

ашарга да, эчергә дә мул алганнар иде. Кайчан тагы шулай туры килә?! Кайткач, хатыннары ашатыр әле, кәсепкә бармаганнар. Әлбәттә, тиз генә аерылышмаслар, Мәснәвидә ике-өч көн кунак булырлар, бер көн бакчасына барып ятарлар, шуннан дустының марҗа бичәсен алып, Баймакка китәрләр. Шулай килештеләр. Мәснәви, минем өй иркен, бер атна ят, дигән иде дә, Ишморза, килешмәс, хатын ачуланыр, диде.

Гомумән, үзләренең кайтып төшүе Уфа өчен бер олы вакыйгага әйләнер кебек иде Ишморзага. Оркестр белән каршыламасалар да, перронда чәчкәләр, күчтәнәчләр тотып каршыларлар. Баймактан да килерләр. Азатлык өчен газап чигеп йөрүчеләр бит – революционерлар! Төшкәч, кочаклашып күрешерләр, хәл-әхвәл белешерләр, шуннан машиналарга утырып чыгып китәрләр. Мәснәви ни уйлагандыр, башкорт Ишморза шушылай күз алдына китерде үзләренең туган җире белән очрашуын.

Поезд туктады. Чынлап та, йоклап кала күрмәгез, дигәндәй, вагоннар кинәт, боларны селкетә биреп туктады. Ашыгасы түгел, берәү дә көтми аларны, хәбәр итеп тормадылар. Аның кайгысы да булмады, туйдан кайтып килмиләр.

Болар вагоннан иң соңгы булып төштеләр. Җиргә баскач, кояшка күзләре чагылгандай, йөзләрен җыерып, тирә-якка карандылар. Ишморза проводницага рәхмәт әйтеп хушлашкан булды, ә теге җирәнгән кыяфәт белән читкә борылды. Ай, чукынсын! Ике байгыш, букчаларын тотып, акрын гына перрон буйлап киттеләр.

Уфа – һаман да шул Уфа, станциясе дә шул ук, һәркемнең үз гаме, берсе ашыга, берсе көлә, берсе кочаклаша, дигәндәй. Башка халык шулай, тик боларның гына кәеф юк, һәр нәрсәгә ачулары килә.

«Подельник» дуслар бүген сөйләшмиләр, урман җанварлары шикелле карашлары белән генә аңлашалар. Менә су эзләп киттеләр. Алдан – Мәснәви, артыннан кара күзләреннән ачу чәчеп Ишморза килә. Авыз кипкән, иреннәр бер-берсенә ябышкан, сөйләшү түгел, ачарлык та рәт юк. Әмәлгә калгандай, суның әсәре дә күренми. Әллә бик иртә булганга китереп җиткермәгәннәр, әллә, гомумән, сатмыйлар, үләм, дисәң дә, бер тамчы су табылмас. Бер җирдә автомат эшли, аңа Ленин мавзолеена кебек чират.

Мәснәви төрмәдәш дустын бәдрәфкә алып килде. Монда да уңмадылар, ишеккә «Уборка!» дигән язу эленгән. Әмма күзе тонган Мәснәви язуга игътибар итмәде, ишекне ачты. Хуҗасы якын гына йөргән икән, ажгырып килеп тә җитте:

– Не видишь что ли, уборка!

– Мамаша, нам только попить!

Теге тавышын күтәрде:

– Дам я вам попить! Что вам здесь, ресторан?! – Вокзал кешеләре усал була инде, телгә аптырамый.

Мәснәвинең зәңгәр күзләре куркыныч елтырады:

– Ты, мамаша, потише! Мы только освободились! – Шулай диде дә эчкә кереп китте. Ишморза тын гына артыннан иярде. Бер йотым су өчен башны салырга да була.

Болар керделәр дә, кулларын да юып тормыйча, кранны ачып, кушучлап

су эчәргә тотындылар. Әмма болай гына туярлык түгел, теге вакыт шешәдән имгән шикелле краннан гына эчә башладылар.

Эчеп туйганчы, алларында милиционер пәйда булды:

– Чты вы делаете, граждане?

Дуңгыз, теге хатын әйткәндер инде! Ух, шул вакытта Мәснәвинең күзен күрсәгез! Эткә ташланырга торган мәчемени!

– А ты не видишь?!

Әмма милиционер көч үзендә икәнен белә, вокзалда мондыйлар еш очрый, тыныч кына итеп:

– Ваши документы? – диде.

– На! – Мәснәви түш кесәсеннән кәгазь чыгарды. Ишморза да тавыштын чыгармыйча гына кәгазен алып бирде.

– Чыккансыз икән, тизрәк ычкыныгыз, йөрмәгез монда адәм куркытып! – Милиционер татар булып чыкты.

– Мәснәви, әйдә киттек! – Ишморза Мәснәвинең җиңеннән тартты. Ә теге ярсуыннан сүз дә әйтә алмый иде, әмма Ишморзага карышмады.

Ирекле затлар вокзал алдына чыкты. Шаккатканга юл кайда, дигәндәй, бераз карашып тордылар. Сәер, дөнья гөж килә, ә бу икәүнең күңелләре буп-буш.

– Безгә барсак инде, бик ерак диярсең... Мин Машиностроительный артында торам, – диде Мәснәви. – Хатын да өйдә юктыр инде...

– Юк, хәзер үк билетка басам. Җәй безнең Сибай поездына кеше күп була, – диде Ишморза.

– Бәлки, билет алгач, килеп чыгарсың. Поездың кич китә, дисең бит?

– Ярар, карармын.

Тагы бераз тордылар. Болай гына аерылышу уңайсыз сыман, әмма төрмә дуслыгының тәмам, ә кичәге сөйләшүләр, биргән вәгъдәләрнең эчкәндә сөйләшкән сүз генә икәнлеген, хәзер үзләре алдында элекке, шулай да бераз ят тормыш торганлыгын икесе дә аңлый иде.

– Ярар, Ишморза дус, бигайбә алайса. Уфага килә-китә калсаң, кагылмый китмә. Хатының белән кил, сөйләшеп утырырбыз.

– Йөреп ятыла бит инде, бәлки, килеп тә чыгылыр әле. Баймак ягына юлың төшсә, туры безгә кил. Авылның исемен беләсең.

– Чты син, әбизәтелно!

– Ярар, Мәснәви, имин кайтып җит, хатыныңа сәлам әйт!

– Ладно, давай!

Башкорт Ишморза белән татар Мәснәви сүзсез генә кул биреште. Нигәдер күзләрен яшерделәр, шуннан эндәшми генә икесе ике якка китеп бардылар...

# ДАСТАННАР – ҮТКӘННӘРНЕҢ САБЫР СУРӘТЕ

Татарда дастан барлыкка килү тенденциясе һәм эпик иҗатка омтылышның тамырлары бик тирәндә. Халык күңелен тетрәндерерлек вакыйгалар һәрвакыт зур иҗат булып бәреп чыга һәм күләмле җитди әсәр буларак танылa, ә дәүләт тоткан татарның озын-озак тарихы андый вакыйгаларга бик бай. Татарларның эпос-дастанлы халык булуы әнә шул тарихка барып тоташа. «Түләк», «Бүз егет», «Кузы Көрпәч», «Идегәй», «Кыйссаи авык», «Кыйссаи Сәкам», «Гыйсә улы Амәт», «Шаһсәнәм һәм Гариб», «Хурлуга белән Һәмра», «Каһарман Катил», «Кисекбаш кыйссасы», «Чура батыр хикәяте», «Күр углы», «Таһир белән Зөһрә», «Йосыф китабы», «Сәйфелмөлек», «Ләйлә белән Мәҗнүн» – болар бәяләп бетергесез гүзәл дастани мирасыбыз үрнәкләре.

Татар дастаны «эпос» дигән төшенчәне дә, «хикәяләп бирү», «тарих сөйләү» дигәнне дә, «поэма» дигән мәгънәне дә үз эченә ала. Дастанда һәрвакыт каһарман була. Халык телендә аларны «батыр» дип атау бар. Зур батырлар зур вакыйгалар барышында туа. Батыр ул – халык өчен әһәмияте биниһая вакыйгаларда кыю катнашучы көрәшче, гадәттән тыш батырлыклар кылучы ир-егет. Мондый батырлар ил азатлыгы, халык бәхете өчен югары идеяләрне тормышка ашырам дип көрәшеп яшиләр, көрәш юлында йә стихияле табигать көчләре, йә идарәче түрәләр, йә аерым бер кеше, йә язмыш белән каршылыкка кереп, гадәттә, һәлакәткә дучар булалар. Менә шундый гадәттән тыш көчле рухлы батырларның тууы, үсүе, көченең ташып торып, куәтен илен-халкын, сөйгәнен яклау-саклау максатында куллануы, тарихи җирлеккә ия зур вакыйгалар эчендә акылы-куәте белән массадан аерылып торуы, зур эшләр башкаруы хакында нейтраль формада сөйләп-хикәяләүне җырлар, сарын, тулгаулар, елау-сыктау, назымнар кебек тезмә юллар белән аралаштыру яисә тоташ шигъри тезмәдә бирү дастан дип атала. Дастанда алга хис-кичерешләр түгел, ә халык тормышының эпик картинасы чыгарыла, сурәт һәр детальдә сәнгати югарылыкны саклап, сабыр гына, хәтта фаҗигаи күренешләргә дә мөнәсәбәтне ачыктан-ачык белдерми генә тудырыла. Шушыларның барысын да исәпкә алып, фольклор кануннарын тиешле дәрәҗәдә үтәп оешкан катлаулы бер әсәр эпос-дастан була. Татар дастаны батырлык темасы белән бергә ике гашыйкның мәхәббәт тарихын да бәян итә, төзелеше белән тоташ шигъри, чәчмә яисә катнаш характерда була.

Эпосны халыкка җиткерүче кешеләрне төрле халык төрле исем белән атап йөрткән. Борынгы греклар аларны аэдлар дип атаган, борынгы һинд эпосын әйтүчеләрне сут яки кушелавлар дип йөрткәннәр, Көнбатыш Африкада бу төр шөгыль ияләре гриотлар, Көнбатыш

Европада шпильманнар дип аталган, рус халкы үзләренең сказительләре белән горурланган, украиннарның кобзарьлары булган. Монгол телле бурятларда мондый осталарны улигершин яисә гесершин, ә алтайдагы төрки булмаган кайбер халыкларда хайджи дип атау кабул ителгән. Эпос-дастан таратучыларның төрки халыкларда да исемнәре төрле: олонхосут, шагыйрь, җомакчы, ашуг, бахшы, сәсән яки кобайырчы, акын, манасчы, кыйссахан, кайчы һ.б.

Эпосны телдән әйтү күчмә тормыш шартларында озаграк яшәгән, мөселман культурасын соңрак үзләштергән яисә ислам тәэсирен бөтенләй кичермәгән халыкларда тотрыклы сакланган. Халык шигыренә нигезләп, зур-зур вакыйгалар турында тоташтан сөйләп бирү фольклорда дастан (эпос) жанры булып ныгыган. Тугандаш төрки һәм төрки булмаган халыкларга хас җыраулык-чичәнлек татарларның халык иҗатында борынгыдан бик киң таралган.

Татар чичәне туй-мәҗлесләрдә көтелгән кунак булган, төрле вазгыятьтә оста сөйләве белән җәлеп иткән. Кагыйдә буларак, ул – үзе яшәгән төбәкнең оста телле, мәгълүм мөхтәрәм кешесе, фольклор музыка коралларында да уйный белгән. Н.Исәнбәт «чичән» сүзенең халыкта сүз остасы мәгънәсендә йөрүен әйтә, казакъларны, башкортларны мисалга китереп, «соңгыларда токтарсыз рәвештә җыр чыгарып әйтә алучы берничә халык шагыйренә сәсән исеме» бирелүен искә ала һәм бу очракта «чичән» сүзенең «матур сөйли белүче генә түгел, илһами рәвештә, кәгазьгә язмастан, тоткарлыксыз шигырь әйтүче-импровизатор» мәгънәсен дә үз эченә алуын күрсәтә[1].

Татарларның иң оештыручы үзәге саналган Идел буенда эпосның думбра чиртеп әйтелә торган сөйләмә формасына караганда, язма-китаби төренә өстенлек бирелсә дә, халыкка җырау-чичәнлек традицияләре, чыннан да, чит-ят түгел. Кайбер дастаннарыбызның шигъри өлешләрен дутар, думбра, саз белән көйләп әйтү традициясенең әле дә исән булуы яисә эпос-дастаннарга якын торган кайбер сөйләмә әсәрләрнең бүгенге көннәрдә дә халыкта актив жанрлар рәтендә йөрүе үк шуңа дәлил. Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан 2000нче еллар азагыннан интенсив төстә уздырылып килә торган, Институт эшчәнлегенең зур бер юнәлешен тәшкил иткән комплекслы фәнни экспедицияләрдә галимнәр татар дастаны эзләренә әле дә тап була торалар. Әле бүгенге көндә дә татарлар яши торган төбәкләрдә дастанны фабула характерында, йә булмаса әсәрдән эпик җырны көйләп-сөйләп бирүчеләрне чичәнлек традициясе кыйпылчыкларын бүгенге көнгә китереп җиткерүчеләр дип санарга мөмкиндер.

Шул ук вакытта татар чичәне телдән эпос әйтүче импровизатор образына бик үк тәңгәл дип әйтеп булмый. Әлбәттә, татар халкы тарихи хәтерендә чичән образлары бар: Җирән чичән, Сыпра (Субра) җырау, Җамукай чичән яисә Идел-Урал төбәге шагыйрь-импровизаторлары саналган Әсән Кайгы (XV гасыр), Казтуган җырау (XV гасыр), Дусмәмбәт җырау (XV гасыр

[1] Татар халык мәкальләре. Җыючысы һәм төзүчесе Н.Исәнбәт. 3 томда. Т.1. Казан: Татар китап нәшр., 1959. Б.67.

ахыры – XVI гасыр башы), Чалгиз (Шалкиз) җырау (XV гасыр ахыры – 1560нчы еллар) һ.б. Соңгы чорда Урта Идел татарларының талантлы чичәннәреннән Сабирҗан акын (Әтнә районы Мәңгәр авылыннан), Байчыгави (Лаеш ягыннан), Кәшшәфетдин Шаһимәрдән Минзәләви (Минзәлә өязе Сөлек авылыннан), Хөсәен Нугай һ.б. – чичәнлекләре белән шулай ук билгеле шәхесләр. Алай да татарларда һәм бигрәк тә Идел буе татарларында, дастаннар һәм дастани традицияләр исән булса да, эпос-дастанны фольклор музыка коралында уйнап, тоташтан телдән әйтеп утыру гадәте бик күптән сүрелгән. Аның каравы, татар эпос-дастаны бүтән юнәлештә үсеш алган.

Татар дастаннарының төп үзенчәлеге шунда: алар китап культурасын үстерүгә зур йогынты ясаганнар, язма әдәби-мәдәни процессны югары баскычка күтәрүдә әһәмиятле функция үтәгәннәр. Хикмәт шунда: халкыбыз күләмле дастаннарны берничә гасыр элек кәгазьгә төшергән, ягъни мәгълүм дастани сюжетлы иң камил, иң төзек вариантлар язмага теркәлеп, кульязма нөсхәләр яисә китапка әверелеп таралган. Язулы һәм дәүләтле халыклар эпосының язмышына карата Х.Короглы түбәндәгечә яза: «Язулы борынгы халыкларның (фарсы, һинд һ.б.) күбесендә эпос, язуга күчерелү белән үк, сөйләмә формада яшәүдән туктаган, чөнки дастан әйтүчене (сказитель) кыйссахан (чтец) алыштырган һәм ул авыл һәм шәһәрнең озын кичләрендә шул ук эпосны үзе «канунлаштырган» формада халыкка укып бирә торган булган. Шәһәр һәм авыл культурасы югары утрак тормышлы иранлылар, һинд, греклар, тарихи үсешләренең билгеле бер чорында, телдән башкарыла торган эпоска караганда язма эпосны кулайрак күреп, тулысынча язма эпоска күчкәннәр»[2].

Күп гасырлык язма мираска ия татарларда да эпик иҗатның язмышы әлеге закончалыкка тәңгәл: иртә язмачылык, утрак тормыш, шәһәрләшү, укымышлылыкның югары дәрәҗәдә булуы, грамоталылыкны һәм белемне пропагандалый торган ислам тәэсире татар дастанының язма-китаби юнәлештә үсүенә йогынты ясаган. Халыкның уку-язу белән турыдан-туры шөгыльләнүче катламы даирәсендә туган күләмле эпик иҗат язуга теркәлгән. Татар халкы үзенең яшәү-тереклек итүе дәверендә эпос-дастаннарны бик күп иҗат иткән. Мондый ядкарьләр, кулдан язып күчерелеп һәм таратылып, тарихи үсешнең татарлар өчен үзенчәлекле чорларында халыкка милли үзаңны, милли үзбилгеләнүне саклап калу чарасы булып та хезмәт иткән.

Сөйләмә эпос-дастаннарга алмашка килгән язма-китаби дастаннарыбыз гарәп язулы кульязмалар булып, китап басу чорында исә басма китапларга әверелеп, хәзерге көннәргә килеп җиткәннәр. Алмашка килгән дисәк тә, сөйләмә дастаннар стилендәге традицияләр китаби дастаннарда да эзсез юкка чыкмаган, әлбәттә. Татарларда озак еллар буена бер үк дастанның сөйләмә төре дә, китаби төре дә параллель яшәгән булуга да мисалларны күпләп китерергә мөмкин булыр иде. Хәлбуки, бер үк сюжетка иң камил дастанны сайлый башласак, нәкъ менә китаби вариантның югары эпик кануннарны да саклаган, шул ук вакытта әдәби камиллеккә җиткән иң тулы әсәр булуын таныйбыз.

[2] Короглы Х. Огузский героический эпос. М.: Наука, 1976. С. 114.

Авторлы әдәби дастаннардан һәм импровизатор иҗаты булган традицион сөйләмә дастаннардан аермалы буларак, китаби төрдәге эпоска карата фәндә «китаби дастан» төшенчәсе кулланыла. Мең елдан артык язу культурасы булган халкыбызда язма-китаби дастаннар барлыкка килү тенденциясе, эпик иҗатның мондый төренә омтылыш борынгыдан ук килә. Сюжет, тематикасы буенча кулъязма һәм хәтта китап булып басылган дастаннарның формалашу тарихы һәм таралуы урта гасырлар ахыры һәм аннан соңгы чор белән билгеләнә.

Дастаннарда халыкның тарихы белән бергә гасырлар дәвамында тупланган акылы, тормыш тәҗрибәсе, тел байлыгы, сүз сәнгатенең кабатланмас бизәкләре урын алган. Халкыбыз хәзинәсе, башка халык авыз иҗаты үрнәкләре белән беррәттән, эпос-дастаннар – яшь буынга милли рухыбызны тапшыруның кыйммәтле чыганагы да. Әлеге бәһаләп бетергесез зур мирас бүгенге көндә дә иҗтимагый тормышыбызда билгеле бер роль башкара килә. Дастаннарның һәм дастаннардан килә торган традицияләрнең онытылмавы шул хакта сөйли. Бүгенге көндә дастан батырларының исемнәре, дастан вакыйгалары опера-балет, театр сәхнәләрендә һәм әдәбият мәйданында яшәвен дәвам итә. Татарларга мәгълүм эпик сюжетларның, билгеле дастаннан эпик җырларның безнең көннәрдә дә актив яши торганнары юк түгел. Алар татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә әле дә язып алыналар. Бу күренешне дә хаклы рәвештә эпос-дастаннарыбыз дәвамы, татар җәмәгатьчелегендә жанрга карата булган ихтыяҗның чагылышы дип бәяләргә була. Дастаннар һәм дастан традицияләре – буыннан-буынга тапшырылып килә торган олы мирас, әлеге байлыкны файдалану, дастаннар сюжетында, стилендә, башкарылу үзенчәлекләрендәге нечкәлекләрне килер буыннарга җиткерү милли үзаңны үстерүне, асылыбызны саклауны нәтиҗәлерәк итә.

Россия халыклары арасында татарларның иң дисперс халык булуы да дастаннар үсешенә үзенең уңай йогынтысын ясаган. Сибелеп урнашкан татар халкының себер этник төркемендә яисә әстерхан татарларында сөйләмә характердагы дастаннар күбрәк сакланып калып, Идел буендагы татарларда исә язма-китаби эпос-дастаннарның тотрыклы үсеш алган булуы шуны раслый. Оештыручы сәяси үзәктән ераклык, шулай ук территория киңлеге һ.б. факторлар Себердә, Әстерхан өлкәсендә яшәүче татарларда сөйләмә эпос-дастаннарның яшәве өчен уңайлырак шартлар барлыкка китергән. Себердә әле XX гасыр урталарынача күләмле эпосны телдән әйтүче татарлар булган. «Мешәк алып», «Йәстәй Мөңке», «Кадыш мәргән», «Кара Күкел», «Йиртөшлек», «Ак Күбәк», «Кузы Көрпәч белән Баянсылу» һәм «Идегәй»нең берничә дистә варианты – чагыштырмача тыныч төбәккә сыенып, себер татарлары иҗатында исән калган сөйләмә дастаннарыбыз.

Академик фәннең фольклористика тармагында дастаннар татар халык иҗатының һәм әдәбиятының төп фундаменты саналып киләләр. XX йөзнең 20нче елларыннан татар халык иҗаты үрнәкләрен интенсив җыю-туплау, героик җырлар, әкиятләр белән беррәттән дастани эпос тарихын да өйрәнү, халыкта киң таралган сюжетларга яңа әсәрләр иҗат итү, мәгълүм дастаннарның җыйнама вариантларын төзү бурычы куела. Әмма татар

дастаннарына, ягъни милли эпоска карата хөкүмәт тарафыннан күрсәтелгән җылы караш чорның иҗтимагый-сәяси шартларына бәйле тукталып кала. ВКП(б) Үзәк Комитетының татар галимнәрен милләтчелектә, Алтын Урда чорын идеаллаштыруда, «ханнар-феодаллар эпосы» «Идегәй»не популярлаштыруда һәм артык бизәп күрсәтүдә гаепләгән «О состоянии и мерах улучшения массово-политической и идеологической работы Татарской партийной организации» дигән 1944 ел 9 август карары озак елларга милли эпосны өйрәнелүдән мәхрүм итә. Шушы вакыйгадан соң татар эпосын, аның тарихи-эволюцион үсешен, яшәү формаларын өйрәнү, башка халыклар фольклоры белән чагыштыру берничә дистә елга артка чигерелә.

Проблемага кабат әйләнеп кайту, дастаннар хакында янә сүз кузгату фәкать XX йөзнең икенче яртысыннан соң гына мөмкин булды. Ф.Урманчеев (1984, 1997, 1999, 2015), И.Надиров (1988), М.Госманов (1990), Ф.Әхмәтова-Урманче (1984, 2000), Ф.Яхин (2000), В.Хәйруллина (1998), М.Әхмәтҗанов (2000), Л.Ибраһимова (2002) һ.б.-ның дастаннарны төрле аспектларда тикшергән монографик хезмәтләре дөнья күрде. XXI гасырның унынчы елларыннан алып Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре М.Гайнетдин (2001), Ф.Вәлиуллина (2007), А.Фәхретдинова (2008), И.Закирова (2011), Л.Мөхәммәтҗанова-Ибраһимова (2014, 2018)), Г.Хөсәенова (2022) тарафыннан эпос жанрына багышланган докторлык, кандидатлык диссертацияләре якланды, дастаннарыбыз хакында киң колачлы монографияләр, фәнни һәм популяр матбугатта саллы мәкаләләр дөнья күрде, дастаннар хакында радио-телевидениедә чыгышлар да активлашты.

Моннан тыш, мәгълүм булганча, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан «Татар халык иҗаты»ның татар телендә 25 томлыгы, рус телендә 15 томлыгы әзерләнеп килә, берничә том, шул исәптән рус телендә «Дастаны» китабы инде дөнья күрергә дә өлгерде. Сүз уңаеннан, татар дастаннарының академик җыентык буларак рус теленә тәрҗемәдә әле моңа кадәр басылып чыкканы юк иде. Татар телендә чыга торган күптомлыкның «Дастаннар» һәм «Китаби дастаннар» дип аталган ике томы шулай ук әзер. Томнар татар дастаннарының иң камил үрнәкләрен үз эченә ала, томнарда дастаннарның халыкта билгеле вариантлары хакында тулы фәнни мәгълүмат бирелә. Шулай ук Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан ел саен уздырыла килә торган «Татар гыйлеме» халыкара яшьләр фәнни мәктәбенең чираттагысын татар дастаннарына багышлау һ.б. чаралар планлаштырылган.

Дастан жанрында китабилыкка кабат кайтып, шунысын искәртү мөһим: Идел буе татарларында эпосның язма әдәбиятка гына түгел, гомумән язмачылыкка, язма культурага бәйлелеге, хәтта буйсынган булуы төрле факторлар аркасында гаять киң җәелеп, тора-бара халык дастаннары таралыш-яшәешендә массакүләм төс алган. Чыннан да, Казан татарлары дастани мирасының иң зур күпчелеген китаби дастаннар тәшкил итә. Башка төрки халыклардагы версияләре чичәннәрнең авыз-

тел иҗаты буларак таралган дастаннар да Идел буенда китаби булып формалашканнар. Мәсәлән, атаклы «Идегәй» (фәндә мәгълүм Н.Исәнбәт, Н.Хәким, А.Ходьзко, С.Чыгатай вариантлары һ.б.) дә, яисә «Чура батыр», «Түләк китабы», «Бүз егет» һ.б. – барысы да татар рухи тормышына иң беренче чиратта җыручы-чичән башкаруында түгел, ә язма-китаби эпос булып кереп урнашканнар. Ә «Кыйссаи Сәкам», «Каһарман Катил», «Гыйсә улы Амәт», «Чыңгыз хан нәселе турындагы дастан» һ.б. – болар, гомумән, башлангычы белән үк язмада таралыш алган дастаннар.

Эпосны халыкка җиткерүче башкаручы-импровизатор иҗаты – язмага кадәрге культураның бер чагылышы, дастанның бу төре тексттан гына гыйбарәт түгел, әйткәнемчә, ул чичән тарафыннан башкарыла, тыңлаучы тарафыннан ишетеп кабул ителә. Күләмле сөйләмә эпоска караганда, язма иҗат белән шөгыльләнүгә омтылган Идел буе татарларының рухи тормышында китаби дастаннар гаҗәеп популяр булган. Дастаннарның популяр булуын күчереп таратылган кулъязмаларның күплеге дә, басма китап чорына кергәннең соңында бик зур тиражлар белән басылып чыккан булуы да раслый. Мисал өчен, татарларда «Каһарман Катил» дастанына карата шул мәгълүм: күчерелүе XVIII йөзгә караган кулъязмаларыннан башлап, бу әсәр XX гасырның 20нче елларына кадәр гарәп язулы китаплар булып шактый зур тираж белән басыла килгән. 1912 елда «Кәримия» нәшриятында китапның 6000 гә якын, ә 1913 елда «Ш.Хөсәеновлар нәшере»ндә төгәл 6000 данә белән басылуы мәгълүм[3], димәк, дастанга халыкта, шиксез, ихтыяҗ булган, әсәр кабул ителгән, яратып укылган, XX гасыр башында да әле «Саф татар телендә, һәркемгә аңлап укырга бик кызыклы»[4] дигән тәкъдимнәр белән өндәп, рекламалау рәвешендә халыкка аңлы һәм максатчан рәвештә таратылган. «Сәйфелмөлек», «Ләйлә белән Мәҗнүн», «Йосыф китабы» һ.б. сюжетка корылган дастаннар турында да шулай дип әйтергә мөмкин булыр иде. «Идегәй», «Чура батыр», «Гыйсә улы Амәт», «Дастане Чыңгызнамә», «Алпамша», «Җик мәргән», «Таһир белән Зөһрә», «Бүз егет», «Түләк китабы», «Сары Салтык», «Хурлуга белән Хәмра» «Мактым-сылу», «Кыйссаи Зәркум», «Хикәят Былбылнамә», «Хикәя Маһфируз вә солтан илә Разанхан», «Каһарман Катил», «Кыйссаи Сәкам», «Кыйссаи Сәед Баттал», «Хикәяте Күр углы солтан» кебек дастаннарыбызның да халыкта күпләгән вариантларда кулъязмалар һәм басма китапларда таралганлыгы мәгълүм.

Татарның бик борынгыдан килә торган кулъязма китабы да, XIX гасырның башыннан дөнья күрә башлаган тулы канлы милли басма китабы да – мәдәниятебез һәм әдәбиятыбыз тарихын өйрәнү өчен үтә кыйммәтле чыганак. Татарларның кулъязма һәм басма китабы аеруча бай һәм зур тарихка ия. Китап тарихын, бигрәк тә меңәрләгән кулъязма китапларны, шулар арасында дистәләгән исемдәге, йөзәрләгән варианттагы дастаннарны өйрәнү иң элек кулъязма материалны туплаудан башлана. Казанда Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында, аннан тыш Милли китапханә, Казан федераль университеты,

[3] Гилазев З.З. Татарская литература начала XX века в книжных изданиях. Казань: ИЯЛИ АН РТ, 2005. – С. 149, 148.(160 с.).

[4] Кыйссаи пәһлеван Каһарман Катил. Саф татар телендә, һәркемгә аңлап укырга бик кызыклы. Казан: матбагаи «Кәримия», 1914. – Б.1. (116 б.)

Милли архив һ.б. фәнни үзәкләрдә татар дастаннарын җыю-туплау һәм сакланышын тәэмин итү юнәлешендә хаклы рәвештә максатчан эш алып барыла килә. Татарларда эпос-дастан бар гына түгел, бик күп, аларның иң камил, иң тулы вариантлары язмада саклана. Институтның Язма мирас үзәгендә генә дә әллә никадәр кульязма дастан барлыгы мәгълүм һәм аларның саны фәнни экспедицияләрдә табылган яңа вариантлары исәбенә ел саен арта тора.

Дастаннарда халыкның тарихы, гасырлар дәвамында тупланган акылы, тормыш тәҗрибәсе, тел байлыгы, сүз сәнгатенең кабатланмас бизәкләре урын алган. Аларда борынгы һәм бик борынгы мифология эзләрен, соңрак формалашкан ислам идеологиясе йогынтысын, сүзне хикмәт белән әйтү, элек-электән фольклорга хас традицион образлар, эпик сюжет һәм мотивларны табарга мөмкин. Халкыбыз хәзинәсе, башка халык авыз иҗаты үрнәкләре белән беррәттән, эпос-дастаннар – яшь буынга милли рухыбызны тапшыруның кыйммәтле чыганагы да. Әлеге бәһаләп бетергесез зур мирасның мәктәптә әдәбият укыту программаларында тиешле урын алуы да шуның белән аңлатыла. Кулланылышта булган мәктәп программасы һәм дәреслекләр нигезендә укучылар дастан жанрының тарихы, төрләре белән танышалар. Алыплар турындагы архаик, романик характердагы мәхәббәт дастаннары яисә стадиаль яктан төрле чорларны иңли торган тарихи дастаннар турында сөйләшү халкыбызның күңел байлыгын, әхлакый идеалларын, матурлыкка омтылышын күзалларга ярдәм итә.

Мәсәлән, халкыбызның гасырларны кичеп, тарихның авыр, эзәрлекләүле еллары аша үтеп, кабат укучысына кайтарылган «Идегәй» дастанын укып анализлау укучыны тормыш фәлсәфәсенә, гади дә, катлаулы да хакыйкатькә якынайта. Бу тарихи дастан Алтын Урда дәүләтенең таркалу елларын, аның сәбәпләрен ачыклый, тарихи аренада зур роль башкарган шәхесләрне халык каһарманы пьедесталына күтәрә. Иң әһәмиятлесе – дастан бабаларның яше, тире, каны тамган, шатлыгы да, бәхете дә, бөтен язмышы да сеңгән туган җир сүзенең асылын аңларга өйрәтә. Әсәр мәкер, хыянәт, ялганның олысы, кечесе юк икәнлегенә төшендерә, дуслык, мәхәббәт хисенең сафлыгын, биргән вәгъдәгә тугрылыкның олылыгын таныта. Явызлык үзе белән явызлыкны ияртә, яманлыкка каршы кылынган яманлык аны үстерә һәм фаҗигагә китерә дип раслый. Дастаннар тормышка карашны киңәйтә, зуррак масштабта фикерләргә, вакытның мәңгелек агышында кеше, аның гамәлләренең мәгънәсен төшенергә өйрәтә. Ил, Ватан, Ата-Ана, Милләт төшенчәләренең кыйммәтен аңлаган кеше үз гомерендә аларга хыянәт итмәячәк.


Татар дастаннары үткән юл бик озын һәм катлаулы. Гомумән, эпос-дастаннарыбыз, милләтнең үзе кебек үк, үлемсез жанр. Нинди генә шартларга юлыкканда да татар эпосының исән калуы, яңадан-яңа отышлы формаларга трансформацияләнеп, камилләшә баруы шул хакта сөйли. Мең елдан артык язма тарихка ия халык булуыбыз татар дастанының элитар жанр булып формалашып җитүенә йогынты ясаган. Дастаннар – буыннан-буынга тапшырылып килә торган олы мирас, бу байлыкны файдалану һәм килер буыннарга җиткерү милли үзаңны үстерү, асылыбызны саклауны

нәтиҗәлерәк итә. Татарлар – дастанлы халык. Дөньяда эпос-дастаны булмаган бик күп халыклар барлыгын да исәпкә алсак, дастаннарыбызның аеруча зур хәзинә булуына, халкыбызның исә нык тамырлы бөек халык булуына тагын да ныграк инанырга мөмкин. Идел һәм Урал буйларында гына түгел, гомумән Евразия далаларында таралып яшәүче татарларда дастан гасырлар буена халык тормышында эмоциональ-экспрессив дәрәҗәдәге рухи азык, тәэсирле язма укып, күңел юату чарасы гына булмыйча, тарихның хәлиткеч әһәмияткә ия этапларында үзенә күрә бертөрле идеологик функция дә үтәп килгән.

Чабып барган ат тоягы тавышын, кошның очып һавага күтәрелүен, исеп үткән дала җилен, ат пошкыруын, кылыч чыңын сөйләме аша тыңлаучыга җиткерергә сәләтле башкаручы тасвирындагы сөйләмә дастаннарыбызга да, шушыларга өстәп, язма мәдәният традицияләрен дә үзләштергән китаби дастаннарыбызга да халык эпик иҗаты кагыйдәләре барлык тулылыгы белән диярлек сыешкан, аларда эпик һәм индивидуаль иҗат башлангычлары бер-берсе белән гармониядә. Татар дастаны – тарихи фактларны, татарларның борын-борыннан килгән яшәү рәвешен төкми-чәчми сөйли торган чыганак. Әйе, татар – дастанлы халык, ә инде аның китаби дастаннары дәрәҗәсенә җиткерелгәннәре башка бер генә төрки халыкта да юк. Татар дастанының китаби камиллеккә ирешкән булуы – милләтнең аңы, укымышлылыгы, рухи бөеклеге белән бәйле сыйфат. Бу төр иҗатны халкыбызның асыл кыйммәтләреннән берсе дип саныйбыз. Бүгенге көндә эпос-дастаннарыбызга карата игътибарның зурлыгы татар дастани традицияләренең дәвамчанлыгын күрсәтә, эпос-дастан стиленең, образ-каһарманнар рухының үлемсезлеген дәлилли.

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең*
*Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм*
*сәнгать институты*
*Халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.*





*Гариф Ахуновның «Казан утлары»нда баш мөхәррир булып эшләгән чагы. Сулдан уңга: Рөстәм Нәбиуллин, Гариф Ахунов, Эльс Гаделев. Март, 1973 ел.*



*Якташлар күрешкән мизгел. Шагыйрь, публицист, мөхәррир Рәфикъ Юныс (сулда, бу айда аңа 80 яшь тулган булыр иде) белән дәүләт эшлеклесе, сәясәтче, галим, публицист Фатих Сибагатуллин. Икесе дә – Арча районы тумасы.*



*Япон язучылары «Казан утлары»нда кунакта. Алгы рәттә: Мөсәгыйт Хәбибуллин, Сакагами Сан, Кондо Сан, тәрҗемәче Ирина, Сиракава Сан. Арткы рәттә: Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев, Кояш Тимбикова, Рәдиф Гаташ, Ринат Мөхәммәдиев. 1981 ел.*



*Шагыйрә Флёра Гыйззәтуллинаның иҗат кичәсе. Тукай клубында. 23 октябрь, 1981 ел.*

*Фотолар* **Рөстәм НӘБИУЛЛИН,**
**Марсель ГАЛИЕВ** *архивларыннан алынды.*

# РӘШИТ СҮНӘЕВНЕҢ ГЫЙЛЕМ ГАЛӘМЕ



Галимлек эталоны – нинди ул? Тормыш-яшәешкә карашларны гына түгел, кешелек дөньясының барышын үзгәртерлек ачышлар ясаумы, әллә инде гомерне фәнгә багышлап, туктаусыз эзләнүләр юлына теләсә нинди шартларда да тугры калумы, яки гыйлемнең киләчәге өчен җаваплылыкны үз кулыңа алу куәтеме, йә булмаса үз халкың өчен мөһим бер генә мәсьәләгә дә битараф кала алмаумы? Бәлки, болар барысы бергә – бер шәхес язмышында, холкында күзәтелгәндә, галимлек эталоны хасил буладыр! Дөньякүләм танылган астрофизик, Россия фәннәр академиясе академигы (1992 елдан), Академиянең Космик тикшеренүләр институты (ИКИ) галиме, Макс Планка исемендәге җәмгыятьнең Астрофизика институты директорларыннан берсе (Garhing, Алмания) булган Рәшит Али улы Сүнәев шушы сыйфатларның барысын да үзенә туплаган, лабаса.

Хәзерге заманның теоретик астрофизика һәм физик космология фәннәрен аның ачышларыннан, хезмәтләреннән башка күз алдына китереп булмый. Ул – күп фәннәр гыйлемнәренә таянып, Галәмне, йолдызларны, галактикаларны киләчәктә өйрәнү юлларын, модельләрен уйлап табучы, кеше аңын шул модельләрне кулланырга көйләүче акыл иясе. Шунысы кызык: Рәшит Али улы тәкъдим иткән методлар һәм модельләр, технологияләр үзгәрү белән, күзәтеп дәлилләнәләр, фаразлары раслана. Әйтерсең, галимнең уе-аңы, бүгенгедән торып, ерак киләчәктәге Галәмне өйрәнү технологияләрен «күрү» сәләтенә ия.

Рәшит Сүнәев 1943 елның 1 мартында Ташкент шәһәрендә дөньяга килә. Нәсел тамырлары элеккеге Пенза губернасы, хәзерге Мордовиянең Кадошкин районындагы Латыш һәм Иса авылларына барып тоташа. Аның әтисе морзалар нәселеннән булган Али Абдрахман улы Сүнәев Латыш авылында сәүдә һәм кәсәбәлек белән шөгыльләнгән хәлле бер гаиләдә туа. Рәшит Сүнәевнең әнисе Сәйдә Исхак кызы Дәүләт-Килдиева Латыш авылына күрше булган Иса авылыннан, әмма булачак ире белән Ташкентта гына очраша. Чөнки Исхакның әтисе, Мордовия төбәгендә билгеле морзаларга барып тоташкан нәсел дәвамчысы, югары гыйлемле, яшь чагында Берлинда, Варшавада, Истанбулда, Мәккә һәм Мәдинәләрдә булган Усман Солтанали улы Дәүләт-Килдиев, коллективлаштыру башлангач, хатыны Өммегөлсем, балалары белән бергәләп, аларны исән-сау саклап калыр өчен чит җирләргә китеп барудан башка юл тапмый.

Мәктәпне алтын медальгә тәмамлап, Рәшит Али улы Мәскәү физика-технология институтына (МФТИ) укырга керә, 1966 елда «кызыл диплом» алып, академик Яков Зельдович җитәкчелегендә аспирантурада укый. Үз сүзләренә караганда, Россия фәненең иң күренекле галимнәреннән берсе – аның фәнни җитәкчесе генә түгел, чын мәгънәсендә остазы, киңәшчесе булып чыга. Физика-математика фәннәре докторы (1973), МФТИ профессоры (1974) булгач та, остаз белән укучы фән юлыннан бергә атлыйлар.

Рәшит Сүнәевнең фәнни хезмәтләре йолдызларны, галактикаларны, бөтен Галәмне өйрәнү белән бәйле. Ул астрофизика фәнендә иң кечкенә күренешләрдән башлап – физик космологиягә кадәр гаять күп мәсьәләләр белән шөгыльләнә. Аның ачышлары кешелекнең Галәмгә, Галәм аша – матди дөньяга карашларын үзгәртергә сәләтле һәм тамырдан үзгәртәләр дә.

Дөнья фәне Сүнәев белән Яков Зельдовичны миллионнарча еллар элек Галәмне хасил иткән Зур Шартлаудан соң беренчел дулкыннар барлыкка килү теориясенең авторлары буларак таный. Галимнең фәнни казанышлары арасында иң күренеклеләре – «кара упкын»нарның (чёрные дыры) һәм нейтрон йолдызларның тибрәнүе теориясе (Шакура һәм Сүнәев, 1973, 1976); кайнар плазмада түбән ешлыклы фотоннарның тизлеге үзгәрү (комптонизация) вакытында нурланыш спектрын ачыклау өчен Сүнәев-Титарчук формуласы (1980); бик борынгы, әле Галәм формалашып килгән вакытта акустик дулкыннарның нурланышка һәм галактикаларның Галәмдә урнашуына тәэсирен фаразлау (1970); галактикаларның тупланышын күзәтергә мөмкинлек биргән «Зельдович-Сүнәев эффекты» (1972) һ.б. Алар хакында җентекләбрәк сөйлик.

Әйтик, Шакура-Сүнәевнең аккрецион дисклар теориясе Галәмдә кара упкыннарны эзләүгә юл ача. Ул йолдызларда матдәләр көчешен һәм энергия бүленеп чыгуны, чиктән тыш авыр «кара упкын»нарның массасы үсүне тасвирлаганда, бөтен дөньяда, гомум кулланылышта йөри. МДУ профессоры Николай Иванович Шакура һәм Рәшит Али улы Сүнәевнең бу хактагы фәнни хезмәте (1973) йолдызлар янында, газ бүленеп чыгуга бәйле, аккрецион дисклар хасил булуны раслый, бүген «кара упкыннар»ны теоретик тикшеренүләрнең нигезе булып тора, астрофизика фәнендә иң күп тапкыр телгә алынган (цитацияләнүче) эш исәпләнә.

Хезмәттә массасы артып торган нейтрон йолдызлар һәм «кара упкын»нар бер үк вакытта бик көчле рентген һәм гамма-чыганаклар итеп карала. Сүнәев-Титарчук формуласы (1980) шушы объектларны күзәтү, нәтиҗәләрен теркәү вакытында алыштыргысыз. Әлеге формула Галәмдә барган күптөрле хәрәкәтләрне (көчешләр, масса арту-кимүләр һ.б.) аңлатырга мөмкинлек бирә.

Астрофизика фәнендә иң мөһим ачышларның берсе итеп, Зельдович-Сүнәев эффекты (SZ-эффект) санала. Әлеге исем белән йолдызара һәм галактикаара газның кайнар электроннарында бик борынгы, Галәм формалашкан вакыттагы нурланышның куелыгы үзгәрүне атыйлар. 1960–1970 еллар чигендә ясалган бу ачыш, чын мәгънәсендә, Галәмне өйрәнүдә, аның төзелешен, зурлыгын күзаллауда инкыйлаб ясый.

Бу проект 1969 елны башлана: Рәшит Сүнәев һәм Яков Зельдович Галәмдә галактикалар тупланган урыннарда микродулкын фонының яктылыгы кимү турындагы фикергә киләләр. Әлеге күренешне аңлаткан, аны куллану мөмкинлекләрен күрсәткән хезмәт 1973 елны басылып чыга. Шул вакыттан алып әлеге тәгълимат күзәтү космологиясендә иң нәтиҗәле методларның берсенә әверелә. Шул исәптән, ул Галәмдә «караңгы энергиянең» ролен һәм берничә мең галактикалар тупланышын өйрәнергә юл ача. «Планк» спутнигын һәм SZ-эффектны өйрәнү өчен махсус төзелгән South Pole Telescope, Atacama Cosmology Telescope, SZ-array телескопларын кулланып, соңгы елларда меңнән артык моңа кадәр мәгълүм булмаган галактикалар тупланышын ачыкларга мөмкин булды. Нәтиҗәдә, хәзер Галәмдә галактикалар тупланышлары каталогларын төзү эше башкарыла.

Кайбер ачышлар күпмедер вакыт узганнан соң гына раслана һәм гамәлдә кулланыла башлый. Әйтик, 1980 елны Р.А.Сүнәев һәм Я.Б.Зельдович галактикалар тупланышындагы нурланышта кинематик эффект турында белдерү ясыйлар. Ул 30 елдан соң, бары тик 2011-2012 елларда гына күзәтү космологиясендә кулланыла башлый. Ләкин моның белән әһәмияте кимеми: бүген ул дөньяның иң эре радиотелескоплары программасына керә һәм нурланышны күзәтеп, галатикалар тупланышларының сурәтен-рәвешен ачыкларга ярдәм итә.

Үзгә бер юнәлештәге фундаменталь тикшеренүләр Галәмнең генә түгел, Җир шарының килеп чыгышына караган күп кенә сорауларга җавап бирә. Шундый зур проект 1968 елны, Р.А.Сүнәев, Я.Б.Зельдович һәм В.Г.Курт белән бергәләп, Галәм формалашкан вакытта водород оешу һәм таркалу тизлеген исәпләүдән башлана. 1970 елны Сүнәев һәм Зельдович әлеге күренешнең нурланышка тәэсирен билгелиләр. 2006 елны Йенс Хлуба һәм Сүнәев водород һәм гелий атомнары һәм ионнарының оптик сызыкларын исәпләп чыгаруга ирешәләр.

Алай гына да түгел: мондый тикшеренүләр Галәм барлыкка килүне тулысынча күзалларга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, 1969-1970 елларда Р.А.Сүнәев һәм Я.Б.Зельдович борынгы дәвер нурланышында энергия югалу процессын детальләп тикшерәләр. Беренче булып алар тарафыннан безнең Галәмнең иң борынгы сурәтен ачыклау методы тәкъдим ителә.

Сүнәев һәм Зельдович 1970 елны реликт нурланышының таралыш почмакларында иң югары акустик ноктлар булуны фараз итәләр, аларны «Сахаров осцилляцияләре дип исемлиләр. 2000 елны акустик пиклар спутниклардан космологик күзәтү вакытында табыла, өйрәнелә. Шул ук хезмәттә Галәмдә галактикаларның урнашуында барион акустик осцилляцияләрнең (БАО) роле фаразланган була. Бүген инде БАО, шулай ук, күзәтү космологиясенең иң мөһим методларыннан санала.

Кайчак ачышлар озак вакытлар дәвамында берсен-берсе дәвам иткән эзләнүләр чылбыры хасил итә. 1973 елны Т.М.Энеев, Н.Н.Козлов һәм Р.А.Сүнәев галактикаларның үзара тартылышына кагылышлы исәпләүләр башкарып карыйлар. Р.А. Сүнәев һәм Ю.Н.Гнедин (1974) исә, үсә баручы рентген пульсарларның рентген спектрларында циклотрон сызыклар булу мөмкинлеген фаразлыйлар. В.М.Лютый һәм А.М.Черепащук белән берлектә 1973, 1976 елларда йолдызларның рентген җылынуына һәм үзара тартылыш китереп чыгарган тирбәлешләргә аңлатма бирелә. М.М.Баско һәм Р.А.Сүнәев (1973) беренче булып рентген нурланышының йолдыз өслегенә тәэсирен ачыклыйлар: йолдыз өслеге җылыну, рентген нурларының чагылышы йолдыз җиле китереп чыгара икән.

Шул ук юнәлештә 1974 елны Р.А.Сүнәев, Л.Г.Титарчук белән бергәләп, беренче булып салкын йолдыз атмосферасында чагылган нурланышның рентген спектрын исәпләүгә ирешә. 1975 елны, А.Ф. Илларионов белән бергәләп, көчле магнит кырына ия булган нейтрон йолдызларда «пропеллер» эффектының әһәмиятен күрсәтә.

Иң гаҗәбе – космологиядә фаразларның дәлилләнүе, әлбәттә. Инде телгә алынганнарыннан тыш, моңа күпләгән мисаллар китерергә була. Мәсәлән, Р.А.Сүнәев, М.Л.Маркевич һәм М.Н.Павлинский (1993) безнең Галактика төшендәге авыр кара упкын янындагы молекуляр болытларның K-альфа тимер сызыгында бик көчле нурланыш булу мөмкинлеген фаразлыйлар. Бүген инде бу нурланыш күзәтелә.

1999 һәм 2010 елларда Н.А.Иногамов һәм Р.А.Сүнәев яктысы сүрән йолдызның моделен төзиләр, аның ярдәмендә көчле энергия бүленеп чыгу механизмын аңлаталар. Йолдыз өслеге буйлап таралган матдәнең ике якты түгәрәк хасил итәргә тиешлеге фаразлана. Бу күренеш тә хәзер гомумбилгеле инде.

Болар – иң күренекле, космология фәнен үзгәрткән ачышлар гына. Әле, теоретик галим булу өстенә, Рәшит Сүнәев гамәли фән белән дә гаҗәпләнерлек дәрәҗәдә нәтиҗәле шөгыльләнә.

Аның бу юнәлештәге эшчәнлеге 1974 елны, Я.Б.Зельдович һәм Р.А.Сүнәевне академик Р.З.Сәгъдиев СССР Фәннәр академиясенең Космик тикшеренүләр институтында (ИКИ) теоретик астрофизика бүлеген оештырырга чакырудан юл ала. 1974–1982 елларда Р.А.Сүнәев бу бүлектә лаборатория эшләтеп җибәрә, 1982 елдан ИКИда Югары энергияләр астрофизикасы бүлеген җитәкли. Шул вакыттан галим тормышында эксперименталь рентген һәм гамма-астрономия этабы башлана. Рәшит Али улы СССР һәм Россиядә өч иң уңышлы орбиталь астрофизик обсерваторияләр – МИР галәм станциясендәге КВАНТ модулендә РЕНТГЕН обсерваториясе һәм

ГРАНАТ, ИНТЕГРАЛ орбиталь обсерваторияләре өчен аппаратура сайлау һәм булдыру, күзәтүләр программасын эшләү белән фәнни җитәкчелек итә. РЕНТГЕН обсерваториясенең иң зур ачышларыннан дип Зур Магеллан Болытындагы Өр-Яңа 1987Адагы каты рентген нурланышын ачу тора. Бу нурланыш йолдыз таркалганда хасил булган 56Ni һәм 56Co, гамма-квантлар бүленеп чыгу һәм аларның салкын сүрүдә үзгәрүенә (комптонизация) бәйле була. Йолдыз һәлакәте вакытында никель-56ның радиактив таркалышы һәм кобальт-56-га, аннары – тимер-56-га әйләнүе Галәмдә, шул исәптән, безнең Җир шарында да тимернең килеп чыгышына аңлатма бирә.

1989 елның 1 декабрендә Байконур полигоныннан ГРАНАТ халыкара орбиталь обсерваториясе җибәрелә. СССР, Франция, Дания рентген телескопларын берләштергән бу галәми мәйданчык 10 ел эшли. Аның нәтиҗәләре арасында Галактиканың үзәк өлешенең җентекле рентген картасын эшләү, «кара упкын»нар һәм нейтрон йолдызларның спектрларын билгеләү, уннарча яңа рентген чыганакларын, шул исәптән, билгеле Галактик микроквазарларның иң яктысын ачу күрсәтелә ала. ПРОТОН ракетасы ярдәмендә орбитага чыккан ИНТЕГРАЛ, үз чиратында, безнең Галактика үзәгендәге салкын позитроннарның аннигиляцион нурланышын өйрәнүдә зур нәтиҗәләргә ирешә.

Р.А.Сүнәев – Россия һәм Германиянең космологиядәге фундаменталь мәсьәләләрне – караңгы энергиянең һәм караңгы матдәнең табигатен, чиктән тыш авыр «кара упкын»нарның барлыкка килүен һәм үсүен, билгесез килеп чыгышлы объектларны өйрәнә торган СПЕКТР-РЕНТГЕН-ГАММА («СРГ») рентген орбиталь обсерваториясенең фәнни җитәкчесе. Бу зур эшкә әзерлек 15 еллап бара, «СРГ» исә Байконурдан 2019 елның 15 июлендә галәмгә оча. Россия, Англия, Дания, Италия, Америка, Финляндия, Швейцария, Германия, Венгрия, Канада, Израиль, Төркия һ.б. илләрнең 2,5 тонна авырлыктагы фәнни аппаратурасына, гыйльми көчләренә таянган бу проект 4 ел эчендә рентген күгендә 3 миллионнан артык актив галактикалар төшен – нурланыш чәчә торган чиктән тыш авыр «кара упкын»нарны, галактикаларның йөз меңләп тупланышын – билгеләргә тиеш. Аппарат Җирдән 1,5 миллион километр ераклыктагы Лагранж (L2) ноктасына – Кояш, Җир һәм Ай һәрвакыт обсерваториянең бер ягында күренә торган урынга – җибәрелә. Ярты ел эчендә ясалма иярчен ул ноктаны әйләнеп чыга, шул вакытта күк йөзен тулысынча рәсемгә төшерә. Обсерваториядә ике уникаль көзгеле телескоп (Россия һәм Германиянеке) урнаштырылган. Алар энергияләрнең рентген диапазонында бөтен күк йөзен күзәтеп чыгарга, сайлап алынган астрофизик объектларны җентекләп өйрәнергә мөмкинлек бирә. 4 ел эчендә 8 бер-берсен тулыландыра торган рәсем-карта төшереләчәк. Нәтиҗәдә Галәмнең иң җентекле, төгәл картасы пәйда булыр дип уйланыла. Әмма иң мөһиме – проект моңа кадәр билгесез булып калган төп мәсьәләгә җавап бирер дип көтелә: күзгә күренмәгән караңгы матдә – вакыт һәм пространство белән идарә итүче көч – Галәмдә ничек урнаша? Безнең яшәеш закончалыкларына карашыбызны үзгәртәчәк әлеге ачышны бүген өченче астрономик революция дип тә атыйлар (беренчесе оптик приборлар барлыкка килү булса, икенчесе – кешелекнең якын Галәмгә чыгуы).

Р.А.Сүнәев әйтүенчә, «СРГ» тикшеренүләренең нәтиҗәләре аеруча безнең Галактиканың үзәгендә урнашкан гигант «кара упкын»ның активлыгына кагылачак. Бүген әлеге «кара упкын» һәм ул суыра торган матдә алмашынып торган рентген нурланышы дип санала. Әмма миллион еллар элек Галактика үзәгендә булган Зур Шартлау әлеге «кара упкын»нан уннарча мең яктылык елы ераклыгына коточкыч күләмдә газ атылуга һәм аның тирәли йолдызлар хасил булуга китергән. Ул чакта Галактикада нурланыш бүгенге белән чагыштырганда, йөз миллионнар, бәлки миллиардлар тапкыр артык булган. «СРГ» телескобы бүленеп чыккан газның үзлекләрен тикшерә, аны миллион градусларга кадәр җылыта торган көчле бәрмә дулкыннарны «күрә». Рентген чыганакларын өйрәнү Галәмне тутырган караңгы энергиянең һәм кара матдәнең табигатен аңларга ярдәм итәр дип фаразлана. Галәм

пәрәвезләрендәге Галактикалар тупланышы, бәлки, безнеке кебек башка Галәмнәр булуны да хәбәр итәр, дигән ышаныч та кешеләрнең күңелен гел ымсындырып тора бит.

Галәмнән җибәрелгән материалларны кабул итү, тикшерү белән уннарча үзәкләр, шул исәптән, Казан галимнәре дә шөгыльләнә.

1990 нчы еллардан башлап академик Сүнәев Татарстан, Казан университеты һәм Татарстан Фәннәр академиясе белән тыгыз хезмәттәшлек итә. Кадрлар тәрбияләүдәге, Татарстан өчен чит илләргә чакыртып, кандидатлар һәм докторлар әзерләүдәге эшчәнлеге аерым бер ихтирамга лаек. 1990 елларда Төркиядә (Анталья) Бакыртәпә тавына югары сыйфатлы спектрометр белән җиһазландырылган 1,5 метрлы телескоп урнаштыру аның ярдәме белән мөмкин була. Еллар буе барган күзәтүләр нәтиҗәсендә, РТТ-150 телескобы ярдәмендә берничә мең нурланыш өлгесе ачыклана, йолдызларның нур тизлеге үзгәреше тикшерелә.

2017 елны 10 ел буе алып барылган тикшерүләр зур ачышка китерә! Астрономия каталогларында HD 208897 номеры белән билгеләнгән йолдызның нурланыш тизлекләрен анализлау вакытында, аның тирәсендә Юпитер планетасы массасыннан 1.4 тапкыр артык авырлыктагы планетаның 353 тәүлек эчендә бер астрономик берәмлек (150 миллион километр) ераклыгын әйләнеп узуы билгеле була. Бу Җирнең Кояш тирәли әйләнү ераклыгына тәңгәл. HD 208897 йолдызы исә бездән 210 яктылык елы ераклыгында урнашкан. Дөньяда Юпитер массасына якынлашкан 10 планета гына мәгълүм! Шуңа күрә Төркиядәге Казан телескобында яңа планета ачылу уникаль вакыйга булып тора!

Бүген бу телескоп бик күп халыкара проектларда, шул исәптән «СРГ» проектында катнаша. Мәскәүдән Рәшит Сүнәев һәм аның укучысы, Россия Фәннәр академиясе академигы Марат Гыйльфанов, Казаннан академик Наил Сәхибуллин җитәкчелегендә бер төркем: Ирфан Бикмаев, Элдар Иртуганов, Алмаз Галиев, Сергей Мельников һ.б.лар Җирдән торып йолдызлар тирәсендә планеталар эзләү программасында яңа ачышлар ясыйлар. Мисалга, Казан галимнәре сайлап алынган рентген чыганакларының берсенең 100 миллион Кояш массасы авырлыгындагы «кара упкын» булуын ачыклыйлар. Әлеге квазар әле Җир формалашмаган, Галәм 10 тапкырга яшьрәк булган чакта ук нур тараткан! Аның рентген һәм оптик фотоннары безгә 12 миллиард ел «очканнар»!

Р.А.Сүнәев – гаҗәеп ачышлары өчен дөньядагы иң мәшһүр бүләкләргә ия булган галим. Америка Астрономия җәмгыятенең Бруно Росси премиясе (1998), Король Астрономия җәмгыятенең Алтын медале (1995), Космология өлкәсендәге хезмәтләре өчен Бөекбританиянең Робинсон премиясе (1995), Король җәмгыяте һәм КОСПАРның Алтын медале (1998), Тын океан Астрономия җәмгыятенең Катерин Вольф Брюс Алтын медале (2000), Русия Фәннәр академиясенең А.Фридман премиясе (2002), Халыкара астрономнар берлегенең танылган Петер Грубер премиясе (2003) һ.б. Галим йолдызларны һәм галәмне өйрәнүдә уңышлары өчен АКШның физика институты һәм астрономия җәмгыяте тарафыннан 2003 елның иң күренекле астрофизигы булып танылa һәм Dannie Heineman фонды бүләгенә лаек була. Бу хактагы карар болай яңгырый: «Бар галәмнән алып, «кара упкын»нарга кадәр нурланыш белән матдә арасындагы бәйләныш мәсьәләләрен гаҗәеп дәрәҗәдә тирән аңлауга ирешкәне өчен». Шуны да өстәргә кирәк: ул – СССР һәм Россиядән Һейнеман премиясен алучы беренче кеше!

Галим ике тапкыр: 1990–1998 елларда Гранат астрофизика обсерваториясендә алып барылган «кара упкын»нар һәм нейтроннарны өйрәнү (2000), «кара упкын»нарда дисклар үзгәреше теориясен булдыруы (2016) өчен – Россиянең фән һәм технологияләр өлкәсендә Дәүләт бүләген ала.

Гомумән, Сүнәевнең күпләгән халыкара бүләкләргә, алтын медальләргә лаек булуы аның фән өлкәсендәге зур казанышларының бәхәссез икәнлеген раслый. Шулардан иң соңгы берничәсен генә атап узу да җитәр. Бик сирәк галимнәргә генә бирелә торган бүләкләр буларак: астрономия буенча Нобель бүләгенә тиң булган

Крафурд премиясен (Швеция, 2008), Халыкара Астрономия җәмгыятенең иң югары бүләге – Рассел премиясен (2008), Германия Астрономия җәмгыятенең иң югары бүләге – Карл Шварцшильд медален (2008), Король Фейсал исемендәге Халыкара премия һәм Алтын медальне (2009), Галәмне өйрәнүдә зур уңышлары, аерым алып, флуктуация теориясе өчен Япониянең төп фәнни бүләге – Киото премиясен (2011), физика буенча Бенджамин Франклин Алтын медален (2012) аерып күрсәтергә мөмкин. «СРГ» проектының казанышлары, «рентген нурларында күкнең иң яхшы картасын булдыруы, космология киңлекләрендә моңа кадәр билгесез булган миллионлаган авыр «кара упкын»нарны ачуы, нигездә «караңгы матдә» белән тулган уннарча мең Галактикалар тупланышы нурларын табуы һәм Галәмнең эре масштабтагы структурасы үсешен җентекле өйрәнү мөмкинлеге булдыруы» өчен 2021 елны Марсель Гроссман исемендәге халыкара премия белән билгеләнә.

Бик күп фәннәр академияләре аны үз әгъзалары итеп күрүне зур дәрәҗә саный. Дөньяның иң мәшһүр университетлары Рәшит Али улын үзләренең профессоры итеп чакыралар. Әйтик, Альберт Эйнштейн гомеренең соңгы 22 елында эшләгән, атом бомбасы ясау буенча Манхэттен проектының фәнни җитәкчесе Роберт Оппенгеймер директор булган, иң күренекле математиклар, физиклар, философлар тупланган Принстон Югары тикшеренүләр институтында, чакырылган профессор буларак, ул ел саен ике ай дәвамында дәресләр алып бара!

Мондый нәтиҗәләргә ирешү өчен, чын мәгънәсендә, тормышыңны-язмышыңны тулысы белән фәнгә багышларга кирәктер! Әлеге юлда таянычым, ышанычым дип Рәшит Али улы гаиләсен күрсәтә. Хатыны Гүзәл Әпсәләмова – табиб, аны татарлар тарих фәннәре докторы, профессор Разия Мөэминованың кызы дип тә беләләр. Әлеге гаиләдә берсеннән берсе талантлы дүрт бала үскән. Олы уллары Шамил – молекуляр биология профессоры, Гарвард университетында эшли. Икенче уллары Усман Мәскәүдә яши, ул компьютерлар белгече, Мәскәү физика-инженерлык университетын тәмамлаган. Кече уллары Али – Алманиянең Карлсруэ Технология институты профессоры, кызлары Зөлфия, моннан 7 ел элек Мюнхен университетында диссертация яклап, медицина докторы гыйльми дәрәҗәсен ала, зур конкурс узып, Берлин университетының атаклы Шаритэ клиникасына эшкә урнаша, элек дәвалап булмый дип исәпләнгән үпкәдәге генетик авыруларны дәвалау белән шөгыльләнә.

Аларның һәрберсе – татар дөньясының, татар фәненең горурланырлык шәхесләре! Киң карашлы, гыйлемнең төрле өлкәләрендә мәгълүматлы, иҗтимагый, гуманитар фәннәрнең дә төрле тармакларыннан хәбәрдар, татар дөньясының проблемаларын да үзенеке кебек кабул итә торган Рәшит Сүнәевнең балалары да шундый ук максатчан шәхесләр итеп тәрбияләнгәннәр! Фәннең иң катлаулы, иң абруйлы өлкәләрендә иң югары казанышларга ирешкән Рәшит Али улы Сүнәев аларны татар булулары белән горурланырга өйрәткән.

Шамил һәм Али Сүнәевләрнең үзләре сайлаган юнәлешләрдә ирешкән уңышлары хакында бүген фән дөньясында күп сөйләнә. Аларның казанышлары – галимнең улларын үз өлкәсеннән «җитәкләп бармавын», ә инде яшь буын Сүнәевләрнең, үз чиратында, фәнгә бирелгәнлеген һәм анда үз юлын табарга омтылуын, галиҗәнап гыйлемгә хезмәт итүне мөһим санавын тагын бер кат күрсәтә.

Рәшит Али улы Сүнәевнең олы улы Шамил, һөнәри яктан караганда, гыйлемдә бөтенләй үзгә юл сайлый: биология, аның да заманча юнәлеше – генетика. Бүген ул – Гарвард медицина мәктәбенең исәпләү геномикасы һәм медицина профессоры, Брайгхем клиникасындагы тикшеренү лабораториясе җитәкчесе, Гарвард университеты һәм Массачусет технология институтының Берләштерелгән институтының ассоциацияләнгән әгъзасы. Әмма физик методларны Галәмне өйрәнүгә хезмәт иттергән мәшһүр әтисе кебек үк, Шамил дә физика ысулларын биология-медицина өлкәләрдә кулланып, ачышлар ясаучы галим булып җитешә.

Мәскәү Физика-техника институтының физика-химия биологиясе факультетын тәгәлләп, ул 1997 елны «Аминокислоталар эзлеклелеге буенча аксым глобуласының урнашуын ачыклау мәсьәләсенә статистик якын килү» дигән темага физика-математика фәннәре буенча кандидатлык диссертациясен яклый. Аннары Германиянең Гейдельберг шәһәрендәге Европа молекуляр-биология лабораториясендә (EMBL) Пир Борк кул астында укуын дәвам итә. Геннардагы мутацияләрнең сәбәпләрен эзләүне ул геном мәгълүматларын статистик тикшерү рәвешендә алып бара.

2004 елга төрле җан ияләрендә күзәтелә торган мутацияләрне үзара чагыштыру мөмкинлеге туа. Шамил Сүнәев ачкан һәм тикшерүләр алып барган асимметрия күренеше авыру китереп чыгара торган геномны (әйтик, «инфаркт өчен җавап бирүче геномны») ачыкларга да, мутацияләргә китергән механизмнарны билгеләргә дә, күзәнәкләрдә ДНКның «хаталы» урыннарын күзәтү һәм төзәтү өчен «җайланмаларны» да, популяциядә мутациянең ныгып калуы һәм таралуы сәбәпләрен дә ачыкларга ярдәм итә.

Бүген Шамил Сүнәев җитәкләгән лаборатория кешедәге генетик үзгәрешләргә (мутациягә) аксым вазифасының һәм структурасының тәэсирен компьютер фаразлау методлары ярдәмендә дәлилләү белән шөгыльләнә. Биредә ДНКның шәхси эзлеклелегенә тулы геном анализы ясала. Лаборатория, шулай ук, генетик үзгәрешләрне анализлауга караган медицина проектлары эшләүдә дә актив катнаша.

Шамил Сүнәев – Россиядә һәм чит илләрдә күп кенә фәнни оешмалар тарафыннан биоинформатика буенча лектор һәм эксперт буларак бик теләп чакырыла торган иң күренекле галимнәрдән исәпләнә. Аның ачышлары «Геном технологияләре» журналының яшь галимнәр өчен премиясенә, Pfizer корпорациясенең HDL холестеринны өйрәнү өчен бирелә торган Халыкара бүләгенә ия булды. Шамил Рәшит улының үз юлын сайлап, зур уңышларга ирешүе, күренекле Гарвард университетының профессоры дәрәҗәсен алуы – дөнья һәм илебез фәнендә үз тарихын яза башлаганлыгы турында сөйли.

Бабасы исемен горур йөртүче Али Рәшит улы Сүнәев – Карлсруэ технология институтында информатика буенча профессор, Гамәли информатика институты директоры. Шунысын да әйтергә кирәк: бу институтның даны да Гарвардныкыннан калышмый, ул Германиянең иң көчле өч техник вузы исемлегендә.

Али Рәшит улы 2010 елны диссертация яклап, сәламәтлек саклау өлкәсендә мәгълүмат системаларының куркынычсызлыгын анализлау методлары һәм аларны гамәли куллану темасы буенча философия докторы (PHD) фәнни дәрәҗәсен ала. Ул – программалар һәм мәгълүмати системаларын үстергәндә, бу эшнең техник һәм социаль якларын да исәпкә алу тарафдары. Аның фәнни эзләнүләре медицинада инновацион кушымталар, санау хезмәте, блокчейн, информацион технологияләр куркынычсызлыгы мәсьәләләрен үз эченә ала. 40 яше тулганчы ул Германиянең иң мәшһүр яшь информатиклары исемлегендә иде.

Шиксез: Рәшит Али улы Сүнәевнең гыйлем галәмендәге һәр йолдыз – үз уллары һәм кызымы ул, яки аспирантлары-докторантларымы – ераклардан күренерлек якты яна, бу яктылык, үз чиратында, кешеләрнең аң-фикерен, дөньяга карашын ачарлык булып, балкышы-җылылыгы белән күпләрне фәнгә җәлеп итәргә сәләтле. Күрәсең, чын мәгънәсендә галимлек эталоны булган остазның үрнәге бу.

1 мартта татар халкының горурлыгы булган күренекле милләттәшебезгә 80 яшь тула. Без дә журнал укучылары исеменнән Рәшит Али улы Сүнәевне юбилее белән ихластан котлыйбыз, аңа ныклы сәламәтлек, барлык фаразларының, планнарының, күзаллаганнарының тормышка ашуын телибез.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

# ТАТАР СӘҮДӘГӘРЛӘРЕ ИСЛАМ ДИНЕН ТАРАТУ СИСТЕМАСЫНДА

***(XVIII гасырның икенче яртысы – XIX гасырның беренче яртысы)***

## Татар сәүдәгәрләре катламы оешу

XVI гасырның икенче яртысы – XVII йөздә татарлар арасында сәүдә белән шөгыльләнүчеләр булмаган түгел. Әйтик, күпсанлы Казан кирмәне гарнизонына кышка азык-төлекне татар алыпсатарлары туплап биргән. 1685 елда йомышлы татарларга чит төбәкләргә барып сәүдә итүдә чикләүләр алынган. Хакимиятнең 1724 елда морзаларны крестьян итеп язганын, 1789 елда Мәхкәмәи шәргыя оешканнан соң гына Идел-Чулман төбәгендә мөселман руханиларының рәсми статус алуларын искәртсәң, сәүдә итүче йомышлы татарлар мөселман җәмгыятендәге дәүләт тарафыннан танылган бердәнбер беркадәр өстенлекле социаль төркем булып чыга.

Татарларда сәүдәгәрләр катламы оешу Россиянең Урта Азия һәм Казакъ җөзләре белән икътисади һәм сәяси мөнәсәбәтләрне җайга салуына һәм үстерүенә турыдан-туры бәйле.

1734 елда казакълар һәм Урта Азия сәүдәгәрләре белән сәүдә-икътисади мөнәсәбәтләрне тәртипкә салу максатыннан, Оренбург экспедициясе оештырыла, Оренбург шәһәренә нигез салына. Рус сәүдәгәрләрен кәрван юлы белән Урта Азиягә җибәрә алмагач, бу җаваплы эшне башкарырга Идел-Чулман төбәгендә яшәгән татарларны җәлеп итәләр. Ягъни сәүдә итүчеләрнең социаль нигезе киңәя. Крестьяннар да, гомумән, актив, тырыш һәм максатчан һәр кеше Казакъ даласы ягына китеп, тормышын яхшырту мөмкинлеген алган. Шушы төбәктә инде сәүдә итеп танылган Сәгыйт Хәялин 1744 елның җәендә, Казан губернасының Байлар Сабасыннан авылдашларын туплап, Оренбург кирмәненнән 18 чакрым ераклыктагы Каргалы елгасы буенда Каргалы авылын нигезләргә хокук ала. Яңа җәмгыятькә 64 мең дисәтинә җир бүлеп бирелә, вәкилләре рекрут хезмәтеннән азат ителә. Каргалыны нигезләү бу төбәктә татар сәүдә колониясен төзүдә, Урта Азия белән сәүдә бәйләнешләре урнаштыруда зур вакыйга була. 1747 елны бередә 142 хуҗалык көн күргәне билгеле *(Сеитов посад: Очерки истории Оренбургской (Татарской) Каргалы / Рашид Искандаров, Анвар Искандаров. Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. С.18, 19).*

Кәрван сәүдәсе табышлы, ләкин куркыныч шөгыль була. Бай татар сәүдәгәрләре Урта Азия шәһәрләренә ватандашларын приказчик яки йөкче итеп кәрваннар җибәргәннәр. Шулай да күпчелек татарлар кәрванбашы яки йөкче булып, рус сәүдәгәрләренә, хөкүмәт кәрваннарына ялланганнар. Алар, шулай ук, үзләренә файдалы шартларда Сәгыйт бистәсендә һәм башка кирмәннәр янындагы татар бистәләрендә яшәүче Хива һәм Бохара сәүдәгәрләренең приказчиклары булып та хезмәт иткәннәр, Россия ярминкәләрендә арадашчы ролен үтәгәннәр.

Татарлар, конкуренция булмаган шартларда Казакъ даласында көнкүреш

әйберләрен һәм хуҗалык итү коралларын ваклап сатуны үз кулларына җыеп, гаять зур табыш алганнар.

Халыкара сәүдәдән һәм ил базарында товар сатудан кергән табышлар, мануфактуралар оештырганда, финанс нигезе булып торган. Эшмәкәрләр XIX йөз башында тире һәм текстиль товарлары әзерләүдә, сабын кайнатуда җитештерүдән – сатуга кадәр тулы циклны башкарганнар. Моның өчен татар эшкуарлары Казакъ даласында арзан гына бәягә сарыкның эч маен һәм эшкәртелмәгән тире, Урта Азиядән киҗе-мамык җепләр сатып алганнар, әзер продукцияне кире Казакъ даласына яисә Россия ярминкәләренә, алмашу ярминкәләренә китергәннәр, шулай ук чит илләргә дә чыгарганнар, яхшы табыш алганнар.

1775 елда Россиядә рәсми рәвештә сәүдәгәрләр үз өстенлекләре һәм бурычлары булган мөстәкыйль сословие булып оеша. Билгеле бер күләмдә акча түләп, алар рекрутлык йөкләмәсеннән, махсус салым исәбенә – җан башына салына торган салымнан да азат ителгәннәр. Гильдия сәүдәгәре булыр өчен билгеле бер капиталга ия булу мәҗбүри саналган, аның суммасын хөкүмәт билгеләгән. Шәһәрләрдә вак сәүдәгәрләр мещаннар сословиесенә язылганнар.

Туң май эретү үзәкләре булып Урал буенда Оренбург һәм Троицк шәһәрләре торган. Туң май Архангельск һәм Санкт-Петербург аша чит илләргә дә чыгарылган.

Татар сәүдәгәрләре киҗе-мамык тукыма өчен җепләрне һәм мануфактура осталарын Урта Азиядән алып кайтканнар. Икенче төрле әйткәндә, эшне чит ил чималын һәм технологиясен кулланып оештырганнар. XIX йөзнең беренче 15 елында татар киҗе-мамык мануфактураларының саны 25тән 42гә кадәр арта; яртысы Әстерханда урнашкан була. Дөрес, алар, Казан һәм Вятка губерналары авылларындагы мануфактуралар белән чагыштырганда, зур булмыйлар. 1814 елны Казан губернасында татарларның 9 туку мануфактуралары эшли, 319 станокта 590 эшче хезмәт куя. Алар карамагында илдәге туку станокларының 55,3 %ы туплана, җитештерелгән комачның 75,2 %ы базарга чыгарыла, 514000 аршин комач яки илдәге барлык киҗе-мамык тукыманың 34 %ы җитештерелә *(Гобәйдуллин Г.Тарихи сәхифәләр ачылганда. Казан: Татар.кит. нәшр., 1989. 259-260 б).*

Тире иләү татар сәнәгатендә төп җитештерү тармагына әверелә. Аларның мануфактуралары базарга 1815 елда, XVIII гасыр ахыры белән чагыштырганда 24-25 мең данә урынына, 111 мең данә иләнгән сыер, тана, сарык, кәҗә тиреләрен сатарга чыгарганнар. XIX гасыр уртасында Урал алдында Эстәрлетамак (1849 елны – 14 мануфактура) һәм Троицк (7 мануфактура) тире иләү үзәкләре исәпләнгән. Урта Идел буенда бу шөгыль Казанда һәм шәһәр яны авылларында киң җәелгән. Казанда Якуп Габбасов мануфактурасы елга 20 мең, Муса Апанаевныкы 13 мең тире иләгән.

Казанда сабын һәм шәм җитештерүнең мөстәкыйль сәнәгать тармагына әверелүе шәһәрнең туң майны төрле төбәкләргә озату үзәге булуы белән бәйле. Әле XVIII йөз ахырында ук шәһәрдә 3 сыер һәм сарык эч маен эретү предприятиеләре эшләгән, шуларның икесен татарлар тоткан. 1850 елларда Казанда 13 шәм җитештерүче предприятиенең җидесенә татарлар хуҗа булган.

1815 елда XVIII гасыр ахыры белән чагыштырганда, 2,5 тапкыр күбрәк, ягъни 50 мең пот товар җитештергәннәр. Казан губернасында сабын кайнату мануфактураларының күбесе татарлар кулында булган. 1812 елны Казан шәһәрендә аларның 12 сабын кайнату мануфактурасында (52 %) 90 эшче елга 59960 пот товар (47 %) җитештергән. Фәкать 1840 елларда Казан губернасында сабын кайнату тармагы Россиянең үзәк губерналары мануфактураларының арзанлы һәм яхшырак сыйфатлы сабыны белән конкуренциядә җиңелә һәм түбән тәгәри.

1816 елда татарларның кулындагы поташ җитештерү мануфактураларының саны дүрт дистәдән артып китеп, аларның 27се – Оренбург, 7се – Вятка, 6сы Казан губерналарында эшләгән.

XIX гасырның беренче чирегендә яңа җитештерү тармаклары пәйда була: 1815 елда Мөэмин Хуҗасәетов Уньжа авылында 37 эшче яллап, язу һәм әйбер төрү өчен кәгазь җитештерә башлый. 1816 елда Вятка губернасының Уржум өязендә берсендә – 11, икенчесендә 15 эшче хезмәте кулланылган тагын ике шундый мануфактура ачыла. Тимербулат Акчурин 1818 һәм 1825 елларда Сембер губернасында йон тукыма җитештерүче 1300 эшче ялланып хезмәт куйган ике мануфактура көйләп җибәрә.

1812 елда Франция белән сугыш башлану йогынтысында моңарчы туктап торган Әсәфулла Иноземцевның бакыр чыгару мануфактурасы эшли башлый. 1825 елда биредә 445 эшче хезмәте кулланыла *(Хасанов Х.Х. Формирование татарской буржуазии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1977. С. 85-86, 87).*

1842 елдан соң Англиядән туку станокларын алып чыгуны тыю бетерелә һәм Россиядә туку сәнәгате кызу темплар белән үсә башлый. Татар мануфактуралары Мәскәү тирәсендәге туку фабрикалары белән ярыша алмыйча, 1840 нчы елларда, нигездә, китайка гына җитештерүгә күчәләр.

XVIII–XIX гасырлар чигендә татар-мөселман җәмгыяте социаль структурасында яңа – ярым өстенлекле, бай һәм дини мәнфәгатьләргә карата битараф булмаган – сәүдәгәрләр катламы формалашуы ачык күренә.

Беренче чиратта, мондый үзгәреш хөкүмәтнең татарларга Көнчыгыш базарында сәүдә итәргә мөмкинлек бирүче протекциясе – уңай шартлар тудыруы һәм татар эшмәкәрләренең бирелгән шанстан тиешенчә файдалануы нәтиҗәсе була. Илдә фәкать I гильдия сәүдәгәрләргә генә чит илләр белән сату-алу итәргә хокук бирелсә, татар эшмәкәрләренең җитәрлек капиталлары һәм рәсми хокуклары булмаса да, хөкүмәт рөхсәте белән мещаны да, II, III гильдия сәүдәгәре дә чит илләр белән сәүдә итә алган. Татарларның алмашу ярминкәләре янына килеп урнашулары эшмәкәрләрнең, бер яктан, таралып яшәү даирәсен, икенче яктан, аларның сату базарын Казакъ даласы, Урта Азия хисабына киңәйтә. Шул төбәкләрдән кертелгән арзанлы чимал хисабына, үзләренең мануфактураларында эшләнгән сабыннары, шәмнәре, комач тукымалары, иләнгән тиреләре шулай ук сугым урыннарында мичкәләргә тутырылган тозланган итләре һәм туң майлары Россия базарында соралган товар булып, өстәмә табыш алу чыганагын хасил итә. Ул да түгел, Идел-Чулман төбәгеннән күченгән игенчеләр көньяк-көнчыгыш чик буйларында урнашкан рус кирмәннәре янында бистәләр нигезләп, шәһәр халкы буларак яши башлый.

Үзбәк, казакъ белән янәшә яки бер торак пунктында диаспора булып урнашкан татарлар арасында төбәкчелек элемтәләре һәм этник берләшү көчәя. Эшмәкәрләр үзләренә ярдәмгә төрле эшләр башкару өчен туганнарын, шулай ук авылдашларын һәм өязләреннән милләттәшләрен чакырганнар. Алар исә, беркадәр акча туплагач, үзләре дә вак сәүдә белән шөгыльләнә башлаган. *(Кореева Н.А. Торгово-промышленная деятельность татарского купечества Казанской губернии в последней четверти XVIII – первой половине XIX в. Казань ОСП «Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ», 2019. С.275-276).*

## Алмашу ярминкәләре һәм ярминкәләр – алыпсатарларның аралашу урыннары

Россиянең көньяк-көнчыгыш чигендә кирмән-шәһәрләр төзү рус-казакъ сәүдә челтәрләре киңәю белән дә бәйле була. Кече җөз казакълары өчен географик яктан иң уңайлы сәүдә урыннары булып Оренбург һәм Җаек (Уральск), ә Олы җөз халкы өчен – Троицк, Кызылъяр (Петропавловск), Омск, Усть-Каменогорск һәм Семей (Семипалатинск) кирмәннәре торган.

1758 елда төзелгән Оренбург алмашу ярминкәсенең 1810 елларга кадәр Россиядәге иң эре сәүдә мәйданы булуы аның ил икътисадында тоткан урыны турында сөйли.

1764 елгы мәгълүматларга караганда, алыш-биреш итүдә сан ягыннан беренче урынны (барлыгы 109 сәүдәгәр һәм 77 приказчик) Сәгыйт бистәсе (38 сәүдәгәр), Казан (20 сәүдәгәр һәм 20 приказчик) һәм Касыйм (13 сәүдәгәр һәм 27 приказчик) татарлары алып торган. Алар барлык сәүдәгәрләрнең 65 %ын, приказчикларның 58 % ын тәшкил иткән. XVIII гасырның 60 нчы елларыннан башлап, рус сәүдәгәрләре товар төяп алмашу ярминкәсенә үзләре килүдән туктыйлар, бу эшне Сәгыйт бистәсе татарларыннан торган арадашчыларга тапшыралар.

Сәүдә мөнәсәбәтләренең Россия өчен әһәмиятен яхшы аңлаган Екатерина II 1782 ел 25 февраль Указы белән Оренбург, Кызылъяр, Троицк алмашу ярминкәләрендә һәм Верхнеуральск кирмәне янында казна исәбенә таштан мәчетләр төзергә боера. Шуларның беренче өчесендә таштан казна мәчетләре корыла.

Алмашу ярминкәләрендә татарларның алыш-биреш итүчеләр арасында күпчелекне тәшкил итүе дистә еллар дәвамында күзәтелә. Хөкүмәт 1755-1807 елларда ярминкәләргә чит ил сәүдәгәрләрен кертми, мондый сәясәт татарлар өчен бик файдалы була: алар илнең чигендә урнашкан алмашу ярминкәләре белән эре Россия ярминкәләре арасында Урта Азия сәүдәгәрләренең арадашчыларына әвереләләр.

Ярминкә кенәгәләрендә һәр губернадан ничә сәүдәгәр килгәнлеге (аларның һәрберсе үзләренең приказчиклары һәм йөкчеләре белән) теркәлгән. Әйтик, 1804 елны Мәкәрҗә ярминкәсендә Казан губернасыннан (күбесе Казаннан) 66 татар сәүдәгәре (араларында мещаннар һ.б. да булган) 96 сату урынын арендага алган, 1820 елда 116 (сату урыннары 118) булган *(Кореева Н.А. Күрс. хезмәт. 292 б.).*

Берәр ай дәвамында барган ярминкәләрдә татарларга сату урыннары бер тирәдә бирелгән. Туган телдә аралашу ихтыяҗы, хәләл ризык белән туклану, бишвакыт намаз уку зарурлыгы аларны яшәү урынын бергәләп арендага алырга мәҗбүр иткән. XVIII гасыр ахыры – XIX йөз башында Мәкәрҗә ярминкәсендә татар сәүдәгәрләренең мәчетләре агач кайрыларыннан эшләнгән булган. XVIII гасыр ахырында мөфти М.Хөсәенов ярминкә вакытында мулла итеп үзенең туганы Фәтхулланы җибәргән. 1800 еллар башында Хәбибулла Габделкәримов, шикаятьләр язып, Түбән Новгород губерна идарәсеннән үзен билгеләтүгә ирешкән *(Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан: Татар.кит.нәшр.1989. 260-263 б.).* Шушы заманнан башлап, һәр елны ярминкәгә Мәхкәмәи шәргыя мулла билгеләгән. Руханилар ярминкә имам-хатыйбы булырга ашкынып, атлыгып торганнар – сәүдәгәрләр сәдаканы мулдан биргән.

1816 елгы янгыннан соң, ярминкә урыны Мәкәрҗәдән Түбән Новгород шәһәре янына күчерелгән. Хөкүмәт яңа урында 1827 елны таштан «татар мәчете» төзетә. Мәрҗани биредә мәчет 1822 елдан булган дип яза. Бу вакытта ярминкә 15 июльдән 15 августка кадәр үткән.

1850 еллар ахырында ярминкәдә теркәлгән 15 мең сатучының 215е Урта Азиядән, 300е татар булган. Алардан тыш, ярминкәгә меңләп мөселман килгән.

1850–1860 елларда ярминкә халыкара сәүдә үзәге булудан туктап, төбәк ярминкәсенә әверелгән (*Сенюткина О.Н., Загидуллин И.К. Нижегородская ярмарочная мечеть – центр общения татарских и зарубежных мусульман. Нижний Новгород: изд-во НИМ «Махинур», 2006. С. 19-42, 51, 62).*

Татар сәүдәгәрләре, шулай ук, товар әйләнеше буенча илдә икенче урынны тоткан, ел саен 25 гыйнвардан 1 мартка кадәр эшли торган Эрбет ярминкәсендә бик актив катнашканнар. Николай I, аларның үтенечен канәгатьләндереп, 1850 елның 18 гыйнварында Пермь губернаторы җибәргән булачак мәчет планын раслаган. Шушы елдан Мәхкәмәи шәргыя Эрбет ярминкәсенә дә имам-хатыйп җибәрә башлаган. Ләкин кирәкле сумма җыелмау сәбәпле, мәчет төзелмәгән. Аптырагач, мөфти С.Тәфкилев Казан бае Исхак Юнысовтан кире кайтарып бирү шарты белән 4 мең сум акча алып, шуңа ярминкәдән ерак түгел урыннан 1867 елда мәчет өчен ике катлы йорт сатып

алдыра һәм биредә җәмәгать намазлары уку башлана *(Загидуллин И.К. Мусульманское богослужение в учреждениях Российской империи (Европейская часть России и Сибирь). Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2006. С. 409-413).*

Сәүдәгәрләр күп вакыт сәфәрдә булганнар. XIX гасыр урталарында Түбән Новгород ярминкәсе тәмамлангач, товарлары белән Бөгелмәдәге Воздвиженск ярминкәсенә килгәннәр (14-22 сентябрь). Аннан Оренбургка юл тотканнар *(Свердлова Л.М. Ярмарочная торговля на Великом Волжском пути // Великий Волжский путь: прошлое, настоящее, будущее / Под ред. А.Г.Гранберга. Казань, 2005. С. 146).*

1798 елда атлар сату ярминкәсе сыйфатында Минзәлә шәһәрендә ярминкә эшли башлый. Ул тиз арада Казан һәм Оренбург губерналары алыпсатарлары өчен төбәк ярминкәсенә әверелә *(Гурвич Н. Ярмарки, к истории ярмарок вообще и к статистике ярмарок в Уфимской губернии. Уфа: Губерн. тип-я, 1884. С. 41).*

XVIII-XIX гасырлар чигендә Казанның татар сәүдәгәрләре берләшеп, бертуган Апанаевлар, Крупенниковлар, Котеловлар, Й.Китаев, М.Якупов, Ю.Ф. Арсаев, Г.Юнысов төбәктәге мануфактуралар продукциясен Кяхтага илтеп, аны кытайлардан чәйгә, фарфор фаянска һәм дөгегә алыштырганнар, чит ил товарын Мәкәрҗә ярминкәсендә сатып, зур табыш алганнар. 1809 елдан Кяхтада фәкать I гильдия сәүдәгәрләре генә алыш-биреш итә алган. Чәй сатучылар иң бай сәүдәгәрләрдән саналганнар *(Свердлова Л.М. Казанское купечество: социально-экономический портрет (кон. XVIII – начало XX в.). Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. С. 70-71).*

Берәр ай чамасы дәвам иткән ярминкәләр татар эшмәкәрләренең үзара аралашу, дөнья яңалыкларын, дин, милләт мәсьәләләре турында сөйләшү урыны булган. Шул ук вакытта ярминкәләргә яңа мәчет, мәдрәсә төзү яки янганы урынына икенчесен кору артыннан йөрүчеләр, Урта Азиягә укырга китүче шәкертләр һ.б. килгән. Мондый кешеләргә ярдәм итү сәүдәгәрләрнең мөселман җәмгыяте өчен җаваплылык хисен арттырган.

## XVIII гасыр ахыры татар-мөселман шәһәрләре

XVIII гасырның икенче яртысы – XIX йөзнең беренче яртысында татар шәһәр җәмгыятьләре оешу, нигездә, Урта Азия дәүләтләре һәм Казакъ даласында сәүдә итүнең нәтиҗәсе буларак күзаллана. Аларны оештыруда, йортлар, кибетләр, кунакханәләр, мәчет-мәдрәсәләр төзеп, татар бистәләрен формалаштыруда бай сәүдәгәрләр гаять зур роль уйнаган. Шәһәр бистәләрендә берничә мәхәлләдән торган бердәм дини-мәдәни җәмгыять руслар белән күршеләр сыйфатында, башка милләт вәкилләренең тормыш рәвешен күреп, алар белән беркадәр аралашып яшәгәннәр, русча да өйрәнгәннәр.

***Сәгыйт бистәсе.*** Татарларны күчерү турында 1744 ел 8 март указы белән Каргалы елгасы буенда нигезләнгән авыл 1784 елдан Сәгыйт бистәсе дип атала башлый, шул ук елны биредә шәһәр идарә органы – Татар ратушасы ачыла. 1792 елда бистәдә 2674 ир-ат теркәлеп, шуларның 1810сы сәүдәгәр катламына, 168е мещан катламына язылган була *(Гобәйдуллин Г. Күрс. хезмәт. 249 б.)*. Биредә Урта Азиядән килгән сәүдәгәрләр дә (1825 елда 130 гаилә) төпләнеп яши башлый. *(Сеитов посад: Очерки истории Оренбургской (Татарской) Каргалы. С. 24).*

1816 елда уздырылган VII ревизия материалларында 1090 сәүдәгәр кулында 230 мең сум капитал булганы ачыкланган. Чынлыкта, татар сәүдәгәрләре барлык капиталларын күрсәтергә ашкынып тормаганнар.

1811-1812 елларда бистәдә 28 таш һәм 17 агач сәүдә итү урыннары булган Гостиный двор корыла. *(Сеитов посад: Очерки истории Оренбургской (Татарской) Каргалы... С. 24, 56)*.

Сәгыйт бистәсе – XVIII гасырның икенче яртысында үзенең мәдрәсәләре һәм мөдәррисләре эшчәнлеге белән татарларда дини мәгариф үсешенә гаять зур өлеш

керткән татар каласы. Бу шәһәртне Көньяк Кавказдан күченеп килеп, биредә 1775 елга кадәр яшәгән, дәрес әйткән Мөхәммәд бине әд-Дагыстани һәм аның шәкертләре тудыралар *(Мәрҗани Ш. Күрс. хезмәт. 243-244 б.)*.

Биредә беренче мәчет – 1749, икенчесе – 1775, өченчесе – 1795, дүртенчесе – 1802, бишенчесе, алтынчысы, җиденчесе 1816 елда төзелә. XIX гасыр башында бистәнең уку йортлары арасында аерылып, 1 нче җәмигъ мәчет каршындагы таш бинада Багдадтан килгән мулла Әбурахшан укыткан, 2 нче мәчет каршындагы ике агач йортта мөфти М. Хөсәеновның кияве ахун Мәүлит Башков белем биргән. Шулай ук 3 нче мәчет каршындагы Мөхәммәт Әмин мәдрәсәсе дан тоткан. Аларның һәрберсендә 150шәр шәкерт, 4 нче мәчет каршындагы ахун Габдрәшит Габдуллин мәдрәсәсендә 100 ләп малай һәм яшүсмер белем алган.

Татар ратушасы Сәгыйт бистәсендә 1838 елга кадәр эшләп килә. Татарлар салым җыю белән бәйле эш кәгазьләрен тиешенчә алып бармау сәбәпле, хакимият аны яба. 1857 елны Сәгыйт бистәсендә 8 мең татар-мөселман яши.

***Казан.*** XVIII-XIX гасырлар чигендә Россиядә тагын бер татар сәүдә шәһәре Казанның Иске һәм Яңа Бистәләрендә оеша. 1789–1791 елларда Казанда 10 татар II гильдия сәүдәгәре булып язылган: М.Габдерәшитов, У.Баязитов, Г.Исхаков, А.Мәсагутов, Г.Мөслимов, В.Мөслимов, С.Нәзиров, Х.Сәгыйтов, У.Үрәзмәтов, М.Үтәмешев. III гильдиягә язылучыларның саны берничә тапкыр күбрәк була *(https://tatarica.org/ru/razdely/istoriya/novoe-vremya/kupechestvo Онлайн - энциклопедия Tatarica)*.

1805 елда беренче тапкыр 2 татар эшмәкәре I гильдия сәүдәгәре булып языла, бу елны Казанда һәммәсе 150 татар сәүдәгәре хисаплана (Кореева, *Күрс. хезмәт.138 б.*).

1800 елда татар сәүдәгәрләренең игълан ителгән капиталлары 553549 сум булса, 1805 елга ике тапкыр диярлек – 909460 сумга кадәр үсә. 1808 елда алдагы дәвер белән чагыштырганда, сәүдәгәрләр гаиләсенең саны 44тән 36га кими. Бу кимү гильдиягә язылу өчен капитал минимумы артуга бәйле була. Чынлыкта алар игълан иткән капиталларның күләме 2,2 тапкыр арта. *(Кореева Н.А. Күрс. хезмәт. 138-139 б.)*.

Кайбер татар сәүдәгәрләре гильдия алгач та туган авылларында яшәүне өстен күргәннәр. Күрәсең, шул рәвешле авылларда урнашкан мануфактуралары белән җитәкчелек иткәннәр *(Кореева Н.А. Күрс. хезмәт. 146 б.)*.

1841-1842 еллардагы рәсми мәгълүматларга караганда, Казанда 5 гаилә I гильдия сәүдәгәре булып язылган, 3 гаилә – II, 68 гаилә III гильдия сәүдәгәрләре булып теркәлгән. 1840 нчы еллар башында губерна каласында 2112 ир-ат һәм 2309 хатын-кыз исәпләнгән *(Фукс К. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Краткая история города Казани. Репринтное воспроизведение. Казань: Фонд ТЯК, 1991. С. 15)*. 1857 елда Казанда 6857 татар яшәгән (*Исхаков Д.М. Историческая демография татарского народа. Казань, 2014. Табл.12. С. 135)*.

Иске һәм Яңа Татар бистәләрендә 1781-1855 елларда магистрат белән янәшә мөстәкыйль шәһәр үзидарәсе органы – Татар шәһәр ратушасы эшли. Ул кешеләрне сәүдәгәр һәм мещан сословиеләренә беркетү, сәүдә таныклыклары бирү, салымнар җыю һәм башка хуҗалык һәм идарә эшләре белән шөгыльләнә; башкарма хакимият буларак, дәүләт органнары алдында җавап тота.

Бистәләрдә, шулай ук, шәһәр инфраструктурасы өчен кирәкле барлык урыннар булдырыла: шәркый Печән базары, Юныс мәйданы, миһманханәләр, куну-туктау урыннары, сәнәгать предприятиеләре, мастерскойлар, мәчетләр, мәктәп-мәдрәсәләр, сәүдә урыннары шундыйлардан. 1857 елны җәмгысе 127 предприятиенең өчтән бере татарларныкы булып теркәлә *(Загидуллин И.К., Свердлова Л.М. Казань // История татар с древнейших времен. В 7 т. Т.6. Казань, 2013. С.75 – 76)*.

1810 елда Казанда мәчетләр саны 11гә җитә. *(Кемпер. Күрс. хезмәт.95 б.)*. К. Фукс ураза вакытында берәр татар ашап тотылса, аны дин кардәшләре шундук тотып,

мулла янына китерүләре, мулланың гаепленең битен буяп, урамга куып чыгаруы, ә урамда башка татарларның аңа таяк белән сугулары яисә теге кеше качып киткәнче пычрак атулары, шул рәвешле дини тәртипне бозучыга тискәре мөнәсәбәт белдерүләре хакында яза.

## XIX гасыр беренче яртысындагы татар шәһәр-бистәләре

Идел-Урал төбәгендә V ревизия (1795 ел) материалларында татарларның Идел-Урал төбәгендәге 15 шәһәрдә яшәгәнлеге күренә: Казан – 2760, Чистай – 793 (Казан губ.), Касыйм (Рязань губ.) – 444, Түбән Новгород – 118, Буа (Сембер губ.) – 36, Хвалын (Саратов губ.) – 59, Кузнецк (Саратов губ.) – 17, Сәет бистәсе – 6481, Троицк – 40, Верхнеуральск – 16, Чиләбе – 14, Оренбург – 10, Уфа – 30, Бәләбәй – 4, Бөгелмә – 26 (Оренбург губ.) (*Исхаков Д.М. Историческая демография татарского народа. Казань, 2014. Табл.12. С. 134 – 137).*

XIX гасырның беренче яртысында төбәкнең якынча 30лап өяз административ үзәкләрендә татар крестьяннары арасында шәһәрләргә күченү һәм мещан сословиесенә язылу башлана. Бу чорда актив шәһәрләшү, бигрәк тә, өязләрдә күзәтелә. 1857 елга татарлар саны Касыймда (709 кеше), Чистайда (2090 кеше), Троицкида (1144 кеше), Эстәрлетамакта (2303 кеше), Верхнеуральскида (623 кеше), Бәләбәйдә (619 кеше) һәм Тәтештә (400 кеше) арта (*Исхаков Д.М. Күрс. хезмәт. Табл.12. 134, 137 б.).*

Шәһәрләшү күрсәткечләре яңа шәһәр мөселман мәхәлләләре оешуда да аермачык күренеп тора. Идел-Кама төбәгендә 1861 елга кадәр яңа мәхәлләләр Сембер һәм Самарада, өяз шәһәрләреннән, Вольск, Хвалында (Саратов губ.), Алабугада (Вятка губ.), Чистай, Тәтештә (Казан губ.) теркәлә.

Бу үзгәрешләр Идел-Урал төбәгендә шәһәр татарларының гомуми саннарында да чагылыш таба. Әйтик, 1782 елны алар 8,7 мең кеше (1,7 %) булса, 1857 елга 29,7 меңгә (2%) җитә. Бу саннарга Көнбатыш Себер һәм Казакъ даласы шәһәрләрендә яшәгән татарлар керми.

Казан һәм Сәгыйт бистәләреннән тыш, XIX гасырның беренче яртысындагы татар-мөселман шәһәрләре исемлегенә без, беренче чиратта, Әстерханны кертәбез. Биредә 1857 елда 13,9 мең татар-мөселман яшәгән. Алар арасында Урта Идел төбәгеннән һәм Рязань губернасыннан күченгән мөселманнардан (59%) тыш, XVIII гасырдан биредә көн күргән татарлашып бетеп баручы Бохарадан, Һиндстаннан, Фарсы төбәгеннән килгән сәүдәгәрләр төркеме һәм җирле юрт татарлары да исәпләнгән. *(Исхаков Д.М. Астраханские татары: этнические состав, расселение и динамика численности в XVIII – начале XX вв.// Астраханские татары. Сб. статей. Казань: ИЯЛИ им.Ш.Ибрагимова, 1992. С. 25-25).*

Шулай ук бу исемлеккә Семей (Семипалатинск) һәм Кызылъяр (Петропавловск) кирмән-шәһәре янында урнашкан татар бистәләре керә: беренчесендә 1864 елда 7 мәчет эшләгән, икенчесендә 1850 еллар азагында 4 мәчет булган (*Загидуллин И.К. Особенности становления татарских общин в городах // История татар с древнейших времен. В 7 т. Т.6. Казань, 2013. С. 60-61).* Оренбург губернасының Троицки исемле өяз шәһәрләрендә дә татарлар тиз артып (1861 елда 4320 кеше), шәһәр җәмгыяте булып яши башлаган *(Денисов Д. Троицк // // История татар с древнейших времен. В 7 т. Т.6. Казань, 2013. С.85).* XIX гасырның икенче яртысында бу исемлеккә Оренбург һәм Орск, XIX гасыр ахырында Уфа калалары өстәлә.

XIX гасыр дәвамында шәһәр мәдрәсәләрендә укыткан мөдәррисләрнең даны тирә-якка тарала. Урал төбәгендәге һәм Казакъ даласында урнашкан шәһәр мәдрәсәләре башкорт һәм казакъ яшүсмерләрен укыту үзәкләре булып та хезмәт итә.

Татар-мөселман җәмгыятендә бай эшмәкәрләр, сәүдәгәрләр катламы оешу, беренче чиратта, империя хакимиятенең сәүдә итү өчен уңай хокукый нигез булдыруы, түбән

катлам вәкилләренә дә сәүдә белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирүдән гыйбарәт. Татарларны Урта Азия белән халыкара сәүдә өлкәсенә тартып кертү, сәүдәгәрләрнең санын һәм аларның кулында капитал туплауны нык тизләтергә мөмкинлек биргән.

Рус хакимиятен, чит дин вәкилләрен ятлар буларак кабул иткән, йомык тормыш рәвеше алып барган, нигездә, коллектив фикер сөреше белән яшәгән крестьян җәмгыятеннән чыгып, туган нигез, туган авыл кебек төшенчәләрне күңел түрендә йөрткән социаль яктан актив бу шәхесләрнең саны арту һәм аларның төрле шәһәрләргә таралып урнашуы татар эшмәкәрләр дөньясын барлыкка китерә.

Елның күп өлешен юлда, ярминкәдән ярминкәгә, каладан калага сәүдә эшләре йөртүче бу төркем вәкилләре рус хакимияте белән дә, башка дин тотучы эшмәкәрләр белән дә уртак тел табарга һәм хезмәттәшлек итәргә өйрәнә. Сәүдәгәрләр рус телен белүче, шулай ук язу танучы, дәүләт тәртипләреннән хәбәрдар төркем тәшкил иткән. Алар татар-мөселман җәмгыятенең яңа элитасына әйләнгәннәр. Йогынтылы бу төркем белән төбәк чиновниклары санлашкан. Аларның чиновникларга ришвәт биреп, шыпырт гына шәхси яки җәмәгать «эшләрен» үз мәнфәгатьләрендә хәл итү өчен акчалары булган. Сәүдәгәрләрнең мәчетләр, мәктәп-мәдрәсәләр төзү, авыр хәлгә тарган дин кардәшләренә, шәкертләргә ярдәм итү һ.б. кайгырту гамәлләре дини менталитетлы җәмгыятьтә Аллаһ ризалыгына тиенү һәм савап җыю өчен, ахирәткә күчкәч, оҗмахка эләгү өчен эшләнгән. Бер үк вакытта бу гамәлләрнең җәмгыять файдасына һәм җәмәгатьчелек мәнфәгатьләре өчен башкарылган булуы бәхәссез.

## Калаларда һәм салаларда мәчетләр төзү

Шулай итеп, яңа иҗтимагый шартларда татарларның социаль тәртипләрендә яңа чалымнар күзгә ташлана. Бу чалымнар бик ачык булып сәүдәгәрләрнең, эшмәкәрләрнең дини институтларга мөнәсәбәтендә күренә. Бу яңа күренешләр «дини активлык» дип атала *(Ислам и религиозный активизм в Республике Татарстан: коллективная монография. /Р.Ф. Патеев, Д.Р.Гильмутдинов, А.А.Закиров и др.; отв. ред. Т.Н. Липатова. Казань: Издательство АН РТ, 2021. С. 23).*

Бохарага, Хивага кәрван йөртә башлаган татарлар Урта Азия ханлыкларындагы иҗтимагый тормышны игътибар белән күзәтәләр. Дин мәнфәгатьләре өчен акча һәм милек сарыф итүче ислам дәүләтләре сәүдәгәрләре белән аралашалар. Дәүләттә һәм иҗтимагый тормышта дини гыйлемгә һәм гыйлем ияләренә хөрмәтле мөнәсәбәтне, гади халык арасында аларга карата булган олы ихтирамны күреп, туган илләренә шуңа омтылырга кирәклеге һәм корылырга тиешле үрнәк мөселман җәмгыяте моделе турында уйлап кайталар. Иң мөһиме – сәүдәгәрләрнең динле булырга омтылулары аларның күбрәк акча эшләү фикере белән тәңгәл килә. Уңышлы эш йөртү һәм файда өчен татар сәүдәгәрләреннән, үзбәкләр һәм таҗиклардагы югары катлам кешеләре кебек үк, дини һәм рухани гыйлемле булу таләп ителә, дип яза татар тарихчысы Г.Гобәйдуллин: «Шуңа күрә татарлар мәдрәсәләр ачалар, әдәби телләрне, барыннан да элек Урта Азиядә киң таралыш тапкан фарсы телен өйрәнәләр. Татар сәүдә капиталы урта гасырлардан үзгәрешсез килгән белем бирү методикасын («Ысулы кадим») куллануны таләп итә. Казандагы һәм аның тирәсендәге барлык мәдрәсәләрдә, Урта Азия белем бирү системасы белән бергә аның идеологиясе дә кабул ителә. Бу мәдрәсәләр соңрак татар мәдәнияте формалашуда зур роль уйныйлар. Башта мәдрәсә өчен дәреслекләр сәүдәгәрләр һәм шәкертләр тырышлыгы белән Бохарадан кайта. Бу китапларның халык өчен әһәмиятен акрынлап сәүдә капиталының югары катламнары да аңлый башлый».

Сәүдәгәрләрнең дини активлыгы, беренче чиратта, күпсанлы мәчетләр һәм мәктәп-мәдрәсәләр, чакыртылган муллаларга яшәү өчен йортлар салдыруда күренә. Карл Фукс 1845 елда Казан каласы мәчетләре Бохараныкы рәвешендә төзелгән дип

яза *(Фукс К. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. Краткая история города Казани Репринтное воспроизведение. Казань: Фонд ТЯК, 1991. 93 б.).*

Әйтергә кирәк, ул заманда яңа мәхәлләне теркәү фәкать яңа мәчет күтәрү юлы белән мөмкин булган: руханилар мәчеткә дип сайланган һәм хакимият тарафыннан билгеләнгән, шулай ук мәктәп-мәдрәсә дә шул Аллаһ йорты каршында ачылган, анда мөдир, мөгаллим яки мөдәррис булып шул мәчеткә беркетелгән имам-хатыйп торган.

Оренбург губернасында шәһәр мөселман мәхәлләләре оешу аеруча актив барган. XIX гасырның беренче яртысында татарлар Эстәрлетамакта (1800 ел), Уфада (1830), Соль-Илецкида (1833), Троицкида (1828, 1838), Уральскида (Җаек) (1861 елга – 2-әү), Сәгыйт бистәсендә (4 нчесе – 1802 елны, 5 һәм 6сы – 1816 да) яңа мәчетләр төзи. Урта Идел төбәгендә Самарада (1844), Хвалынскида, Чистайда (1830 елларда), Тәтештә (1850 елларның икенче яртысы) мәчетләр калка.

Мәчет төзү, шәһәр руханиларының тормышы турында кайгырту бай кешеләрне бистә халкының лидерына әверелдергән. Бигрәк тә яңа оешып килгән шәһәр мәхәлләсендә бай кешеләрнең булуы авыр чакта матди ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә дә мөмкинлек биргән. Зур шәһәр җәмгыятьләрендә һәр бай үзе намазга йөргән мәхәллә мәчетен кайгырткан. Шул рәвешле, бай катлам вәкилләре шәһәр шартларында дини институтларны финанслаучы булып танылганнар.

Сәүдәгәрләр һәр алыпсатарлар, авылларда тәрбияләнгән шәхесләр буларак, туган мәхәлләләрендә дә мәчетләр кордырганнар.

Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле хезмәтендә «Авыллардагы һәм тирә-яктагы мәчетләр турында бүлек» бар. Анда автор Татарстанның хәзерге Кукмара, Балтач, Арча, Әтнә һәм Саба районнарына кергән 12 авыл мәчетен төзү һәм төзекләндерү тарихларын бәян итә. Ул тасвирлаган мәчетләрне, нигездә, шушы авылда туган яки шушы төбәктән чыккан эшмәкәрләр, сәүдәгәрләр салдырган. Икенче игътибарга лаеклы күзәтү – байлар, янгын чыгып, агач мәчет бинасы көл булмасын өчен таш мәчетләр корырга омтылганнар.

Мәрҗани материалларын карап үтик.

Бәрәскәнең таш мәчетен шушы авыл кешесе мәшһүр сәүдәгәр Ибраһим Борнагол 1769 ел азагында төзетеп бетергән *(Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Татар. китап нәшр., 1989. 386-387 б.).*

Ашыт мәчетен 1796 елда Ишморад бине Мортаза бине Исмәгыйль бине Юныс бине Идрис төзеткән була. Шушы авылдан чыккан Семей (Семипалатинск) сәүдәгәре Хәсән бине Мөсәгыйдь бине Ибтәкеш бине Туктамыш бине Туктар 1859 елда гыйбадәтханә бинасын яңадан кордыра *(Шунда ук. 386 б.).*

Кышкардагы таш мәчетне авылның мәшһүр бае Баязид бине Госман бине Габделкадыйр әл-Кышкари 1776 елның ахырында төзетеп бетергән. Сәүдәгәр мәдрәсә бинасын да шушы вакытта кора. Аның вафатыннан соң, улы һәм оныгы Муса бине Нәзир һәм Мортаза бине Мостафа бине Нәзир – зур сәүдәгәрләр – бинаны төзәттереп, кайгыртып торганнар *(Шунда ук. 389 б.).*

Орыдагы таш мәчетне шушы авылның зур сәүдәгәре Нәзир бине Туктамыш бине Мөслим 1787 елда салдырган. Күрәсең, аны төзегәндә, таш бина кору кагыйдәләре төгәл сакланмаган. Гөмбәзе төшеп, мәчет урталай ярылгач, манарасы аву чигенә җиткәч, аны шушы авылдан чыккан сәүдәгәр Садыйк бине Гобәйдулла бине Ибраһим бине Давыд бине Бикмөхәммәд 1872 елда ныгытып, бөтенләй үзгәртеп кора *(Шунда ук. 389-340 б).*

Мәчкәрә авылының таш мәчетен Габдулла бай Үтәмешев 1791 елның азагына төзетеп бетергән, 1793 елда анда беренче намаз укылган. Мәрҗани, шулай ук, әлеге сәүдәгәрнең йөз иллеләп мәчет салдыруы турында халык арасында киң таралган сүзләрне дә китерә *(Шунда ук. 387 б.).*

Курсаның таш мәчетен Гобәйдулла бине Муса бине Исмәгыйль бине Апанай һәм аның бертуган энесе Габделкәрим төзетә. Габделкәрим 1863 елны бинаның алгы ягын өч тәрәзәгә арттырып ныгыта *(Шунда ук. 388 б.)*.

Ташкичүнең таш мәчетен 1817 елда Оры авылының мәшһүр сәүдәгәре Сөләйман Нәзиров бина итә *(Шунда ук. 382 б.)*.

Кысна (Хөснә) авылы мәчетен 1800 елда Нәзир бине Баязид бине Госман бине Габделкадыйр әд-Кышкарый төзетә. 1847 елны бинаны улы Муса бай төзекләндерә *(Шунда ук. 383 б.)*.

Мәрҗән авылындагы XVIII гасыр ахырында Ш.Мәрҗанинең шактый зур байлыкка ия булган бабасы Габделкәрим (1791 елда вафат булган) төзеткән мәчет җимерелүгә якынлашкач, гыйбадәтханәне чыгышы белән Ябынчы авылыннан булган танылган бай Габделкәрим бине Әбүбәкер бине Габдулла бине Хәбибулла бине Ишбай төзәттерә *(Шунда ук. 383 б.)*.

Өч мәчетле, бай һәм сәүдәгәр кешеләре күп булган Олы Мәңгәр авылының җәмигъ мәчетен 1794 елда Мөнасиб бине Мөслим бине Бутай (1837 елны вафат була) бина кыла. Югары мәхәлләнең бишвакыт намаз укый торган мәчете 1805 елда салына. Шушы елларда ук Түбән мәхәллә мәчетен Габделваһһаб бине Бәкер Иштәк эшләтә (ул Троицк шәһәрендә иске таш мәчетне дә төзетә) *(Шунда ук. 390-391 б.)*.

Байлар Сабасы авылындагы таш мәчет 1797 елны шушы авыл кешесе Мөнасиб бине Габделхаликъ бине Мөсалим бине Мәскәү бине Бимаҗ тарафыннан эшләнә. Янгыннан соң, 1841 елда Казан сәүдәгәре Габдеррәшид бине Габделкәрим бине Мөхәммәдрәхим авылда яңа таш мәчет төзетә *(Шунда ук. 391 б)*.

Мәрҗани Казан губернасы авылларындагы барлык таш мәчетләр тарихын язып чыккан дип әйтергә мөмкин. Ул заманда авылларда зур чыгымнарга барып, таш мәчетләр эшләтү гайре табигый, яңа күренеш булган. Аларның күпчелеге XVIII гасыр ахырында корылган булу игътибарны җәлеп итә. Автор, нигездә, өлкәннәрдән ишеткән мәгълүматны һәм үзе шаһит булган вакыйгаларны файдаланып бәян итә, ислам дине өчен малларын кызганмаган дин кардәшләрен мактый. Байларның, мәчетләр төзеп, Аллаһның ризалыгын алырга тырышулары авылларда ислам динен ныгытырга мөмкинлек биргән. Таштан салынган мәһабәт ислам йортлары авыл халкының горурлыгына әверелгән.


Шул рәвешле, мәчет төзү күпчелек очракта шәхси инициативага нигезләнгән булган. Һәр мәчет салдыручы үзенә ахирәттә Аллаһның ярлыкавын өмет иткән, бу тормышта авылдашлары, дин кардәшләре арасында олы абруй казанган. Бай сәүдәгәрләр, шулай ук, үзләренең васыятьнамәләрендә мәчетләр булдыру өчен акча бүлеп күрсәтергә гадәтләнгәннәр.

Бай кеше табылса, шактый зур чыгымнар сораган бу мәшәкать авыл җәмгыятенә кагылмаган дип әйтергә мөмкин. Иганәче булмаса, авыл имамы вәгазьләве нәтиҗәсендә игенчеләр җәмгыятенең урта хәлле вәкилләре берләшеп чыгымнарга барганнар, яки җәмгыять үзе мәчет төзүгә акча бүлеп биргән.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*

# ӘХСӘН ХАТЛАРЫНДА МОҢ ЯТА

Кулыма «Әхсән хатлары» дигән китап килеп керүгә, тукта әле, мин әйтәм, Әхсән нинди хатлар язды икән дип, укырга тотындым.




Әхсән белән мин «Бичура» спектаклендә таныштым. Ул спектакльне бик ошаткан булып чыкты. «Мин әле сиңа бу эшең өчен бер әйбер эшләячәкмен», – дигән иде. Бу минем рәсемемне эшләячәк икән дип, бик борчылып, уйланып йөрдем, ягъни ничек итеп эшләргә җыена икән? Бер вакытны аның Казанда күргәзмәсе булды, агачтан эшләнгән сыннарын күреп, аптырап калдым. Кара әле, мин әйтәм, агачтан да, тактадан да, бик тырышсаң, менә нинди әйберләр эшләп була икән, дип уйлаган идем. Мәскәүдә укыганда, Мексикадан рәссам Эрьзяның эшләрен алып кайтканнар иде. Ул безнең якташ – мукшы-удмурт рәссамы булып чыкты. Менә аның агачтан эшләгән эшләре күңелдә калган.

Инде хәзер күз алдына китерегез: минем мәрхүмә әни фотога төшмәде, җаным шунда калыр дип, Аллаһы Тәгаләдән курыкты. Кая инде ул гади татар кешесенә рәсем сәнгатен аңлау, безнең үз рәссамнарыбыз да бит 1930 елларда гына андый һөнәр белән шөгыльләнә башлаганнар. Кая инде ул агачтан яки тактадан эшләнгән тормышның бөек символларын күз алдына китерү, без әле аларны карарга әзер түгел идек дип уйлыйм. Гомумән, татарда кеше рәсемен ясау бик зур гөнаһ саналган. Мин үзем рәсем сәнгатен бик тирәнтен өйрәнгән кеше түгел, шулай булгач, ялгыш фикерләрем дә булырга мөмкин. Менә күңелемә Бакый ага Урманченың «Сагыш» сыны гомерлеккә кереп калды. Хәер, андый югарылыкта эшләнгән сәнгать әсәрен бик сирәк күрдем. Мин моны ни өчен язам соң, чөнки чын сәнгать остасы кул астында булган бөтен мөмкинлекләрдән: тимер, таш, агач, киндердән үзенең җаны теләгән чын сәнгать әсәре эшли ала. Дөньяда моның мисаллары бик күп.

Ә менә татарда бары тик агачтан гына шундый күп сәнгать әсәрләре тудыручы, ялгышмасам, рәссам Әхсән Фәтхетдин. Әле яңа гына киндергә төшерелгән рәсемнәрне карарга өйрәнеп килүче халыкка агачтан эшләнгән сәнгать әсәрендә катлаулы мәгънәне ачып бирү үзенә күрә бик четерекле, авыр хезмәт. Моның тирәнлеген аңлау, адәм баласының ниндидер бер әзерлеккә җитешкән булуын таләп итә.

Бер генә мисал: «Татар зираты». Менә шул эшнең мәгънәсен аңлату өчен Әхсән Фәтхетдин Равил Фәйзуллинның кыска шигырьләрен бик урынлы файдаланган. Сүз дә юк, тамашачы аларны болай да үзенчә кабул итәр иде, ләкин шигъри

юллар булмаса, нәрсәдер җитмәгән кебек тоела миңа. Әйткәнемчә, аларның мәгънәсен аңлау өчен әдәбиятны, татар дөньясын белергә кирәк, ә бу бераз гына булса да интеллект таләп итә.

Хатларны укый башлагач, нишләп Әхсән Фәтхетдин ничәмә-ничә еллар буе Равил Фәйзуллинга хатлар язып торган, болар бит үзе бер роман дип аптырадым? Ир кеше, гадәттә, хатлар язарга яратмый, язса да, сирәк кенә газиз әнкәсенә яки сөйгәненә яза. Ә монда язучысы кем диген – художник. Мин аларны хат яза торган кешеләр итеп күз алдыма китерә алмый идем. Әдәбиятта Һади Такташның «Киләчәккә хатлар», Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар», Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять», Мөдәррис Әгъләмовның «Тукайдан хатлар» кебек әсәрләре бар. Бу әсәрләр халыкка язучылар тарафыннан үзләренең нинди талантлы икәнлекләрен исбат итү өчен язылганнар. Әхсән үзенең хатларын халыкка түгел, бары тик Равил Фәйзуллин өчен генә яза һәм кулына тапшыра.

Мин үземчә шуны аңладым: Әхсән Фәтхетдин тормышында нindидер бер кискен адым ясый, ягъни рәсем сәнгатендә үз юлын табарга, талантлы рәссам икәнен исбатларга тели. Менә шул вакытта аның юлында Равил Фәйзуллин дигән шагыйрь очрый һәм ул аның күңелендә нindидер өмет нурлары уяткан, күрәсең. Беренчедән, Равил – талантлы шагыйрь, башкалардан аерылып тора. Шигъриятта яңа алым белән иҗат итүче – сүз кыска дүртьюллык шигырьләр турында бара. Икенчедән, Равил кеше буларак, шулхәтле киң күңелле, кешелекле, бигрәк тә талантлы кешене сиземләү аңа табигать тарафыннан бирелгән. Тагын бер үзенчәлеге: ул сине ничек бар шулай кабул итә, сине үзгәртергә тырышмый.

Инде хәзер Әхсәннең тормышын күз алдына китерик: җанын борчып торган уйларын, хыялларын ул кемгә сөйләсен? Хатыны рус, ул никадәр яхшы кеше булмасын, татар милләтенең киләчәге, аны нинди язмыш көткәнен, бигрәк тә Түбән Кама шәһәрендә татар халкының милләт буларак юкка чыгу алдында торганын аңа ничек аңлатасың? Мин инде татарның теле, моңы турында әйтеп тә тормыйм. Күңелеңә, җаныңа җыелып килгән газапларны кемгә сөйлисең? Ул вакытта бит әле аны чын талантлы рәссам итеп кабул итүче кешеләр бик сирәк була. Менә шул вакытта бәхетенә Равил Фәйзуллин дигән талантлы шагыйрь очраган, ул аны төннәр буе тыңлап утырырга риза була. Хәзер инде Әхсән сөйләп кенә, үз хәлен аңлатып бетерә алмам дип уйлаган, күрәсең. Бу хатлар аны эшләргә, ничек кенә булса да эшләргә дип рухландырып торганнар, күрәсең. Шулай инде, талантлы кеше түзә алмый бит ул. Хәзер инде ул Равилнең үзенә кайбер киңәшләрен бирә башлый, алай гына да түгел, хәтта шигырьләр язарга керешә. Ике талантлы кеше бергә туры килү – сирәк очрый торган бәхет.

Менә бит ул үзенә нинди сораулар бирә: «Иҗат кешесенә газапларны табигать нигә күбрәк биргән? Тормыш газабы нәрсә ул? Эшме, әллә җәзамы? Нигә кайчак күңел тилерә? Газаплану бәхетме? Нигә ат күзләренә бөтен дөнья сыя? Нигә кайчак кул бармый, күңел күтәрелми, бөтен нәрсә әзер булса да?» дип яза Әхсән Фәтхетдин.

Әле менә ни өчен Әхсәнгә Мансур Гыйләҗевнең «Бичура» әсәре бик нык тәэсир итте икән дип уйлап куйдым. Минемчә, темалары уртак. Татар халкының ничек юкка чыгуы аның өчен үзе бер фаҗигагә әйләнә. Татар авыллары бетсә, татар халкының киләчәге билгесез, дигән фикер аның җанына тигән. Әхсәннең этисе үлгәч, йортларын сүтеп, гомер иткән нигезләре юкка чыккач, бу вакыйганы ул бик авыр кичерә. «Бичура» спектакле шул турыда бара да инде. Минем үземә булган хөрмәтен, ул вакытта аңлап та бетермәдем. Менә хәзер миңа бүләк иткән искиткеч альбомын карап утырам, өч телдә язылган: рус, татар, инглиз телләрендә. Мин бит аңа рәхмәт әйтергә дә оныттым, ә бит ул минем кем, нинди артист икәнемне аңлатырга теләде. Инде хәзер артист буларак, шуны әйтәсем килә, сүз дә юк, кыяфәте рус художникларына бик нык охшаган иде. Әллә, мин әйтәм, хатыны марҗа булгач, аны шундый кы-

яфәттә күрергә теләде микән? Ул вакытта әле сакал-мыек, озын чәчләр үстереп йөрүче кешеләр бик сирәк иде. Булса шул артистлар, художниклар гына булгандыр.

Артистлык дигәннән, анда ул сәләт әллә каян сизелеп тора иде. Хатларын укыгач, бу ничек болай мәгънәле итеп язарга өйрәнде икән, дип уйладым. Әллә китапны чыгарганда, язуы өстендә бераз эшләделәр микән, чөнки өйдә татарча сөйләшмәгәч, урамда кешеләр белән гел русча аралашкач, мондый камиллеккә ирешү – үзе бер бәхет. Хатларын укыганда, тагын шуңа игътибар иттем: гаиләсе турында берни дә язмаган. Бәлки балалары булмаганга язып торасы килмәгәндер. Хәер, аның шәхси тормышын мин генә белми торганмындыр.

Аның хатларын укыганда, татар халкының әдәбиятын, тарихын белгәне күренеп тора. Ә инде халкыбызның эчке дөньясын, моңын шулкадәр күңеле белән тоя, Аллага шөкер, бездә дә андый кешеләр бар бит әле дип сөенеп куясың. Милләтеңнең фаҗигасен ачарга тырышкан рәссамга ул елларда бик авырга туры килгәндер. Ләкин татар халкы мәйданнарда: «Ирек!», «Азатлык!», «Безнең үз дәүләтебез булырга тиеш!» дип, меңләгән кешенең җан ачысы белән кычкыруы, Әхсәнне «Кычкыручы», «Кимсетелгәннәр», «Ачуланган» кебек эшләрне иҗат итәргә этәрмәде микән? Без бу эшләрдә канга сеңгән куркуны, гаделсезлектән кичергән җан газабын, болай яшәү мөмкин түгел дигән мәгънәне тоябыз, һәм ул аны рәссам буларак, безгә ачып бирергә тырыша. Ул бөек төзелешләрне, матур шәһәрләрне, бөек геройларның рәсемнәрен ясау урынына «Шүрәлеләр», «Ияләр», «Зират», тагын әллә нинди борынгыдан килгән гореф-гадәтләрне, йолаларны, чишмәләрне, урманнарны, болыннарны, туган җиребезне сурәтләп, әгәр алар үзебезнеке булмаса, безнең киләчәгебез юк дигән фикерне әйтергә теләде микән?

Хәзер аңлаган кешегә аңларлык, дөньяда һәр әйбернең иясе бар, бу җир-суларның иясе – без, татарлар, дип әйткәне әллә каян күренеп тора. Шуңа күрә күңелдә нindидер бер өмет тә уянган төсле, шулай да үз йөзен югалткан кешеләр, без үзебез түгелме соң, дип уйлап куясың. Хатларында ул менә шушы сорауларга җавап эзли. Аның һәр нәрсәгә үз фикере бар: җәмгыятькә, табигатькә, аерым шәхесләргә. Чөнки ул – рәссам, башкалардан ул шуның белән аерылып тора. Сүз дә юк, язучыларның, рәссамнарның талантын вакыт кына билгели, кайбер рәссамнарның эшләрен замандашлары кабул итеп бетермәскә дә мөмкин, ләкин вакытлар үтү белән чын талантлы рәссам булса, аңа игътибар артканнан-арта гына бара. Кара акылым белән шуны әйтәсем килә, киләчәктә дә Әхсән Фәтхетдиннең эшләрен халык караячак, чөнки татарда аңа охшаган башка рәссам юк. Равил Фәйзуллин кеше буларак, аның хатларын китап итеп чыгарып, өстеннән бик зур йөк төшергән, моның өчен аңа ничек инде рәхмәт әйтмисең?! Мин әйтмим, бу хатларны бөтен кеше дә укыр дип, шулай да әдәбиятны, сәнгатьне яраткан кешеләр, бу хатларга игътибар итмичә калмас.

**Әзһәр ШАКИРОВ,**
*Россиянең һәм Татарстанның*
*халык артисты,*
*Татарстанның Г.Тукай исемендәге*
*Дәүләт премиясе лауреаты*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### УТЫРЫШ

«Казан Экспо» халыкара күргәзмәләр үзәгендә Татарстан Мәдәният министрлыгының коллегия утырышы булды. Анда Россия Федерациясе Дәүләт Думасының Мәдәният комитеты рәисе Елена Ямпольская, РФ мәдәният министры урынбасары Владимир Осинцев, «Роскультцентр» директоры Марина Абрамова, Мәскәү мәдәният департаменты җитәкчесе Александр Кибовский, РФ Дәүләт Думасы, ТР Дәүләт Советы депутатлары, ТР министрлыклар, ведомстволар, мәдәният учреждениеләре җитәкчеләре, әдәбият-сәнгать әһелләре катнашты. Узган елгы эшкә хисап белән ТР мәдәният министры Ирада Әюпова чыкты. Утырышта Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясады. Ул моңарчы күрелмәгән ярдәм өчен федераль министрлыкларга, депутатларга рәхмәт әйтте. Ул рәхмәт сүзләрен «Пушкин картасы» кебек әһәмиятле проект өчен дә ирештерде. Киңәйтелгән утырыш бер төркем әдәбият-сәнгать әһелләренә, мәдәният хезмәткәрләренә дәүләт бүләкләрен тапшыру белән тәмамланды. Бүләкләнүчеләр арасында шагыйрь Ләис Зөлкарнәй дә бар. Аңа «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеме бирелде. Котлыйбыз!

### КОТЛАУЛАР

Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов татарстанлыларны 21 февраль – Халыкара туган тел көне белән тәбрик итте. Бу уңайдан ТР Дәүләт Советы Рәисе, Татарстан халыклары ассамблеясе рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да котлавын ирештерде. Халыкара туган тел көнендә Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында, Милли музейда, мәдәният учреждениеләрендә, уку йортларында, мәктәпләрдә төрле чаралар үткәрелде.

### ҖӘЛИЛНЕ ИСКӘ АЛДЫЛАР

15 февраль – Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең туган көнендә татар зыялылары, җәмәгатьчелек вәкилләре, язучылар, сәнгать вәкилләре каһарман-шагыйрьнең Казандагы 1 Май мәйданындагы һәйкәленә чәчәкләр салды. Аннары Җәлилне искә алу тантанасы ТР Милли музеенда дәвам итте. Монда Моабит дәфтәрләренең төп нөсхәсе күрсәтелде. Быел аны алып чыгу хокукы музейның элекке директоры Люция Вәлиевага бирелде. Чарада ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Юлия Әдһәмова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, ТР Милли музее генераль директоры Алисә Вяткина, композитор Эльмир Низамов, «Җәлил укулары» халыкара шигырь укучылар бәйгесе җиңүчесе Газиз Хөҗҗәтов, җырчы Илгиз Мөхетдинов, Г.Кариев театры артистлары, Казан театр училищесы студентлары һ.б. чыгыш ясады. Чараны Айдар Шәйхин белән Зәринә Сафина алып барды.

* * *

М.Җәлилнең туган көнендә аның исемендәге премиянең быелгы лауреатларын игълан иттеләр. Менә алар – «Шаян ТВ» телеканалы, шагыйрь Рифат Сәлах, җырчы Илүсә Хуҗина, Г.Камал театры артистлары Фәннүр Мөхәммәтҗанов, Ләйсән Гатауллина.

### МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ КҮРГӘЗМӘСЕ

«ТАТМЕДИА» бинасының беренче катында Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев төшергән фоторәсемнәрдән торган «Алтай сулышы» күргәзмәсе ачылды. Анда авторның Алтай табигатен чагылдырган 30лап эше куелган. Күргәзмәне ачу тантанасында «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла, Татарстанның халык шагыйрьләре Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин, Татарстанның халык артисты Гөлзадә Сафиуллина, язучы-тәрҗемәче Гәүһәрия Мәһдиева, әдәбият галиме Миләүшә Хәбетдинова, Татарстан фоторәссамнар берлеге рәисе Рамил Галиев һ.б. чыгыш ясады.

### ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасарлары Илсөяр Иксанова, Факил Сафин (Чаллы), берлекнең Әлмәт бүлеге җитәкчесе Рәфкать Шаһиев узган утырыштан соң башкарылган эшләргә хисап тоттылар. Аннары ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт, М.Горький исемендәге әдәби премияләргә кандидатлар тәкъдим ителде. Идарә Тукай бүләгенә «Вөҗдан үре – йөрәк түре» һәм «Яну

дәверләрендә» китаплары өчен иң күп тавыш җыйган шагыйрә Флёра Гыйззәтуллинаны тәкъдим итте. Яшерен тавыш бирү исемлегенә тагын язучылар Марат Әмирханов, Айдар Хәлим, Рәфкать Кәрами кертелгән иде. М.Горький исемендәге әдәби премиягә Әлфия Галимуллина («Вселенная Равиля Бухараева» китабы өчен), Александр Аввакумов («Бог примет всех») тәкъдим ителде. Утырышны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды.

### ЮБИЛЕЙ

Түбән Кама шәһәренең Г.Тукай исемендәге Үзәк китапханәсендә язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданы, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты Фәтхулла Абдуллинны 85 яшьлек юбилее белән котладылар. Тәбрикләү сүзләрен Түбән Кама шәһәре мэры Рамил Муллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла (ул юбилярга ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның Рәхмәт хатын тапшырды), берлекнең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, Казаннан кайткан язучылар Хәбир Ибраһим, Илзирә Вәлиуллина, Мөслимнән якташлары – Халыклар дуслыгы йорты директоры Рушад Солтанов, шагыйрә Лилия Садриева, яшь прозаик Йолдыз Зәкиева, җирле каләмдәшләре һ.б. ирештерде.

### СӘФӘРЛӘР

«Мәдәни җомга» газетасы, «Казан утлары» һәм «Безнең мирас» журналларының баш мөхәррирләре Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин, «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең PR-директоры Ләйсән Сафина, «Миллиард.татар» сайтының баш мөхәррире Арслан Минвәлиев, хәбәрчеләр Регина Яфарова, Гөлүзә Ибраһимова Свердловск һәм Чиләбе өлкәләрендә булып кайтты. Сәфәр барышында алар Татарстанның Свердловск өлкәсендәге даими вәкиле Хәйдәр Гыйльфанов, Чиләбе өлкәсенең татар конгрессы рәисе Лена Колесникова белән очрашты, Свердловск, Чиләбе өлкәләре һәм Екатеринбург, Чиләбе, Магнитогорск шәһәрләренең татар җәмәгатьчелеге белән түгәрәк өстәлләр уздырды, Чиләбе өлкә фәнни китапханәсендә «Чиләбе өлкәсенең татар поэзиясе антологиясе» китабын тәкъдим итүдә катнашты, Екатеринбургның татар җәмәгатьчелеге белән берлектә Муса Җәлил һәйкәленә, Чиләбе татар җәмәгатьчелеге белән берлектә Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Исхак Әхмәров һәйкәленә чәчәкләр салды, Чиләбе өлкәсенең Кунашак районындагы Караболак, Мөслим, Төбәк, Бәгәрәтамак кебек татар авылларында мәктәп укучылары, авыл халкы белән очрашты.

* * *

Удмуртиянең Ижау каласындагы М.Җәлил исемендәге китапханә «Вконтакте» социаль челтәрендә Муса Җәлил һәм Рафис Корбан шигырьләрен сәнгатьле уку онлайн конкурсы игълан иткән иде. Конкурста Удмуртиянең Ижау, Сарапул, Можга, Воткинск шәһәрләреннән, Татарстанның Әгерҗе районыннан 90лап кеше катнашты. Ижауның Халыклар дуслыгы йортында конкурска йомгак ясау тантанасы булды. Анда җиңүчеләргә дипломнар тапшырылды. Чарада «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррирләре Рафис Корбан, Фәнил Гыйләҗев чыгыш ясадылар. Җиңүчеләргә «Казан утлары»ның яңа саннарын, бу басманың 100 еллык юбилее уңаеннан чыгарылган фотоальбом, үзләренең китапларын бүләк иттеләр.

### «МӘЙДАН – БАТЫРЛАР ӨЧЕН!» КОНКУРСЫНДА ҖИҢҮЧЕЛӘР

**Повесть**

I урын. **Айгөл Әхмәтгалиева**. «Без барабыз, ул килмәс»; II урын. **Лилия Гыйбадуллина**. «Кара батыр»; III урын. **Нәбирә Гыйматдинова**. «Остаз». Кызыксындыру премияләре: **Рифә Рахман** (Батыр асты»), **Нурания Гыйльметдинова** («Исемең өстә булсын»), **Фәтхулла Абдуллин** («Сәет батыр токымнары»)

**Хикәя**

I урын. **Зәбир Гыймаев.** «Керәшче»; II урын. **Ландыш Әбүдәрова.** «Кара каплан»; III урын. **Хисаметдин Исмәгыйлев.** «Беренче Сабантуй». Кызыксындыру премияләре: **Рафис Корбан.** («Соңгы Сабантуй»), **Галимҗан Гыйльманов** («Батыр асты»), **Рашат Низамиев** («Келәмдә очрашу»)

**Шигърият**

***(Балалар арасында җиңүчеләр)***

I урын. **Илсаф Рамазанов** (Ульяновск өлкәсе, Иске Кулаткы районы, Урта Терешка мәктәбе); II урын. **Нияз Кәбиров** (Яшел Үзән районы, Мулла Иле мәктәбе); III урын. **Тимерхан Вәлиәхмәтов.** (Казан, Кадет-интернат мәктәбе). Кызыксындыру премияләре: **Анжела Захарова** (Биектау, 5 нче мәктәп), **Әдилә Кәбирова** (Арча районы Яңа Кырлай мәктәбе), **Әминә Ялалтдинова** (Олы Әтнә мәктәбе).

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстанның халык шагыйре **Разил Вәлиевкә** Мәҗит Гафури медален тапшырдылар. Ул моңа үзе җитәкчелек иткән «Җыен» фондының Мәҗит Гафури турында чыгарган китабы өчен лаек булды.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман Ф.ГИМАЛТДИНОВА «Хан Орды Узбек», рассказы Р.БАТУЛЛЫ, Р.МУХАМАДИЕВА; стихи Г.БАТТАЛ, Э.САФИНОЙ, Р.САЛЯХИЕВА.*
*«Свет далёких огней»: стихи М.ЧАХОРОВСКОГО в переводе Л.ШАЕХА.*
*«Литературный конкурс «Учитель – прекрасный человек на земле!»: рассказ Р.ЗАЙДУЛЛЫ.*
*Журнал «Агыйдел» в гостях у «Казан утлары»: статья М.КУНАФИНА к 100-летию журнала «Агыйдел», стихи Х.НАЗАРА, Г.СИТДИКОВОЙ, К.АРАЛБАЯ, Г.ЮНУСОВОЙ, А.УТЯБАЯ, Г.ЯКУПОВОЙ, С.АБУЗЯРА, Й.ИЛЬЯСОВОЙ, Т.КАРАМЫШЕВОЙ, Л.САКМАР, Х.ЮЛДАШЕВА, Т.ИСКАНДАРИИ, А.ГАРИФУЛЛИНОЙ, З.ХАННАНОВОЙ, Г.КАЛИМУЛЛИНОЙ, Г.КУТУЕВОЙ, Л.АБДУЛЛИНОЙ; рассказ Р.СУЛТАНГАРАЕВА «Татарин и башкир».*
*«2023 год – год дастанов»: статья Л.МУХАМЕТЗЯНОВОЙ.*
*«Наука»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Обзор книги»: статья А.ШАКИРОВА.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: озеро Средний Кабан;*
*кандидат филологических наук, поэтесса Эльвира САФИНА.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and Poetry»: novel by F.GIMALTDINOVA «Khan Uzbek of the Horde», stories by R.BATULLA, R.MUKHAMADIEV; poems by G.BATTAL, E.SAFINA, R.SALYAKHIEV.*
*«The Light of distant fires»: poems by M.CHAKHOROVSKY translated by L.SHAEKH.*
*«Literary contest «Teacher is a wonderful person on earth!»: story by R.ZAYDULLA.*
*Magazine «Agyidel» visiting «Kazan Utlary»: article by M.KUNAFIN on the 100th anniversary of «Agyidel» magazine, poems by H.NAZAR, G.SITDIKOVA, K.ARALBAY, G.YUNUSOVA, A.UTYABAY, G.YAKUPOVA, S.ABUZYAR, Y.ILYASOVA, T.KARAMYSHEVA, L.SAKMAR, H.YULDASHEVA, T.ISKANDARIA, A.GARIFULLINA, Z.HANNANOVA, G.KALIMULLINA, G.KUTUEVA, L.ABDULLINA; story by R.SULTANGARAEV «Tatar and Bashkir».*
*«2023 is the year of the Dastans»: article by L.MUKHAMETZYANOVA.*
*«Science»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«1100 years since the adoption of Islam in the Volga region»: article by I.ZAGIDULLIN.*
*«Book review»: article by A.SHAKIROV.*
*From the photo archive of the magazine.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Lake Sredny Kaban;*
*Candidate of Philological Sciences, poetess Elvira SAFINA.*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Урта Кабан.
*И.Абрамова фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* галимә, шагыйрә Эльвира Сафина.